КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ
ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН
БАШЛАП ЧЫГА

# Бу санда

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Луиза ЯНСУАР. Мин сүзләрне җылы сөткә манам... *Шигырьләр.* ....3

Рәдиф СӘГЪДИ. Әлмирәнең хәтере ачыла. *Роман.* ....8

Лилия ГЫЙБАДУЛЛИНА. Гали Рәхим. *Поэма (Гали Рәхимнең тууына – 130 ел).* ....57

Марат КӘБИРОВ. Тик син генә. *Повесть.* ....67

Рәшит БӘШӘР. Учларымда гөлләр үстердем мин... *Шигырьләр.* ....114

«МӘЙДАН – БАТЫРЛАР ӨЧЕН!» ӘДӘБИ КОНКУРСЫ

Амур ХАН. Потап. *Хикәя.* ....118

ЯҢА ИСЕМНӘР

Оксана ИЛЬЮП. Ялган кояш күзне чагылдыра... *Шигырьләр.* ....134

КАРДӘШ ХАЛЫКЛАР ӘДӘБИЯТЫ

Мила КУРУДИМОВА. Алда ни көтәсен кем белгән... *Шигырьләр.*
*(Гагауз теленнән Фәнил Гыйләҗев тәрҗемәләре).* ....137

СӘНГАТЬ

Гали АРСЛАНОВ: «Кулыңнан килсә, кешегә ярдәм ит!»
*(Әңгәмәдәш – Алинә ХӘБИБУЛЛИНА).* ....141

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Газинур МОРАТ. «Шөгарә» сүрәсе өмет уята. ....145

Тәлгат ГАЛИУЛЛИН. Хисчән фикерле шагыйрь. *(Рәшит Әхмәтҗанов иҗаты турында уйланулар).* ....149

Ландыш ӘБҮДӘРОВА. Донкихотлар ничек үлә? *(Равил Сабырның «Фәхрине үтереп ташладылар» романына бәяләмә).* ....156

ТАРИХ

Лирон ХӘМИДУЛЛИН. Сөембикә шәҗәрәсенә өстәмәләр. ....159

*Фотоархив:* Лирон Хәмидуллинга – 90 яшь. ....164

ЯКУТЛАР ТАБЫЛАДЫР ВАКЫТ БЕЛӘН

Гали РӘХИМ. Шәрык шагыйрьләре. *(Дания Заһидуллинаның кереш сүзе белән).* ....166

ИДЕЛ БУЕ БОЛГАР ДӘҮЛӘТЕНДӘ ИСЛАМ ДИНЕН КАБУЛ ИТҮНЕҢ 1100 ЕЛЛЫГЫ

Илдус ЗАҺИДУЛЛИН. Мәхкәмәи шәргыя оешу. ....177

*Газиз тавышлар:* Җырчыларның моң әнкәсе. *(Зөләйха Хисмәтуллинаның тууына – 100 ел).* ... 188

Юксындырып искә төшәң... *(Хәйдәр Гайнетдиновның тууына – 70 ел).* ....189

*Сәхифәне Нәсим АКМАЛ алып бара.* ....186

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....190

казан
утлары
№ 11 (1201) 2022

*БАШ МӨХӘРРИР –*
**Рөстәм Госман улы**
**ГАЛИУЛЛИН**

*ИДАРӘ:*
**Ирада Әюпова**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Искәндәр Гыйләҗев**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Ркаил Зәйдулла**
**Илгиз Зәйниев**
**Илфак Ибраһимов**
**Зиннур Мансуров**
**Ким Миңнуллин**
**Газинур Морат**
**Рүзәл Мөхәммәтшин**
**Айдар Сәлимгәрәев**
**Равил Фәйзуллин**
**Илсур Һадиуллин**
**Данис Шакиров**
**Ленар Шәех**

*Баш мөхәррир урынбасары:* **Вакыйф Нуриев.**
*Җаваплы сәркатип:* **Ландыш Әбүдәрова.**
*Бүлек мөхәррирләре:* **Фәнил Гыйләҗев, Рафис Корбан.**
*Мөхәррирләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Гөлия Сәлахова.**
*Сайт мөхәррире:* **Ләйсән Зарипова.** *SMM-белгеч:* **Алинә Хәбибуллина.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Камалова** (өлкән бухгалтер)**.**
*Машина йөртүче:* **Наил Кадыйров.**

✉✉: Редакция адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Кабул итү бүлмәсе – 222-09-83 (өст.1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Җаваплы сәркатип – 222-05-50 (өст. 1617).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1267), касса – 222-09-84 (өст.1874).*
Сайт: kazanutlary.ru; электрон почта: kazanutlari@yandex.ru

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмахананең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Гамәлгә куючы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче адресы: 420097, Казан, Академия урамы, 2.
Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 27.10.2022, график буенча 27.10.2022, басылып чыгу вакыты 01.11.2022
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 $^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ О-3207. Тираж 7524.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2020 елның 13 ноябрендә теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-79467.
Индекслар: ПО277 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен),
П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), П2368 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
12+

© «Казан утлары», 2022 ел



Луиза
Янсуар

# МИН СҮЗЛӘРНЕ ҖЫЛЫ СӨТКӘ МАНАМ...

## Бөреләр

*– Ә сез кая барасыз?*
*– Тал песиләренең хәлен белергә.*
*– Өзеп алып кайтасызмы?*
*– Өзмибез! Сыйпап, хәлләрен генә беләбез дә кайтабыз.*

Биш һәм утыз биш яшьлек
икәүнең сөйләшүеннән.

Ә сүзләр... Ә сүзләр кирәкми.
Илемә. Бөтенләй. Эндәшмим.
Бик тиздән җуярмын шикелле
Борынгы бабамнар сөйләшен.

Бик тиздән уярмын шикелле
Ташларга кыйгачлап тамгалар.
Һәм безнең бүгенге язуыкны
Иртәгә оныклар камларлар.

Ә йөзләр... Ә йөзләр кирәкми.
Илемә. Каплыймын. Йөземне.
Һәм көлеп туарам җилләргә
Тамчылап-тамчылап үземне.

Бик тиздән тоярмын шикелле
Кан тәмен... Ирендә – тоз гына...
Һәм сәлам бирерләр чордашлар,
Танымый, һәр читкә, узгынга.

---

Луиза ЯНСУАР (1981) – *шагыйрә; Россия-Италиянең Халыкара «Белла» һәм Республиканың М.Җәлил исемендәге, язучыларның С.Сөләйманова исемендәге әдәби премияләр лауреаты. «Мин күкләргә кайтам», «Болан кызы», «Без җан өргән учак» исемле китаплар авторы. Казанда яши.*

Ә таныш берәүне күрмичә,
Узарлар оялып... хыялын
Хәтергә төшермәс өченгә...
Беткән ул корымга буялып.

...Учымда – йоп-йомшак учлары.
Талларда – йоп-йомшак бөреләр.
Талларда – йоп-йомшак бөреләр.

Тереләр!

## Яшәүнең икенче ягында

Һәм беләм җавапның юклыгын.
Мин беләм юклыгын җавапның.
Тик ничек яшәргә... белмимен...
Дәшәргә: «Мин сине... яраттым...»

Күзләре кан тулы шәфәкънең
Күземә тутырып каравын
Тоям да йөрәгем суына...
Һәм төкерек йоталмый тамагым.

Мин сине шулкадәр сагынам.
Син – аргы ягында дөньяның.
Син – аргы ягында чынлыкның.
Уйласам, башымны җуямын –

Бу кадәр булалмас хәлләрдән...
(«Догаңнан калдырма – шул гына...»)
Мин тоям: көннән-көн, төннән-төн
Котылу өмете суына.

Без Җирдә югалткан җәннәткә
Мин белмим нинди хак түләсе...
Кабердән кубарып, хаклыкны
Тапканмы кайчандыр бирәрсе?!

Мин сине шулкадәр сагынам.
(«Догаңнан... догаңнан калдырма...»)
Ышансам, акылны җуярмын –
Яшәүнең икенче ягында.

## Вакытлы

Син кайтыр диңгезләр илендә
Мин йөрим онытып сагышны.
Җир тулы – кешеләр тавышы.
Җир тулы – кешеләр каргышы.

Бу кадәр нәфрәтне күтәргән
Токымнар барын мин хәтерлим.
Һәм җанны... икенче тормышка...
Икенче язмышка әзерлим.

Син минем – иң татлы әрнүем.
Син минем – иң авыр бәхетем.
Белми дә калырсың шикелле...
Белми дә – никадәр кадерең.

Мин кайтыр диңгезләр илендә
Син оныт мәңгегә каргышны!
Һәм ишет: сабыйлар көлешә...
Сабыйлар – белмәгән сагышны.

...Бу Җирнең – вакытлы ялгышы...

## Үбәр идем...

**1**

Шундый газап бар дисәләр җирдә –
Дәшми яшәү. Көләр идем, юләр!
Беркемнән дә сорый алмам бүтән:
«Ни хакына алар, – дип, – үлделәр?!»
Шундый газап бар дисәләр җирдә –
Карый алмау кеше күзләренә.
Таный алмау. Һәм аклый да алмау –
Үзгәрелә, диеп, үзгәрелә.
Шундый газап бар дисәләр җирдә –
Яратам дип әйтә алмау бүтән –
Бу кояшны. Төсе зәңгәр Күкне.
Ваз кичәргә каламы ул Күктән?!
Шундый газап бар дисәләр җирдә –
Аңлый алмау нәрсә чын, ни ялган.
Ә саргайган сурәтләрдә кемнәр?! –
Синең бабаң белән минем бабам.
Шундый газап бар дисәләр җирдә –

Үлем белән аклау... яшәү хакын...
Һәм улавы шашкан аналарның:
«Бу баламны мин нәрсәгә таптым?!..»
Юк, ышанмас идем... Юк, ышанмас...
«Әнә, Иблис! Без – аңарга каршы!!!»
Көзгеләргә кара! Бер очрашсын –
Үз карашың белән үз карашың.
Бары үзең белән! Көчең җыеп,
Үчең җуеп җитә бер каравың...
Аңлар өчен: мең гасырлар буе
Без чәрдәге – Олы! Бер! Яраның!
Ул күзләргә әнкәсе дә баккан.
Әнкәсе бар җирдә һәр баланың!!!

**2**

Мин... башыңны тезләремә куеп...
Маңгаеңнан канлы эзне юып...
Тыңлар идем җилләр пышылдавын.

Тыңлар идем җилләр пышылдавын.
Һәм мәкләрнең талгын кыштырдавын.

«Котылу юк бүтән, улым...» – диеп
Үбәр идем сине, юләремне.

Кеше күтәрә алмас газап барын
Беләм хәзер – Синең белгәнеңне.

## Һомай*

*И заключил Владимир мир с болгарами, и*
*клятву дали друг другу, и сказали болгары:*
*«Тогда не будет между нами мира, когда*
*камень станет плавать, а хмель – тонуть».*
*И вернулся Владимир в Киев.*
«Повесть временных лет»

Баш очымда Күк бар. Табанымда – туфрак.
Мәңге шулай иде. Һәм бүген дә шулай.
Җилкәмдәге толым. Җилендәге кулым.
Карындагы улым. Ирек кошы Һомай.

Күмерләнгән дала. Илгә төшкән яла.
Даудан купкан афәт. Яудан откан гадәт.
Күкрәктәге сөтем. Учактагы төтен.
Туфрак упкан каһәр. Җилләр йоткан нәләт.

Тамырларым белән тән береккән җирем.
Мәңге шулай иде. Һәм бүген дә шулай.
Кулымдагы кылыч. Җанымдагы корыч.
Бишектәге кызым. Бәхет кошы Һомай.

Һавадагы бөркет. Үз-үзеннән өркеп,
Күзләренме чукый? Чукый йөрәгенме?
Беркемгә дә сөйли, сөйли алмам инде
Ватанымда (газиз!) ниләр күргәнемне.

Ишеткәнне ниләр. Йомылмас бу җөйләр.
Чәчемдәге чулпы. Җәйләүдәге елкы.
Хөрлек бәрабәре гомерләрен биргән
Бабамнарның коты. Бабамнарның холкы.

Була алмам бүтән. Ахыргача көтәм.
Күләгәң бер төшәр, төшәр ләса, Һомай?!
Өскә калка ташлар. Өскә калка башлар.
Төпкә бата колмак... Колмак кына бугай.

* Һомай – күләгәсе кемгә йә кайда төшсә, бәхет китерә торган мифик кош.

## Ирек

*Ирек – күпмәгънәле сүз.*
Сүзлектән

Яратырга өйрәттеләр безне.
Туган илне. Туган телне. Сүзне.
Ал әләмнәр белән алтын көзне.
Һәйкәлләрне. Һәм югалган эзне.

Киләчәкне – кемдер бүләк иткән.
Игеннәрне – тир тамызып иккән.
Кулъяулыклар чит-читенә чиккән
Вәгъдәләрне. Угланнарны – киткән.

Тәрәз төбендәге яраннарны.
Аналарны. Сабый балаларны.
Күкрәктәге данлы тамгаларны.
Исәннәрне. Ятып калганнарны.

Хакыйкатьне. Ул бер һәм бердәнбер.
(Аны, белмим, җирдә кем күргәндер).
Яратырга өйрәттеләр. Барыбер.
Сәгать теле кебек безнең хәтер.

Саный, саный, саный мизгелләрне.
Алышына иман, изгеләре
Ватанының. Күптән өзделәрме
Кендек җебен артык сизгерләре?

Яратырга өйрәттеләр безне
«Тынычлык» һәм «ирек» дигән сүзне.
Кара ипи белән ап-ак бүзне.
Каберләрне. Һәм күмелгән эзне.

...Мин сүзләрне җылы сөткә манам
Туфрагымда – кендек каным тамган.
(Яшәргәме, үләргәме калам?)
Ул әремдәй ачы. Татлы һаман.

Һәм бу ирек – нәкъ үзенә таман...

## Бар иде шәһәрләр...

*и я уже боюсь писать –*
*так много спетого сбылось.*
*и я теперь учусь молчать...*
Диана Арбенина

**1**

Мин бүтән сүзләргә ышанмыйм.
Хакыйкать җан биргән дөньяда
Бер генә мизгелгә тын алып,
Сөенәм зәп-зәңгәр Күк барга.
Тереләр, үлеләр... Ни хакы?
Күтәрә алмас, юк, бизмәннәр.
Күзләрем яшерәм... Җир тулы
Кемнәр ул?! – Тәүбәдән бизгәннәр...
Кемнәр ул? Йөрәгең аркылы
Узалар типкәләп, теткәләп...
...һәм карый, карый яз күземә,
Кичерү көткәндәй, үпкәләп...

**2**

Бар иде шәһәрләр... Исемдә!
Без анда яраттык тилереп.
Һәм үптек Күкнең күз яшьләрен,
Бәхеттән, хәсрәттән илереп.
Мин бүтән ышанмыйм сүзләргә.
(...бер Күккә, Кояшка ышанам...)
Күзләрем күтәреп карыйм да:

«Исәнме?..» – дип сорыйм кошлардан.
Исәнме? Зәп-зәңгәр күзләре
Карыймы һаман да дөньяга?!
Йөрәгем тибәлми торганда,
Пышылдыйм: «Зинһар, – дип, – Ул барга...»
Йөрәге тибәлми торганда,
Исенә төшерсен... Ялварам!
Без анда яраттык тилереп...
Без әле... яшәрбез яңадан!
...терелеп төзәлмәс ярадан...

## Кыл

*Ике яктан кычкыралар миңа.*
Зөлфәт Хәким

Ике яктан – йөрәк авазлары.
Ике яктан – утлар... утлар... утлар...
Битлек артындагы дөреслекләр.
Исемнәре барлар... йөзе юклар.

Ике яктан – язмыш илерүе.
Әләмнәре... әрәмнәре – илнең.
Кояш йөзендәге күләгәләр.
Юкка чыккан яме, тәме телнең.

Ике яктан – гүргә иңгән яшәү.
Ике яктан – җанын биргән үлем.
...Учларымда – сызым-сызым юллар...
Чәчләремә коям нигез көлен.

Учларыма кысам Ватанымның
Кантар-кантар өметләрен... кысам...
Йөрәгемдә ничә ызан барын
Белми идем... атламый да узам...

Кыл уртасы гүя Мәңгелекнең.
Ул Мәңгелек шундый сусыл... татлы...
...Мин Күгемә карыйм, көн дә торып,
Һәм яшерәм карашымны: якты!!!

Күпме ара – бездән безгә чаклы?

## Күгелҗем

Ул белми – кем кемгә дус хәзер.
Ул белми – кем кемнең дошманы.
Кем кемне элмәктән коткарып,
Кем кемне чалырга кушканны.

Күзләрен яшерер урын юк.
Сүзләрен яшерер юк урын.
Акшарлы диварлар... Учына
Нигәдер сөртелә тик корым.

Яшәүдән ваз кичкән иленә
Ул күрә инану иңгәнен –
Бары бер, бердәнбер чынлыкка.
Җаннарның тәненнән киткәнен.

Ул белми – кем белән серләшеп,
Кем белән илереп еласын.
Һәм килгәч зарыккан «тынычлык»,
Кем тезгә кизәнеп сугасын.

Йөрәген яшерер урын юк.
Урын юк яшерер йөрәген.
...Урманнар утыра күгелҗем,
Белми дә куркырга кирәген...



Рәдиф
Сәгъди

# ӘЛМИРӘНЕҢ ХӘТЕРЕ АЧЫЛА

РОМАН*

Әлмирә утырган поезд теркелдәп куйды да, ниһаять, тартылып кузгалып китте. Күз яшьләрен сөрткәләгән әнисе, төрле киңәшләрен бирергә ашыккан Әхмәт абыйсы перронда кул болгап калдылар. Аерылышу сагышыннан кызның үзенең дә күңеле тулды, шулай да күз яшьләрен якыннарына күрсәтәсе килмәде, карашын яшерде. Инде менә хәзер, купеда үзе генә калгач, җебеп алса да була. Проводникның әйтүенә караганда, Яшел Алан станциясендә тагын ике кеше утырачак икән. Шундый озын юлда гәпләшеп барырга иптәшләр булыр ичмасам, дип уйлап куйды кыз. Поезд ул арада, даңгыр-доңгыр килеп, Киров дамбасын да узып китте. Рельслар тимер тәгәрмәчләр бәрелүдән үзенә бер төрле көй чыгаралар иде. Тыкы-тыкы-тыкы-тек, тыкы-тык-тык! Әлмирә сагышлы хисләрен онытып торыр өчен тәрәзәдән карап бара башлады. Әнә Аракчиноның дача бакчалары. Бер апай түтәлләр арасында чүп утап маташа. Арырак абзый кеше утын яра, мунча ягарга җыена, күрәсең. Бигрәк тә матур инде безнең Идел буйлары, дип уйлап куйды табигать белән хозурланып баручы кыз. Шушы Ослан тавын, Алла бирсә, бер тукымага төшерәм әле, укып бетереп, исән-сау әйләнеп кайтырга гына язсын! Абыйсы Әхмәт тә аңа: «Барыр җирләрең бик матур, читләрнең алдаучан һавасыннан башың әйләнмәсен, барыбер үзебезнең Татарстаныбызга, Казаныбызга җитми ул, – дип киңәш-нәсыйхәтен бирде. – Дөньяның иң гүзәл шәһәрләренең берсенә барасың, вакытыңны әрәм үткәрмә, андагы архитектураны, затлы биналарны кара. Болгар-Казан төзелешләреннән алынган бик күп нәрсәләрне шәйләрсең. Мөмкинлегең булса, Анна Ахматованың улы – бөек тарихчы, искиткеч шәхес Гумилёв дәресләренә йөргәлә. Татарларны чын күңелдән яраткан, ихтирам иткән рус кешесе, безнең тарихны дөресләп язган, шуның аркасында бик күп явызлыклар күргән галим», – диде. Әнисе дә: «Күзеңне-башыңны акайтып

* Журнал варианты

Рәдиф СӘГЪДИ (1957) – *драматург, прозаик, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Гаяз Исхакый, Фатих Хөсни, Туфан Миңнуллин, Шәйхи Маннур, Дамир Сираҗи исемендәге әдәби премияләр иясе. Күпсанлы пьесалар, китаплар авторы. Казанда яши.*

йөрмә! Итәкләреңне җыеп йөр», – дип, күз яшьләрен сөртә-сөртә озатып калды.

Әлмирә кечкенәдән сурәтләр ясарга яратты. Әнисенең туган ягы Әтнәгә кайткач та, төрле болын чәчәкләренә сокланып, иптәш кызларына күрсәтергә дип, төсле карандашлар белән дәфтәренә рәсемнәр төшерә иде. Күршедә яшәгән Исрафил абыйсы ул кайтканны күрсә, таза беләкләрен, киң күкрәкләрен күрсәтергә теләп, ишегалдындагы краннан салкын су белән коена торган булды. Имеш, кара, ничек таза, көчле ул! Болдырга чыккан Әлмирә аны күзәтә. Чыннан да чибәр тагын үзе! Кояшта каралган тән, сумала кебек кап-кара бөдрә чәч! Буе да кыска түгел! Үзе тагын җәйге ялында колхоз эшенә дә чыга, йөк төяүче булып йөри икән. Әлмирә быел 7 классны бетерсә, Исрафил тугызынчыны тәмамлаган. Урта мәктәптән соң зоотехник булырга хыялланып йөри, ди дәү әнисе. Шулай күзәтә торгач, яртылаш ялангач, юынып торган егетнең кыланмышларын рәсемгә төшерде дә куйды бермәлне. Кайбер җирләрен кәмитләп тә җибәрде. Мускулларын булганнан да зур итеп кабартты, аягындагы галошларының размерын зурайтты, бөдрә чәчләренә бигудилар элде. «Чаян» журналына бирерлек сурәт килеп чыкты. Әзер булгач, рәшәткә аша: «Мә, үзеңне күрәсең киләме?» – дип, рәсемне Исрафилга сузды. Егет юеш чәчләрен сөлгегә сөртә-сөртә елмаеп аңа таба атлады. «Яле, карыйм әле», – дип алды да, бермәлгә аптырап калды, аннан кызның шаяртуын аңлап,  рәхәтләнеп көләргә тотынды. Әлмирә дә аңа кушылды. Соңыннан Исрафил аңа: «Сезгә «Чаян» журналында эшләргә кирәк, кызык-мызыкларны тотып ала беләсез икән», – дип мактап куйды. «Ярый, бер истәлегең булыр, гүзәл Әлмирә туташ, хәзер кереп әнкәйгә дә күрсәтәм, ул да көлсен әле бер рәхәтләнеп», – дип борылып, болдырга таба атлады.

– Кирәкми, кирәкми, Исрафил абый, зинһар, күрсәтә күрмә тагын, йә үпкәләр, – дип, аның артыннан кычкырды.

Аның Әхмәт абыйсы рәссам-мөхәррир, Камал театрында баш рәссам булып эшли. Әлмирәнең аңа ияреп барып, спектакльләр дә караганы бар, бигрәк тә аңа «Диләфрүзгә дүрт кияү» комедиясе ошый. Сәхнәдәге героиня кебек чибәр буласы, егетләрне үз артыннан чаптырасы, алардан төрлечә көләсе килә. Бу ниятләре беркайчан да барып чыкмаячагын аңлагач, «Их, Наилә Гәрәева кебек чибәр булмагач», дип, авыр сулап куя. Тик ул бик нык ялгыша. Ходай аңа буй-сынны да, чибәрлеген дә өеп биргән. Урамнан үткәндә дә, егетләр аңа сокланып, борылып-борылып карап калалар иде. Әле беркөнне театрга килгәч, режиссёр Марсель Сәлимҗанов та күреп алып, абыйсыннан: «Әхмәт, кемең соң бу?» – дип кызыксынып сорап куйды.

– Сеңлем, Марсель Хәкимович, театр карарга бик ярата, менә премьерага алып килдем, – дип җавап бирде.

–Чибәр икән сеңлең! Әйдә быел театр училищесына укырга кереп карасын, буй-сынлы чибәрләр кирәк безгә, – диде режиссёр.

– Юк, Марсель абый, ул минем кебек рәссам булачак, – дип, кырт кисте Әхмәт.

– Бик кызганыч, ярый, сеңлем, уңышлар сиңа! – дип, баш режиссёр юлын дәвам итте.

Шунда Әлмирә аптырап:

– Нишләп, абый, имтиханнар биреп карамаска, баш режиссёр үзе чакырып торганда, – дип үпкәләбрәк сорады.

– Кирәкми! Беренчедән, акчасы да бик аз, эше дә авыр, аннан конкуренция бик көчле, бигрәк тә хатын-кызлар арасында, – диде абыйсы.

...Әлмирә уйларыннан арынып, поезд тәрәзәсеннән кабат тышка күз салды. Ул шул мизгелдә Обсерватория дигән язуны чамалап калды. Исрафил хәзер кайда икән? Авылындадыр инде, элеккечә һаман шулай салкын су белән коена микән? Армиядән кайтып, авыл хуҗалыгы институтына керергә җыенып йөри дип ишеткән иде Әлмирә. Менә быел әбисе янына да кайта алмады. Укуы бетүгә документларын, рәсемнәрен Ленинградның рәссамнар әзерли торган институтына җибәргән иде, авылга кайтып киләм дип йөргәндә генә, чакыру кәгазе килеп төште. Шатлыгы эченә сыймады. Ул ныклап имтиханнарга әзерләнә башлады. Шулай итеп авылга кайтып килү насыйп булмады. Армиядән кайткан Исрафилны бер күрәсе килгән иде дә, булмый инде язмагач. Үзгәргән микән? Хәрби хезмәт үзгәртә бит ул егетләрне. Әй, күрәсе иде бер үзен?! Чын ир-егеткә әйләнгәндер инде.

***

...Әле ике генә җәй элек Совет Армиясенә китәргә җыенып йөргән егет уналты яшьлек тал чыбыгыдай сылу кызны кызыл матаена утыртып, җиләк җыярга урманга алып барган иде. Әллә кыз алдында үзен күрсәтергә теләпме, яңгырдан җыелып калган күлдәвекләргә дә исе китмичә барганда, матае таеп китте дә, егылып, биш-алты адым пычрактан шуып бардылар. Өс-башы пычракка баткан Әлмирә «Беттек!» дип уйларга гына өлгерде.

– Әлмирә, матурым, син исәнме? – диде егет. Кыз ни булганын да аңлый алмыйча, селкенергә дә куркып ята иде. Коты очкан Исрафил: – Әлмирә, бәгърем, нишләттем мин сине, җанкисәгем! – дип, аңа иелде. Кызның вак бөдрә кара чәчләреннән сыйпады. Кыз курка-курка гына шомырт кара күзләрен ачып, үз өстенә иелеп югалып калган егетнең йөзенә бакты. Аның сыдырылган сул як битенә, чәчләренә пычрак сыланган иде.

– Бер җирең дә авыртмыймы, Әлмирә? – дип сорады ул, борчылып.

Кыз: «Белмим!» дигәндәй башын гына селкеп куйды.

– Әйдә, тор әле, матурым, аягыңа басып кара! – дип, көчле, нык куллары белән пычрактан күтәреп алды. Кыз ни булганына төшенә башлаган иде, хушына килгәч, иңбашларын дерелдәтеп елап җибәрде. Егет ни эшләргә белмичә бимазаланды. Кызның чәче-башына, болын чәчкәләре төшерелгән яңа сарафанына пычрак чәчрәп, мескен кыяфәткә керткән иде.

– Зинһар, гафу ит, кичер мине, Әлмирә, зинһар, кичер, – дип әрнеде Исрафил. Кызны кочагына алды, тынычландырырга кереште. – Иң мөһиме, Аллага шөкер, аяк-кулларыбыз исән, урман янында чишмә бар, битләребезне әйбәтләп юарбыз, яме, аннан мин сиңа икенче күлмәк алып бирермен, иртәгә районга барабыз да, үзең сайларсың!

Кыз яшьле күзләре белән аңа күтәрелеп карады. Әле генә тынып калгандай тоелган тирә-юнь, хуш исле дөнья аның өчен кабат ишетелә, яңгырый башлады. Чут-чут килеп, кошлар сайрый, бөҗәкләр безелди, назлы җилләр дә элеккечә исә икән. Ниһаять, хушына килеп, дөнья агышын ишетте Әлмирә. Ул гына да түгел, үзе дә сизмәстән алсу иреннәрен

Исрафилнең битенә тидерде. Бу әле аның беренче үбешүе, тәҗрибәсез, коры үбешү генә иде. Кыз чын күңелдән яратып, сөеп, хисләргә чумып үбүләрнең ни икәнен белми, тоймый иде әле. Ләкин ул Исрафилгә булган хөрмәтен шулай белгертеп куйды. Егетнең шатлыгы эченә сыймады, димәк, Әлмирә дә аңа битараф түгел. Күзе төшеп, күңеле тартып йөргән үсмер кыз яңа гына аңа үзенең мөнәсәбәтен белгертеп куйды түгелме соң? Җаны тәненнән аерылып, болын тургайлары сайраган күкләргә очып менеп киткәндәй, тирә-юньдәге гүзәл табигать җәннәт бакчасыдай тоелды аңа.

– Әлмирә, җаным, син минем армиядән кайтканымны ике ел буе көтәрсеңме соң?

– Белмим шул, – дип кенә куйды кыз, үзенең яңа гына кылган омтылышыннан уңайсызланып.

***

Галия ханым кече кызы Әлмирәне татарчасы шомарсын дип, ел саен диярлек туган авылы Таллы Күлгә кайтара иде. Өлкән балалары Әхмәт белән Алия Киров районындагы милли мәктәпне тәмамладылар. Өстәвенә, икесе дә рус теленнән дә «бишле»гә генә укыдылар. Ә менә Әлмирәгә татарча уку тәтемәде. Галия белән Илгизгә Казанның Таулар бистәсе чигендә үк, заманча төзелгән тугыз катлы йорттан өч бүлмәле фатир бирделәр. Ике бүлмәле хрущёвкадан соң монысы шуның хәтле уңайлы тоелды аларга. Әлмирә белән Алия бер бүлмәгә урнашсалар, әти-әниләре икенчесенә хуҗа булды. Улларына Әхмәткә залны насыйп итте Ходай. Егет кеше егет кеше инде. «Әй, әни, апа белән Әлмирә кияүгә чыгып киткәч, барыбер миңа кала бит инде ул! – дип кенә әйтеп куйды. Нәфесле түгел шул аларның уллары. Гади, ярдәмчел, тәүфыйклы, нәкъ әтиләре Илгиз кебек инде. Ул да балаларына мохтаҗлык килмәсен дип, көне-төне төзелештә мастер булып эшли. Нинди эшкә тотынса да, ут уйната. Үзләренең зур балконнарын улы Әхмәт белән тәрәзәләр куеп, җылытып, вагонка белән тышлап, төссез лак белән буяп та куйдылар. Хәзер улларының җылы җәй көннәрендә балконнан залга кергәне дә юк. Рәсемнәрен дә шунда ясый, чәен дә тәмләп шунда гына эчә, хәтта шунда ятып йоклый да. Әтиләре дә тирә-юньгә, табигатькә сокланып туя алмый. Үзләренең җиденче катларыннан Салмачы бакчаларына, куе булып үскән урманнарга карап утырырга ярата. Әхмәт тә, теге кинодагы кебек үзалдына «ляпота» дип куйгалый. Илгиз абый аңлап бетермичәрәк:

– Нәрсә, нәрсә дисең, улым? – дип сорый.

– Искиткеч урыннан алганбыз, әти, фатирны дим!

– Шулай, улым, шулай, өй салынганда, бик кызыгып үтеп китә торган идем, әле бер мәлне очраклы гына кереп, фатирларын да карап чыктым. Әһ, мин әйтәм, балаларым бәхетенә биредән өлеш чыгарып куйсалар, дим. Аллаһы Тәгалә ишетте, ахры, минем үтенечемне! Зур рәхмәт аңа! – дип, Илгиз кул аркасы белән яшькелт күзләрен сөртеп куйды. Нечкә күңелле шул аларның әтиләре. Әллә инде фаҗигале сугыш кырларыннан мең афәтләр күреп, авыр тән яралары алып кайткангамы, әле сугыштан соң да ул шактый гына хәрби госпитальләрдә яткан. Өстәвенә, беренче хатыны Сәрвәрнең дә аны көтмичә икенче берәүгә кияүгә чыгып куюы йөрәген телгәләгәндер.

Ахры, Әхмәт, Алия, Әлмирә кебек балалары туасы булганга язмышы шулай сынагандыр, ошбу нәниләренә эти итәргә насыйп кылгандыр. Галия белән алар хәрби госпитальдә танышканнар. Инде сугыш бетәргә дә күп калмаган була. Яралары төзәлеп килгән фронтовикка хат китерәләр. Ничек туры килгән диген, аны медсестра Галиягә тапшырырга туры килә. Башта кадерлесеннән килгән хатны ачып укырга ашыйкмыйча гына күкрәгенә кысып утыра яралы солдат. Кеше-кара күзенә чалынмаслык итеп кенә иснәп тә алгалый. Әйтерсең лә, аңа туган җиренең, сөйгән ярының хуш исләрен сеңдереп җибәргәннәр, диярсең. Ике Кызыл Йолдыз, бер Дан ордены, «Батырлык өчен» медале тагылган гимнастёркасын иңенә салып, ул хастаханә бакчасына чыгып китә. Уе – иркенләп, ләззәтләргә бирелеп, ашыкмыйча гына хат-кәлимәне уку. Ләкин көтеп алынган бу хат тетрәндерә разведка взводы командирын. Яңадан аяктан ега. Шул язманы китереп тапшырган Галия дә үз-үзенә урын тапмый, үзен гаеплегә саный. «Әй, эчтәлеген белгән булсам, ертып кына ыргыткан булыр идем!» – дип үрсәләнә. Вакыты чыккан саен яралы солдат янына килергә тырыша. Үзенчә җайларга, тынычландырырга төрле җылы сүзләр эзли. «Борчылмагыз, Илгиз абый, сезнең кебек сугышчан офицерга иң затлы, иң чибәр кызлар кияүгә чыгачаклар! Сезнең кебек батыр кешене мәңге тапмаячак ул, менә, күрерсез!» – дигән була. Менә шулай итеп алар аралаша башлыйлар. Галия дә аны аякка бастырыр өчен хәленнән килгәнчә тырыша. Булыр-булмас хезмәт хакына тавык шулпалары пешереп, базардан алып, алма-грушалар китергәләп тора.

– Син, сеңлем, хезмәт хакын күпме аласың соң? – дип сорады аннан көннәрдән бер көнне Илгиз, сынаулы караш ташлап.

– Сез сорамагыз, Илгиз абый, мин әйтмим, – диде җитди чырайлы кыз. – Ярый, мин китим әле, башка палатадагыларның да хәлләрен белергә кирәк, – дигән сәбәп табып, ишеккә юнәлде. Өлкән лейтенант аны уйчан күзләре белән озатып калды. Янәшәсендә яткан бер аягы яралы солдат: «Каян булсын инде аларның хезмәт хакы, ашарларына җитсә, шул әйбәт инде... Минем үземнең бер туганым Әгерҗе госпиталендә эшли. «Көне-төне яралыларны карап, көчкә өйгә кайтып егылабыз, медицина хезмәткәрләре җитми, күбесе сугышта, рәтле-башлы йокы, җүнле ризык күргәнебез юк! Тизрәк каһәр суккан сугыш бетсен, Гитлер дигән иблис дөмексен дигән өметләр белән генә түзәбез, булганына риза булып яшибез», дип язган иде. Тамаклары туйгачы ашарга да җитми аларның хезмәт хаклары, иптәш өлкән лейтенант!

– Шулайдыр шул, – дип кенә куйды Илгиз, нидер уйланып.

Инде көннәр озынаеп, тәрәзәдән кояш нурлары бөркелә, җылы яклардан кайткан кошлар чыркылдаша башлады. Ул да түгел, пыскып кына барган шыксыз тормышның караңгы диварларын ишеп төшереп, урамда ыгы-зыгы, шау-шу, ура тавышлары оран салды. Атлый-йөри алган солдатлар ни булды икән дип, тәрәзә төпләренә өерелделәр. Палатага Галия атылып килеп керде. Эченә сыймаган шатлыгы язгы ташулар кебек саф күзләреннән ташып тора.

– Сугыш беткән, немец фашистлары капитуляция ясаган! Барыгызны да бөек җиңү белән! – дип, берәм-берәм барысын да кочаклап чыкты. Госпитальдә ятучыларның күзләре дымланды. Воткинск шәһәреннән сугышка чакырылган Витя Камаев хәтта елап җибәрде:

– Туганнар, сөйгән ярларыбыз, әти-әниләребез янына исән-сау әйләнеп кайтачакбыз! Әнкәйнең бит дүрт агай-энесе үлде, мин генә исән калдым. Мин генә! – дип үкседе.

– Да кончай реветь, радоваться надо! Товарищ старший лейтенант, бүгенге көнне билгеләп үтәргә спирт таба алырбызмы икән, праздник же! – диде аның күршесе Володя.

Илгиз күз яшьләрен җиң очына сөртеп алгач, ятагы астыннан чемоданын тартып чыгарды. Аннан кабаланып, киемнәре астыннан солдат флягасын алды.

– Әйдә, Володя, барыбызга да җитәрлек итеп бүл әле, чиста спирт! – дип елмаеп җибәрде. Владимир гына кара урманда адашкан бәндә кебек:

– Болай булгач яшибез, братцы! Витюк, кил әйдә, стаканнарыгызны алып, утырма анда имчәк баласы кебек шыңшып! – дип, иптәшенә кычкырды. Кулына ике пыяла савыт кыстырган солдат килә-килешкә:

– Берүзем генә исән калдым бит, үзем генә! Әнкәй ничек түзә икән, җанкисәккәем! Күңелем әле дә ышанып бетми. Әйдәгез әле, туганнар, минем яу кырында ятып калган Андрей, Пётр, Николай дядяларым, Камаевлар өчен, аларның якты истәлеге өчен дә тотып куйыйк! – дип, калай кружкаларны шапылдатып, тумбочка өстенә китереп куйды.

– Башта, хөрмәтле солдатлар, торалмыйча урын өстендә ятучыларны сыйлыйк, аннан инде үзебезне карарбыз, сөйләштекме? Галия сеңлем, сез, зинһар, безне сүгә күрмәгез тагын, нинди көн бит, нинди көн! Гомергә бер генә килә торган кайгы-сагышлы да, шатлыклы да бүгенге көн!

– Илгиз абый, шулай да тәртипле генә, яме. Авыр яралыларга бик аз гына салыгыз. Җиңү килгәч кенә өзлегеп китә күрмәсеннәр! Ярый, тагын бер бер мәртәбә олы бәйрәм белән сезне! – дип, чыгу ягына борылды.

Кече сержант Володя:

– Иптәш медсестра, Җиңү бит, әйдәгез инде, биш кенә грамм, – дип, аңа да тәкъдим ясады.

– Рәхмәт, Владимир Устинович, минем аны эчкәнем юк, эчмәячәкмен дә, – дип, Галия тырт-тырт басып, горур гына чыгып китте.

– Во, молодец! – диде Володя. – Татарка шул, безнекеләр булса, кулымнием белән йолкып алып йоткан булырлар иде, шундый зур җиңү хакына. Ну, Галия чибәркәйгә дә рәхмәт, как говорится, безгә күбрәк тәтиячәк, шулай бит, – дип, гадәттәгечә, ат кебек кешнәп куйды.

***

Көне буе чабып, эт булып арган, төнге дежурда утырган Галиянең бүлмәсен шакыдылар. Шундук йокысы ачылып китеп, чәчен-башын рәтләгән итте дә ишеккә юнәлде.

– Кем анда? – дип сорады ул ачарга теләмичә. Чөнки бүгенге ыгы-зыгылы көн теңкәсенә тигән иде. Әтисе Галиәкбәр абый әйтмешли, урыс, ашарына тапмаса да, эчәренә таулар аударып булса да юнәтә, дигәндәй, эчеп алган солдат халкы башта сыйланырга теләп, аннары спирт табып бир инде, дип йөдәтте. Төнге икеләрдә генә шау-шу килгән хәрби халык тынычрак калды. Шулай да шыпырт кына килеп шакучылар да бүген ишле булды. Күбесенә, әлбәттә, зәм-зәм суы кирәк булып, шуны эзләп чапса, кайберләренә әле

хатын-кыз кочагы да тансык икәнлеге билгеле булды. Барысыннан да, кайсын җайлап, кайсын сүгеп, кайсын начальнигы белән куркытып, котыла торды. Инде менә Аллага шөкер, тынычлык инде дигәндә генә тагын бер оятсызы табылды. Ишек артыннан:

– Гафу ит инде, Галия, борчыган булсам, мөмкинме бер генә минутка? – дигән тавыш ишетелде. Илгиз абыйсының тавышын ишетеп, кыз икеләнеп калды. Кемнән-кемнән, Илгиз абыйсыннан шундый мәгънәсезлекне көтмәгән дә иде ул. «Аракы теләнергә җибәргәннәрдер инде үзен, йә булмаса, башкалар кебек... Тфү-тфү, Аллам сакласын! Барысына да үзем гаепле! Хәленә керәм дип азындырып бетермәдем микән хәрби офицерны? Бәлкем, ул үзен бик лаеклы дип уйлыйдыр!» дигән күңелсез уйлар сызылып үтте аның башыннан.

– Илгиз абый, төнлә йөрмәсәгез инде, сүзегез булса, көндез әйтергә кирәк иде.

– Өч көннән чыгаралар мине, Галия. Бер күрешеп сөйләшермен дигән идем. Зинһар, гафу итегез, – дип китәргә генә борылган иде, ишек киләсенә җан керде. – Галия, зинһар, гафу ит инде, сезне бүген миннән башка да интектерделәр. Көндез сүз катырга, үзең күрдең бит, шау-шу, ыгы-зыгы булды. Өч көннән мин Башкортстанга – Туймазыма кайтып китәм. Иң авыр, иң четерекле, күңел телгәләнгән чакларымда юатучым да, тәрбияләүчем дә син булдың! Инде бүген миллионлаган кешеләр тилмереп көткән сугыш беткән көн килде! Шул уңайдан сиңа дигән кечкенә генә бүләгем бар иде, – дип, бер төргәк сузды.

– Мин бит аны сездән бүләк алыр өчен эшләмәдем. Хезмәтем шулай кушканга...

– Зинһар, сеңлем, мине рәнҗетмә! Бездә – татарда бераз дорфарак булса да, үпкәләмә, әйтим инде: «Биргәннең битенә төкермә!» диләр. Мин бит сине чын күңелдән үз итеп, яратып...

– Илгиз абый, уңайсыз миңа! Ут-сулар кичеп кайткан фронтовиктан бүләкләр алып ятарга!

– Ошамаса, ыргытырсың, кире алмыйм! – дип, офицер үпкәләбрәк китеп барды. Кыз аның артыннан ни әйтергә дә белмичә, аптырап басып калды. Үз уйларына чумып, бүлмәсенең ишеген бикләгәч, күне кыршылган иске диванга килеп утырды. Шактый вакыт өстәлгә куйган төргәккә төбәлеп карап торды. Шулай да кызыксынуы җиңде. Сүтеп караса, анда роза чәчәкләре төшерелгән, кырыйлары чуклы шәл һәм сыек зәңгәр җирлеккә борчак кебек түгәрәкләр сибелгән күлмәклек иде. Кыз озак еллар стенада эленеп торып тоныклана башлаган коңгырт кара буяулы рамга куелган көзгегә күз салды. Мондый шәлнең бит аның төшенә дә кергәне булмады, ул әйләнә-боргалана үзен күзәтте. Эченнән генә: «Кара, затлы шәл бөркәнгәч, Галия бәләкәчем, син дә хан кызлары кебек үк булмасаң да, ярыйсы гына икәнсең бит!» – дип шаяртты. Аннан күлмәклек тукыманы алып, алгы ягына каплап, кием итеп тектергәч, ничек күренәчәген күз алдына китерергә тырышты. Бу матур чүпрәкне ул Бауман урамында сугыш башланган елны Тукымалар кибетенә әнисе белән кергәч күреп кызыгып торган иде. Менә бит ул ничек! «Бирәм дигән колына, чыгарып куяр юлына!» дигәндәй, ничек матур! Әгәр дә шуннан тектерелгән күлмәкне киеп, шушы шәлне бөркәнеп,

әниләре авылы Таллы Күлгә кайткач, кич утырырга чыксамы? Юк, юк, алай ярамас, мондый затлы кием-салым колхоз рәисенең кызларында да юк. Гади киемле иптәшләре алдында теләсә-теләмәсә дә, масаю кебегрәк килеп чыгачак. Шәлне әнисенә бүләк итәргә дә, күлмәкне тектергәч, киеп Казан урамнарыннан гына әйләнергә туры килер. Биредә бит аны кем танып бетерсен! Рәхмәт инде, Илгиз абыйга, яхшылыкларымны онытмаган бит! Каян тапкан диген, шундый кызыл малны, бөтен җирдә мохтаҗлык булганда. Ул бит беркая да чыгып йөри алмады. Димәк, ул аны каяндыр элегрәк юнәткән, димәк, сөйгән яры Сәрвәргә дип ниятләнгән булган.

Галиянең әле генә шатлык сибеп торган күзләрендә аптырау катыш югалып калу, оялу хисләре чагылды. Юк, юк! Хакым юк! Мин бит кеше өлешенә керәм, иртүк кире үзенә кайтарырга кирәк! Әлеге мал башымны кысачак, тәнемне өтәчәк!

Әле яңа гына унсигез яшен тутырган кызның күзләреннән үпкәләү катыш рәнҗеш яшьләре атылып чыгып, тукымага тамдылар. «Мин беркайчан да башкаларга ниятләнгән малны алмаячакмын! Хакым юк, хакым юк!» – дип телгәләнде аның керсез йөрәге. Аннан сикереп торып, тукыманы селеккәләп җыя башлаган иде, арасыннан коңгырт буявы кырылып бетә язган кәгазь кисәге очып идәнгә төште. Иелеп алып, дәфтәр битен ачса, Ленин бабай башы төшерелгән 25 сумлык акчаны күрде. Кәгазьдә: «Бәхетле бул, Галия!» дип язылган иде.

Икенче көнне иртән, әле сигез тулганчы ук, өенә кайтып китәр алдыннан ул палатага юнәлде. Ахры, Илгиз абыйсы аның керәсен сизенгән иде, урыныннан торды. Кызның сүз әйтергә, ничек әйтергә дип бимазаланганын күреп, ул: «Әйдә, чыгып сөйләшик, биредә ял итәләр» – дип, кызны үз артыннан ияртте.

– Илгиз абый, сез бит якыннарыгызга дип ниятләп алган бүләкләрегезне миңа биреп рәнҗетәсез! Менә күрерсез, үзегезгә дигән насыйп ярыгызны табарсыз! Ләкин мин бу бүләкне кабул итә алмыйм, хакым юк, – диде.

– Ялгышасың, Галия! Инде тагын бер көн күрешәсебез калды. Мин әлеге бүләкләрне биредә эшләүче хезмәткәрләрдән Казан кибетләреннән алдырттым. Сиңа ниятләнгән алар, бары тик сиңа гына, Галия! Җылы тәнеңдә тузсын!

Кыз тетрәнеп куйды:

– Гафу итегез, Илгиз абый! Бик зур рәхмәт инде! Белмәдем! – диде. Сылукайның иреннәре дерелди иде. Сагышланып калган күзләре аска иелде.

– Галиякәй, әгәр дә мин өйгә кайтып, туган-тумача, дус-ишләремне күреп, кире әйләнеп килсәм, каршы булмассыз бит?

Аптырап калган кыз ни әйтергә дә белмичә газапланды.

– Көтелмәгән сорау шул, – дип кенә пышылдап куя алды.

– Адресыңны бирсәң, атнага бер булса да, хат-кәлимә юллар идем! Ул арада ерак араларны якын итеп килеп тә җитәрмен. Мин, мин, бик... рәхмәтле сиңа! – диде ул, уңайсызланып, бик яратам дип, турыдан-туры әйтмәсә дә сизелә иде.

– Берсекөнгә, сезне озатканда, адресымны бирермен, Илгиз абый, – дип пышылдады кыз. Аннан томанлы уйлары эчендә югалып калган кыз

хастаханәнең озын коридоры буйлап китеп барды. Ләкин эчке сиземләве белән ул шуны аңлады – битараф түгел икән бит ул Илгиз абыйсына. «Хәзер менә китеп югалыр да, бүтән күрешә алмасак?» дигән борчу китереп кысты аның күңелен. Сулышы кысылды, һава җитми башлады. «Тизрәк, тизрәк, саф һавага чыгарга кирәк. Югыйсә хушымнан язачакмын», дип бимазаланды ул. Күз яшьләрен сиздермәс өчен башын иеп, урамга ашыкты.

* * *

Поезд тагын бер станцияне узып китте. Шулай да Әлмирәнең очлы күзләре «Васильево» дигән язуны чамалап калырга өлгерде. Ул берара үзләренә каршы чапкан гүзәл табигатькә, урман-кырларга, эреле-ваклы күлләргә сокланып, күз салып бара торгач, кабат үзенең уй-хыялларына кереп чумды. «Быел башта хәзерләнеп, соңыннан Ленинградка барып, имтиханнар биреп йөреп, Сания дәү әнисе янына да кайта алмады! Алла бирсә, кышкы сессияләрне исән-сау үтсә, каникулда туп-туры әбисе янына чабачак, ятмасын көн саен тәрәзәдән күзен ала алмыйча Әлмирәсен сагынып, саргаеп. Арада иң яраткан оныгы бит ул аның. Назлап, иркәләп туймый. Онлы кулларын чиста тастымалга сөртеп ала да, «Кил әле, җимешем! Кысып-кысып кочаклыйм әле үзеңне, бәбкәчем» дип, чакырып, ике бит алмасыннан чуп-чуп итеп үбә. Куе чәчләреннән сыйпый. Әлбәттә, дәү әнисе аны назлавын башка оныкларына күрсәтмәскә тырыша; бүтәннәр алдында Әлмирәнең үзенә дә уңайсыз. Ояла-ояла гына әбисенең кочагына кереп чума. Борынына хуш исле ипи, каймак тәмнәре килеп ирешә. Казанда калган әнисе әйтмешли, җәннәтнең бер почмагы инде изге әниләребезнең назлы кочагы. Мин кайткан чакта Исрафил абый да туры килсә икән! Ул бит Совет Армиясеннән кайткач, авыл хуҗалыгы институтына керәм дигән иде. Нишләптер күңеленә бик якын аңа ул күршеләре... Үзе ярдәмчел, үзе чибәр! Аның белән дус булгач, авыл зимагурлары да килеп бәйләнеп, начар сүзләр әйтеп йөри алмады. Үзе дә ник бер дорфа кылансын! Саклап-яклап кына йөртте. Алла бирсә, беренче стипендияләремне алгач, үзенә бик яхшы галстук бүләк итәм әле. Әлмирә «Алла боерса», «Алла бирсә» дигән сүзләрне соңгы вакытта бик еш искә төшерә, чөнки дәү әнисе һәрдаим: «Нинди генә эш башласаң да, кызым, Аллаһы Тәгаләдән, бисмилладан башла!» – дип әйтә килә.

Имтиханнар бирергә барганда да, әнисе аны үзен генә юлга чыгарып җибәрергә курыкты. Ленинград каласында югары белем алып кайткан, революциягә кадәр башкала булган шәһәрдәге һәр урамны биш ел эчендә шактый гына күргән Әхмәт абыйсы озатып йөрде. Атнадан артык яна-көя, курка-курка имтиханнар биреп йөреп, әлеге гүзәл шәһәрне рәтле-башлы өйрәнергә дә өлгермәде. Кайтып китәсе көнне поездлары төнлә генә кузгалудан файдаланып, алар Эрмитажга керергә өлгерделәр. Әлмирәнең күптәнге хыялы тормышка ашты. «Эрмитаж» француз теленнән кергән сүз икән. Абыйсы аңлатуынча, татарча тәрҗемәдә «сукбай почмагы, яки тормыштан ваз кичкән» дигәнрәк мәгънәне белдерә икән: irmitoige. Ленинградның йөзек кашы булган, дөньяның иң зур күргәзмәсенә нишләп шундый исем кушканнардыр инде, аңламассың? Мәгънәсе әллә ни ятышлы булмаса да, русчасы матур яңгырый тагын! Французчарак сакауланыбрак эрмитагә дип җибәрсәң, үзеңне бөек халыкның олы мәдәниятенә якынайгандай сизәсең

икән! Әлмирә французларның үзләренә охшатыбрак, эрмитагэ дип кабатлады да үзенең кыланмышларыннан көлеп үк җибәрде. Ярый әле, ул урнашкан купеда кеше-фәлән юк, нинди җүләр кыз икән дип уйларлар иде.

...Әле күптән түгел генә имтиханнар биреп йөрде. Салкын суга төшкәндәй туңды, ут эченә эләккәндәй янды. Ни генә булмасын, алдылар аны Ленинградның данлыклы рәссамнар, сынчылар, архитекторлар әзерли торган институтына. Горурланмас җиреңнән горурланырсың! Биредә бит В.И.Баженов, И.Е.Репин, И.И.Шишкин, И.К.Айвазовский, В.А.Серов, Н.К.Рерих кебек даһи рәссамнар белем алган, осталыкларын чарлаган. Ничек бәхетле ул! Алар үткән юллардан, баскычлардан атлап йөриячәк, алар утырып укыган бүлмәләрдә белем алачак. Тырышлыгы бушка китмәде шул! Имтиханга ясап җибәргән Казан, Болгар күренешләрен ошаттылар, күрәсең, имтихан алучылар. Ленинградка кагылышлы сорауларга да әйбәт җавап бирде. Абыйсы: «Андагы профессор, докторлар үзләренең тарихи калалары белән горурланалар гына түгел, масаялар да!» – дип кисәткән иде. Шуны исендә тотып, бар белгәнен күрсәтергә тырышты.

«Эрмитажның ачылган елы дип 1764 ел санала, Екатерина II Германиядән 225 данә рәсем сатып алдыра. Күпчелеге әлеге иҗатчыларның Голландия һәм Фламандия мәктәпләренә карый. Шулай ук Кышкы Сарай эчен бизәргә шәхси коллекционерлардан Брюльнең, Крозаның, Уолполяның һәм башка рәссамнарның картиналары кайтартыла. Инде 1774 елда ук биредә 2080 сурәт төпләнә. Октябрь революциясеннән соң буржуйлардан конфискацияләнгән картиналар белән дә тулыландырыла һәм эшче-крестьяннарның уртак мирасына әйләнә!» – дип сөйләде дә сөйләде Әлмирә, каушавын да онытып. Ленинның Финляндиядән кача-поса, грим-париклар киеп кайтуын да, Икенче Бөтендөнья сугышында Ленинград блокадасының фаҗигаләрен дә – берсен дә калдырмады. «Җитте, җитте, чибәркәй, әйбәт беләсең!» – дип, тарихтан да «бишле» куйдылар аңа. Артыннан гына кәефен төшереп: «Үзе татарка гына булса да, Ленинград туташларыннан да әйбәтрәк белә!» – дип, озын гына чандыр гәүдәле, карчыга борынлы, ач чырайлы, усал күзле марҗамы шунда, яһүдәме, аңа ишетелерлек итеп сөйләнеп, төрттереп калды.

...Поезд бертуктамый чаба да чаба, тиздән Яшел Үзән тукталышы. Әлмирәгә генә ничектер моңсу булып китте, күңелсезләнеп калды. Ул кинәт якыннары белән аерылышуына сагышланып куйды. «Йа Ходаем, әти-әниемнәр, туганнарым, ап-ак чәчле, назлы куллы дәү әниләрем нишләрләр инде миннән башка. Борчылып, кайгырып ятмасалар ярый инде. Мин сезнең йөзегезгә кызыллык китермәм, кадерлеләрем!» – дип, ул аерылышу сагышыннан елап ук җибәрде.

«Патшалар котырышып, типтереп яткан ташкала ул!» – дип, бәясен төшереп алган иде Әхмәт абыйсы. Шулай дип әйтергә ярыймы инде гүзәл шәһәр турында? Ничек теле әйләнә? Ленин бабай каласының архитектурасы гына да ни тора? Әйтерсең, бөтен дөнья җәүһәрләрен бирегә китереп туплаганнар! Вакытым булды исә, музейларга, театрларга йөриячәкмен. Паркларда, елга-канал буйларында һава сулап, шул матурлыкларын күреп, күңелемне, күземне рәхәтләндерәчәкмен. Аврора крейсерын да, Кронштадны, Исаак соборын да барып күрәчәкмен!

...Поезд тәгәрмәчләре тимер рельсларга ышкылып, чыелдаган тавыш чыгарып, станцага килеп туктады. Вокзал рупорыннан ике генә минут торачакларын, вагоннардан чыгып йөрмәүләрен үтенделәр. Әлмирә тәрәзәдән урам якка күз салды. Яшел Үзән вокзалы бинасында якты утлар яна. Инде кич булуга карамастан, халык кайнаша. Кайсыдыр әнә поездга утырырга ашыга. Кемдер пассажирларга пәрәмәч-өчпочмак тәкъдим итеп йөри. Икенче берәве сатарга ысланган балык алып чыккан. Өченчесе исә кәрҗиненә эчемлек шешәләре тутырып, шуларга ия эзләп каударлана. Ул да түгел, рупор: «Хөрмәтле пассажирлар, 22 нче номерлы Ленинград поезды кузгала. Игътибарлы булыгыз!» – дип хәбәр сала. Вагон коридорында да ниндидер хәрәкәт барлыгы ишетелә. Ул утырган купе ишеге ачылып, аннан урта яшьләрдәге, гади генә киенгән бер хатын-кыз, аның артыннан 25-27 тирәсендәге прапорщик түргә узды. Хәрби: «Хәерле кич, мадам!» – дип сәлам бирсә, хатын-кыз исә: «Исәнмесез!» – дип куйды.

– Сез иркенләп урнашыгыз, мин коридорга чыгып торам, – дип, Әлмирә урыныннан торып, кысыла-төртелә ишеккә юнәлде. Прапорщик аңа:

– Благодарю, мадам! – дип кыланыбрак башын иеп калды.

Поезд кузгалды. Күңелдәге моңсулык тагын да көчәйде. Вагон тәрәзәсе кырыеннан ялт-йолт итеп, баганадагы утлар йөгерешеп үтә. Табигатьнең бәрәкәтле, мал-мөлкәтле чоры – әнә, караңгы төшүгә карамастан, кыр кораблары – комбайннар икмәк суктыра, бункерлар тулганны көтеп торган йөк машиналары да күзгә чалынып үтә. Саф һавага ияреп, ачык тәрәзәдән вагонга үлән, икмәк, гомумән, көзге табигать исе ишелеп тула. Әлмирә киң итеп сулыш алды. Дәү әнием дә бәрәңгеләрен алырга җыенып йөридер инде. Бу атнада булышырга Әхмәт абыйсы иптәш малае Рафикъ белән кайтып килергә ниятләделәр. Әй, шунда мин дә булсам! Бәрәңге җыеп аргач, мунча кереп, тузаннарны коеп чыгасың да дәү әнинең мәтрүшкәле тәмле чәен эчеп ләззәтләнәсең. Аннан арып-талып, изрәп йокыга китәсең! Ә инде иртән аны, гадәттәгечә, чәчләреннән сыйпап дәү әнисе уятыр да: «Тор әйдә, кызым, юынып ал, мич авызында гына яраткан коймакларыңны пешердем, суынып, бәрәкәте киткәнче авыз итеп кал!» – дияр иде. Ә коймаклары мичтә, күмер өстендә пешкәнгә микән, искитмәле, ашап туймаслык була аның. Кунак кызы аларны яңа аертылган каймакка манып-манып ашый. «Ой, дау ани, ничек тамлы!» – дип әйтеп куя. Бу сүзләрдән хуҗабикә генә риза бәхил түгел:

– Яле, татарча матур итеп әйт әле! Нәрсә дигән сүз инде ул? Ой, дау ани, ничек тамлы!

– Ә как надо соң, дау ани?

– Дәү әни! Дәү! Ә белән, йомшак итеп әйт! Аннан тамлы да түгел, тәмле. Яле, кабатла әле, балам! – дип, татарча дөрес итеп сөйләшергә өйрәтә. Шулай сабак ала торгач, рус мәктәбендә укыган Әлмирәнең дә авылга кайткан саен теле чарлана башлады. Шулай да үсмернең дөньяга карашы үзгәрәк шул. Кайчагында нишләп рус булып тумаганмын икән, дип тә уйлап куя. Мәктәпләрендә бит тарих укытучылары Марина Фёдоровна дәрес саен татарларны яманлап, нотыклар укыды. Имеш, татар халкы кыргый булган, башка милләтләрне талаган, суйган. Әгәр дә алар булмаса, имеш, руслар әллә кайчан коммунизм төзегән булырлар иде.

Татарлар бүген шундый матур, алга киткән илдә яшәүләре белән, имеш, бөек рус халкына бурычлы.

Әлмирә андый дәресләрдә оятыннан җир тишегенә кереп китәрдәй булып, классташларыннан оялып утыра. Борынгы бабаларының шундый вәхши булуларына йөрәге әрни: «Нишләп шулай дөнья буйлап шәһәр-калаларны җимереп, талап йөргәннәр соң алар? Шанлы калалар төземәгәннәр? Алай дисәң, Болгарны, Казанны кемнәр салган?»

Әлбәттә, меңләгән шәһәрләр төзегән рус халкы белән ярышып булмый. Чыңгызхан, Батый яуларына каршы көрәшеп, зур батырлыклар күрсәткән халык бит ул. Төрекләрне акылга утырткан, шведларны, немецларны суга батырган, японнарны дөмбәсләгән, утраугa бикләгән халык бит!

...Шалтырап, купе ишеге ачылып китте. Анда ай кебек балкып, салам чәчле, зәңгәр күзле прапорщик пәйда булды. Кәефе әйбәт күренә.

– Спасибо, добрая фея! Без киемнәребезне алмаштырдык. Рәхим итегез! – дип, кулы белән артистларча ишеккә ишарәләде. Әлмирә «яхшы» дип кенә куйды да купега юнәлде. Анда спортчы кебек киенгән ханым утыра иде. Купеның җыйнак өстәленә коньяк шешәсе, «Боржоми», казылык, ит менеп кунган, ипи кисеп куелган. Әзерлек белән хәрби кеше шөгыльләнә, ахры, өч рюмка коньяк шешәсенә төбәлеп, стройдагы кебек катып калганнар. Ул да түгел, кулына помидор-кыяр тутырылган эмаль савыт тоткан хәрби кабат пәйда булды.

– Яхшылап юдым. Анфиса Карповна, курыкмыйча ашарга була. Өч стакан чәйгә дә заказ бирдем, хәзер китерәләр. Яле, минем каядыр кәнфитләрем дә бар кебек, рөхсәт итсәгез, добрая фея, сезнең урын астыннан шуны да чыгарып идем. Гафу итегез, исемегезне дә белмим! Мин үзем Артур Михайлович булам!

– Әлмирә!

– Бик шат, Әлмирә чибәркәй!

Студент кыз урыныннан торды. Хәрби сул кулы белән ятак капкачын өскә күтәрде дә, уңы белән казына торгач, бер тартма тартып чыгарды. Коньяк эчәргә укырга баручы кызны күпме генә кыстасалар да, сүзләре үтмәде.

– Юк, юк, рәхмәт, минем, гомумән, эчкәнем юк, – дип, кире кага торды. Прапорщик исә:

– Ну, алайса, су салып, безнең белән чәкештереп эчегез, – дип, Әлмирәгә дигән рюмканы бушатып, су белән чайкагач, «Боржоми» тутырды.

– Әйдәгез, безнең өчен! – дип, ир кеше үзенекен эчеп куйды. Чырае бер мәлгә сытылып алды, коньяк кире килеп чыкмасын тагын дигәндәй, шатыр-шотыр китереп, кыяр чәйнәргә тотынды. Өстәлдәге нигъмәтләрне дә капкалап алгач, хәрби кеше танышырга тәкъдим итте:

– Әйдәгез, хөрмәтле дамалар, яхшылап танышыйк инде. Мин үзем Волжск шәһәреннән. Мари республикасына керә ул. Әнкәй авырып киткәч, бер атна отпуск биргәннәр иде. Үзем Муромда стрелковый полкта хезмәт итәм. 26 яшь, ни кызганыч, өйләнмәгән. Әлегә үземнең икенче яртымны таба алганым юк, гаеп итмәгез! – дип тезеп салды. Ике рюмкадан соң битләре алсуланып киткән Анфиса да:

– Мин Яшел Үзәннән инде! Суыткычлар заводында эшлим, дөресрәге, эшли идем. Ирем Андрей тинтәкләнә башлады да... Эчсә, шыр тилегә

әйләнә! Кул селтәп, тоттым да Мәскәүгә подругаларга чыгып киттем әле. Шул исерекнең көен көйләп ятарга, әнә анасына барып торсын, поты бер тиен! – дип, кыю гына биографиясен сөйләп атты.

– Менә анысын дөрес эшләгәнсез, Анфиса Карповна! Гомер бер генә ул. Телисең – болай яшәргә була, телисең – шул исерек белән интегеп, гомерне заяга уздырырга да мөмкин! Кыю хатын икәнсез, чын урыс хатыны! Әйдәгез, безнең бөек халкыбызның чибәр, үткен бер вәкиле өчен! – дип, рюмкасын күтәрде.

– Артур Михайлович, без бит яшь чибәркәебез белән рәтләп танышмадык, әйдә, сүзне аңа да бирик әле! Югыйсә гел без генә бытылдыйбыз!

– Так точно, дорогие дамы! Зинһар, Әлмирә, сеңлем, гафу итегез! Сүз сезгә бирелә!

Әлмирә уңайсызланып куйды. Шулай да өлкәнрәкләр сорагач, җавапсыз да калмады.

– Студент мин, Ленинградка рәссамлыкка укырга барам, Казаннан! – дип кенә куйды.

– Вот, молодчина девчонка, нинди матур шәһәрне сайлаган! Ул каланың урамнары гына да музей бит! Анда Пётр Беренче, Кутузов, Суворовлар яшәгән. Пушкин иҗат иткән!

– Ой, шул каланы күптән барып күрергә хыялланам, җаем гына юк! – дип, Анфиса да кемгәдер үпкәләгәндәй әйтеп куйды. Ахры, исерек иренәдер инде.

– Я вам обещаю, Анфиса Карповна, мин сезне ул тарихи калага лично үзем алып барам, риза гына булыгыз!

– Мин бик риза да бит, Артур Михайлович... Ләкин сез хәрби кеше буларак ничек постыгызны ташлап китәрсез? Ай, хәйләкәр дә инде, сез, офицер иптәшләр, ни генә вәгъдә итмисез! – дип кеткелдәп куйды Анфиса.

– Минем өчен кыен эш түгел ул, өч-дүрт көн отгул алам да. Командир белән дуслар без! Әйтәм аңа тегеләй дә болай, «Сөйгән ярыма бөек Ленинградны күрсәтәсем килә, разрешите выполнять?» диячәкмен!

– Ну да, сиңа бит ул эчем авырта дип, эштән кайтып китү түгел, хәрби берләшмә! Җибәргәннәр ди сине! – дип, Анфиса ханым сәер генә күзләрен ялтыратып куйды.

– Яхшы! Алайса син минем белән Муромда төшеп каласың. Бер бүлмәле фатирымда яшәп торырсың. Калганын үзем җайлыйм! Сөйләштекме? – дип гайрәтләнеп алды хәрби кеше, тәвәккәллек күрсәтеп.

– Карарбыз! – дип кенә куйды Анфиса Михайловна, сынаулы күз карашы ташлап.

Әлмирә генә ничек инде әле танышырга да өлгермәделәр, өстәвенә, берсенең законлы ире бар, әллә юри кыланып сөйләшәләр инде, дип сәерсенде. Юк, шаярышалар гына бугай болар, дип уйлады.

Кечкенә генә өстәл артында мәҗлес дәвам итте. Хәрби белән Анфиса йокларга, ял итәргә уйламыйлар да иде. Шуны аңлап алган үсмер кыз Артур Михайловичтан:

– Ә мөмкинме, мин сезнең урынга өскә менеп ятсам? – дип сорады.

– Әлбәттә, чибәркәем, менеп ята күрегез! Сорап тормасаң да була иде. Айт-два, и анда, шулай бит, Анфиса Карповна, – дип, нигәдер шатланып әйтеп куйды.

– Ят, ят, сеңлем, без әле әз-мәз генә гәпләшеп утырабыз, тыныч йокы синә, – дип җөпләде офицерның сүзен үткен хатын.

Әлмирәгә озак интегеп ятарга туры килмәде, бишек кебек вакыт-вакыт тирбәтеп алган вагон да, бертуктаусыз моңсу гына текелдәгән тимер тәгәрмәч тавышлары да аңа изрәп йокыга китәргә ярдәм итте, күрәсең.

Иртәнге җиделәр булгандыр, юлдашларын барлап, уңайсызланып, аска күз салса, купеда беркем дә юк иде. «Димәк, Муром каласында төшеп калганнар! Нәрсә булды соң бу, дөрес хәлме, әллә күзенә генә күрендеме?! Әллә төшенә генә кердеме?! Юк, чынбарлык иде ул! Ничек шулай чит кеше белән, очрашканнарына ике сәгать тә үтмәде, иренә хыянәт итте! Ничек була соң инде бу! Шуннан соң кире өенә кайтып, иренең күзенә ничек карар?!»

***

Казан үзенең сәфәргә чыгып киткән кызын август аеның балкып торган кояшлы көннәре, тулган айлы, күк йөзенә чәчелгән йолдызлы төннәре белән озатып калса, 31ендә – җәй аеның соңгы көнендә иртәнге якта поезд, декабристлар түнтәрелеше, большевиклар инкыйлабы, блокадалары белән тарихка кереп калган, рус патшаларының яшәү оясы булган Петербургка, ягъни хәзергечә Ленинградка килеп керде. Шәһәргә җиткәнче үк күк йөзен каплап алган болытлар: «Туган-тумачаларыңны, кояшлы Казаныңны, бергә уйнап үскән дусларыңны ташлап, әти-әниеңне сагышларга салып нишләп йөрисең?» дигәндәй шыбырдап, бертуктамый яңгыр койды. Ярый әле вокзалдан 13 нче номерлы троллейбуска утырсаң, ул урнашасы вуз тулай торагының ишек төбенә үк китереп туктата. Зур, авыр юл чемоданын көчкә сөйрәп, ниһаять, тагын биш ел яшисе «казённый» йортына яңгырга чыланып килеп тә җитте. Ишек төбендә каравылда торучы, урта яшьләрдән өлкәнрәк, иреннәрен мул итеп чат кызыл иннеккә манган сары чәчле түтәй, аның юлламасын алып, күз салгач, ашыкмыйча, иркенләп, амбар кенәгәсенә нидер тутырды. Аннан күтәрелеп карап: «Кызым, сез яшисе 25 нче бүлмә икенче катта. Бүген юлдан килеп ялыккансыздыр, ял итегез! Иртәгә комендант инструктаж үткәрер! Төкле аягың белән, балам, бөек илебезгә лаеклы кеше булырлык итеп белем алыгыз», – диде, мәрхәмәтле күзләре белән елмаеп карады.

– Рәхмәт Сезгә!

– Мин Вера Андреевна булам, кызым!

– Бик шат, Вера Андреевна! Мин Әлмирә атлы!

– Ярый, кызым, бар, бар, яхшылап урнаш, соңыннан кайда нәрсә барлыгын әкренләп төшенерсең! Юлия, сеңлем, яңа иптәшеңне бүлмәсенә хәтле озатып куй әле, зинһар, интегеп эзләп йөрмәсен, – дип, беләгенә кызыл тасма бәйләгән зәңгәр күзле бер кызга мөрәҗәгать итте.

Иптәшләре белән сөйләшеп торган туташ: «Яхшы, Вера Андреена, хәзер озатып куярмын! – дигәч, танышларына: – Яхшы, соңрак сөйләшеп бетерербез, – дип, Әлмирәләр янына килде

– Яле, сеткаңны булса да бир, үзем күтәрешәм! Кулың талгандыр.

– Рәхмәт, Юля! – дип, Әлмирә сул кулындагы челтәр бишторен яңа танышына сузды.

– Кайсы яклардан буласыз?

– Казаннан!

– Татарстаннан инде алайса!

– Әйе!

– Мин Киров өлкәсе Малмыж каласыннан. Сезнең Казан аша үтеп-китеп йөрибез! Нократ Аланында төшәбез дә, аннан автобус белән тагын 40 чакрым юл кала. Сезнең шәһәрегез бик матур, поезд тәрәзәсеннән генә булса да карап, сокланып үтәм. Бер мөмкинлек туса, рәхәтләнеп, Кремлегезне карап йөрисем килә дә... Тик кайчан туры килер, белгән юк!

– Соң, каникулга бергә кайтып килербез... Бөтен тарихи, кызыклы урыннарын үзем күрсәтермен, бездә кунак булырсыз!

– Рәхмәт, Әлмирә! Менә сез торасы бүлмә шушы була. Мин үзем 37 нчедә, өченче катта. Берәр соравың булса, рәхим ит, ишек ачык, ни әйтсәң дә, өченче курска килдем бит, тәҗрибәм җитәрлек!Ияләшәсең, борчылма, башта гына мәшәкатьләр ишле кебек күренә дә, бер-ике айдан кайда-нәрсә ятканын аңлыйсың, бернәрсәсе дә юк аның! Ярый, хәзергә, якташ! – дигәч, кыз башын селеккәләп, калын сары чәчләрен дулкынландырып китеп барды.

Әлмирә кыяр-кыймас кына, уңайсызланып, ишекне ачты. Эчке якта соры күзле, сипкелле, почык борынлы бер кыз ятагы кырыендагы тумбочкага борылып, тамак ялгап утыра. Әлмирә аңа: «Исәнмесез!» – диде. Кызый, «Здрасьте», дип куйды да, өстәлдәге ашамлыкларын җыеп алып, кечкенә шкаф-тумбочкасына тыкты. Аннан яңа килүчегә: «Менә бу урын буш, тегесендә Лиза дигән кыз ята, әле кибетләргә чыгып китте», – дип аңлатып алды.

– Рәхмәт! – дип, Әлмирә ятакка күз салды. Уң як стена буендагы карават аның күңеленә хуш килде. Чемодан белән сетка биштәрен сөяп куйгач, әлеге кызга борылды:

– Минем исемем Әлмирә!

– Дуня, – дип куйды яңа танышы, теләр-теләмәс кенә.

«Чит кеше булгач ятсына, ахры!» – дип уйлап куйды Казан кызы.

– Дуня, сез кулларыгызны кайда юасыз?

– Ишектән чыккач, сул якка барасың, юыну бүлмәсе, бәдрәфе дә шунда ук. Каршысында кухня да бар!

– Рәхмәт!

Кичкырын өченче бүлмәдәшләре пәйда булды. Елизавета исемле икән, Ленинград өлкәсеннән, шәһәрне дә яхшы белүче, зәңгәр күзле, сары чәчле, шат күңелле рус кызы булып чыкты.

– Минем туганнар да җитәрлек биредә. Әнинең сеңлесе Тамара түтәй дә, аннан әти ягыннан да туганнан туган дяденька бар! Үзләренә торырга чакыралар чакыруын! Тамара түтәйнең ире Андриан эчәргә ярата, өстәвенә, апай да бертуктаусыз: «Кичкә калып йөрмә! Чит компанияләргә барып кермә! Егетләр белән йөрергә иртәрәк әле сиңа, берәрсе бүксә тутырып качмасын», дип, колак итен ашап тора. Миңа, унсигез яшьлек чибәр кызга, каравылчы кирәкми бит инде. Туганнан туган абзыйлар шәһәр янындагы бистәдә, аларында торыр идем дә, кич кайтып-китеп йөрүләре куркыныч! Ленинградның бит аның үзәге генә музей кебек, арткы ягына чыктыңмы, башка дөнья башлана. Барак, хрущёвкалар тулы исерекләр, төрмәдән чыккан башкисәрләр, ал санын бер яртыга бирергә дә риза җиңел холыклы

хатын-кызлар! Бер Ходаем үзе сакласын! Ял көннәре кунакка гына барып килгәләсәм инде. Ну, Дуня белән без танышлар инде, ә сез кайдан килеп чыктыгыз? – дип, Лиза шаян күзләрен Әлмирәгә төбәде.

– Казаннан мин, Лиза!

– Ишеткәнем бар! Бик матур кала, диләр! Элек мин Татарстанны да, Казанны да, гомумән, татарларны Монголиядә яшиләр дип уйлый идем! Бер мәлне безнең Кызыл Армия районына Лев Гумилёв килде. Безне Үзәк Мәдәният сараена җыйдылар. Беләсеңме, ул татарлар турында шундый җылы сүзләр әйтте, шаккаттым! Югыйсә ул тарих китапларында гел әллә нәрсә бит. Имеш, татарлар кыргыйлар, бернинди цивилизацияләре дә юк, дип төшендерделәр. Ә Гумилёвны тыңласаң, сездән дә дан-шөһрәтле халык юк икән! Ышаныргамы, ышанмаскамы, белгән юк! Әй, ярар әйдә, иң мөһиме, кызлар, без данлыклы уку йортында белем алачакбыз! Мин моның белән горурланам! Шуңа күрә дә туганнарымның фатирын түгел, тулай торакны сайладым. Театр-музейлар да якын гына, институт үзе дә янәшә. Алла бирсә, бию түгәрәгенә дә йөрергә дигән хыялым бар. Өлгереп кенә булсын. Ә егетләр монда буа буарлык, нинди генә сорты юк, күз чагыла хәтта. Ой, кызлар! Яшибез болай булгач, – дип, бодай саламы төсендәге калын толымнарын сыйпап куйды.

Лиза, чыннан да, чая да, чибәр дә иде. Сылу гәүдәсе өстенә, янып торган, аяз күк йөзе кебек зәңгәр күзләре, озын керфекләре, ап-ак тешләрен күрсәтеп елмаюлары, тулып торган сусыл иреннәре күпләрне гашыйк итәрлек. Нәфис булып күренеп торган тулы ботлары, күпләрне ымсындырырлык, төгәлрәк итеп әйткәндә, кара-чутыр Әлмирәнең капма-каршысы иде ул! Өстәвенә, гадилеге белән дә үзенә тарта.

– Ой, кызлар, онытып да торам, әйдә, әни пешереп тыккан балык бәлеше белән сыйлыйм әле үзегезне, – дип, өстәлгә күчтәнәчләрен чыгарып тезә башлады. Дистәләгән күкәй, кыяр, помидор, яшел суган, мичтә пешкән авыл күмәче, дуңгыз мае, ит кисәкләре пәйда булды. Ике литрлы Кытай термосы да үзенә урын тапты биредә.

– Тукта, Лиза, минем дә бит Казан күчтәнәчләрем бар, – дип, Әлмирә дә үзенең азык-төлек букчасыннан тавык, пәрәмәч-өчпочмаклар, шактый гына зур кисәк сыер ите, җир җиләге, чия кайнатмалары, төрле-төрле конфетлар тутырылган кәгазь пакетын чыгарып, өстәлгә өйде.

– Ой, кызлар, бәйрәм итәбез бүген, – дип куйды хөр күңелле Елизавета. Аннан утын бүкәне кебек караватын саклап утырган итләч битле, коңгырт күзле, коңгырт чәчле Дуняшага да: «Син, дускаем, нишләп анда чиркәү карчыгы кебек боегып утырасың, әйдә, өстәлгә рәхим ит», – дигәч, Дуня да торып, тумбочкасында казынгач, өч бутерброд, өч прәннек күтәреп, өстәл янына килеп утырды.

– Кызлар, әйдәгез, башта тиз бозыла торган ризыкларны ашыйбыз, әрәм булмасын, – дип, Әлмирә абыйсы тыгып җибәргән пычак белән тавыкны бүлгәләде.

Иң беренче итеп, дәү әнисенең ишегалдында кайчандыр кыткылдап йөргән, Аллаһы Тәгалә тарафыннан ризык итеп бирелгән кош итеннән тамак ялгадылар. Аның калган яртысын кырыйга куйгач, Лизаның әнисе пешергән балык пирогыннан да авыз иткәннәр иде, ашказаннары

былбыл кошныкы хәтле генә булган сылу кызларның тамаклары туйды да куйды.

Әлмирәнең әнисе яхшылап юып, киптереп җибәргән күрәгәләрне салып, чәй дә эчкәч, күңелләре тагын да күтәрелеп, бермәлгә канәгатьлек хисләре тоеп утырдылар, беренче булып Елизавета телгә килде.

– Ну, кызлар, байларча яшибез бит, әй! – дип кеткелдәп җибәрде. Әлмирә шул арада тавык кисәге өстенә тоз сибеп, сары төстәге калын кәгазь белән ризыкларның өстен каплап куйды.

– Әлмирә, теге сумсаларыңны да татып карыйсым килгән иде, шартлап булмый, дустым. Татарларның ниләр ашап, шулай матур булып үсүләрен ачыклауны иртәгәгә калдырабыз инде.

– Рәхмәт сезгә! – дип, Дуня гына өч бутерброды белән шул ук сандагы прәннекләрен кире күтәреп алып китте. Лиза гына яңа танышы Әлмирәгә сораулы караш ташлап, «Бу ни булды инде?!» дигәндәй, җилкәләрен сикертеп, аптыравын белгертеп куйды. Өйдән әти-әниләре төяп җибәргән азык-төлекләре, Алланың биргәненә шөкер, бер атнага кадәр җитте. Итле пәрәмәчләрне табада җылытып, тамак ялгасалар, яшелчәләрдән салат әвәләделәр. Дуня дигән дуслары гына шул өч бутербродын күтәреп анда-монда йөрде. Өстәлдә ризык бетеп, җилләр уйный башлагач кына, Дуняшаның күчтәнәчләренә дә чират җитте. Һәм бу өч бутерброд белән өч прәннек тәмам булды. Икенче көнне төнлә нәрсәдер кыштыр-кыштыр килгәнгә Лиза уянып, шыпырт кына утны кабызса, итләч битле, чепи күзле Дуня бер кулына ысланган колбаса кисәге, икенчесенә ярты ак күмәч тоткан килеш ашап утыра иде.

– Әлмирә, карале бу күсене, безнекен атна буе орды-орды да, хәзер качып, үзенекен бүсеп ята! – дип, нәфрәт белән әйтеп куйды Лиза. – «Бурсык!»

Шул хәлләрдән соң Лиза белән Әлмирә бар булганын уртакка куеп, көн күрсәләр, Дуняның ашау урыны тумбочка өстенә күчте. Юньләп аралаша да белмәгән төнтек Дуняны бүлмәдәше Лиза күралмас булды. Бу хисләре аның куерганнан-куера барды. Үзләре булмаган чакта, өстәлдәге ризыкларга да кул сузуы ачыклангач, зәңгәр күзле чая кыз комендант белән уртак тел табып, Дуняны башка бүлмәгә күчерттерде. «Бурсык» киткәндә: «Что я плохого сделала?!» – дип, рәнҗешен белгертте. Әлмирә генә кызганып: «Яшәсен иде лә шунда!» – дип әйтеп куйды.

***

Дуня урынына бүлмәгә аның танышын – Валяны урнаштырдылар. Валентина озын буйлы, сумала кебек кап-кара чәчле, калын кашлы, күкрәкләре ташып торган, җилбәзәгрәк, шул ук вакытта үткен дә бер кыз иде. Көне-төне, дигәндәй, Лиза белән сөйләшүләре, бөтен фикерләре ир-атлар тирәсендә бөтерелде. Үзе итагатьле дә тагын, «Әлмирә, кадерлем, безгә игътибар итмә инде син, чибәркәем, без ни сөйләшмәбез дустым белән», – дип тә әйтеп куйгалый. Ләкин яңа урнашкан кыз Дуняның капма-каршысы, нык юмарт булып чыкты. Бар булганын өстәлгә чыгарып сала да: «Кызлар, тагын берәр нәрсә кирәк булса, тартынып тормагыз, әйтегез! Әгәр кибет-фәләнгә барсагыз, азык-төлекне үзегез алып кайтыгыз инде, яме, кадерлеләрем!» – дип, Лиза белән Әлмирәнең кесәләрендә сукыр бер тиен калмаганда да, Ленин бабай башы төшерелгән кызыл унлыкларны

чыгарып бирә торган булды. «Мине кибеткә генә йөртмәгез, зинһар, болай да йокым туймый, үтенеп сорыйм, дусларым, акча – миннән, табын әзерләү – сездән!» – дип үтенә иде.

Әлмирә башта каян ала икән соң ул шундый суммаларны, дип аптырый иде. Лизаның әйтүе буенча иптәшенең әтисе Тула өлкәсендә зур җитәкче икән. Ай саен 100 сумны җибәреп кенә тора, ди. «Кемнеңдер хезмәт хакы бит бу!» Тора-бара дәртле Валяның Ленинградта да бай ир-атлар белән генә аралашуы беленде. «Бу хәерче студент халкы белән нишлим соң мин?! Рәтле сүзләре, кимендә кафега чакырып сыйларлык сәмәннәре дә юк. Йөриләр шунда бушка селкенеп!» – дип шаяртып та куя. Үзе кичләрен кабат юкка чыга да таң алдыннан гына кайта. Дәрескә дә баралмыйча көне буе йокы симертә. Үзе тагын шуның хәтле белемле, бөтен зачётларын да, имтиханнарын да яхшы билгеләренә генә тапшыра. Бер атна җитә үзенә, бөтен программаны бүлмәгә бикләнеп сөреп чыга. Яхшы укыганга, дәресләрен калдыргаласа да, институт җитәкчелеге дә, укытучылар да артык бәрелмиләр, күрмәмешкә салыналар. Лизаның әйтүе буенча, Валяның җитәкче әтисенең абруе да, көчтәнәчләре дә үз эшен эшли. Валентина Валерьевна судагы балык кебек йөзә бирүдәге тормышта.

Укулар бара тора, көннәр-атналар уза тора. Бөтен хыялы белән Ленинград каласын карармын, бөек кешеләр яшәгән җирләрдән йөрермен, дип килсә дә, көз җитү сәбәпле, иртә караңгы төшә. Өстәвенә, бик еш яңгырлар явып тора, урамга чыгып йөрүләргә киртә ясый. Кайчагында яр буйларында йөреп, каршыдагы тарихи йортларга күз салып кайткалыйлар, анысы да азык-төлеккә дип кибеткә чыкканда гына. Лиза: «Менә бу йортта Маяковский торган, әнә тегесе кенәз Йосыповларныкы», – дип аңлатып йөри. Әлмирә: «Ярый әле шундый ачык күңелле бүлмәдәшне бирде!» – дип, эченнән генә сөенә. Валя турында әйтеп тә торасы юк, юмарт, эчкерсез кызый булып чыкты. Бүлмәдә сирәк-мирәк күренсә дә, кайтканда берәр кыйммәтле торт, йә булмаса кызыл уылдык, ысланган казылыкларга хәтле күтәреп кайта, онытмый бүлмәдәш кызларын. «Сыйланыгыз, кызлар!» – ди дә киеме-ние белән караватына авып, йокыга да тала. Немецлар килеп, бомбага тотсалар да, уятам димә инде син аны. Әйтерсең, Ленинградның блокадада чагындагы кебек, 12-14 әр сәгать станок артында торып, аяктан егылганчы пушкаларга снаряд ясаган. Иртән үзләре укырга киткәндә, алай-болай Валя торса, тамак ялгасын дип, боткасын-шулпасын да, чәен-җимешен дә әзерләп китәләр. Суынмасын дип, ризыкларның өстенә хәтле каплыйлар.

***

Дәресләрнең берсен дә калдырмыйча, лекцияләрне дикъкать белән тыңлап барырга тырышты Әлмирә.

Менә бүген дә Бөтендөнья сәнгате тарихын укытучы Реснер Елена Исааковна сөйләгәннәрне тыңлавы үзенә бер рәхәт. Кайбер укытучылар, профессорлар кебек эчпошыргыч тонда сөйләми. Яхшы артистлар, оратор-трибуннар кебек, тиешле җирендә паузасын да ясый, тема үзгәрүенә карап, тавышы да бер югарылыктан икенчесенә күчә. Төпле белемле булуы да үзенекен итә.

«1884 елның башында сәнгать, ювелир әсәрләрне барлаучы Кабинет-министрга кыйммәтле бүләкләр турында язма доклад ясый. Күпчелек очракта төрле орденнар, бизәнү, көнкүреш әйберләрен чит ил осталары ясый. Кейбель, Кемперер һәм Ренуар кебек осталар ясаган әсәрләр затлы санала. Зур Диңгез белән Борчаклы урамнары чатындагы бинаның беренче катында калын кесәле сатып алучылар өчен ювелир кибет ачыла. Булмаган тауарны заказ биреп тә эшләтеп була, шул сәбәпле Юлий Бутцка мөрәҗәгать итәләр. Шулай ук Томас Полвин белән Юлий Бутцның иҗади хезмәттәшлеге 25 елдан артык дәвам итә. Остаханәләрдә эш кайнап тора. Ни кызганыч, әлеге һәм башка осталарның күп кенә эшләре революция, гражданнар сугышы елларында юкка чыга. Озак вакытлар 1830–1870 елларда Петербургта «Инглиз кибете» дан тота. Нева проспекты белән Зур диңгез урамнары кисешкән чатта урнашкан әлеге сату ноктасында балчык савыт-саба, алтын-көмеш кашыклар, төрле кыйммәтле асылташлар, затлы хушбуйлар да биредә үз хуҗаларын таба», – дип тәмләп сөйли Елена Исааковна.

Ә менә тарих фәненнән керүче Екатерина Владимировнаның дәресен яратмый Әлмирә. Бертуктаусыз татарларга пычрак атуы, русның бөтен бәла-казаларын әлеге милләткә сылтый баруы кызны курсташлары алдында оялудан җир тишегенә кереп китәрдәй итә. Шундый дәресләрнең берсендә иптәше Лиза түзмәде: «Ә сезнең Лев Николаевич Гумилёв чыгышларын тыңлаганыгыз бармы?» – дип сорады.

– Юк, тыңларга җыенганым да юк!

– Ул әйтә, Россия империясен төзегәндә, татарлар иң алгы рәттә барганнар, – ди. – Меңләгән шәһәр-калаларны да әле сез искә алып киткән халык төзегән, ди. Татарларга урынсыз яла ягыла дип тә чаң кага.

Екатерина Владимировнаның билгесез төстәге күзләренә явызлык чаткылары бәреп чыга. Тешләрен кысып, юка иреннәрен җәеп:

– Совет дәүләтенә каршы алып барган агитация өчен төрмәдә утырып чыкканын оныткандыр! – дип ысылдый. – Бөек рус халкына каршы коткы таратучы ул!

– Сез үзегез кайсы милләттән соң?

– Чын рус кешесе мин, кадерлем! – дип, горур гына әйтеп куя лектор.

– Ә нигә алайса сезнең чын фамилиягез Штенгард?!

Сорауны ишеткәч, явыз яһүдә бермәлгә өнсез калды. Шәкертләр бер яктан Лизаның кыю сорауларына сокланса, ни булыр икән инде дип, сагаеп та калдылар. Педагог күзләрен алартып:

– Минем фамилиям нинди генә булмасын, мин чын рус кешесе! – дип, журналын кулына алып, тырт-тырт атлап, аудиториядән вакытыннан алда чыгып китте.

Студентлар: «Менә хәзер уку йортыннан кудыртачак инде!» – дип пышылдашалар. Әлмирә дә дусты Лизага сокланып карап: «Нинди туры сүзле, кыю фикерле кыз бу?!» – дип уйлап куйды.

Ләкин, ни генә булмасын, эшне тавышсыз-тынсыз гына үткәреп җибәрделәр.

Әлмирә октябрь башында Лиза дусты белән бию түгәрәгенә йөри башлады. Төрле чаралар, спорт ярышлары, Яңа ел бәйрәмнәре үткәрелә торган әлеге зал бик зур һәм иркен иде. Өске ягында балконнар чыгып тора.

Алар борынгы рим, грек архитектурасына охшатып, колонналар, ягъни таш баганалар белән терәтелгән. Биек түшәмгә зур люстраларда йөзләгән лампалар – Ильич утлары кабына. Алар күк йөзендәге йолдызлар кебек әкияти төсмерләр биреп җемелдиләр. Әлмирә бу иркенлек-киңлектә үзен бөтенләй кечерәеп, чебен-черки кебек кенә калгандай хис итте. Ул, кабат-кабат зур, шактый күләмле люстраларга каерылып карый-карый, Лизаның артыннан атлады. «Кайчандыр әлеге залда дистәләгән көйчеләрдән торган оркестр уйнаган, төрле зурлыктагы түрәләр, даирәләр, югары катлам аксөякләре, патшалар, чит ил кунаклары итагатьле кыланып биегәннәр. Янәшәдәге кечерәк заллардагы өстәлләр затлы ризыклардан, алма-банан, мандарин, кызыл-кара уылдык, затлы балык, чучка итләреннән сыгылып торган. Шампан шәраблары елга булып аккан. Елена Исааковнаның әйтүе буенча, идарәче даирәләр коточкыч мохтаҗлыкта яшәүче кара халык өстендә типтереп яшәгән. Хайван дәрәҗәсенә төшерер өчен әлеге надан катламны көне-төне эчертеп, авызлыклап тотканнар. Исерекләрнең кыланмышларыннан көлеп, тамаша кыла торган булганнар. Чибәр-чибәр кызларны сайлап алып, асрау ясап, соңыннан зина юлына кертеп җибәргәннәр. Кайбер ата-аналар чарасызлыктан үзләре үк балаларын шушы юлга этәргәннәр. Менә буржуазиянең чын йөзе. Халыкны мыскыл итеп, типтереп яшәүләр патшаны бәреп төшереп, большевиклар диктатурасы урнаштырылганчы дәвам иткән. Аңа хәтле рус халкының биш проценты гына хәреф таныган. Бөек юлбашчыбыз Владимир Ильич Ленин гына надан халыкның белемен, аңын күтәрергә мөмкинлекләр тудырган. «Укырга, укырга, укырга!» дигән киң мәгънәле лозунгны да ул әйткән. Ниһаять, гади халыкка да белем алырга мөмкинлекләр тудырыла. Меңләгән мәктәпләр, уку йортлары барлыкка килә. Театрлар, концерт заллары гади халык өчен дә киң итеп ишекләрен ача. Унбиш-егерме ел вакыт үтми, СССР дәүләте иң белемле, иң укымышлы илгә әйләнә. Ватаныбыз коллыктан, түрәләр вәхшилегеннән мәңгегә котыла. Завод-фабрикалар, төрле предприятиеләр төзелә. Ә аларда хезмәт кылыр өчен белемле затлар кирәк!» дип сөйләгән иде укытучы. Менә хәзер алар Лиза дусты белән байбичәләр генә масаешып вальс әйләнгән гигант мәйданның үзендә! Сул почмагына биш-алты ширма куелган, ахирәте Лиза әйтүенчә, шунда кереп, биючеләр киемнәрен алмаштыралар икән.

Ниһаять, берсеннән-берсе чибәр, яшьлекләре ташып, каннары кайнап торган, төрле милләт вәкилләре булган студентлар, педагоглары Артур Вагапович каршына тезелешеп бастылар. Исем-фамилияләрен барлагач, тәннәрен язып алдылар, соңыннан ритмик йөрүгә, аннан йөгерүгә күчтеләр. Беренче көннәрендә буталышып, вакыт-вакыт бер-берсенә бәрелешкән тәҗрибәсез шәкертләрнең төрле тактка атлап, табан аслары белән шакылдатып көй чыгарып йөрүләренең сыйфаты ике атнада нормага керде. Бию сәнгатенә бөтенләй сәләтләре, килеш-килбәте дә туры килмәгәннәре бию түгәрәген ташлап китеп барырга мәҗбүр булдылар. Рәтләр сыегайса да, иң-иң тырышлары, гәүдәләре сыгылмалылары арасында Әлмирә белән Лиза да бар иде.

...Нинди генә сылу гәүдәле чибәр кызлар, бөркет кебек кавказлылар юк биредә. Тәнәфес булдымы, Дагыстан егетләре, чечен, ингушлар, осетиннар

үзләренең милли биюләрендә ярышалар. Бармак очларына гына басып, идән паркетларын санныйлар. Салмак кына башланып киткән хәрәкәтләр, берзаман дәртле биюгә әйләнә. Тез белән идәнгә чүгеп алулар, бөркет кебек очып йөрүләр күбесендә соклану уята. Бигрәк тә ирек яратучы, буйсынмас милләт вәкиле булган чечен егете Аслан Мөхәммәтов, ирекка омтылган арыслан кебек ярсып-ярсып бии. Шомырт кара бөдрә чәчләре, тәлгәш-тәлгәш булып битенә төшеп, зур күзләрен каплый. Ул аларны кабат артка сыпырып җибәрә дә лачын кебек уктай атыла. Гимнастлар гына башкарырдай сальтолар ясый. Бар да аның ярсып биюенә, чибәрлегенә сокланып кул чаба. Аның саен тау бөркете киң итеп канатын җәя. Тирә-якта бер-берсенә елышып торган кыз-кыркын егетебездән күзләрен ала алмыйча мөкиббән китеп карап торалар. Лизага да бүген әллә ни булды, саф зәңгәр күзләрен бер генә мизгелгә дә Асланнан аерып ала алмады. Үзе Әлмирәнең кочагына сыенып: «Менә ир ичмаса!» – дип куйды. Шундый көннәрнең берсендә аны Артур Вагапович читкә чакырып алды да, нур сибеп торган шомырт кара күзләре белән төбәлеп: «Әлмирә Илгизовна, Яңа ел концертында үзегезнең берәр милли биюегезне башкарыгыз әле?!» – дип үтенде. Кыз аптырап калды. «Нишләп нәкъ менә миңа тукталды икән, яхшырак башкаручылар да җитәрлек бит. Ул молдаванкалар дисеңме, шул ук кавказлылар ничек җир җимертәләр?!» дип уйлап бетермәде, кызның күңелен аңлап алган укытучы:

– Әлмирә, бөек татар халкының бию-җырларында тирәнлек ята. Моңнарыгыз күңелне тетрәндерә, биюләрегез дәртле, табигать кебек гүзәл! Күрсәтик әле барысына да татарның милли биюен! Ул арада сезнең халыкның киемнәрен дә тектереп алырбыз.

– Берүзем генә башкарып чыгармын микән соң, оялам да... Аннан күмәк биюдә дә катнашасым бар?! – дип мескенләнеп, нәүмизләнеп куйды.

– Биерсең күмәген дә, ә татар биюенә килгәндә, иртәгә үк күнегүләрне башлыйбыз! – дип, кинәт борылып китеп барды.

***

Әлмирәнең биюе «Су буенда» дип аталып, эчтәлеге дә гади генә иде. Чишмә буенда бер егет сөйгәнен көтеп йөри, бүләккә яулык та куенына тыгып килгән. Ул шул яулыгы белән ниләр генә эшләп бетерми. Күкрәгенә кысып назлый да, гимнастлар кебек күккә атып җибәреп, кире тотып та ала. Тезләренә җәеп салып, назлый, сыйпый да. Гүя гап-гади чүпрәк кисәге белән түгел, ә кадерле сөйгән яры белән серләшә. Кыз килгәнне сизеп, таллар арасына кереп поса. Чибәре чишмә суларын чиләкләре белән чөмереп ала да кайтырга юл тота! Егет капылт кына пәйда булып, каршысына килеп баса, кыз ояла, кеше-кара күрмәсә ярар иде дип бимазалана. Шулай да мәхәббәт җиңә, менә алар сак кына тал чыбыгыдай бөгеләләр, сыгылалар. Кыз оялып, йөзен яшерә. Ләкин егет тә максатчан. Яулык бүләк итә дә кызның югалып калуыннан файдаланып үбеп ала. Чибәркәй үпкәли, бүләкне кире кайтара. Егет кесәсеннән йөзек чыгара да, ярәшү билгесе итеп тезләнеп, сөйгәненә суза: кыз кирелеген җиңеп, кулын бирә. Салмак кына, талгын гына бию кабат җанланып китә. Бәхетләре ташып торудан ике яшь йөрәк кызганнан-кыза барып, дәртләнеп бииләр. Артур Вагапович әлеге татар сәнгатенә

Кавказ тауларыннан ыргылып агып төшкән чишмә-елгалар дәртен дә, тау бөркетләренең ук кебек омтылышларын да өстәде бугай!

Бию бетүгә, бар да дәррәү кул чапты. Партнёры Аслан Мөхәммәтов та сокланып: «Син нинди чибәр!» – дип мактап куйды. Үзенең кояш кебек балкыган битеннән тир тамчылары паркетка коела. Аның янына беренче булып авызын ерып, Лиза килеп җитте.

– Искитмәле биедегез, нинди матур татар әсәре! Аслан да, әйтерсең, чын татар егете инде. Соңыннан нәрсә диде соң ул сиңа? – дип тә төпченде бүлмәдәше.

– Әйбәт килеп чыкты, – дип, Әлмирә, кавказ егетенә гашыйк булган Лизаны рәнҗетмәс өчен бераз үзгәртебрәк җавап бирде. Ул да түгел, яраткан укытучысы Елена Исааковна Реснер да киң итеп елмаеп, ай кебек балкып килеп җитте.

– Афәрин, матурым! Син чын татар кызы икәнсең, – дип кочып алды. – Мин горурланам Сезнең икегез белән дә, – дип, Лиза белән икесен дә олылады. Аннан: – Ярый, кызлар, күңелле ял итегез! Әллә кая чыгып йөрмәгез, институт тирәсендә генә булыгыз! Урам тулы исерекләр хәзер, – дип китеп барды. Әлмирә аның артыннан сокланып карап калды. Үзе эченнән: «Елена Реснер да яһүдә бит, нишләп Штенгард кына шулай явыз күңелле икән?» – дип уйлап куйды. Ул да түгел, курсташлары уратып алып, чыр-чу килделәр. Бераздан инде алар бәйрәм тәэсиренә бирелеп, бар дөньяларын онытып, зур залда рәхәтләнеп биешәләр иде. Элек биредә халыкның канын эчеп ятучы аксөякләр генә вальс башкарса, бүген инде күп милләтле илнең киләчәге ял итә иде.

...Шулай итеп, зур хәстәрлекләр, әзерлекләр күреп көтеп алган Яңа ел бәйрәме дә шау-гөр килеп үтеп китте. Тулай торак ике көннән җен-пәриләре качкан йорт кебек тынып, мул өстәлләре бушап калды. Комендант Ашут Хазарян гына помидор кебек кызарган зур борынын ишек саен тыгып: «Калдык-постыкларыгызны чүп савытларына чыгарып ыргытыгыз. Кем тулай торакны пычрата, 10 сум штраф!» – дип кисәтеп йөрде. Ул ун тәңкәләре кесәләрендә булсамы, рәхәтләнеп бер-ике атнага җитәр иде әле! Калталарында ипилек-тозлык кына сәмәннәре калды. Кайсыбер әтәчрәк егет кисәкләренең тишек кесә төпләрен әйләндереп карасалар да, касса чекларыннан гайре бернәрсә дә табылмас иде. Бүлмә саен тынычлыкларын бозып, әҗәткә акча теләнеп йөрүчеләр көнләп түгел, сәгатьләп ишәйде. Бигрәк тә Миасс каласыннан килгән Володя Малин: «Кызлар, үтермәгез, зинһар, өйдән акча килүгә өстәп, процентлары белән үк кайтарам», – дип, бәйрәм хөрмәтенә хәмер чөмерә-чөмерә кура җиләге төсенә кергән чыраен ишек саен диярлек күрсәтеп йөрде. Тик бирүчеләр генә табылмады. «Кура җиләге» кушаматлы әлеге студент кисәгенең бурычларын түләми, оныта торган гадәте барлыгын да вуз халкы күптән белә иде шул. Шулай да Чиләбе якларыннан килгән егеткәебезнең иң соңгы чиккә килеп җиткәч куллана торган чарасы да бар иде. Ул да булса, Гайсә пәйгамбәр сурәтләре төшерелгән иконалар ясап, чиркәү, базар тирәсендәге әби-чәбиләргә сатып җибәргәли иде. Үткән елны шулай сатып йөрүен кемдер деканатка җиткергән. Комсомол җыелышлары үткәреп, студентыбызны иманга китергәннәр иде. Үзенә соңгы сүз биргәч, мескен

чырайлар ясап: «Җәмәгать, гафу итегез, әти инвалид, әнкәй җилкәсендә тагын берсеннән-берсе кечкенә биш бала! Ничек яшәргә соң миңа?» – дип артистланып алган. Шуннан соң нинди дә булса җәзага тартыласы урынга, аңа матди яктан ярдәм күрсәтергә кирәк дигән карар чыгарганнар. Әтисенең инвалидлыгын раслаган белешмә соратып алуын үтенделәр. Аның шулайаклануына дус-ишләренең дә кызып-кызып нотык сөйләүләре нәтиҗә ясаган. Воронеждан килгән дусты, шешәдәше Геннадий Антипов: «Әгәр дә без иптәшебезне шушы хәлендә ташлыйбыз икән, нинди комсомоллар, нинди совет кешеләре булыйк без?! Руслар бер-берсенә терәк булмасалар, явыз монгол-татар ордаларын, Тефтон-немец рыцарьларын җиңә алырлар идеме?! Володя Малин соңгы тиенен дә иптәшләре белән бүлешә торган кеше, өстәвенә өендәге инвалид әтисе, бер ызба эне-сеңелләре барлыгын да онытмыйк, иптәшләр!» – дип шыттырган. Аңа икенче бер ахирәте Уралмашов та кушыла: «Авыр, бик авыр «кура җиләге»нең хәле. Ул бит алган стипендиясенең дә яртысын ачтан үлмәсен өчен туганнарына җибәреп ята», – дип яклап чыга. Кызгандырырлык иде Малинның хәле! Дәлилләр көчле булу сәбәпле, аңа көне-сәгате белән унбиш сум күләмендә ярдәм күрсәтелә. Әлеге өч иптәш шул кичне үк унбиш сумны ресторанда дөмектереп кайталар. Тагын хәерчелек җилләре китереп бәрә «кура җиләге»нең битенә. Шундый шыксыз, бәрәкәтсез көннәрдә аңа Одессадан килгән бишенче курс студенты Иван Захарчук тап булды. «Сиңа, брат, спонсор табарга кирәк, рәхәтләнеп тәк ятарсың, ашарыңа пешкән, киемсалымың юылган, үтүкләнгән булыр, карт бичәнең күңелен генә күрә бел!» – дип, хохол аңа ярашлы киңәшен бирде, чөнки бу өлкәдә тәҗрибәсе зур иде. Спонсорны бер литр бәрабәренә үзе табып бирергә вәгъдә итте. Ачлы-туклы йөргән көннәрнең берсендә Захарчук аны үзе белән ияртеп, каядыр кунакка алып китте.

***

Анастасия Ивановна кырык бишен күптән түгел генә тутырган, урта гына буйлы, ипи кибетендә мөдир булып эшләүче, симез генә гәүдәле, тупылдап торган хатын иде. Улы башка чыгып, аерым яшәү сәбәпле, анакай өч бүлмәле сталинкада ялгызы гомер сөрә. Вакыт-вакыт оныклары килеп, дөбер-шатыр-губернатор дигәндәй, бөтен фатирның астын-өскә китерүләрен исәпкә алмаганда, алтмыш биш квадрат метрлы торак күп вакыт тып-тын тора, ыгы-зыгылы сату-алу эшеннән талчыгып кайта да, өченче номерлы ипи комбинатының ак ипиенә калын итеп колбаса телемнәрен тезеп, күне тузып каешланып беткән креслосына чума. Зур пыяла касәсендәге каты чәен йоткалап, бутербродларны бер-бер артлы карынына озата. Кайбер көннәрдә калын итеп сыер мае ягып, өстенә калын итеп сыр кисәкләре ябыштырып, ризыкны төрләндерә. Әле үткән атнада гына Берёзовка авылында яшәп ятучы өлкән абыйсы Анатолий дуңгыз мае китереп китте. Салоны аның ир туганы гына шулай оста итеп ясый белә. Күз җиттеме, Анастасия авылларына: «Абый, дуңгыз итең белән салосыннан өлеш чыгарырга онытма», – дип хәбәр җибәрә. Бәрәңге белән суганын, кишер белән кызыл чөгендерен дә абзасы күз саен өенә китереп тора. Андрюшасы эчүеннән тыела алмыйча, кырыгын да тутырмыйча китеп

баргач, таба-казан ашларын сирәк пешерә торган булып китте. Әзерләсә дә, улы, килене, оныклары килсә генә! Дөрес, бәйрәмнәрдә өстәлен мулдан хәстәрли белә ул. Ахирәтләре белән шау-гөр килеп күңел ачарга ярата. Ялгыз калгач, иренең бер иптәшен, теле белән сандугач булып сайрагач, аның уңганлыгына, сөйкемлелегенә баллар яккач, йортка да кертеп караган иде. Мәрхүм Андрееннан да күбрәк чөмерә торган булып чыкты, чучка танау. Аек чакта бал яга торган теле, салып алса агулы еланныкына әйләнә икән. «Әнчек» тә калмый, «дуңгыз кавеме» дигәне дә... Ниләр генә әйтеп бетермәде ир тинтәге. Хет ирлек бурычын тиешенчә үти белсә икән, адәм актыгы! Түзде-түзде дә исерек килеш өстәлен әйләндереп ташлаган дуамалны очыртып кына чыгарып җибәрде. «Андый ирнең булганыннан булмавы хәерлерәк!» Иптәш хатыны әнә башкалар белән типтерергә яраткан ирен фатирыннан сөреп чыгарды да «Дөнья рәхәте!» – ди, яшь-яшь студент кисәге белән ләззәт дәрьяларында йөзеп яшим, дип кенә җибәрә. «Ятма ирләр назына тилмереп, әйдә, үзеңә дә ыжгырып торган яшь-җилкенчәкне табабыз!» – дип, аны да үгетләде.

– Табуын табарбыз да, кырык бишен тутырган, гәүдәсе дә калынаеп киткән түтәңә яшь-яшь егеткәебез карар микән соң?

– Яхшылап ашатсаң-эчертсәң, юл чыгымнарына әз-мәз генә акчасын да тамызгалап торсаң, кая китсен ул?! Ике дә уйлама! – дип, иптәшен үгетли торгач, ниһаять, тутырылган үрдәк кебек тупылдап торган Анастасия бәхетен сынап карарга булды. Шуның өчен бүген эшеннән: «Врачларга күренәсем бар!» – дигән сәбәп табып, отгул алды.

Соңгы тапкыр Яңа ел бәйрәмендә генә аш пешергән хатын киләсе кунаклар хөрмәтенә борщ пешерергә ниятләде. Нәрсә-нәрсә, чөгендер шулпасының бөтен әмәлен китереп хәстәрли белә торган иде ул. Иң беренче эш итеп, дуңгыз итен юып, кәстрүлгә салып, кайнарга куйды. Ит пешкән арада кызыл чөгендерне ваклап, кашык очы белән генә алып, лимон кислотасы өстәде, томат пастасы да кушты, табага салып, томалап парландырырга куйды. Тамыразыкның икенче өлешен угычта ваклап чыгаргач, бер литрлы савытка шулпа белән салып, монысына да лимон кислотасы өстәде, кайнап чыгарга куйды. Кәбестәсен, бәрәңгесен, кишерен, суганын турады. Шулпага тоз белән шикәр комы да өстәде. Ит пешкәч, аны сөзгеч плауник белән алып, кәчтрүлгә калган нигъмәтләрне чумдырды. Ризыктан хуш ис бөркелсен өчен суган кабыгын кайнатып, суын шулпага салды. Иң соңыннан гына болгар борычын ваклап сипте. Быгыр-быгыр килеп, саргылт-кызгылт күбекләр чыгарып пешкән ашның утын кысты. Иң соңгы аш тәмләткеч итеп дуңгыз маенда изелгән сарымсак һәм дәфнә яфрагы белән борыч борчагын салды. Бик зур мәшәкать сораган затлы шулпа, ниһаять, әзер иде. Шулай да әле аны плитә өстеннән алгач та, кимендә бер егерме-утыз минут тастымал белән каплап торырга кирәк. Бөтен шартын китерде Анастасия бүген киләчәк кунаклар хөрмәтенә. Газ плитәсенең миченә майонезга бутап, тавык, эре кисәкләргә туралган бәрәңгеләрен тыкты. Бер литр сыешлы графинга ике шешә аракыны урнаштырды. Соңыннан ярты стаканын кире алып, аның урынына гранат согы өстәгәч, эчемлек изумруд төсләренә кереп, балкып бетте. Селёдка белән скумбрияне дә кисәкләп тәлинкәгә тезде, өстен түгәрәкләп киселгән

суган, петрушка үләне белән дә бизәде. Үзе тозлаган помидор белән кыяр да өстәлдә урын тапты. Иң четереклесе кием сайлау булып чыкты, яшел төстәге кечерәеп калган үзе яраткан бәрхет күлмәген көчкә киде, кире салу кигәненнән дә мәшәкатьлерәк булып, интегә торгач тирләп-пешеп чыкты. Каен яфраклары төшерелгән күлмәге гәүдәсен тагын да юанайтып күрсәткәндәй тоелды. Нәрсә генә киеп карамасын, бер тамчы да сылулыгы артмады. Киемнәр алдаша белмиләр иде шул, кайчандыр бил булган урында да сыгылмалыклар барлыкка килмәде хәтта. Май баскан түшләре дә кимемәде. Үзе кебегрәк ир заты килсә, болай сайланмас та, интекмәс тә иде. Көткән кешесе бит улыннан да биш елга яшьрәк икән! Шулай да куе зәңгәрсу күлмәгенә тукталды, алгы ягына үрелгән калын толымын салындырды. Сул күкрәге өстенә чәчәк таҗларын хәтерләткән брошкасын такты. Ярты сәгатьләп көзге каршында бөтерелгәндер. Шунда сискәндереп, ишек кыңгыравы яңгырады. Хатын тагын үз килбәтенә бер күз төшереп алгач: «Йа, Ходаем, бер үзеңә тапшырдым!» – дип, ишеккә юнәлде.

Сагаеп кына башланган мәҗлес әкрен генә кыза барды. Кыздырырлык нәрсәсе дә җитәрлек иде. Хохол малае һәр күтәрелгән тост алдыннан фатир хуҗабикәсе Настя ханымны күкләргә күтәреп мактады. «Анастасия Ивановна алны-ялны белмичә халкыбыз өчен иң игелекле шөгыль белән хезмәт кылучы, икмәк өләшүче изге җаннарның берсе ул! Андый фидакарьләребез булмаса, бик авырга туры килер иде яшәешебездә!»

Настя башта бу мактаулардан уңайсызланып: «Ярар инде, Ваня, кызартасың бит, битләремә хәтле кызыша башлады!» – дип кеткелдәде. Захарчук: «Әйдәгез, хөрмәтле туганнар, табыныбызның хуҗасы өчен тотып куйыйк әле!» – дип, рюмканы башкаларга да урын калдырмаслык итеп авызына каплады. Аннан тавык ботын алып кимерергә тотынды. Үзе чәйни-чәйни: «Ашап туймаслык тәмле итеп пешергәнсез, Ивановна! Молодец!» – дип сөйләнде. «Бу симез сарыкны ничек кочаклап йокларга икән соң?» – дип сагаебрак утырган Малинга да, кем әйтмешли, ямьсез хатын-кызлар булмый, аракының гына әз булуы бар, дип күз кысты. Бу өстәлдә анысы да җитәрлек иде. Графинның төбенә төшеп җиткәч, кызып алган хуҗабикә өч литрлы банка белән күз яшьләре кебек ялтырап торган көмешкә китереп куйды. Ниһаять, алды көмешкә Володя Малинны да. Күзләре яна, дәрте ташыганнан ташый бара башлады. «Сез, Настюша матушка, миңа беренче күрүдә үк ошадыгыз, мин сокланам сезнең уңганлыгыгызга! Эш бит кемгә күпме яшь икәнлегендә түгел, ә бер-береңә симпатиядә. Ә ул симпатия сездә бар, Ивановна!» – дип, фраерларча рюмканы авызына каплады. Хохол малае Иван белән аның олы яшьтәге сөяркәсе Легенда Степановнаның да башына ныклап китте бугай! «Горько, горько!» дип кычкыра башладылар. Малин башта торып басты, аннары Анастасия ханымның алдына тезләнеп, симез кулыннан суырып үпте...

Иртә белән ул будильник тавышына уянып китте. Башын күтәреп, тирә-юньгә күз салса, Настя матушкасының мул түшләренә башын салып йоклаган икән! «Как спалось?» – дип сорап куйды хуҗабикә, аның селкенгәнен күреп. «Яхшы, яхшы, Настя, бик яхшы! Тик дәрескә өлгерергә кирәк. Тиз генә юынып алырга да. «Әйе! Ни, э-э-э, стипендия алганчы бер биш сум биреп торалмассың микән! Шундый күркәм ханым белән таныштырганы өчен Захарчукны да сыйлармын дигән идем».

Анастасия Ивановна чандыр Малинны үзенә тартып алып, үбәргә тотынды. Яшь иптәш тә акчаны эшләп алырга кирәклеген аңлап: «Ох, как хорошо мне с тобой!» – дигән булып, симез хатынның затсыз тәнен күрмәс өчен күзләрен йомып, матушканың өстенә капланды.

Шул ук кичне «кура җиләге» Малинны бөтен җиргә дә өлгер Захарчук белән «Ләззәт» кафесында күрергә була иде. «Матушка» биреп җибәргән кызыл унлыкны иптәшенә күрсәтеп:

– Менә ул безнең сәмәннәр, менә! – дип, борын төбендә селеккәләде. Захарчук авызын ерып:

– Әйттем бит мин сиңа, ашаталар, эчертәләр, өстәвенә тәрбияләп йоклаталар да. Күрәсеңме, шытырдап торган унлыкны да кыстырып җибәрергә онытмаган! – дип, яшь кияүнең җилкәсенә сугып алды. Володя исә мут кына елмаеп:

– Анысы шулаен шулай да, яшь нечкәбилләрне күз алдына китереп кыланырга туры килә инде. Үзем монда, күңелем тегендә дигәндәй!

– Иң мөһиме фантазияң көчле булсын! Зато, братан, кышкы салкыннарда складларга барып, вагон бушату түгел инде, шулай бит! Абзаңа рәхмәт әйт, а то йөрисең шунда бүлмә саен теләнеп!

– Ну, анысы өчен зур рәхмәт инде, Ваня! Ничек дидең әле, ямьсез хатын-кызлар юк, тик аракының гына әз булуы бар! Ә безнең бүген барысына да җитәрлек сәмәнебез кулда! Мәҗлесне башлап җибәрер, сусауны басар өчен башта сыра, кыслалар алабыз, «Пивка для рывка!» дигәндәй, аннан аракыга күчәрбез, шуннан соң безгә бөтен матушкалар да матур булып күренәчәк! – дип, Малин заказ бирергә прилавка ягына кыланып атлап китте.

...Мәҗлес кызганнан-кыза барды. Институтта бик астыртын, хәйләкәр саналган Захарчукның да тезгеннәре йомшарды, һәрвакыт йозакта торкан авызы ачылды. Үзенең уй-хыялларын чәчеп сала башлады.

– Менә, братан, минем укып бетерергә ярты елым калып бара. Син мине булдыксыз, затсыз бер адәм заты дип уйлама. Кирәк булсамы, мин иң чибәр, иң горур студенткаларны да түшәгемә салам! Любоен! Ә инде матушкалар янына йөрүем мохтаҗлыктан гына ул! Безнең хәерче студент кызлардан нәрсә аласың! Әле бергә ятып йоклар өчен шәрабын, тортын, конфетын, колбасасын тыгып алып барырга кирәк! Карыйсың, стипендиядән җилләр искән! Шуннан соң яшәп кара инде менә син!

– Это точно! – дип җөпләде аны беркатлы иптәше. – Әйдә, шуның өчен салып куйыйк әле, братан, – дип, фужерын күтәрде. Тегесе аның кулын этеп:

– Аның өчен мин бүген мәңге эчмим! Күтәрсәм дә, яшь, чибәрләр өчен генә! Бигрәк тә бер курсистка өчен, – диде дә, бермәлгә уй-хыялларына кереп чумды. Малин гына түземсезләнеп:

– Кем соң инде ул, кем?! – дип төпченде.

– Ну, братан, сиңа гына сер итеп әйтәм, тик син башкаларга ни-ни! Аңладыңмы? – дип, исерек, алышынган күзләре белән Володяга текәлде. – Ну, синнән сүз чыкмый инде.

– Син нәрсә, братан, мин синең серләреңне башкаларга җиткерәмме инде?! Алла сакласын. Ант менә! – дип, Чиләбе малае чукынып ук алды.

– Исеңдә тот, братан, теге татарочка Әлмирә тиздән минеке булачак! Менә күрерсең! Теге юлы аның биегәнен күрдем дә исем-акылым китте.

Аның матурлыгы, аның сыгылмалылыклары төшләремә кереп йөдәтә. Берәрсе белән күзаллап, көнләшеп тә куям хәтта!

– Белмим, белмим, ул бик тәрбияле, горур кыз бит! Барып чыгар микән ул ниятең, белмим, белмим, братан. Ну, шулай да уңышлар сиңа!

– Син мине, «малина», әз беләсең икән әле! Шушы биш ел эчендә мин кемнәрне генә үземнеке итмәдем! Нindидер кыргый татарканы каратмасам, Иван Шустрый дигән кушаматым хәрәм булсын! Менә күрерсең! Әйдә шуның өчен!

Малин үзенекен эчеп, бушап калган фужерны өстәлгә куйды да:

– Карале, берсекөнгә бит беренче семестрны тәмамлау хөрмәтенә студентлар «Балтика» рестораныга бара! Әлмирәнең анда булуына 100 процент гарантия бирә алам! Бүлмәдәше Лиза әйтте.

– Бу шанс, братан! Димәк, анда барсалар, эчәчәкләр. Без һәр адымнарын күз алдында тотарга, кирәк икән, кыстый-кыстый тагын да күбрәк чөмерергә мәҗбүр итәргә тиеш. Калганы... калганымы, безнең эш! Такси, гостиница и так далее! Ул кыз өчен соңгы тиеннәрем дә кызганыч түгел!

– Ну син, Ваня, чыннан да Дон Жуан! Синең барысы да уйланылган, төгәл планың төзелгән! Ну, молодец! Синнән өйрәнергә дә өйрәнергә! Тик Әлмирә белән эшең барып чыгарына гына шикләнәм!

– Менә күрерсең! – дип, калайланган күзләре белән иптәшенә ачу белән акаеп карады тегесе.

– Ышанам да, тик белмим, бу чибәркәй сине кабул итәр микән?!

– Алайса, әйдә, бәхәсләшәбез, әгәр дә мин отсам, син миңа ике шешә коньяк куясың!

– Әгәр дә мин отсам, син миңа менә бу эстоннар теккән костюмыңны салып бирәсең, – дип, исерек Иванга үзенең таләбен куйды.

– Акылың алтын икән, беләсеңме, бу пиджакның бер ящик коньяк бәясе торганлыгын?

– Алайса, бәхәсләшмим, үзең бит әйдә дә әйдә, мин дә мин, дисең. Йә алай, йә болай инде, братан! – дип елмайды беркатлы Малин.

– Ярар, риза, җиңү барыбер минем якта булачак, – дип, кулын сузды елгыр егет.

***

Менә беренче сынау чоры да килеп җитте. Көтеп йөри торгач, үзенең төрле дөнья мәшәкатьләре белән ярты елга якын гомере узып та киткән икән. Үзенең ыгы-зыгылары, борчулары белән беренче курс студентлары тормышына да тәүге тапкыр кышкы сессия килеп керде. Кемдер көне-төне, күзләре кызарып беткәнче китаплардан хәреф чүплэде. Икенче берләре караңгы кичләрдә, лампа астында шпаргалка язды. Өченчеләренең исә дәрестә алган белемнәре дә яхшы билгеләренә сынау тотарга җитәрлек иде. Андый аз санлы шәкертләр арасында Казан чибәре Әлмирә дә бар.

Россия империясендә ювелирлык сәнгатенең үсешенә кагылышлы сорау эләкте аңа.

– Патша идарә иткән чорларда классик киеренкелек артканнан-арта бара. Гади халыкның яшәү шартлары начарлана. Дөньядагы иң көчле армиясе булган французларны Парижга хәтле куып, Наполеонның оясын туздырып

кайткан халыкның хәле нык мөшкелләнә. Үз илләре өчен борчылган Ватан сугышы геройлары, алдынгы карашлы дворяннар патшага каршы бунт күтәрәләр. Әлеге каршылык уңышсыз тәмамланса да, күпмедер дәрәҗәдә үзгәрешләр китерә. 1825 елның 14 декабрендә самодержавиегә каршы ачыктан-ачык кораллы чыгыш ясаган кешеләр кулга алына. Николай I фетнәчеләрне рәхимсез җәзалый: төп башлап йөрүчеләрне асарга, калганнарын Себергә һәм Кавказга сөрергә әмер бирә. Баш күтәргән өчен Кавказга күчерелгән Чернигов полкы хәрбиләре арасында Казан губернасы вәкилләре дә күп була. Мамадыш өязеннән Якуб Тимергалиев, Тәтеш өязеннән Ишмөгашит Биктимеров, Терентий Дурнаев, Ибраһим Мостаев, Лаеш өязеннән Фәйзулла Баязитовлар бар!

– Җитте, Әлмирә, икенче сорауга күч, монысына җитәрлек җавап бирдең, молодец, – дип мактап җибәрде яраткан укытучысы Елена Исааковна.

– Петроградта байлар өчен ачылган ювелир кибетләренең артуы белән бергә, шул байлыкларны таларга йөрүчеләр дә ишәя. Башкалада яшәүче каракларга читтән килгән зур тәҗрибәле мошенник, авантюристлар да өстәлә. Байлыгы сыгылып торган «Инглиз» кибетләре угрыларның күзен кыздыра. 1833 елны аларга хәрби офицер, курлянд дворяны Боуфель кул суза. Купшы киенеп, Николс белән Плинке тоткан магазинга килеп, үзен граф Ламсдорф дип таныта. Имеш, авыру хатыны өчен дип, ул заман өчен бик зур сумма булган дүрт меңлек товар сайлый. Шуны приказчик белән «Лондон» трактирына китерүләрен сорый. Товарны бик каты чирләп ятучы хатыныма күрсәтәм әле дип, бүлмәгә кереп китә дә тәрәзәдән чыгып кача. Тагын ике айдан шул ук юл белән корал урларга ниятләгәндә, корал сату кибетендә аны тотып алалар. Мондый хәлләр бик еш кабатланып тора, – дип, икенче сорауга җавап биреп бетермәстән, укытучысы аны туктатып, «Зачёт!» – дип, кызның белеменә бәя дә куйды.

Әлмирә башка фәннәрдән дә имтиханнарын уңышлы тапшырып, каникулга кайтырга җыена башлады.

Ике көннән, Аллаһы Тәгалә насыйп итсә, ул поездга утырып, туган каласына омтылачак. Әти-әнисе, абыйсы белән күрешү мизгелләрен күз алдына китереп, аның йөрәге ашкынып типте. Караватына ятып, күзләрен йомса, пөхтәлек, илаһилык ташып торган фатирлары исенә төшә. Хуш исләр чыгарып, татар ашлары пешереп яткан әнисенең: «Әйдә, кызым, яңа пешкән коймак белән тәмләп чәй эчеп алабыз!» дип чакырулары күз алдына килә. Дәү әнисе, Таллы күле исенә төшеп, сагынудан күзләренә яшь тула. Дәү әнисе дә: «Бик сагындым, балам, татлы балым минем», – дип, ай саен хат язып сала. Әбисеннән күрше Исрафил абый ни хәлләрдә, дип сорар иде, ояла. Ә шулай да нишләптер күрше егетен дә күрәсе, иптәш кызлары белән дә очрашасы килә. Кайчагында күз алдына мотоцикл белән мәтәлеп китеп, пычрак сөреп шуып барган чакларын, беренче тапкыр алсу иреннәрен егет кеше иренենә тидереп алуын искә төшереп, кыз татлы хыялларына чума. Исрафил абыйсы аны көчле куллары белән күтәреп алып, чишмә буена алып төшкән мизгелләрен кабат күңелендә барлый. Кара бөдрә чәчле, урта буйлы, нык бәдәнле күрше егетен алыштырырлык ирләрне очратмады әле ул. Аның белән ут җимертеп, татарча биегән чечен бөркете Аслан Мөхәммәтовны гына чагыштырсаң инде. Икесе дә каратут чырайлы, икесе дә шомырт кара

бөдрә чәчле, көч-гайрәтләре ташып тора. Ләкин ул егетнең иптәшләреннән Грозныйда ярәшкән кызы барлыгын ишетеп белә. Өстәвенә, бүлмәдәш, сердәш, дус кызы Лиза да әлеге ут кебек егеткә гашыйк булып йөри.

Сүз катып караучылар җитәрлек анысы Әлмирәгә дә. Яңа ел бәйрәмендә бөтен сылулыгын, тал кебек сыгылмалы гәүдәсен күрүләре булды, әле берсе килеп – киногa, әле икенчесе килеп ресторанга чакырып аптыратты. Әрсезрәкләре оятларын югалтып, үзләре белән каядыр кунача барырга да өндәп маташтылар. Андыйларына җавап та биреп тормады гүзәл кыз!

Ә бер кичне алар ишеген пөхтә генә киенгән бер адәм заты шакыды. «Әйе, керегез!» дигәч, ул түрдән үтте.

– Гафу итегез, мин Николай, өченче курста укыйм. Яңа ел бәйрәмендә Сезнең биюегезне күреп сокланган идем. Өстәвенә, якташым да икәнсез!

– Сез дә Казаннанмы әллә?! – дип шатланды Әлмирә.

– Арчадан мин! Исемем Николай!

– Мин бик шат, Николай! Гафу итегез, әтиегезнең исемен белмим! – диде кыз.

Николай бермәлгә бу сораудан югалыбрак калды. Нәрсәдәндер шикләнгәндәй, бүлмә эчен күзәтеп алды. Шуннан соң гына, Николай Нәсихович дип пышылдады.

– Әллә сез дә татармы? – дип сөенде Әлмирә.

– Әйе, – диде, күзләрен туры караудан яшергән ир.

– Нишләп алайса исемегез Николай?

– Наил атлы идем мин, биредә артык игътибар итмәсеннәр дип, Николайга алыштырдым, – диде ул, авыр сулап.

– Нишләп? Наил менә дигән матур исем бит? Минем әле туганнан туган энем дә шул атлы, – дип аптырады сәерсенеп калган кыз.

– Бәйләнергә сәбәп булмасын өчен фамилияне дә Кадыйровтан Константиновка күчердем!

– Нигә?! – дип, Әлмирә берни аңламыйча озын керфекле күзләрен челт-челт йомгалады.

– Татар икәнлегемне белмәсеннәр өчен, – дип шаккатырды Әлмирәне әлеге сәер Арча бәндәсе.

– Белсәләр соң! Шуннан ни була! Менә мин горурланам үземнең татар кызы булуым белән! Әйдә, рәхәтләнеп татарча сөйләшәбез, Наил Нәсих улы! Арчада туганнарыгыз бармы соң? – дип авыз тутырып, күрше бүлмәдәгеләргә дә ишетелерлек итеп татарча сорады Әлмирә.

– Ярыймы, сезнең белән икенче юлы, аулаграк җирдә күрешәбез?! Уңайсыз ничектер, ишетсәләр, нәрсә уйламаслар!

– Уйласыннар! Болар чын татарлар икән дип уйласыннар! Аның яхшылары беркайчан да башкаларны кимсетмәс!

– Ярый, ярый, мин чыгыйм әле, икенче юлы күрешкәч, яме, – дип чыгып китте бу кыюсыз егет. Кыз гына нәрсә булды соң әле бу дип аптырап калды. «Үзе татар, үзе татар булуыннан курка, Аллаһы Тәгалә, әти-әнисе бүләк иткән исемен читләрнекенә алыштырган. Сәер!»

Үзе чибәр генә тагын, пөхтә киенгән булса да, мондый адәм кирәкми аңа. Каян килеп бу мәхлук ут кебек чечен Асланга, күрше егете, курку белмәс Исрафил абыйсына җитсен, ди! Үз күләгәсеннән үзе өркеп йөри торган бәндә түгелме соң?! Мондый ир аны мәңге яклый да, саклый да алмаячак!

* * *

Кышкы каникулга туган ягы Казанга кайтырга нибары ике генә көн калды. Поезд билетлары күптән алынган, үз вакытларын көтеп чемодан кесәсендә саклана. Вакыт-вакыт ул аларны кулына алып, кадерле бер ядкарьне назлагандай сыйпаштыра, шатланып үбеп куя. Әлеге кәгазь кисәге әти-әнисе, абыйсы, апасы, әбисе белән күрештерәчәк бит аны! Алар назына мохтаҗ кызның күзләре дымлана. Каршысына кабат туганнары килеп баса, шунда ук барысын да кочаклап ала да: «Кадерлеләрем!» дип эндәшә. Ничек сагынган икән бит ул шушы ярты ел эчендә үзенең якыннарын. Ярый әле ике арада сәлам хатлары йөреп торды, ярый әле вакыт-вакыт заказ биреп телефоннан сөйләшеп аралаштылар. Бик еш гәпләшеп тә булмый бит, һәр минуты өчен түләргә кирәк; чәнчелеп китмәгәе, тик Әлмирә аерыла алмыйча сөйләшә дә сөйләшә. «Тагын ун минутка озайтыгыз әле!» – дип, коммутаторга кычкыра. Студент халкының болай да санаулы акчаларын ашый гына чыбыклы элемтә. Шунлыктан АТСка еш йөрергә сәмәннәре калмый. Кайчагында иптәш кызларыннан бурычка сорап тора. Баштарак теләнергә уңайсызлана, ояла иде. Биредә алып-биреп тору гадәти хәл икәнлеген аңлагач, оялуын җиңеп, алгалый башлады. Соравын сорыйсың, тик биреп торучылары сирәк табыла. Бирүен бирер дә, кайберәүләр кебек кире кайтармаса. Шуңа күрә студентларның иң байлары да акчаларын чыгарып салырга ашыкмыйлар. «Юк шул! Яңа гына тегене, моны алган идем!» – дип, кире кагалар. Әмма Әлмирә вакытында кайтаруын, өстәвенә берәр кап шоколад йә булмаса конфет та өстәп биргәнен күреп, үтенечен җавапсыз калдырмыйлар иде. Шулай да Әлмирә сылуның хәле күпләрнекенә караганда да яхшырак. Йә абыйсы, йә әти-әнисе, хәтта ай саен ук булмаса да, кадерле дәү әнисе дә почта аша акча сала. Татарлар әйтмешли, акмаса да тамгалап тора. Йә кып-кызыл унлык, йә Ленин бабай башы төшерелгән егерме бишлек Ленинград каласына юл ала. Шундук бурычларын да түли кыз, калганнарын азык-төлек, вак-төяккә тотып бетерә. Дөге, карабодай, токмач, тушёнка, консервылар белән запас туплап куя. Үзе генә дә түгел, иптәш кызлары белән бергәләп туплыйлар. Бер мәлне әлеге тупланган запасларына сокланып, ул:

– Әй-ли, кызлар, күпме җыелган малыбыз, ничек ашап бетерербез?! – дигән иде, шаян Лиза аңа:

– Ә сугыш башланса?! – дип әйтеп куйды. Әлмирә аптырап: «Нинди сугыш тагын, Лиза, бәгърем, сугыш беткәнгә инде...» – дип куйды беркатлыланып.

Ахирәте рәхәтләнеп көлде үзеннән.

– Була гына күрмәсен инде, Лиза, Аллам сакласын!

Бүген дә Лиза дусты аны көне буе беренче семестр тәмамлануы уңаеннан үзе белән «Балтика» ресторанына барырга өндәде:

– Син белмисең генә, ничек кавказ ашларын хәзерлиләр анда, телеңне йотарсың! Өстәвенә заманча музыка уйнап тора. Язучылар, рәссамнар, артистлар да килә, хәтта! – дип, ярты сәгать буе үгетләде. Нинди затлы хашламалар, пылаулар, чөгә балыгыннан әзерләнгән шулпалар турында тәмләп-тәмләп сөйләде...

Яратмый иде ул шау-шулы, ыгы-зыгылы, салмыш адәмнәр белән тулган җирләрне. Күңеленә, рухына, тәрбиясенә һич кенә дә хуш килми Әлмирәнең акырыша-бакырыша, мактаныша торган урыннар. Чәрелдәп көлгән җилбәзәк хатын-кызлар, шулар алдында бөркет булып күренергә тырышкан, йөзәр, меңәр сумнарын бер кичтә туздырып җилгә ыргыта торган ир затлары белән тулган урыннарны Ленинградка килгәч тә, ерактан әйләнеп узарга тырышты. Әнчек чәчбикәләр алдында зурдан күренергә тырышкан адәм затларыннан гына да түгел, әлеге тәүфыйксыз һавага мәңге ияләшә алмаячагын белә иде ул.

Туган шәһәре Казанда да абыйсы: «Әйдә, банкетка алып барам, хет республика интеллигенциясен якыннан күреп кайтырсың!» – дип чакыргач, бер тапкыр теләр-теләмәс кенә ияреп, «Таң» ресторанына барган иде. Ә анда күренекле рәссам Ифрат Илшатовичның юбилей кичәсе икән. Кемнәр генә юк иде биредә. Күренекле язучылар дисеңме, араларында яшь бәрән йонын хәтерләткән бөдрә чәчле, итләч калмык битле, көр тавышлы Туфан Миңнуллин да бар; артистлардан җирән чәчле, сипкелле, тик шулай да сөйкемле Шәүкәт агасын да шундук танып алды ул. Ничек инде шундый киңкырлы талантларны танып белмәсен, ди?! Шәүкәт Биктимеров Әхмәт абыйсы белән күрешеп, сәлам бирешеп киткәндә, Әлмирәгә күз салып:

– Әй, малай, бигрәк чибәр икән сеңелкәең, кайда калды икән соң минем унсигез яшем! Бәхетле бул, матурым, – дип, авызын тутырып елмайган иде. Аны шундук татар байлары уратып алып, үзләренең өстәленә кыстый башладылар, кайберләре фотога төшәргә үтенделәр. Ул да түгел, бар халыкның игътибарын алып, төп ишектән Әлфия Авзалова белән Илһам Шакиров пәйда булды. Әлеге дә баягы, әрсезрәк кунакларның күбесе Шәүкәт абыйны шундук онытып, яңа килүчеләр ягына ыргылдылар. Күренекле артист кына көрсенеп тә, шаяртып та:

– Әй, малай, зур талантлар магнит кебек үзенә тарта шул инде! – дип куйды.

Татар халкын моңга күмгән артистларны сүз белән йолыккалый да башладылар. Кайсыларыдыр бүген юбиляр хөрмәтенә җырласагыз иде, кемнәрдер бергә фотога төшсәк иде, дисә, бер юантык, купшы киенгән, чәчен печән кибәне кебек баш очына өйгән, якты утта бармакларындагы алтын йөзекләре ялтыраган әрсезрәк ханым:

– Илһам, миңа ике кешегә филармониядә булачак концертыңа контрамарка бир әле, югыйсә мин директорлык иткән кибеткә үзең гел колбаса сорап керәсең бит! – дип, халыкның игътибарын үзенә юнәлтеп, кеткелдәп көлеп җибәрде. Илһам абыйсы әлеге әрсез симез хатынга бик исе китмичә генә:

– Мин бит колбасаны акча түләп алам, ә сез минем концертка бушлай кермәкче буласыз! – диде.

– Соң, ярар инде, гомергә бер мәртәбә контрамарка сорадым, килгәндә дә тегесен-монысын, коньягын тыгып киләм бит мин, концерттан соң рәхәтләнеп сыйланырбыз икәүләп! – дип чәрелдәде. Бу сүзләргә җырчы абыйсы җавап бирергә өлгермәде, каяндыр килеп чыккан Галиәсгар Камал театрының баш режиссёры Марсель Сәлимҗанов:

– Ялыктырмагыз әле юк-бар белән безнең даһи сайрар кошларыбызны. Илһам, Әлфия, әйдәгез, минем арттан! – дип, кунакларны үзе белән ияртеп алып китте. Кибетче хатын күзләрендә усал чаткылар уйнатып, калын иреннәрен бөрештереп:

– Колбаса сорап кермәссез микән әле! Менә Шәүкәт абый килсә, аңа күчтәнәчкә бушлай бирәм, – диде дә аның янына барырга җыена башлаган иде, шунда кабат Марсель Сәлимҗанов пәйда булып:

– Шәүкәт, синең урын биредә түгел бит инде, уз төп өстәлгә, әнә Туфаннан үрнәк ал, әллә кайчан түргә кереп утырды! – дип, аны орышып алды.

– Шулай дисеңме? Ярый алайса, Марсель хәтле Марсель чакыргач, бернишләп тә булмый! – дип, түргә атлады артист. Сатучы хатын гына яңа объект эзләп: «Сөйләшер кеше дә калмады!» – дип куйды. Кеше алдында бәясе төшкән симезкәйне әйләнә-тирәдәгеләр күрмәмешкә салышып, йөзләрен яшерделәр.

Беркатлы үсмер кыз Әлмирә шаклар катып күзәтте биредәге чуар халыкны. Тост артыннан тостлар әйтелде, мактау сүзләре яңгырады, бүләкләр дә мулдан яуды. Барысы да җыр-биюләр белән аралашып барды.

Кемдер коньяк, кайсыларыдыр шәраб, күпчелеге ак аракы белән һәр чыгышны җөпләп куя барды. Мәҗлес кызганнан-кыза, өстәлдәге ризыклар кимегәннән-кими, аның саен маҗара эзләп буталып йөрүчеләр ишәя, әлли-хөлли генә иҗатлары булган, шулай да элита арасына керергә хыялланган уртакул сәнгатькәрләр, үзләренә игътибар җитмәү сәбәпле, тезгеннән ычкына баралар иде. Ниндидер иҗади темаларга бәхәсләр кузгатып, акырып-бакырып, белдекле булып кыланалар. Берсе әнә кондициягә җитте, татарда король Лирны үзе генә уйный алганлыгын, Әлдермештән Әлмәндәрдәге карт роленең Шәүкәт Биктимеровка дөрес бирелмәгәнлеген, имеш, ул әлеге образны ачып бетерә алмаганлыгын дәлилли башлады.

– Шәүкәткә ул роль, гомумән, килешми. Аны йә миңа, йә Роберт Әбүлмәнбетовка бирергә кирәк иде. Үзе сары, үзе сипкелле сала мыжыгына шундый җаваплы эшне тапшыралар диме инде?

– Ну, зато Шәүкәт абый искитмәле итеп уйнап чыкты. Аның бит тавышы да, йөреше, килеш-килбәте дә чын ирләрнеке! – дип китереп сылады тегеңә опера һәм балет театры артисты Рафаэль Сәхәбиев. Тегенең исерек күзләре орбитасыннан атылып китәрдәй булып акаеп чыкты.

– Син мине, мине мыскыл итәсеңме? Әле иҗатка алдың кереп, артың кереп җитмәгән килеш? Иртәгә үк оперныйдан кудырам, судка бирәм мин сине! Ул мине, җәмәгать, «зәңгәр» диеп мыскыл итте! – дип акырырга ук тотынды. Бу хәлгә түземлеге бетеп, ахрысы, кабат олпат гәүдәле Марсель Сәлимҗанов пәйда булды.

– Хәзер үк, Фирдияз абый, өегезгә кайтып китегез, пешүегез җиткән, ни сөйләгәнегезне белмисез!

– Мин бит, Марсель Хәкимович, ул бит... – дип, теге нидер әйтергә тырышып маташкан иде.

– Йә иртәгә эштән китәргә дигән гариза кыстырып кил, аңладыңмы?

Теге мескен җиргә сеңеп куйды.

– Аңладым, аңладым, Хәкимович, хәзер үк өйгә таям, – дигәч, Сәхәбиевкә тагын бер нәфрәт белән карап алды да борылып, гәүдәсен горур тотарга тырышып чыгып китте.

– Рафаэль, ник котыртасың шул самодурларны! Күрмисеңмени, башы киткән!

– Гафу ит, Марсель абый! Рәтләп белми идем мин аны!

– Аннан киләсе атнада кереп чык әле! Бәлкем, безгә күчәрсең, җырчы артистларым җитми! – дип пышылдады Хәкимеч, Рафаэль ишетерлек кенә итеп.

– Яхшы, Марсель абый, уйлап карармын, – дигән җавапны ишеткән режиссёр китеп барды.

Мәҗлес дәвам итте, ул сузылганнан-сузылды. Баштарак кызык тоелган әлеге кичә, озынлыгы, шау-шуы белән үсмер кызның күңеленә тия башлады. «Әллә кайтып китикме, абый?» дип әйтергә дә уңайсызланды. Янәшәдәге өстәлдәгеләргә теләр-теләмәс кенә колак салды. Тезгеннәре сыегайган ике ир-ат, бик белемле булып күренергә тырышып, тема табып бәхәсләшәләр. Көдрә, сары пумала башлысы, Мәскәүдә белем алып, «Кристалл» сулары чөмереп кайткан ямьсез генә бер адәм, Нурулла дигән табындашы белән иҗат эшенә кереп чумдылар.

– Нурул, син бит Станиславский системасының «С» хәрефен дә белмисең, шуңа күрә дә сәхнәдәге бөтен уеның ясалмалыктан тора. Ә беләсең килсә, бу система тормыш чынбарлыгын чагылдыруга корылган. Актёр образга кереп, үз каһарманының тормышы белән яшәргә тиеш!

Нурулла дигәненә зәм-зәм сулары тәэсир иткән, күрәсең, бите тимгел-тимгел бүртеп чыкты, ачу белән:

– Сезнең ул Станиславский мәктәбен куып таратырга кирәк, искергән галәмәт ул. Мейерхольд юнәлеше иҗади яктан дөресрәк, актёр сәхнәдә яшәп маташырга түгел, ә героеның тормышын уйнап кына күрсәтергә тиеш. Аңладыңмы, җаным?! Мәскәүдә укып кайткан буласыз да, биредә аннан акыл сатасыз! – дип чәпчеде.

Әлмирәгә бер дә кызык түгел иде аларның сөйләшүе. Аңа Станиславский системасы да, Мейерхольд мәктәбе дә таныш түгел. Бернәрсә дә төшенә алмады. Менә Шишкин, йә булмаса Репин иҗаты турында сөйләшсәләр, нәрсә дә булса аңлар иде. Биредәге тавыш аның башына каба башлады. Ул да түгел, бию музыкасын куйдылар.

Озак та үтмәде, ике ир кеше, эткәләшә-төртешә, үгезләр кебек сөзешергә тотынды. Берсе икенчесенең хатынын биергә чакырып, арт санын кабаларга керешкән, чәчбикәгә бу хәл ошаганмы-юкмы, билгесез, ләкин кемдер бу хәлне шундук иренә җиткергән. Аларны гына аралап алулары булды, вестибюльдә шофёрлар белән сәхнә эшчеләре арасында низаг килеп чыгып, тукмаклашырга ук тотынганнар. Эш тирәнгә китәргә җыенганын күреп, милиция хезмәткәрләре килеп чыгып, өч адәмне үзләре белән алып киттеләр. Тагын нинди галәмәтләр килеп чыккан булыр иде, абыйсы Әлмирәне шок хәлендә күреп: «Бүгенгә җитеп торыр, әйдә, сеңлем, кайтабыз!» – дип, ишеккә юнәлде.

* * *

Менә бүген дә аның «Балтика» ресторанына бер генә дә аяк атлыйсы килми.

– Озак утырмабыз, югыйсә бөтен студент халкы ял иткәндә, без генә калсак, кыланчыклар, дип үртәячәкләр, әллә кем булып калмыйк әле, дустым! – дип үгетли торгач:

– Тик озакка түгел, яме! – дип ризалашты Әлмирә.

Шулай уйланып, икеләнеп утырганда, ишекне шакып та тормыйча өченче курста укучы удмурт кызы Юля Камаева килеп керде. Керә-керешкә:

– Яле, дустым, биеп җибәр әле, сиңа бүген ике хат бар, әгәр дә тыпырдамасаң, бирмичә интектерәм! – дип, авызын шар ерып, таләп куйды.

– Ярар инде, Юля, тилмертмә! – дип, эченә шатлык йөгерсә дә биергә ашыкмады Әлмирә.

– Әйдә, әйдә, чибәркәй, югыйсә, егетләрдән килгән сәлам хатыңны мәңге бирмим, – дип котырткач, ул йомшак кына басып, иңнәрен чайкый-чайкый биеп китте.

Хатларның берсе авылдан дәү әнисеннән иде, икенчесе – менә сиңа мә, сюрприз, Исрафил абыйсыннан! Адресын аңа дәү әнисе биргәндер инде. Кыз иң башлап, кайсын ачып укыйм икән инде дип аптырап калды. Дәү әнисенең язмасы сагыш-сагынудан торганы билгеле иде. Ә менә Исрафил күршеләре нинди сүзләр тезде икән?!

«Сәлам, күрше кызы Әлмирә! Бу хат, бәлкем, синең өчен көтелмәгәнрәк тә булыр. Ләкин мин сине совет армиясе сафларында хезмәт иткәндә дә, инде кайтып, институтка укырга кергәч тә оныта алмадым. Сагыну хисләре белән тулган хатларымны язсам да, җибәрергә кыюлыгым җитмәде. Ә көннәрдән бер көнне дәү әниең: «Сез Әлмирә белән хәбәрләшәсезме соң?» – дип сорагач, сискәнеп киттем. «Юк», – дип әйткән идем, «Кыз баланы яратсаң, һәр көнне дөньяда барлыгыңны белгертеп тор, билгесезлек өметне җимерә ул», – дип кисәтте. Инде менә бар кыюлыгымны җыеп, сиңа сәламнәремне юллыйм! Үзеңнән дә сәлам хатлары көтеп калам. Әлбәттә, бер күрешеп аңлашсак, тагын да бәхетлерәк булыр идем. Теләсәң, вакыт табып, Ленинградка да килеп китә алам! Сине чын күңелдән яратып, күрше абыең Исрафил!»

Әлмирәнең йөрәге дулкынланып тибә башлады. Исрафил абыйсы онытмаган икән бит аны, онытмаган!

Кызның алма кебек алланып, тулып торган бите буйлап яшь бөртекләре тәгәрәде. Болар – шатлык тамчылары иде.

Ул күзләрен йомып, күңелендә үткәннәрне җанландырды. Менә дәү әнисе мич тирәсендә кайнаша, бүлмәгә тәмле исләр тарала. Шул арада чыгып, сыерына су эчертеп, савып та керә. Ул да түгел, килеп, бәбкәченең өстендәге юрганын төзәтеп китә... Исрафил абыйсы... Менә алар матайда очалар. Таеп китеп, яңгыр ясаган боламыкта шуып баралар. Күрше егете коты очып, аны күтәреп ала. Салкын чишмә суында юыналар. Кыз үзенең тулып торган алсу иреннәре белән аны үбәргә үрелә. Кич белән Исрафил аны танцыга чакыра. Аларның биегәнен кыз-кыркын астыртын гына көнләшеп күзәтә...

***

Борчаклы урамы буйлап елга ягына төшсәң, «Балтика» рестораны каршысына килеп чыгасың. Бу Ленинградның аксөякләр катламы яши торган эшмәкәрләр дөньясы. Урам буйлап сине кыйммәтле кибет-салоннар, бакалеялар, әзер кием-салым кибетләре, банклар, төрле эчемлекләр сатыла торган эреле-ваклы кафелар озата бара. Шуннан автобус станциясе дә ерак түгел. Урамның як-ягына борынгы тарихи йортлар тезелгән. Ике ягына да утыртылган имән, нарат, чыршы агачлары тәртип белән сузылган һәм алар сине урам чатына хәтле озата бара. Вакыт-вакыт елга буеннан сузып-сузып, пароходлар һәм хәрби су корабларының сәлам биреп кычкыртуларын да ишетергә туры килә. Бу тирәдә маҗара эзләп йөрүче, сәрхуш моряклар да җитәрлек. Кайчагында шуларны ауларга өерләре белән хатын-кызлары да йөри. Ә кем белә, бәлки берәр тельняшкалы хатынлыкка алып куймасмы?! Әтәчрәк, тәҗрибәсез, мактанчык диңгезчеләрне ияләштерү кыен түгел аларга! Соңгы арада якынлашып-аралашып киткән вахтёр түтәй Вера Андреевна да кисәтә Әлмирәне. «Кызым, ул тирәләрдә ялгызың йөри күрмә! Үткән елны пединститутта укучы бер ачык авыз кызны моряклар тотып көчләгән. Анда кызлар өчен солдатлар белән моряклар гел сугышып, ызгышып торалар! Аң бул, балам!» – ди.

Бер ярты ай электер инде Вера түтәсе аннан:

– Син, кызым, Казаннан булгач, татардыр инде? – дип сорады.

– Әйе, Вера түтәй!

– Элек мин татарларны кысык күзле, кәкре аяклы, ярты чакрымнан ат исе килеп тора торган вәхшиләр итеп күз алдына китерә идем. Үзебезнең йортта торган Агзам Хамзович белән хатыны Хәтирә апайларны да өнәмичә, әйләнеп уза идем. Нишлим соң, шулай укыттылар, шулай өйрәттеләр! – диде. – Үзеңә генә бер алар турында иркенләп сөйләрмен әле, – дип тә өстәде.

Вакыт-вакыт дәү әнисеннән, әти-әнисеннән посылка килсә, ул игътибарлы Вера түтәенә дә күчтәнәчләр биргәләде. Йә әбисе җибәргән корт белән атланмайдан, ысланган иттән өлеш чыгарды. Кайчагында казылыктан авыз иттерде. Өлкән түтәенә бигрәк тә гәрәбәдәй сары атланмай белән сөтле-эремчектән ясалган корт ошады: «Йөрәгемә шифа булып ята, балакаем, ошбу ризыкларыгыз», – дип, рәхмәтләрен җиткерә килде. Ә көннәрнең берендә Ленинград блокадасының бөтен фаҗигаләрен күргән, аны саклаганда, ирен югалткан апасы чирләп китте. Вахтада утырганда, бертуктаусыз йөткерә иде. Тәне кызышканлыгы да сизелә.

– Вера апа, сез бит салкын тидергәнсез, кайтып дәваланырга кирәк, – дип борчылды кыз.

– Юк, юк, кызым, без әллә нинди салкыннарны күргән, әллә нинди җил-бураннарны да җиңеп чыныккан адәмнәр, менә дежурствомны иртәгә иртән тапшырам да кайтып ятармын, – дип карышты. Ләкин хәле начарланганнан-начарлана бара иде. Шуны күреп, ахирәте Лиза белән киңәшкәч, блокада әбисен өенә кайтарып җибәреп, чиратлашып үзләре дежурга җигелергә булдылар. Комендант белән дә сөйләшеп килешенгәч кенә, ул өлкән апаларына өенә кайтырга ризалык бирде. Китәр алдыннан Әлмирә аңа кечерәк кенә бер төргәк сузды.

– Вера түтәй, менә монда киптерелгән кура җиләге, юкә чәчәге, термоска берәр аш кашыгы салып пешерегез дә бал белән эчегез! Соңыннан бик каты тирләячәксез, тормагыз, төренеп ятыгыз, түзегез! Ике-өч көннән аякка басасыз! – дип озатып калды. Ярый әле дәү әнисе бар. Бәбкәчем салкын тидереп чирли калса дип кайгыртып, дару үләннәре җибәреп ята. «Менә бүген кирәге чыкты да куйды», дип сөенде ул.

Ике көн дә үтмәгәндер, аны вахтадагы телефонга чакыртып алдылар. Кем булыр икән дип төшсә, Вера түтәе икән. «Кызым, бик зур рәхмәт кипкән кура җиләге белән дару үләнеңә! Ике көн буена бөтен ятагым лычма су булды, хәтта йөзәргә дә мөмкин! Бүген Ходайның биргәненә шөкер, аякка бастым, әкертен генә йөрештерәм! Чәен дә үз кулларым белән куеп эчтем, бүген әле менә ит салып, аш та куеп җибәрдем. Болай булгач, рәтләнәм инде, балам! – диде. – Тагын ни бит әле, кызым, берсекөнгә кунакка килеп чык әле, сөйлисе сүзләрем дә күп, ул арада тулысынча терелеп тә бетәчәкмен. Тик бик соңга калып йөрмә, дәресләрең бетүгә туп-туры безгә кил», – дип, сүзен тәмамлады.

«Нигә чакыра икән, нинди сөйлисе сүзләре бар икән?» дип аптырап калды Әлмирә.

Вера түтәсе ай кебек елмаеп, ромашка төшерелгән матур зәңгәр күлмәкләрен киеп каршы алды. Бик якын кешесен күргәндәй, якын итеп, кочагына алып:

– Әй, матуркаем, килдеңме?! – дип, иркәләп аркасыннан сөйде. Яшь кызга дәү әнисе назлагандай тоелды. Борынына да кадерле дә, таныш та булган тәмле ис килеп тулды.

– Әй, нинди татлы исләр чыгаргансың, Вера түтәй! – дип әйтеп куйды Әлмирә.

– Син килә дип, кызым, кичә улым Викторга шалтыраттым. Мәйтәм, «Яраткан балам килә, тиз генә яхшы сыйфатлы куй ите табып китер әле, «Восточный» базарында үзбәкләрдән ал, ул халыкта бәрәкәтле дә, чиста да була!» – дип әйттем. Шуннан менә сезнең милли ризыгыгыз пәрәмәчне пешердем! Ничек килеп чыккандыр, белмим, дөресен син генә әйтә аласың, Әлмирә! Әйдәле, әйдә, залга уз, ризыкларым суына! – дип, кызның өстен салдырыша башлады.

– Ай-яй, Вера Андреевна, искитмәле тәмле итеп пешергәнсез! Моны бит шул дәрәҗәдә кайбер татарлар да әзерли алмый, – дип шаккатты кыз. – Авызда эреп китә!

– Аның, кызым, үзенең бер тарихы бар! Шуны да сөйләрмен, дигән идем, чөнки безнең буынның санаулы гына көннәре калып бара!

– Юкны сөйләмәгез әле, Вера Андреевна!

– Шулай-шулай, кызым! Җитмешне узгач, һәр сәгатен, хәтта минутыңны да саныйсың икән ул! Эш анда да түгел! Минем сөйлисе сүзләрем сез – татарларым турында!

– Әйе, Вера түтәй! – дип, Әлмирә гаҗәпләнеп, игътибарын аңа юнәлтте.

Хуҗа ханымның күзләре уйчанланды, җыерчыклы битләрен сагыш басты. Ни сәбәпледер, күзләреннән яшьләре чыгып, түбән тәгәрәде. Кунак кызыннан уңайсызланып: «Хәзер кызым, хәзер үтә ул!» – дип, урыныннан торып, тәрәзә янына китте.

– Зинһар, борчылмагыз инде, Вера Андреевна!

– Хәзер, хәзер, кызым, хәзер үтә ул! Гомер узган саен язмыш коточкыч авырлыклар күрсәтсә дә, яшьлекне сагыну көчәя генә бара икән, балам! Менә бүген дә күңелем тулып, үпкәләрем кысылды! Хәзер үтә ул, үтә, – дип, Вера ханым күз яшьләрен кулъяулыгына сөрткәләде дә кире килеп, стакандагы компотын йотып куйды. Күзләре уянып, ачылып киткәндәй булды. – Сугыш башлануга иремне Ленинград оборонасына җибәрделәр, алай да кайткалап йөри, үзе белән «коры паек»ларын да җыеп, миңа алып кайта. Шуңа карамастан, яшәүләре көннән-көн начарлана. Карточка-талонга бирелгән ипинең нормасын киметкәннән-киметәләр. Әле аны алырга да сәгатьләр буе чират торырга кирәк.

1942 елның февралендә иремнең үле хәбәре килде. Бомба астында калып, бөтен взводлары кырылган. Йөри торгач, ире фронтта үлгән дип, өстәмә ипи дә бирә башладылар. Ул да тамак туйдырырга җитми. Бер яшьлек улым Викторга күбрәк өлеш чыгарырга омтылам! Алтын балдагым белән алтын йөзегемә хәтле кишер, кәбестә, кызыл чөгендергә алмаштырдым, сабыема витаминнар керсен, дим. Шундый хәерсез көннәрнең берсендә карточкаларымны алып, ипигә киттем. Юл сумкамны култык астыма кысып тоттым да каршы бәргән буранны ерып, көчкә атлыйм! Күпме барганмындыр, арттан китереп тондырдылар да, һушымнан язганмын. Ярый әле, үтереп үк китмәгәннәр, аңыма килсәм, айлык паек кәгазьләремнән җилләр искән. Иске кул сумкам гына кырыйда ята. Бу инде ач үлемгә тиң! Көчкә өй ягына атлыйм! Улым Викторыма нәрсә ашатырмын дип сыкрыйм! Үзебезнең ишегалдына кайтып җитеп ауганмын. Минем бәхеткә, Агзам Хамзович күреп алган! Аңыма килсәм, үзебезнең фатирда, үземнең ятагымда ятам, улым исә идәндә агачтан ясалган машинасы белән дырылдый. Шулай итеп, тамагы тук бала гына уйный ала. Үземнең башым үтерердәй чатный. Шулай да авыртуымны җиңеп, боргаланам, ни күрәм, креслода йокымсырап, берәү утыра, бүлмәгә тәмле аш исләре таралган! Кем соң бу?! – дип аптырыйм. Караватн шыгырдаганга, ахрысы, йокымсырап утырган кеше дә уянып бетте. «Вера, хәлләрең ничек соң? Сине бит Агзам абыең яралы килеш ишегалдыннан алып керде, башыңны бәйләдек, ләкин барыбер врачларга күрсәтергә кирәк! Хәбәр иттек, килерләр, бәлкем», – ди.

Минем коткаручыларым, мин өнәмәгән, күрмәмешкә салышып йөргән күршедәге татарларым булып чыкты. Элегрәк бит стена аша Агзам Хамзовичның баянда уйнап җырлаганы ишетелсә, шуның хәтле противный булып тоела иде миңа. «Нәрсә шыңшый соң ул, дөньяны сагышка батырып?» – дип сүгә идем. Без бит ияләшкән: «Оппа-асса карама, эчә торган замана!» дип, мәнсез җырлар уларга. Соңыннан гына сезнең көйләрегездә тарих тирәнлеге, сагыш-кайгыларның буыннан-буынга тапшырылып барганлыгын аңладым, – дигәч, Вера түтәсе моңсуланып калды. Әлмирә хуҗабикәне, сүзен үз җаена дәвам итүен теләп, сорау биреп ашыктырмады. – Шуннан, кызым, кычкырып-кычкырып елый башладым. Миңа ияреп, Викторым үкси. «Ничек яшәрбез соң хәзер, паек талоннарсыз?! Коткармаска кирәк иде, хәзер карап торып, улымның үлемен күрәчәкмен, – дип акырам. «Тынычлан, Вера, карап торып ачтан үтермәбез! Агзам абыең талоннар мәсьәләсен түрәләр белән җайлап карармын, диде. Син

тикшерүчеләр килгәч, барысын да сөйлә! Борчылма, үзебез исән булганда, сезгә дә аяк сузарга ирек бирмәбез», – диде күршем. Шулай дигәч, Вера ханымның күзләреннән кабат әрнү яшьләре коелды. Иреннәренә төшкән тамчыларны йота-йота сүзен дәвам итте. – Мин йөз чөергән, өнәмәгән татарлар ярдәм кулы суздылар. Яхшылап карасам, күзләре дә кысык түгел, аяклары да төп-төзләр икән. Җырларында көй түгел, җан агыла икән! Җан! Бик күп яралар, газаплар күргән бөек халыкның җаны агыла икән. Ләкин әле боларны аңлар өчен, ялганнан арынып өчен миңа Гумилёв китапларын укырга, татарлар белән турыдан-туры аралашырга кирәк булачак. Барысы да алда иде әле. Ахры, 1942 елның аяусыз салкын кышында Хәтирә ханым белән Агзам абыйны безнең бәхеткә Ходай җибәргәндер. Үзләренең ике балалары өстенә, минем Викторым да бик еш аларга кереп йөрде. Сабыемның тамагы туя башлады. Шулай да эчтәге шайтан котырта: «Каян алалар икән соң алар шушы авыр заманда яшәрлек кенә ризыкны?» Соңыннан аңлашылганча, күрше абые урманчылыкта егерь булып эшли икән! Җитәкче түрәләр дә кеше бит, аларда да бала-чага җитәрлек. Властьлыгыңнан файдаланып, болай да ач-ялангач кешеләр өлешенә кереп урлашсаң, кемлегеңә карап тормыйлар, стенага терәп аталар иде ул заманда. Ә Агзам абый оста мәргән дә булган, «диверсантларга каршы урманда көрәшергә!» – дип, аңа җитәкчелек бронь биргән һәм ул өметләрен аклый. Әллә ничә дошман төркемен, диверсантларны юкка чыгара. Фронтта булмаса да, күкрәгеннән ике Кызыл Йолдыз, бер Кызыл Байрак орденнары, күп кенә медальләр бизи иде аның. Ә инде аучылыкка килгәндә, куян, болан, кабан, поши кебек киек җанварларны атып, җитәкчелеккә илтеп тапшыра. Итен илтеп бирсә, баш-аякларын, кайчагында эчке әгъзаларын өенә алып кайтырга рөхсәт итәләр. Шул ук вакытта зур түрәләр сыйланудан калган җанвар сөякләрен, безнең бәхеткә, бик еш ук булмаса да, Ходай насыйп итә торган иде. Әй, кызым Әлмирә, ул сөяк шулпаларының тәмлелекләре төшләремә керә!

Бер биш-алты ел элегрәк инде, улыма: «Виктор, каян булса да поши сөякләре табып алып кайт әле, авыр чорларыбызны җиңеләйткән шулпаны пешереп ашарбыз», – дим. Көлә, «Анакай, кем сиңа хәзер итсез сөяк сатсын инде?» – ди. Алып кайт, мин әйтәм, үзебез тунарбыз, дигәч, ял көнне урманчылыктан ун кило сөякле ит табып кайтты. Пешердек, ашап карыйбыз, әй, Ходаем рәхмәте, юк инде элеккеге тәмлелеге. Күбрәк кайры тәме килә!

Менә шулай, кызым! Менә шулай итеп, без Агзам абыйлар аркасында исән чыктык. Ул йөреп, талоннар да юнәтте, ире фронтта үлгән, үзен кыйнап талаганнар дип, рөхсәт кәгазе алган. Соңрак, сугыш беткәч, пәрәмәч пешерергә дә Хәтирә ханым өйрәтте. Викторым да аларга кереп йөри, балалары белән аралаша торгач, татарчаны яхшы гына сукаларга өйрәнгән иде. Кайчагында бәйрәмнәрдә бераз төшереп алса, хәзер дә, «Эх, алмагачлары, сайрый сандугачлары!» – дип җырлап җибәрә.

Шулай дигәч, хуҗа әби кабат күз яшьләренә тыгылды, аннан кеткелдәп көлеп җибәрде.

– Менә шуларны сагынып яшим хәзер! Алар мөселман зиратына җирләнгән. Елына бер-ике тапкыр барып, елап, рәхмәтләр әйтеп кайтам.

Кайчагында улым да минем белән бара... Аннан, кызым, син бик чибәр, зинһар, кирәк-кирәкмәгән җирләргә чыгып йөрмә, яшьлек алдаучан була ул. Дөньяда әшәке җанлы бәндәләр дә күп. Егетең Казанда калган булса, яратсаң, шуңа чык!

***

Кемнәр генә юк иде бу кичне «Балтика» ресторанында. Кемнәр генә юк, биредә дип әйтелә дә әйтелүен, кайсы кем икәнлеген шайтан белгән! Көтү-көтү өелеп вестибюльдә торалар, тарту бүлмәсе төбендә. Лиза әйтмешли, бу көтүдә артисты да, аферисты да, галиме, язучысы да, ниндедер томанлы мәсьәләләрне хәл итәргә дип җыелган «братва»лар да, ялагайлар, куштаннар да, иминлек саклау вәкилләре, хәтта шыпырт кына колак салып утыручы агентлар, диңгезчеләр, хәрбиләр, сөяркәләр, уйнашчы хатыннар – барысы да биредәдер кебек.

Һәм шуларга өстәлеп, хәерче студент халкы да булыр-булмас тиеннәрен дә туздырып кайтырга, юк-барны сәбәп итеп, бүген бу каһәрле урынга җыелган. Имеш, элеккедән калган йола, икенче семестрны да уңышлы тапшырыр өчен, бирегә килеп тугарылып кайту, соңгы сәмәннәреңне корбан итү файдага булачак икән. Аның шулай икәнлегенә беркем ышанмаса да, йоланы тотарга тырышалар. Хәтта шуңа багышлап чыгарылган әйтеме дә бар: «Семестрыңны тапшырдыңмы, киләсеннән дә уңышлы котылыр өчен «Балтика»га бар!» – дип әйтелә икән.

– Суворов нәрсә дигән? Соңгы күлмәгеңне сатып булса да, мунчадан соң йөз грамм эч, дип әйтеп калдырган, – диде Лиза.

– Без бит мунчага бармыйбыз! Мин бит, гомумән, эчмим, үзең беләсең Лизочка, минем белән анда сезгә бик күңелсез булачак! – дип карышты Әлмирә.

– Эчмәсәң соң, безгә күбрәк калыр, ә без, рус халкы, салып алсак, бәйрәм итә беләбез, – диде дә Лиза шундук шаярып такмаклап та җибәрде:

– Гашыйк булдым кавказлыга,
Гашыйк булдым Кавказга!
Бик чакырса, разый булып,
Менәр идем лапаска! –

дип кыланып алды. Соңыннан уйчанланып, моңсуланып: – Мин бит анда тау бөркетемне күрергә дә барам! – дип куйды. Зәңгәр күзле, чибәр Лиза тау бөркете Асланның туган җирендә сөйгән яры калганын да, гашыйк җаннарның араларына керергә ярамаганын да аңлый. Нишләтә ала соң ул үзен? Югыйсә хисләрен йөгәнләп тә карый, ләкин күз алдына бөдрә чәчле, янып торган шомырт кара күзле кавказ егете килә дә баса. Хисләре кимисе урынга, кабарганнан-кабара гына. Кайчагында чарасызлыктан өметсезлеккә бирелеп: «Әллә үз-үземә кул салыргамы инде?!» – дип тә куя.

Ахирәте Валентина-Валяның ачуы чыга:

– Дура, әллә бөтенләй тилердең инде?! Юк өчен өзгәләнәсең! Әйдә, берәр акчалы адәм белән таныштырам, басыласы җирең басылыр, әпититең ачылыр! – дип үгетли.

– Юк! – дип әрнеп әйтеп куя гыйшык утларында янучы иптәше. – Юк, йә анықы, йә беркемнеке дә түгел мин! Беркемнеке дә түгел! – дип, караватына капланып үксергә тотына. Әлмирә белән тәҗрибәле Валя да аңлыйлар аның хәлен, тик ничек ярдәм итә алсыннар инде алар?

* * *

Залга кереп җитәргә өлгермәделәр, биредәге шау-шу Әлмирәнең башына капты. Тәмәке төтене, спиртлы эчемлекләр исеннән күңеле үк болгана башлады. «Ничек түзәрмен икән инде бу атмосферага? Икенче юлы аяк басасым юк мондый җирләргә!» дип, үкенеп уйлап куйды. Иптәшенең төсе киткәнлеген күреп, Лиза, өстәлгә утыруга шешәсен ачып, фужерга «Боржоми» туырып, ахирәтенә сузды.

– Мә, эчеп куй әле, төсең киткән!

– Бәлкем миңа кайтып кына китәргәдер?

– Нинди кайту, ди, берүзеңме?! Ходай сакласын! Мондый төннәрне Иблисләр караңгы, буранлы урамнарда безнең кебекләрне сагалап кына торалар, – дип, иптәшен бу ниятеннән баш тарттырды.

Әлмирә өстәл янында утырган килеш сагаеп кына ял итүчеләргә күз салгалады. Ирләрнең күпчелеге ак күлмәк, кара кәчтүм-чалбардан, кара галстуклардан. Хатын-кызларның күбесе исә озын бәрхет, плюш күлмәкләрдән. Кайберләре муеннарына җылы кәшемир шарф ураган. Чәчләрен модага ияреп, салам эвәнәсе кебек итеп баш очларына өйгәннәр. Төрле ташлар белән бизәлгән муенсалары, колак алкалары көчле ут астында йалт-йолт килә. Ир затлары аларга итагатьлек күрсәтеп, җайлап урындыкка утырталар, елмаеп-көлеп, нindидер кызык-мызыклар сөйләп, кәефләрен күтәрергә, ярарга тырышалар. Болары шәһәр байлары, аксөякләре, ахры, дип уйлап куйды Әлмирә. Чыгар ишек ягына караган саен затлы киенгәннәр кими бара. Анда күбрәк хәрбиләр шаулаша. Дөресрәге, түбән чиндагылар басып алган. Тагын да кырыйдарак студент халкы гөрләшә. Ярый әле, Валялары таныш-белешлеге аркасында үзләренә урынны да түрдән сайлаган, ул да түгел, Валентинаны күреп, яннарына фырт кына киенгән, шактый гына симерергә өлгергән ир заты килеп басты.

– Хәерле кич, хөрмәтле хатын-кызлар, бәйрәм белән сезне, – дип котлады. Студенткалар:

– Рәхмәт, рәхмәт сезгә! – дип баш иделәр. Валентина исә:

– Рәхмәт! Сезне дә, Шамил Гарипович, бәйрәм белән! – дип, исем-фамилияләренә хәтле әйтеп җавап кайтарды.

– Мин Сезне үзебезнең өстәл янында күрергә теләр идем, Валентина Валерьевна! Сөйләшеп бетерәсе сүзләр дә бар, – дип, теге Валяны үзләренә чакырды.

– Яхшы, бер ярты сәгатькә генә булса да килеп китәрмен, – дигән җавапны ишеткәч, ир кеше кызларга баш иеп китеп барды.

– Азәрбайҗаннан! Сату эшләре белән шөгыльләнә. Безнең Тулада да эти аша азык-төлек сату урыннары ачмакчы була. Мин, кызлар, барып, аралашып килим инде, тәмле ашыйсыбыз, рәхәт яшисебез килсә, тыңларга туры килә, – дип, ирония белән елмайды да: – Ярый, кадерлеләрем, менә сезгә 25 сум, үзегезгә нәрсә заказ бирәсез, миңа да шуны алыгыз! Тагын...

шул инде, Лиза, виски ал, тик ачылмаган шешә булсын, югыйсә алдыйлар, – дип, акча сузды.

– Яхшы, Валя, озак йөрмә инде, безгә күңелсез булачак бит! – дип үтенде Лиза.

– Тырышырмын! Мин теге симезкәйләрне бераз савып килим әле! – дип китеп барды. Ул да түгел, җир тишегеннән килеп чыккандай, чырае кура җиләге кебек кызарган мәңге бурычлы студент Малин пәйда булды.

– О-о-о, какие красавицы наши! С праздником Вас! – дип котлады. Кызлар да бик исләре китмичәрәк:

– Сезне дә бәйрәм белән, – дигән булдылар. Кура җиләк Малин ничек кинәт килеп чыккан булса, шундук юкка да чыкты. Якасы тузган коңгырт күлмәгенең арты гына күренеп калды. Ул да түгел, официант кыз сүз катты:

– Ниләр заказ бирәсез, кызлар, бәйрәм киче белән сезне!

– Рәхмәт! Бер шешә виски, тик ачылмаган булсын! – дигәч, Лиза күтәрелеп карады. Теге мул итеп алсу-кызыл төскә буялган калын иреннәрен турсайтты. – Аннан, яшелчә һәм итле ассорти! Зур чәйнек белән үлән чәе һәм безнең идеальный кызыбызга яхшы пирожный, өч туңдырма ваниль белән, өсте җир җиләге белән бизәлгән, шоколад белән баетылган булсын. Һәм 200 грамм сухое вино!

Әлмирә теге коры шәрабның үзенә икәнлеген аңлап алган иде.

– Миңа сухое да, юеше дә кирәкми, – дип кәҗәләнде.

– Булсын! Эчмәсәң эчмәссең, шунда безгә көч биреп, чәкештергәләп утырырсың! Билләһи, яратмасам, Дуняны куган кебек очыртып чыгарыр идем үзеңне.

– Алай булгач, үзем икенче бүлмәгә күчәм, – дип үпкәләгән булды Әлмирә.

– Күчеп кенә кара, мәңге кичермәячәкмен, гафу ит инде, мин дураны, дорогая моя татарочка! – дип, иптәшен кочаклап алды.

Озакламый авызын ерып, Валя кире әйләнеп кайтты.

– Кызлар, гафу итегез инде. Сезнең белән озак утыра алмам! Теге бәндәләрне ычкындырмыйк, араларында ике яһүд өммәте дә бар. Мине алары кызыксындырмый, шимбәләр алар ике имине дә бушлай гына саварга яраталар. Азәрбайҗаннар исә киң күңелле, үзләренә кирәк булганда. Берсе бик чибәр малай, шоколад-конфет кебек инде менә, шомырт кара чәчләре Каспий диңгезенеке кебек дулкынланып тора. Исеме дә кызык – Али, мин аңа эчемнән генә Али баба дип кушамат та тактым. Үзе белсә шартлар иде. Азәрбайҗаннан эшләр белән килгәннәр, берсе җиңел промышленность министрының урынбасары икән. Әйдәгез, кызлар, берәрне сезнең белән тотып куям да... Сал тизрәк, нишләп оешмаган кеше кебек утырасың, – дип, Елизаветаны сүгеп алгандай итте. Тегесенең үпкәсе бөтен чыраена чыккан иде.

– Бәйрәм көнне дә ташлап качмасаң!

– Соң, килеп-китеп йөрим бит! Әйдәгез, алайса, хәзер кавалерлар белән сөйләшәм дә, сез дә алар өстәленә күчеп утырырсыз!

– Юк, юк, Валя! Зинһар, сүз кузгата күрмә, мин мәңге бармыйм. Килүем дә сез үпкәләмәсен дип кенә!

– Ярый, Әлмирә, нәрсә кирәк, заказ бирегез, барысына да үзем түлим бит. Аннан борчылмагыз, гел яныгызга килеп-китеп йөрермен!

Чәй эчәргә өлгермәделәр, конферансье музыка игълан итте. Шуны ишетеп, Валя урыныннан торды да:

– Йә, ничек, кызлар, кыяфәт ярыйсымы?! – дип боргаланып куйды.

– Шикарно! – диде Лиза, үпкәләгән кебек.

Валя китеп өлгермәде, Малин белән Иван Захарчук пәйда булдылар. Каян килеп чыкканнардыр, җен балалары кебек?!

– Какие наши красавицы, и без кавалеров! – дип, украин малае, йөзендә ясалма шатлык чалымнары ясап, авызын ергандай итте. Әлмирә аны болай да өнәми иде. Әллә нәрсә шунда – үз-үзен тотышында, сөйләмендә табигыйлек юк. Төскә-биткә дә ямьсез түгел үзе, ләкин сөйкемлелек дигәне, гомумән, бирелмәгән.

– Сезне, хөрмәтле курсташлар, танцыга чакырырга рөхсәт итегез! – дип, Захарчук үзенең кытыршы кулын Әлмирәгә сузды, кавказларча баш игән булды.

– Юк, юк! Башым да чатнап тора.

– Әлмирә, они же свои! Бер селкенеп алыйк инде, бәйрәм икән, бәйрәм булсын, – дип, Лиза торып, кура җиләге Малинга кулын сузды. Әлмирә дә теләр-теләмәс кенә урыныннан торды. Хохол Иван гына эченнән кызның биергә теләмәгәнен кылануга санап: «Ну, бер биетәм әле мин сине!» – дип, явызларча уйлап куйды. Үзе авызын ерган булып:

– Миңа зур бәхет сезнең белән танцевать итү, гүзәл Әлмирә.

– Рәхмәт!

– Карыйм, бик күңелсез утырасыз! – диде дә:– Шундый көнне дә чибәр кызларның күңелен күрмәсәк, җир күтәрмәс безнең бу ялгышлыкны, – дип, кура җиләгенә борылды. Аннары сагаеп кына, кызга күз салды, сүзләре чәчбикәгә ничек тәэсир итте икән дип сынавы иде.

Бәйләнчек Захарчук аңа бик терәлмәсен дип, кыз, ике кулын да тәртә кебек сузып, якынаерга ирек бирмәде. Өстәвенә, тегенең авызыннан килгән сасы аракы исе бөтенләй гайрәтен чигергән иде. Күңеленнән музыка тизрәк тәмамланса ярар иде, дип бимазаланды. Ләкин магнитофон туктарга уйламый да кебек тоелды аңа.

– Казанда бөтен кызлар да сезнең кебек чибәрләрме соң?

– Барысы да!

– Күптән барып, шәһәрегезне күрергә хыялланып йөрим, бәлкем, кунакка чакырырсыз? Мин бөтен расходларын үзем түлим!

– Мин хәзер үзем дә кунак кына шул анда!

– Юк, юк, гафу итегез, Ходаем үзе сакласын сезне туганнарыгыз алдында фаш итүдән! – дип, акылсыз сүз оештырды, ул гына да түгел: – Кунакханә снимать итәрбез, то есть, итәрмен, – дип тә өстәгән иде, Әлмирә:

– Минем торырга үземнең иркен, зур фатирым бар, Украинаңа кайтып снимать итәрсең, – дип, хохолны ачу белән этеп җибәрде. Шул мизгелдә колакларын тондырган, исеме-аты билгесез булган музыка тәмам булды. Дилбегәнең үз кулыннан шуа башлаганын сизгән «шустрик», юхаланып:

– Әлмирә, шаярттым гына, гафу ит! Мин бит синең белән горурланам. Бишкә генә укыйсың, ә ничек биисең! Божественно! Каяндыр Монголиядән килгән чибәркәйнең талантыннан һушым китте, – дип, каш астыннан гына сынаулы караш атты. Бу сүзе белән ул кызның аңына

«Кыргый Азия далаларыннан килсәң дә, менә мин бөек славян кавеменең бер лаеклы вәкиле, сине дә кешегә саныйм», дигән мәгънәне җиткермәк булды. Кызның бу сүзләрдән йөзе кызарып чыкты, күзләреннән нәфрәтле очкыннар чәчелде.

– Аллага шөкер, безнең Татарстанда бер генә монгол да юк һәм синең кебек мәгънәсез хохоллар да юк! – дип, ачу белән әйтеп салды Әлмирә.

Захарчукның бу сүзләрен ишетеп торган Малин:

– Дуслар, курсташлар, әйдә, бер кирәкмәгән темалар кузгатмыйк әле, бәйрәм тек бәйрәм булсын! – дип, виски шешәсенә сузылды.

– Точно, сал әйдә, братан, интернационализм өчен, коммунистлар партиясе өчен, генераль секретаребыз өчен тотып куйыйк әле, – дип, Захарчук аны хуплады. Әлмирә аларга:

– Барыгыз, үз өстәлегезгә барып тыгыныгыз! – дип кычкырып җибәргәнен сизми дә калды.

Иптәш кызының тавыш куптарырга яратмаганын белгән бүлмәдәше Лиза да сәерсенеп куйды. Конфликтны киметер өчен ул:

– Ярар инде, берәр рюмка эчсеннәр дә, – дип әйтеп бетермәде, Әлмирә:

– Мин хәзер үк кайтып китәм! – дип, катгый гына урыныннан торды.

– Булды, булды, егетләр, яле, тиз генә урыннарыгызга сызыгыз әле!

Эшнең кая таба барганын төшенеп алган ике йолкыш, үпкәләгән булып, урыннарыннан тордылар.

– Яхшы, яхшы, кызлар, китәбез! Ләкин безне тагын бер вальс әйләнүдән мәхрүм итмәссез инде, – дип мескенләнде ачуыннан кара көйгән Захарчук. Дусты Малин: «Киттек, киттек!» – дип тарткалагач, Иван Әлмирәгә акаеп карап алды да иптәшенә иярде. Читтән күзәтеп торсаң, алар кикрикләре шиңгән йолкыш әтәчләрне хәтерләтәләр иде.

– Нәрсә инде син, үзебезнең курсташлар иде бит алар! – дип аптырап сорады Елизавета.

– Син аның миңа нәрсәләр сөйләгәнен ишеттеңме соң?

– Нәрсә тагын?

– Мине Казанга ияртеп кайт та, кунакханә алып, шунда икәү яшәрбез дип хайванлана башлады.

– Булмас! Хәзер мордасын җимерәм бит мин аның! – дип, ачуы кабарган Лиза да урыныннан сикереп торды.

– Кирәкми, Лиза, киттеләр бит инде, зинһар, тавыш чыгарып йөрмә! Күңелем сизгән иде, нәрсәмә дип килдем инде мин бирегә?! – диде Әлмирә.

– Ярар, озак утырмабыз! Хәзер Валюша килсен дә... Тукта, аның килүен көтеп утырсаң, сызылып таңнар атар, тотып куям әле берне! – дип, инглиз самогонын авызына каплады.

Әлмирә генә:

– Ничего себе! – дип шаккатты.

– Без өйрәнгән инде, безнең менталитет шундый! – диде Лиза, тозлы кыярын шатыр-шотыр чәйни-чәйни.

Залның икенче почмагына урнашкан өстәлдә дә көчле әйткәләшү бара иде.

– Бу татар кызын урынына утыртмыйча, Украинага кайтып китү юк!

– Ташлале шуны! Нәрсәгә кирәк ул сиңа?! Ярар, чибәр, акыллы, матур бии! Ә нәрсәгә кирәк ул безгә! То есть, без аңа! Ваня, братан, безгә үзебездәйләрне табарга кирәк!

– Мин сиңа таптым бит инде!

– Ну, әйтеп тә карыйсың син! Мин шул ит кисмәкләренә калганмыни?!

– Калмаган да... Йөрисең бит әле!

– Үзең соң!

– Үзем дә шундый! Әйдә, сал әле тутырып! Теге татарканы кара син, үз өстәлегезгә барып тыгыныгыз, ди бит! Миңа шундый сүзне беркемнең дә, беркайчан да әйткәне булмады! Сал тагын, әйдә!

– Тыгыныгыз, димәде ул, барып эчегез генә, диде.

– Барыбер, шул тыгыныгыз дигәнгә тиң инде ул!

– Оныт! Күтәрдек, әйдә, – дип, кура җиләге Малин рюмкасын чәкештерергә күтәрде. Ипи кисәген кабып җибәргәч, Чиләбе егете сынаулы караш ташлады, аракы күп эчүдән тегенең күзләре калайланып чыккан иде. Бәхәсләшүләре хакында уйлап, үз-үзенә: «Вакыт җитте бугай!» диде дә, әшнәсенә: – Братан, парины мин оттым бит, сал әйдә костюмыңны, – дип куйды.

– Ашыкма! Эш бетмәгән әле! Уен дәвам итә! Ат белән соңгы ходны ясарга кала, – дип ысылдады.

– Файдасыз! Нишләмәк буласың тагын?!

– Сал әйдә, күп сөйләнмә!

Әлмирәләр өстәлендә дә күңелсезлекләр көчәя иде.

– Кая соң бу Валя дигән җилбәзәк?! Киләм диде дә юкка чыкты?!

– Кайтыйк, әйдә, музыкаларына хәтле башка капты, – дип үтенде кәефсез Әлмирә. – Ни өчен гел шул Леонтьев репертуарын да, Михаил Боярскийны акырталар? Туйдым!

– Ярый, бар, чыга тор, мин Валентинаны табып сөйләшәм дә... Урамда күрешербез! – дип, Лиза кулына сумкасын һәм өстәлдән виски шешәсен алып, алпан-тилпән атлап китеп барды.

Әлмирә дә: «Уф, Аллага шөкер, тизрәк саф һавага чыгарга кирәк!» – дип, ишеккә юнәлде. Урамда җиңелчә генә буран себерә. Тротуар кырыенда клиентларын көтеп, биш-алты такси һәм шәхси машина артларыннан төтен чыгарып эшләп торалар иде. Кырыйдарак нидер көлешә-сөйләшә бер төркем ир-ат басып тора. Рестораndагы даңгыр-доңгыр килгән музыка ике катлы тәрәзә пыялалары аша да урамга ишетелә. Алай дисәң, әнә бер тәрәзә, тегендәрәк тагын берсе ачык икән, аннан ургылып, урамга җылы һава чыга. Көтмәгәндә, кемдер аның беләгеннән кысып тотып алды. Борылып караса, күзе-башы алышынган Захарчук икән!

– Әлмирә, дорогая, прости, я не достойно вёл себя, прости! – дип сөйләнде. Кызда авызыннан тәмуг исләре саркып торган Иванга карата коточкыч җирәнү хисләре уянды.

– Ал кулыңны, кит янымнан! – дип усалланды Әлмирә. Үзе эченнән: «Кая югалды соң бу Лиза?» – дип өзгәләнде.

– Альмирушка, телисеңме, хәзер алдыңа тезләнәм, телисеңме, үз-үземә кул салам, ташлама гына, – дип, кызны үзенә сөйрәде.

– Кит, зинһар!

– Әйдә, әйдә, минем белән кунак йортына! Мин сиңа кыйммәт ташлы алтын алкалар бүләк итәрмен. Италия аяк киемнәре, сумкалар... – дип, кызны кулыннан тотып, таксига таба тартты. Әлмирә бимазаланып:

– Малин, ал, зинһар, дустыңны! – дип ялынды.

– Братан, оставь ты её в покое! Пошли домой! – диде Малин. Үзе куркынып, як-ягына каранды.

– Ты со мной пойдёшь, с...! – дип, Захарчук тагын кызга ябышты. Шунда Әлмирә:

– Кит минем яннан, хайван, – дип, аның битен тырнап алды.

– Ох, ты, стерва, – дип, хохол Әлмирәне сугып карга аударды. Кызның авызыннан кан китте. Ул канаган авызын тотып: «Помогите!» – дип кычкырды. Шул ук мизгелдә Захарчукның аяклары җирдән өстә асылынып калдылар. Ниндидер озын буйлы, пәһлеван гәүдәле бер ир заты аны якасыннан тотып күтәргән иде. Әлмирә кычкырып елап җибәрде, аның иреннәре генә түгел, саф күңеле дә җәрәхәтләнгән иде! Олпат гәүдәле әлеге джентльмен тегене кар өеменә болгап ыргытты да иелеп, мескен хәлдә яткан кызны күтәреп алды.

– Тынычлан, тынычлан, барысы да тәртиптә, – дип, аны нәни балаларны юаткандай юатты. Пәһлеван гәүдәле булса да, тавышы ягымлы чыга иде. Ул арада ишектән Валя белән Лиза атылып килеп чыктылар да «Ни булды, Әлмирә?» дип аңа таба йөгерделәр.

– Захарчук мине көчләп, кунакханәгә алып китмәкче иде, карышкач, битемә китереп сукты, – дип, кыз кабат әрнеп елап җибәрде. Үзе: – Ни өчен? Ни өчен? – дип такмаклады.

– Где он, хана ему! На порядочную девчонку руку поднимать! – дип, Валя үтерердәй булып теге бәндәне эзләде. Урам буйлап йөгерешкән ике шәүлә шул арада каядыр китеп, юкка да чыктылар. Валя теге олпат гәүдәле егеткә борылып: – Роман, шуны табып, арт сабагын укытыгыз әле, порядочный кызларга бәйләнгәне өчен бер сабак булсын! – диде.

– Урынына куярбыз! – диде пәһлеван гәүдәле егет.

***

Валентиналары тулай торакка бер көннән соң гына әйләнеп кайтып керде. Иске кием-салымын кая куйгандыр, билгесез! Ләкин өстендәге затлы коңгырт төстәге пәлтәсен салып җибәрүгә, бүлмәдәшләре «ах» иттеләр. Җитен тукымасыннан тегелгән яшькелт җылы костюм кигән, беләгендә шундый ук төстәге кул сумкасы. Һәм нәфис тәпиләрендә кызларның төшләренә дә кермәгән озын кунычлы, биек үкчәле мех аяк киемнәре иде. Муенына да ачык яшел шарф ураган. Колакларына да ут яктысында җем-җем итеп, күз кысып торган алкалар таккан. Ташлары кызгылт гранитмы, әллә рубинмы, кем белгән. Бүлмәдәш кызлары телсез калдылар. Әйтерсең, бүлмәгә бергә мохтаҗлык кичергән студентка түгел, ә Англия королевасы килеп керде. Йә булмаса, симез нефть магнатының сөяркәсе, диярсең. Дуслары – хәерче студентларның күзләрен кыздырып, чит ил модельләре кебек арт саннарын уйнатып, нәфис нечкә билләренә учлары белән таянып, бүлмәдә боргаланып алды. Чибәр иде шул Валя чукынчык! Зур күзләре кызган сумала кебек ялтырап, янып тора, калын чәчләрен сүтеп

таратып җибәрсәме? Ни кызганыч, ошбу байлыгын, уңга-сулга булмаса да, акчалыларга өләшә иде. Әлмирә аңа сокланып та, кызганып та карый! Кияүгә чыгып, иренең яраткан хатыны гына булып, ташып торган чибәрлеге белән гаиләсенә бәхет өләшсә, чөкердәшеп яшәсә... Юк, шул, юк! Үзе дә: «Мин гаилә өчен тумаган!» – дип кенә җибәрә. Өстәвенә инглиз телен дә су урынына эчә, тот та бүген үк чит илләргә агент итеп җибәр! Актёрлык осталыгы да җитәрлек, маҗара эзләп йөргән ирләрне дә шундук үзенә карата белә! (Һәм киләчәктә дә Валя чит илдә, СССР илчелегендә хезмәт итә. Ни кызганыч, гаилә генә төзи алмый ул, бәлкем аңа ул мәшәкатьләр кирәкмәгәндер дә!)

Валяның күтәреп кайткан пакетыннан өстәлгә түп-түгәрәк мандариннар белән гранатлар коелды. Кул сумкасыннан ике банка кофе һәм өч кап шоколад та үзләренә урын тапты.

– Рәхәтләнегез, кызлар! Валя түтәгез исән булсын дип теләгез! Әлмирә, как у тебя дела? Всё нормально?

– Әйе, рәхмәт, Валя! Иртәгә, Алла боерган булса, кич белән Казаныма юл тотам!

– Молодец син, шундый чибәрлекләрең белән үзеңне тыйнак тотасың! Миңа карама, синең үз юлың бар! Теге астыртын Захарчукны минем егетләр эзләп караганнар иде дә таба алмыйлар! Кура җиләге аны өенә кайтып китте, ди. Ярар, чәнчелеп китсен, яшәсен шунда! Ходай үзе якасыннан алганчы. Ярый әле Роман туры килгән.

– Кем соң ул Роман? – дип кызыксынды Лиза.

– Ленинградныкы ул, каядыр шушы тирәдә тора. Гәүдәгә куркыныч күренсә дә, бик мәрхәмәтле, ярдәмчел егет! Җирле волейбол командасының капитаны. «Динамо»мы, «Торпедо»мы шунда. Аның дустының этисе Орнальд Львович Ваенблад белән чәйләп утырганда, ярыштан кайтып кергәннәр иде. Хуҗа үзе диңгез портында складлар җитәкчесе. Ой, кызлар, эт булып ардым! Сезнең белән сөйләшә-сөйләшә үлеп йокым килгәнлеген дә онытып җибәргәнмен!

– Валя, дустым, бу ханский кием-салымнарыңны кунакларга барганда биреп торырсың әле. Ярыймы, хәзер үк киеп карасам? – дип теләнә үк башлады Лиза.

– Ой, кызлар, арыдым, теләсә нәрсә эшләгез, – дип, Валя туарыла да башлады. Ләкин чишенеп бетә алмады, гөрселдәп караватына ауды да шундук йокыга да китте.

– Менә сиңа, мә, хәзер безгә туарырга да туры киләме инде сине, – дип, Лиза кыйммәтле аяк киемнәренә ябышты.

***

...Әлмирәнең Казанга кайтып китәсенең алдагы төне куркыныч төшләр күреп, саташулар белән, тынгысыз үтте. Төрле күренешләр кереп йөдәтте. Имеш, ул дәү әнисе янына юлга чыккан. Менә кыз поездан төшеп калды, ни сәбәпледер станцада аны каршы алырга килүчеләр күренмәде. Әле генә чанага җигелгән атлар, «УАЗ» машиналары көтеп торуын күреп сөенгән генә иде, ул да түгел, алар эреп юкка да чыкты. Берүзем сигез чакрымлы шушы көртле юлны ничек үтәрмен? – дип бимазаланды ул. «Тукта, вокзал

эченә кереп торырга кирәк. Бәлкем әле авылдашлар да килеп җитәрләр. Дәү әнисе бит каршы алырга берәрсен җибәрермен, борчылма, кызым, дигән иде. Керсә, вокзал эчендә дә бер адәми зат та юк. Таллы Күлгә шалтыратып белешергә дип, касса ишеген шакып карады. Милиция пункты дигәнен дә каккалады, тик аңа җавап бирүче табылмады. «Юк, юк, дәү әнисе аны мондый хәлдә калдырмас, аны килеп, каршы алырга кемнән дә булса, бәлки Исрафил абыйсын үтенгәндер. Иң яхшысы, юлга чыгарга да каршыларына бара торырга кирәк!

Менә ул ат-машина эзләре калган юл буйлап атлый. Кулындагы күчтәнәчләр тутырылган биштәрен, кулы талгач, әле берсенә, әле икенчесенә күчерә. Шулай атлый торгач кайтыр юлын, эзләрне югалтты. Тиздән йомшак карга кереп чумды. Әле бер, әле икенче якка омтылды. Кире вокзалга кайтып, көтеп торырга да уйлаган иде, станца йорты да эреп юкка чыккан. Көчле буран башланып, гомумән, бернәрсә дә күренмәс булган. Әлмирә, өне китеп, изаланып елый. Үзе: «Коткарыгыз!» – дип кычкыра. Шулчак колагына эт өргән, кешеләр сөйләшкән тавышлар ишетелгәндәй булды. Кыз бар көченә: «Мин монда, мин монда, дәү әни, мин монда! – дип оран салды. Берзаман кышкы буран ничек кинәт башланса, шулай кисәк туктап та калды. Юлда адашучы ярдәм эзләп, тирә-ягына күз салса, җаны өшеп китте. Аны ач бүреләр өере уратып алган икән! «Йа Ходаем, коткарыгыз мине, коткарыгыз! Әле бит мин яшәргә дә өлгермәдем, коткарыгыз, нигә миңа мондый язмыш, ни гөнаһларым өчен?!» дип, чарасызлыктан сыгылып төште. Ул да түгел, икенче күренеш башланды. Кыш та юк, кары, ач бүреләре дә. Ул яшел чирәмле, дару үләнле кыр буйлап каядыр атлый, баш очында кошлар сайрый, кояш мулдан нурларын сибә. Бу җирлек таныш та кебек аңа, түгел дә шикелле. Каршына урман килеп басты. Ул каен агачлары арасыннан бара, нәрсәдер эзли, тик һич кенә дә төшенми. Ул да түгел, урман кинәт бетә, алга күз салса, коты очып, яр кырыенда тукталып калмакчы була. Тик соң инде, атлап килгән инерциясен тыеп калалмыйча, упкын төбендәге шаулап торган күлме, буамы шунда, суга түбәнгә оча. Мондый биеклектән төшкәч, беркем дә исән калырлык түгел. Ни сәбәпледер, ул авырлыгын югалткандай, ук кебек атылып түгел, ә салмак кына дәрья өстенә якынлаша. Кыз шуның дулкыннарына төшеп бәрелгәнче бөтен туганнарын, тормышын барлап чыгарга, бәхилләшергә дә өлгерә. Үзе өстенә һинд хатын-кызларыныкыдай ак төстәге киндер тукыма ураган икән. Дулкыннарга төшеп бәрелүгә, яшәргә булган көчле теләк аны ярга таба йөзәргә мәҗбүр итә. Менә ул ташлы-комлы су кырында басып тора, очлырак ташлар кадалып, табаннарын әрнетә. Шуңа карамастан, Әлмирә калку тау башына ашыга. Үзе яңа гына кичергән куркыныч кичерешләрдән үксеп-үксеп, ярсып-ярсып елый...

Студент кыз шул халәттә уянып китеп, күзләрен ачты да, кайдалыгын аңышмыйча, тирә-юнен куркып күзәтте. Ничектер таныш та кебек иде аңа биредәге манзара. Әнә өстәл, әнә өч урындык, янәшә караватта изелеп йоклаган кеше бүлмәдәше Валя түгелме соң? Тегендә почмакта ахирәте Лиза ята бугай. Кыз әкрен генә чынбарлыкка кайтты, үзенең исән-сау, үзе яшәгән тулай торакның бүлмәсендә икәнлегенә төшенә башлады. «Йа Ходаем, хәерлегә генә булсын инде бу төшләрем! – дип укынып алды. «Аллага шөкер, исән икән бит, аның белән берәр хәл булса, әти-әнисе, туганнары, дәү

әнисе андый кайгыны ничек күтәрерләр иде? Ул аяк очларына гына басып, шыпырт кына бүлмәдән чыгып китте. Юынгычлар урнашкан бүлмәгә кереп, салкын су белән битләрен юды, җилкәсеннән асылынып төшкән сөлге очлары белән сөртенгәч, яктылык җитеп бетмәгән кырыклы лампочка астында, сул як стенага эленгән агач рамнарын күгәрек ашап каралтып бетергән, пыяла артындагы көмешенең дә чат-чатлары яргаланып беткән борынгы көзгегә күз салды. Аңа төсе киткән, күз төпләре каралып чыккан икенче бер Әлмирә карап тора иде. Төнге тетрәнүләрен кабат күңелендә барлады, тыела алмыйча күз яшьләре кабат атылышып чыктылар. Тынычланырга тырышып, ул кабат су кранын ачты. Салкын сулы кулларын битенә каплады...

Кире студентлар бүлмәсенә кайткач, сак кына ятагы астындагы чемоданын чыгарып, әле күптән түгел генә тузаннан чистарткан кием тартмасын, тузан кунмаган булса да, кабат сөрткәләде. Биредә каласы артык-портык киемнәрен караватк кырыена өсте-өстенә өйде. Әбисе бәйләгән җылы кофтасын, йон оегын, бияләен икенче кырыйга куйды. Аннары юлда киеп кайтырга ниятләгән өс-башын, ике көн элек туганнарына дип алган күчтәнәчләрен яңадан барлап чыкты. Дәү әнисенә дип алган хөрмә белән өрек җимешләрен кулларында сыйпап, кире юл букчасына салды. Мандарин белән лимоннар да биредә үзләренә урын тапты. Абыйсына дип бүләккә алган камыштан үрелгән эшләпәне, изелмәсен дип, эченә иске гәҗитләр тутырып, чемоданына урнаштырды. Рәссам туганы әлеге баш киемнәрен җәйге кызуларда пеләшләнә башлаган башына элеп йөрергә ярата иде. Аның берсе – чүпрәктән, яңгырлы көннәрдә кия торганы күннән тегелгән ике башлыгы бар. Ләкин алар күптәнге булу сәбәпле, тузганнардыр инде. Кыз, җәйнең матур бер көнендә сеңлесе алып кайткан яңа бүләк эшләпәсен киеп, Идел ярында басып торган абыйсын күз алдына китерде. Күңеленә шатлык иңде. Аның әле тагын бер күчтәнәче бар. Монысы да күрше Исрафил абыйсына күптән бүләк итәм дип уйлап йөргән, буй-буй зәңгәр-кызыл сызыклы галстук иде. Ул аны куенына кысты. Ничек итеп Исрафил абыйсының муенына элүен күзаллады. «Рәхмәт, сеңлем», – дип аны күрше егете кочагына ала, битләреннән үбә. Кыз шул ләззәтле мизгелләрне күзаллап, иркәләнеп: «Кирәкми, Исрафил абый, оялам! – дип пышылдавын сизми дә кала. Кемнеңдер: «Шулай иртә таңнан нишлисең? – дигән тавыш ишетеп, ул сискәнеп куйды. Дусты Лиза икән.

– Җыенам, – дип пышылдады ул, уңайсызланып.

– Ә, – дип куйды да бүлмәдәше, стена ягына борылып ятып, кабат йокыга талды. Әлмирә дә иптәшләренә комачауламас өчен әлеге шөгылен туктатып торырга булды. Кием-салымнарын кырыйгарак куйды да йокысы килмәсә дә, сузылып ятты. Күзләрен йомып, әти-әнисен, дәү әнисен, абыйсын күз алдына китерде. Алар янында туганнарыңның җылысын, яратуын тоеп яшәүләре нинди бәхет булган икән ул! Тиздән якыннары белән күрешү мизгелләрен күңелендә җанландыргач, йөрәге ашкыныбрак тибә башлады...

Шулай татлы хыялларга чумып ята торгач, эреп йокыга киткәнен дә сизмичә калды. Кемнеңдер шак та шок, шак та шок ишек шакуын ишетеп уянып китте. Лиза йокы аралаш: «Кем бар анда?» – дип мыгырданып куйды. Валентинасы исә ишекне вату гына түгел, таш җибәреп тәрәзәңне койсалар да, уянырлык түгел. Әлмирә аяк очларына гына басып килеп,

ишекне ачты. Анда кулына кызыл тасма таккан, бүген вахтёр янында дежурда торучы бер кыз басып тора иде. «Закировага хат бар», – дип, ул конверт сузды. «Рәхмәт!» – дип кенә пышылдады Әлмирә. Ишек биген тавыш чыгармаска тырышып кына бикләгәч, сәлам хатына күз салды. Кемнән икән? Ни сәбәпледер, кире адресы юк иде. Сәер, нишләп үзенекен сырламаган соң ул? Әлмирә караватына җайлап кына утырды да, сак кына конвертны ачты. «Исәнме, Әлмирә! Бу хатны сиңа яхшылык теләүче берәү яза. Синең башыңны бутап, Исрафилнең хат язуын белдем дә, эшкә ачыклык кертергә уйладым. Егетебез хәрби хезмәттә булганда, бер марҗа кызына бала ясап калдырган...» «Нәрсә ясап калдырган?» дип төшенә алмыйча утырды студент кыз. «Бала ясап?.. Булмас ла! Тыйнак, тәртипле, чибәр Исрафил абыйсымы? Дөрес хәл түгел бу, дөрес түгел!..» Аның күзләрендә яшь барлыкка килде. Алар бите буйлап тәгәрәп, самолёт рәсеме төшерелгән марка ябыштырылган конверт өстенә тамдылар. Ул җебегән күзләре белән яңадан хатка күз салды. Тоныкланган карашы аша: «Хәзер күрше Түбән Көек авылы кызы Фәрдия янына чаба! Тегесе тиздән өйләнешәбез, туй була дип хәбәр тараткан. Шуңа күрә, шуңа күрә, бик ышанып йөрмә син ул бабникка! Сиңа яхшылык кына теләүче авылдашың», – диелгән иде анда. Кәгазь кисәге кызның кулыннан төшеп китеп, бер мәл очып барып, өстәл астына кереп ояладе. «Булмас ла, Исрафил абыйсы андый түгел ул! Алай булырга тиеш түгел иде, түгел!» дип сыкрады кыз. Шактый гына үзен кулга алалмый утыргач, уң кулы белән мендәре астын капшап, икенче бер конвертны тартып чыгарды. Исрафил абыйсына дип язган, ләкин җибәрергә кыюлыгы җитмәгән соңгы сәлам хаты иде ул. «Онытмаганың өчен бик зур рәхмәт, Исрафил абый! Аллага шөкер барысы да яхшы, әйбәт кенә укып йөрим. Зачётларымны уңышлы гына биреп бетердем. Тиздән каникулларга, башта Казанга, аннары дәү әнием янына Таллы Күлгә кайтам. Соңгы вакытта мин дә, Исрафил абый, сезнең турыда бик еш уйлыйм, сагынам хәтта! Авылымны, дәү әниемне, барыгызны да бик сагынам. Тиздән күрешергә насыйп булса иде дип хыялланып йөрим. Сезнең белән мотоциклга утырып, очып кына йөргән, хәтта очып барып төшкән мизгелләрне дә, нинди бәхетле көннәр булган икән, дип искә алам. Минем Сезне бик күрәсем килә, Исрафил абый! Үзеңә генә әйтәсе сүзләрем дә җитәрлек!» дип хисләнеп язган иде ул бу хатны. Менә бүген аның көчәеп барган мәхәббәт хисләренә бозлы су сиптеләр.

...Ваклап туралган саф мәхәббәт хатының кисәкләре, салмак кына төшкән кар бөртекләренә ияреп, юыну бүлмәсенең форточкасыннан аклыкка күмелгән урамга коелдылар.

*(Ахыры киләсе санда.)*

*Гали Рәхимнең тууына – 130 ел*



Лилия
Гыйбадуллина

# ГАЛИ РӘХИМ[*]

ПОЭМА

*Максут – тавыш кына булган чакта сүзләрнең, шул вак-төяк дөнья сүзләренең ни кирәге бар? Сайраучы кошларны тыңлаганда, без алардан сүз сорамыйбыз бит!*

Гали Рәхим «Өч тапкыр»

*Гади дөнья кешеләре аны үзе теләгән биеклеккә менгерүдән гаҗиз иделәр.*

Гали Рәхим «Күкләргә таба»

Адәм гомеренең кадере ни?
Ак биләүдән алып кәфенгәчә,
Фанилыкны кичкән даһиларның
Һәрбересен дөнья хәтерләсә:
Күңеленә, иманына салса
Җиргә туар яңа адәмнәрнең,
Карамыйча, барламыйча гына
Калтыраган дәвер әләмнәрен,
Истә тотса үз баласын милләт,
Тукып торса галәми бер хәтер,
Әйтер идем: адәм кадере дә
Шәхесенең үз зурлыгы кадәр.
Әйтер идем…

[*] Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе тарафыннан үткәрелгән конкурсның «Поэма» номинациясендә беренче урынны алган әсәр.

Лилия ГЫЙБАДУЛЛИНА (1987) – *шагыйрә; «Белла» халыкара әдәби премия лауреаты. «Мин бәхетне күрәм!..», «Тынлык кайтавазы», «Кайту» исемле китаплар авторы. Чаллыда яши.*

**1**

*Сез моннан элек нинди искиткеч эшләр, әкиятләр генә булырга ярый торган гаҗәепләр көтмәгез, юкса алданырсыз. Мин сезгә бары бездән йөз еллар, бәлки, артыграк та элегрәк, дөньяда торып киткән бабаларыбызның тормышыннан үземә мәгълүм булган бер кисәген ачып күрсәтмәкче булам.*

Гали Рәхим «Габдерәшит бабай»

Кәрван килә, олау-олау
Бәрәкәттер төягән.
Кәрван килә! Кәрван килә!
Кәрванбашы иярдә.
Сәүдә килә, мал-кот килә,
Килә әллә кайлардан –
Ефәк юлдан.
Кәрванбашның
Чигә чәче чаларган.
Олау-олау ефәк кайта,
Китап кайта, тоз кайта.
Идел-йортта базар гөрли.
Кем сатыла, кем сата…
Идел буйлап каек килә,
Койрыгында хат-хәбәр.
Базар булса – татар була,
Татар барда – хәтәр бар.
Хәтәр кайда – татар шунда.
Лашман тарта, таш вата,
Лаеш шулпасын татыгач,
Калага кайта татар.
Сәүдә итү канда бит ул,
Сыегаймаган, сынмаган.
Мал тәмле – бармак очында,
Ымсындыра, тынмаган.
Мөхәммәтшакир егетнең
Сынатырга уе юк.
Сынатканның сыны сына,
Сынатканның сые юк.
Бөркет күзле, нык беләкле,
Куш йөрәкле бул гына.
Болгана базар Казанда,
Замана да болгана.
«Аягына мал ияргән»
диләр Шакир турында.
Ут уйнаткан егет-җилән
Һәрзаман күз уңында.
Мал таба белгән ир-атның
Кыйммәте – малда түгел.
Үзе кыйммәт, заты кыйммәт,
Югалыр бала түгел.
Карт сәүдәгәр Исхак ага,
Мал аера белгәнгә,
Шакирны кияве итә,
Мулдан була бирнә дә.
Данлы Айтуганов кызы
Бибигайшә сылуга
Кияү килә, кияү килә!
Атлар чаба салулап.
Атлар чаба, дугаларда
Җиз кыңгырау чыңнары.
Гомерләрнең алтын туе –
Яшәү җыры, тынмале!
Тынмале, кушыл аннары
Нарасый тавышына,
Дәверләр түгел, гомернең
Туйлары алышына.

**2**

*Өйнең түбәсе ачылып, күтәрелеп киткән кебек булды. Җирдән – күккә, мәгърибтән – мәшрикъка нур тоташкан иде. Өйнең диварлары югалдылар. ...Туган бала ахырзаман пәйгамбәре иде…*

Гали Рәхим «Туды...»

Заман йоклый әле. Карынында
Яңа дәвер яралганын тоймый.
Сөембикә торыннары әле
Калфак бизи, курчак-курчак уйный.
Дәвер йоклый әле исәңгерәп,
Иңсәсендә иске кара бишмәт.
Сәгъди абзый кышкы озын кичтә,
Мичкә арка терәп, аркан ишә.
Йокымсырый әле татар иле,
Азан көтә Казан урамнары.
Гасыр тәмамлана. Татар җаны
Фәрман көтә: «Уяныргa ярый...»
Шәкерт Исхакыйның таң алдыннан
Тын йокысы инде бүленгән чак.
Татар йорты тәрәзендә инде
Яңа гасыр таңы беленгән чак.
Уяныргa кирәк. Сабый Апуш
Иҗек таный, каләм тотып карый.

«Тәрҗеман»ның кыштырдавын ишет,
Төрки дөнья, уянсаң да ярый!
Бик борынгы каннар кызышканда,
Уянганда кала, һәрбер сала.
Җиргә иңгән яңа кешеләрдә
Заманасы һәрчак терәү таба...

Казан бае Шакир сәүдәгәрнең
Тәрәзендә бүген төне буе
Ут тынмады, һәм таң сызылганда
Әче елап җиргә туды улы.
Яшь атаның кулы калтырыйдыр,
Ялтырыйдыр күзләрендә яше.
Бибигайшә бикә олан тапты,
Йә, рәхим ит җиргә, яңа кеше!
Хаталардан, хасталардан гали
Булып үс син. Бисмиллаһи… яле…
Ак биләүдә коңгырт күзле сабый –
Мөхәммәтшакир улы Мөхәммәтгали.
Дүрт саның да төгәл булсын, олан,
Күңелеңә иман нуры тулсын,
Бәхет, тәүфикькынаң артып торсын,
Котлы булсын гомрең, котлы булсын!..

Уяныргa кирәк, уйланырга,
Исәннәргә юл барларга кирәк.
Бишек эргәсендә татар ире
Басып тора, җиргә аяк терәп.
Үз җиренә ныклы аяк терәп,
Үз җиренә үзе булып терәк,
Тора татар ире. Дәвер ахры.
Бу сабыйны үстерергә кирәк...

**3**

*...Киләчәктә Мөхәммәдгали әфәндедән әдәбиятымызга зур хезмәтләрене өмид итәчәгендә шөбһә кылмыймыз.*

Галиәсгар Камал. 1909 ел

*Утка кергәч бит, яна алмас ташы,*
*Шунда тик мәгълүм була алмаслыгы.*
*Кайгы-хәсрәттә сыналыр ир башы,*
*Җилкәнең дә чыдый алып-алмаслыгы.*

Гали Рәхим

Яу белән яу арасында,
Кала салып, кирмән корып,
Иген игеп, чуен коеп,
Тимер бөгеп, дага кагып,
Мең ярага дәва табып,
Йөрәгенә ямау салып,
Мәйданнарда билен бирми,
Башын ими, горур калып,
Гасырларны кичә халык,
Чордан чорга күчә халык,
Яши халык дөнья тулып,
Яши халык татар булып!

Таш булса да чатнар иде,
Чуен булса – сынар иде,
Давыл булса – тынар иде,
Ялкын булса – сүнәр иде.
Татар чыдый, татар түзә,
Колачы киң – күкләре тар.
Күк күкрәткән тарихы бар,
Асылы сау – Китабы бар!

Таяк түгел, әлиф икән –
Иң беренче хәреф икән.
Хәрефләрең язмышында
Хәвеф арты хәвеф икән.
Кара яудан Казан ауган,
Кәгазь янган, китап янган,
Ата-баба затлылыгы,
Тарихыңның хаклылыгы
Телдә калган, ташта калган.
Ә башкасы аның – ялган…

Иман шарты белән бергә
Китап хакын хаклаганнар.
Кулдан кулга күчергәннәр,
Телдән телгә ятлаганнар.
Тарихының чылбыры күк
Хәреф арты хәреф тезгән
Күңеленә татар углы.
Сакла, Раббым, хәтерсездән,
Маңкортлыктан, денсезлектән
Аралый күр торыннарны!
Китап тотмаган сабыйлар
Татар булып торырлармы?
Кеше булып торырлармы?..

Мөхәммәтгали олан үсеп,
Кулларына китап ала.
«Мөхәммәдия»гә бара,

Мәдрәсәдә белем ала.
Инкыйлаблы гасыр башы,
Чоры – хикмәт, иле – гауга.
Татар ире – Казанында,
Карашы хөр, офыгы тар.
Китап тоткан бу оланны
Киләчәккә илтәсе бар.
Гыйлемле дә, китаплы да,
Сәүдәгәр дә булсын улы.
Атасының, бабасының
Сәүдә йөртеп унды юлы.
Дилбегәне тапшырырга
Күпме калган – Алла белсен...
Мәскәүләрдә гыйлем җыйсын,
Дус-иш тапсын, дөнья күрсен.
Иле – урман, көн – караңгы,
Ходай белсен алдагысын…

Ата хакы – хакларсың да,
Ничек салып таптарсың шул.
Мәскәүский институтта
Сәүдә гыйльмен ятларсың шул.
Мәскәүләрнең каланчасы
Казаннардин шәйләнәдер,
Мәскәүләрдә укый Гали,
Тик гаме юк сәүдәдә гел.
Галәми ат – әдәбият,
Тел гыйлеме, тарих фәне
Ымсындыра яшь күңелне.
Әйе, егет бик яшь әле.
Яшь әле ул, өлгерәчәк,
Күңелләргә ут әләчәк.
Үз хаклыгы ялкынында
Үзе беркөн өтеләчәк.
Гасыр башы. Алда әле
Тар камытлы хөр киләчәк.

**4**

*1915 елда Мәскәү Коммерческий институты студенты Г.Рәхим каникул вакытында Болгар хәрабәләренә бара.*

Мөхәммәт Мәһдиев

*Болгар хәрабәсе, сине бу шигъриятсезлек, бу проза арасында күргәнче, күрми тору артык иде. Синең хыялың, синең күләгәң үзеңнән матуррак, үзеңнән моңлырак иде...*

Гали Рәхим «Болгар хәрабәләрендә»

Суык, суык, зыңлап торган суык.
Тыным өреп җылытырмын, димә.
Үзең чатнап бозга әйләнерсең,
Бу дөньяга тимә!..
Бу дөньяда ятим тыннар йөри,
Хәрабәләр тирәсендә җирсеп,
Хыялланма, син мәңгелек ятим,
Син – гомерлек ятим, илсез-җирсез.
Хәрабәләр – алар хәбәр юкса
Синдәйләргә ерак үткәннәрдән.
Гасырларны кочагына йомып,
Алар бәлки сине көткәннәрдер.
Алар сиңа өмет иткәннәрдер,
Җиткергәндер салмак Идел җиле…
Ә калганын син беләсең инде.
Хыялыңны ягып, үкенечең
Күңелеңә кайнар очкын салды.
Якты романтикаң, садәлегең
Хәрабәләр йолкып алып калды.
Син бирегә кайтачаксың әле

Татлы бер ымсыну белән сусап.
Хәрабәләр, ташлар, тузган нигез…
Гел әйдәкләр шунда гомер-сукмак.
Гел сагалап торыр татлы сусау,
Тыенкы бер моңлы сагыш сыман,
Кайтачаксың әле, кайтачаксың,
Юлларында Идел суы, олан.
Хәрабәләр бәгыренә түгел,
Син дөньяга, язмышыңа тидең.
Кагылдың да, ул таныды сине,
Болгар ташы сине көткән иде.
Гасырларны кичкән сагышларын,
Ачы ятимлеген, әрнүләрен
Синең бәгыреңә салды алар –
Җимерелгән Болгар каберләре.
Төрбәләре сиңа текәлгәндә,
Сулышларын аркаң белән тойдың.
Син Болгарга килгән бу кичәдә,
Җаның ертып,
Шагыйрь булып тудың!..

**5**

*Татар әдәбиятында үзгә юл сызып барган язучы буларак та, фәндә яңа сукмаклар ачкан галим, төрки тирәлектә мәгълүм фикер иясе төсендә дә танылган, милли тарихта тирән эз салган шәхесләр бар. Гали Рәхим – шундыйларның берсе.*

Дания Заһидуллина

Яңа гасыр. Унҗиденче санә.
Ил күгендә гөмбәз кителгән.
Хат Мәскәүгә, студент Рәхимовка
Кайгы тулы хәбәр китергән...
Ул Казанга кайтты.
«Гали кайткан!..»
Күрешергә килә дуслары,
Белешергә, кайгы бүлешергә:
«Бирешмә син, дускай, туктале,
Ил тезгене бәйдән ычкынган чак,
Илдә шундый ал таң атачак!..
Татар сүзен ишеттерер вакыт,
Безнең кулда хәзер киләчәк!»
Ишетә дә, ишетми дә кебек...
Ул әткәсен бүген җирләде.
Атасының соңгы туе бүген,
Ул атасын бүген җибәрде
Аллаһ хозурына.
Түр капканы
Ябып куйды аннан анасы.
Әнкәсенә, ике сеңлесенә
Терәк булып Гали каласы.
Ул Казанга кайтты, гомерлеккә.
Сагынгандыр Кабан ярлары.
Иделенә кайтты татар ире.
Карашы хөр, җаны яралы.
Ә җанында – өермәдәй сусау,
Ә йөрәге һаман ашкына
Мәгърифәтле, мәнле, сәгадәтле,
Мәхәббәтле язмыш каршына.
Ул атлыйсы юллар өр-яңалар,
Тапталмаган, беркем узмаган.

Тарихыңны барлап, алгарышны,
Аңышуны көтә бу заман.
«Аң»га[1] килә Гали.
Аркадашлар,
Терәк булыр дуслар янына.
Әхмәтгәрәй Хәсәнинең әнә
Бар хыялы – дәшеп аңына,
Татар халкын өзеп уйкуыннан,
Күзен ачу, хушка китерү.
Үлмәгән ул милләт, йоклый гына,
Юкса үзе исән һәм тере!
Уятырга, уйлатырга кирәк,
Кирәк уятырлык егетләр,
Ибраһимов, Хәлфин, Тинчуриннар,
Фатих Әмирханнар кебекләр.
Гали Рәхим исме тынчу чорга
Киң тәрәзә булып уелыр.
Татар рухын кузгатырга кыйган
Асылларның берсе ул булыр.
Ул – мөгаллим, галим, тарихчы да,
Тәрҗемәче, сәнгать белгече...
Кырык ирнең җилкәсенә таман
Йөкне ялгыз тарткан бер кеше!
Казандагы Татар урамыннан,
Татар дөньясына атлаган,
Заманасы кылыч кайраганда,
Сүз сайлаган, каләм саплаган.
Аның эзе – без атлаган юллар,
Аның эзе – җырда, шигырьдә.
Тарих, мәдәният, сәнгатебез –
Гали Рәхим салган нигездә.

**6**

*Чакма чактым – булды бит ут органым,*
*Бушка китмәде минем утырганым.*
*Чакма чаксаң син минем кальбемә гәр*
*Бушка булмас дөньяда һәм торганым.*

Гали Рәхим

Ул, йолдызлар яктылыгын тоеп,
Якынлыгын тоеп һәлакәтнең,
Янды, янды, яза-яза янды,

Мәгәр әйтер сүзен ярып әйтте:
Әдәбият – игү атыбыз ул,
Борынгыдан килгән мирас, диде.

[1] «Аң» – 1912 елның 15 декабреннән Казанда нәшер ителгән матур әдәбият, нәфис сәнгать һәм әдәби тәнкыйть журналы. Мөхәррире – Әхмәтгәрәй Хәсәни.

Эзләү кирәк, барлау кирәк аны,
Тапканыбыз әле бик аз, диде.
Меңьеллыклар аша җиргә бакты,
Моң хәтерен, тел хәтерен тапты.
Ул асылташ булып төпкә батты,
Хәрабәдәй калкып, кабат кайтты.
Ул күпләрнең күзен камаштырды:
Үзе – галәм, үзе – адәм заты.
Ул күпләргә кыргый кояш булды:
Үзе биек, үзе шундый якты.
Дәверләрне бергә тоташтырды,
Әдәбият – аның игү аты.
Әдәбиятының тарихына
Татар – Гали сүзе аша кайтты.
(Әлегәчә кадәр төрки галәм,
Үз тарихын, сүз тарихын барлап,
Гали Рәхим белән Г.Газизнең
Хезмәтенә[2] бага, өмет баглап).
Ул Такташны тәүге абайлаган,
Яңа йолдыз итеп таныган,
Кәләпүшен салып, башын игән
Тукай шигырьләре алдында.
Каюм Насыйриның язганнарын
Җыеп, җөпләп, көнгә чыгарган,
Янә бик күп асылташлар тапкан
Онытылу дигән чормадан.
Газиз исемнәрне кайтарган ул,
Йөзен тузан япкан чорлардан.

Татар җыры диеп җан җилпегән,
Халык сүзе диеп җилкенгән.
Бөртек-бөртек асыл моңнар җыйган,
Авыллардан, җирдән, ил-көннән.
Берәмтекләп васыятьләр җыйган
Онытылган каберташлардан.
(Чынга алсаң, җирдә һәрбер тарих
Каберташларыннан башлана,
Һәм нәкъ шунда төгәлләнә дә ул –
Бу хакыйкать инде бәхәссез.
Күпләр өчен җирдә кыйммәтебез –
Каберташларының бәһасе...)

Язган, язган, яна-яна язган –
Моң карашлы, кайнар йөрәкле.
Мә, алыгыз! Сутын илгә чәчкән,
Җылы, тере хәтер кирәкме?!
Казандагы мәшһүр уку йорты,
Сирәк кульязмалар бүлеге –
Татарларга гыйлем бирмәсә дә,
Кирәк монда татар гыйлеме…
Кирәк монда татар җегәрлеге,
Татар тырышлыгы, зиһене.
Кулъязмалар, ак күгәрчен булып,
Китапларга оча җилпенеп.
Күпме язма, күпме хезмәт монда
Хәтерлидер аның кулларын,
Күз нурларын түгеп һәр хәрефкә,
Тыңлаган ул чорлар моң-зарын.
Университетның елъязмасын
Барлаганда, тарих язганда,
Искә алынамы Гали Рәхим,
Хәлфин, Насыйрилар бармы анда?
Мәрҗаниләр, Галимҗаннар бармы?
Газиз Гобәйдуллин, Вәлиди..?
Татар иле олылыймы бүген
Игелекле татар галимен?
Казанында, туган Казанында –
Йөрәгендә татар йортының
Бу шәхесләр рухы дога көтә,
Бу исемнәр бара онтылып.
Алар гүя көн дә атылалар
Һәм аталар яңа таң сыман.
Шәхес олылыгын күтәрергә
Ил гөмбәзе һаман тарсына…

**7**

*Шау килеп даулый давыллар, җил исә.*
*Җил-давылларның эчендә мин исә*
*Нәкъ саламдай бөтереләмен әйләнеп,*
*Бер өермә очыртып алып китте исә.*

Гали Рәхим

Аксак дәвер килә. Зәһәр белән
Адым саен адәмнәрен таптап.
Кара таяк белән дегет сылый,
Ак кәгазьне мөһер белән таплап,
«Дошман» дигән кара тамга сала,
Ата, изә, сыта, сөрә, таптый...
Рухы гарип дәвер килә илгә –
Инкыйлабый дәвер – аксый-аксый.
Кем диеп соң дәшеп күрешергә?
Кемнәр диеп аңа кул бирәсе?

[2] Г.Газиз белән берлектә язган «Татар әдәбияты тарихы» хезмәтенә ишарә.

Корбан сорый, корбан таләп итә
Илдә кызыл төсләр кабиләсе.
Кан кызылы күреп шашынган да,
Карап тора – кыргый, хәтәр, ертлач.
Мәчетләрнең манарасын кискәч,
Китапларны учлам-учлам ерткач,
Туенмаган әле, корбан кирәк,
Адәми рух кирәк туеныргa.
Адәм каны кирәк, буялганчы,
Кызарганчы чумып коеныргa.
Кызыл төсләр кабиләсен җиргә
Чиру-чиру кирәк тудырырга...
Шул кабилә уртасында – Кеше,
Басып тора. Табан асларында
Җир шуыша, юкса үз җире бит,
Тәпи китеп, аяк басканы ла.
Үз җире бит, үз иле лә юкса,
Тирәсендә – белеш-танышлары.
Ник чалшайган әле сөйләмнәре,
Ник үзгәргән әле тавышлары?
«Буржуй» имеш, чит ил шпионы,
Язганнары – халык күзен буяу.
Андыйлар күп, имеш. Кабиләгә
Көн-таң атса, булу кирәк уяу.
Кыргый өер арасында – Кеше,
Таянырлык ник бер адәм калсын.
Кайберләрен «кара козгын» чүпли,
Чит илләргә чыгып кача кайсы.
Япа-ялгыз басып тора Кеше,
Ни дияргә, ни кылырга белми.
Ул бары тик Хак хаклыгын хаклый,
Бүтәненә орынмый да тими.

Ул бары тик халкы хакын хаклый,
Тарих, әдәп, әдәбият хакын.
Ул бары тик изге эшләр яклы,
Ул – халкына шагыйрь, чичән, акын.
Рухы имгәк дәвер уртасында
Таягына таянган да әнә
Басып тора аксак татар ире.
Бик авырдыр, бик шомлыдыр аңа.
Сабый чагында да, егылганда,
Шулай читен иде. Күтәрделәр.
Сынган аяк сызлый, ул – ятакта.
Үтәр, диләр зурлар, үтәр, диләр.
Кулларына китап тоттырдылар,
Савыкканчы, әйдә, укый торсын.
Кеше чатан булса булсын, мәгәр
Эче төзек, рухы дөрес булсын.
Ялгызлык һәм таяк... Штиблетының
Олтан түшәделәр сыңарына.
Аяк сындыруы сәбәп булды
Гамьсез балачактан чыгарына.
Ялгызлык һәм таяк – гомерлеккә
Иярделәр тугры юлдаш булып.
Ул дөньяга чыкты, күңеленә
Кояш нуры тулып, китап тулып.
Ул дөньяга чыкты
Кеше булып.

Ә дөньяда кайный, шаулый базар,
Адәм рухы – монда чутлы товар.
Кеше калебенең бәясе дә
Шәхесенең олылыгы кадәр.
Бәяләсәң әгәр.

**8**

*Менә ул – безнең олуг анабыз Идел, минем аяк астымда… Син безнең туган Иделебез, үз Иделебез идең ләбаса, ник үзеңнең балаларыңны ташладың? Ник безне әллә кемнәр синең шәфкатьле ярларыңнан сөрделәр? Ятлар, синең үги улларың, хәзер сине «Анабыз Идел» дип атыйлар. Кайчанга чаклы шуңа риза булып торырсың син? Чынлыкта син безнең анабыз идең, ничә йөз еллар безне үз кочагыңда тәрбияләгән идең! Тәкъдир какканга карап, ни өчен син дә безне кагасың инде, Идел?..*

Гали Рәхим «Идел»

Богауларммын, димә, Идел-суны,
Идел бит ул тирән, киң бит ул,
Дәрья гына димә, Идел бит ул!
Идел яры – туган ил бит ул.
Иделләрне богауларммын, димә,
Ирләренә богау салсаң да,
Идел суы һаман ага торыр,
Кизләүләре көйсез калса да.

...Ул Иделгә килде. Ул иелеп,
Күзләренә бакты Иделнең.
Идел күзләрендә – моң карашлы,
Дөньясыннан арган ир иде.
Идел күзләрендә үзен күрде,
Һәм таныды үзен, таныды.
Ул Иделен тапты, илен тапты,
Ул иленә монда табылды.

Дәрья өсләрендә акчарлаклар
Давыл юрап канат кагынды.
Дулкыннарда упкын шавы улый,
Каекларны куар чагыңмы?..
Дөнья ярын кага Идел суы,
Фирүзәдәй дулкын йөзендә
Күпме хисләр ярсып ярала да
Күпме гамьнәр шартлап өзелә.
Адәм баласының рухы белән
Фани тәне бәйле, богаулы.
И бәхетсез бәндә, бәдәнеңдә –
Кан кызуы, хәтер елавы,
Көенече, сөенече бергә,
Мәхәббәте, зары, нәфрәте...
Барысы да янә кабатлана –
Яшәешнең гореф-гадәте.
Барысы да кабатлана икән,
Кем аңыша, кемдер аңышмый.
Идел суы кебек ага вакыт,
Вакыт агышына карышмый,
Гомер төсле ага Идел елга,
Бер дулый да, берчә тын ала.
Гомер кичү – Идел кичү икән,
Каршы ярга кемнәр чыгала?..
И Иделем минем, Идел-анам!
Син безнеке идең, күптәнме?
Инде башкаларга «анакай» син,
Кочаклыйсың бүген бүтәнне.
Башкаларга багып ага, ахры,
Җылы дулкыннарың җай гына,
Идел буйларында ятим халкың
Үз Иделен, илен сагына.
Сагыш-әрнүләрен юарга соң
Дулкыннарың мәллә тышаулы?
Ул Иделгә таянырга базды,
Ул иленә чиксез ышанды.
Ул өзгәләп ташламакчы иде
Милләтенең үләт богавын,
Богауларга ул үрелгән чакта
Илләрендә иде болгавыр.
Ул умырып ыргытмакчы иде
Иркен бугазлаган ятьмәне,
Чумды, чәбәләнде, чорналды тик.
Дөньясының иргә ят мәле.
Кемнәр аңлар аның ярсуларын,
Кем үзсенер аның тавышын?
Идел болганганда, кем абайлар
Акчарлакның канат кагышын?
И Иделнең ялгыз акчарлагы,
Иделемнең очар канаты,
Ник ташландың упкын авызына
Канатларың ертып, канатып?
Күңелеңдә – фирүзә күк дулкын,
Күңелеңдә иркен киңлекләр.
Кунар урын эзләп атылдыңмы
Күк түреннән кубып, биектән.
Ихлас гамең ят тоелды монда,
Ихласлардан монда куркалар,
Җиргә иңгән акчарлаклар юлы
Лагерь, зинданнарда туктала...
Буш бу тормыш, монда син эзләгән
Матурлыкны каплый өркәклек.
Мәңге гүзәл гамьнәр төрмәсе бу,
Адәмнәре монда өрәк күк.
Шуңа күрә сине аңламаслар,
Танымаслар татлы җырыңны.
Хыял канатларың әрәм итмә,
Әрәм итмә җиргә җылыңны.
Чал Иделнең моңлы дулкыннары
Хәтерләрләр канат кагышың.
Син – илеңнең иләс акчарлагы,
Син – Иделнең әче сагышы.

...Ул Иделгә кайтты.
Дулкыннарда
Идел кичкән җаны чагылды.
Иделендә үзен таныды ул,
Ул иленә монда табылды!

**9**

*Күкрәгеңдәге ялкын белән йөрәгемне көлгә әйләндерергә тырышма – ул болай да күмерләнгән инде; янып торган утыңа таба тартма мине – мин аның саф ялкынын сөремләндерермен генә... Иман бир! Үзең өчен куркам мин...*

Гали Рәхим «Нәсер»

*Чөнки һәрвакыт, һәрвакыт серле сарайларда мин синең белән бергә...*

Гали Рәхим «Серле сарайларда»

«Гайшәм!
Телисеңме, мин күкләргә ашам!
Яңгыр булып киләм яныңа.
Богауланган давыл булып узам,
Чәчләреңә генә кагылам.

Күзләреңнән генә үбеп үтәм,
Керфекләрең тибрәр назымнан.
Мин һәрвакыт синең белән, бәгърем,
Мин һәрвакыт сине сагынам.
Тилмергәндә йотым суга анда,
Йотым җылы сүзгә, өметкә,
Лагерь капкалары тын торганда,
Ачылуын күпме көтеп тә,
Дала җилләренең каһәр тыны
Сарылганда тәнең, җаныңа,
Син бирешмә, бәгърем, син түзем бул,
Мин һәрвакыт синең янында.
Минем хисем, минем исем, әйе,
Кара ярлык синең өчен дә...
Оныткандыр диеп онытылма,
Син һәрвакыт минем исемдә.

Бердәнберем, бергенәм син минем,
Гомрем сыман, үлемем сыман да.
Син үкенмә, тик хәтерлә шуны
Сабыр канатларың сынганда:
Мин яраттым сине, гомерем буе
Тугры булдым шушы хисемә.
Син бирешмә, Гайшәм, озак яшә.
Яшә озак – минем өчен дә,
Бу дөньяга яралмыйча калган
Өзелеп көткән балам өчен дә...
Котылгысыз көзге яңгыр коя –
Синең күз яшьләрең төсендә.
Күзләреңнән үбәм, керфекләрең
Яңгыр булып үбәм һәрберен.
Мин һәрвакыт синең янәшәңдә,
Мин ...кичердем сине, бәгырем...»

**10**

*Тарих бар, аның кануннары бар. Гали Рәхим, Җәмал Вәлиди, Газиз Гобәйдуллиннарның билгесез каберләре бар. Ә ул каберләр безнең чәчәкле лоджияле, верандалы дачалардан, безнең абруйлы исемнәрдән көчлерәк. Көчлерәк…*

Мөхәммәт Мәһдиев

*Тормыш, ник син бу кадәр әшәке дә, ник синдә мин теләгән матурлык юк? Тормыш, ник син буш?*

Гали Рәхим «Җәйге нәсер»

Хатлар, хатлар – хата-ялгышларның
Елъязмасы, тарих ядкаре.
Ник китмәдең, Гали, Казаныңнан,
Тыңламадың Газиз әйткәнне:
«Күченеп кил, кардәш, Бакуга син,
Сәмәркандка күчен, булмаса...
Синдәй галим төрки галәменең
Һәр илендә тансык лабаса».
Казан якларында көн сүрелә,
Ил гөмбәзен кара шом баса…

Акыллылар кирәкми бу илгә,
Кара эшче булсын, кол булсын,
Уйсыз-юлсыз маңкорт булсын адәм,
Даһиларның эзе көл булсын.
Затлы татар, атлы татар монда
Кирәк түгел элек-электән.
Йортын баскан, батырларын аскан,
Чабатасын түргә элдерткән.
Мирасың шул, диеп ышандырган,
Ышанмыйча, төпкә бакканын
Зинданнарга салган. Затлыларны
Репрессияләр белән баскан ул.
...Мәче тычкан белән уйнаган күк,

Бер каптырып, берчә җибәреп,
Гали Рәхим белән уйный дәһшәт,
Тәмен белеп уйный, кинәнеп.
Утызынчы елда тоткын итеп,
Эшкә куа Балтыйк буена.
Империя «дошман» мәхбүсләрнең
Кан-күз яше белән коена.
Өч-дүрт елдан илгә кайта Гали,
Йортсыз-җирсез, ялгыз, ташландык.
Куәт кирәк җаның асырарлык,
Яңа көнне ялгыз башларлык.
Озаккамы көннең яктылыгы –
Ник эндәшми Казан урамы?
Муенына кара язмышлары
Шушы урамнарда уралды.
Назлама син, азгын Казан җиле,
Вәгъдә итмә якты иртәләр.
Күңел сынык, өстә кара болыт,
Утыз җиденче ел иртәгә…

Суык, суык, зыңлап торган суык,
Бу дөньяны җылытырмын, димә.
Үзең катып, бозга әйләнерсең,
Бу дөньяга тимә икән, тимә.

Кырлач төсле кыргын зинданнарда
Ак күбәләк кебек тапталып,
Хатынына, дусларына, илгә,
Заманага инде ят калып,
Тилмергәндә тынчу төрмәләрдә,
Тибендеме йөрәк түрендә
Сыңар өмет – берәр заман мине
Искә алырлар дип илемдә?
Иңнәрендә кырык иргә таман
Йөк күтәргән галим, ахырда,
Салкын зиндан идәнендә иңрәп,
Ак күбәләк төсле талпына.
...Кайтардылар аны. Шыр сөяккә
Калган гәүдә каткан, бөгелгән.
Моң карашы дөньялыктан бизгән,
Бугазына үлем үрелгән.
Чал Казанның Горький урамында
Дүртенче йорт асты – нәкъ шушы
Подвал инде «зэк» галимнең җирдә
Җан асраган соңгы куышы.
Суык монда, зыңлап торган суык,
Мичкә ягар сыңар утын юк.
Дәвер китте.
Гали, салкын мичкә
Арка терәп, калды утырып.
Илдә суык, зыңлап торган суык,
Җелегенә кадәр үтәрлек.
Гарип шагыйрь соңгы сәгатьләрен
Салкын йортта ялгызы үткәрер.
Ягылмаган мичкә арка терәп,
Катып калыр – шушы азагы.
Шагыйрь китәр.
Илдә кырлач калыр.
Җирнең җылылыгы азаер.
...Кул чанасы тартып икәү бара,
Мәет утырып бара чанада...
Чана эзен каплап, бурап-бурап,
Казан урамына кар ява.
Кырык өчнең өченче март көне.
Буран бурый, буран котыра.
Дәвер сөйрәп барган һәр олауда
Җансыз-сансыз шагыйрь утыра.
Олау бара татар зиратына,
Соңгы нокта, актык тукталыш.
Көн бураны адаштырмас аны,
Юл тапталган инде, юл таныш…
Бу зиратта каберлеләр сирәк,
Кадерлеләр сирәк отыры.
Эзен буран сара, чана бара
Татар зиратына туп-туры.
Адәм гомеренең кадерләре
Хәтерләүгә генә тәңгәл ул.
Мәшһүр Гали Рәхим кадере дә
Милләтенең хәтере кадәр ул.
Кабере булса икән баш иягә,
Хәтерлибез әле, дияргә…
Хәтерсезлек дигән кадерсезлек
Безнең арттан һаман ияргән.
Вакыт җиле исә безгә каршы,
Зиндан ишекләре шыр ачык...
Чанасында
Сансыз Шагыйрь рухы
Артыбыздан калмый барачак.



Марат
Кәбиров

# ТИК СИН ГЕНӘ*

ПОВЕСТЬ

**Автордан**

*Әсәрдәге барлык вакыйгалар, күренешләр, персонажлар, фактлар уйлап чыгарылган һәм аларның чынбарлык белән бер уртаклыгы да юк. Һәртөрле охшашлыклар, тап килүләр – очраклылык һәм алар беркемнең дә намусына тап төшерергә тиеш түгел.*

*Болай дип кисәтү дөрес. Ләкин әсәрне укыганда син, даими укучым, барыбер, тормышыбыздагы фаҗигаләрнең берсен искә төшерәчәксең. Котылгысыз рәвештә. Һәм син хаклы. Бу әсәргә нәкъ шул вакыйга этәргеч бирде.*

*Мин андый фаҗигаләрнең беркайчан да булмавын телим. Шуңа күрә әсәремдә «альтернатив тарих» тудырырга теләдем. Бу бер җирлексез түгел. Хәтта ниндидер көчләр тарафыннан эшкәртелеп, котылгысыз хәлгә калган очракта да кеше үзен хәтәр адымнардан саклау өчен көрәшә ала. Җиңеп чыгамы ул, җиңеләме – анысы башка мәсьәлә. Көрәшкә алынуы мөһим. Бу очракта аның җиңүенә өмет бар. Җиңү дә бер югалтусыз гына булмаска мөмкин.*

*Билгеле вакыйганы, билгеле персонажларны хәтерләтсә дә, бу әсәр – альтернатив тарих, димәк, тормышта булган вакыйганы бөтенләй башка яссылыкта күзаллау. «Ә бит шулай да була алыр иде…» дип уфтану. Билгеле бер факт нигезендә уйлап чыгарылган вакыйгалар тезмәсе.*

*Әсәрне укыганда да, аңа йомгак ясаганда да, шуңа игътибар итәрсең, ашык-пошык хөкем чыгарырга тырышмассың дип өметләнәм.*

*Ә хәзер без синең белән җитәкләшеп, коточкыч вакыйгалар дөньясына атлыйбыз…*

---

* Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе тарафыннан үткәрелгән конкурсның «Повесть» номинациясендә икенче урынны алган әсәр.

---

Марат КӘБИРОВ (1970) – *шагыйрь, прозаик; Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. «Онытма таңнарны», «Мәхәббәт яңгыры», «Китап» исемле китаплар авторы. Казанда яши.*

## 1

Кызның чәче-башы тузган, кашлары җыерылган, күзләреннән дәһшәтле очкыннар чәчелә иде. Ул нәфрәтле карашын Илнурга кадап, буарга теләгәндәй, ике кулын алга сузып, аның өстенә атлады. Килеп җиттем дигәндә, кулларын төшерде дә сөзәргә әзерләнгән тәкә кыяфәтенә кереп туктап калды.

– Козёл! Урод! – дип сөзеп чыгарды ул. – Кем син? Нигә кысылдың монда?

Илнур бераз аптырап калды.

– Сине яклыйсым килде...

Кыз отыры кызды гына.

– Ә син миннән сорадыңмы? – Берничә минут элек кенә ярыйсы ук матур булып күренгән кыз аждаһа кыяфәтенә керде. – Ә бәлки, миңа шулай ошыйдыр.

Егет берни дип тә әйтәлмәде. Бу аның өчен бөтенләй көтелмәгән хәл иде. Ит изгелек, көт явызлык дигәне нәкъ шушыдыр инде.

Һәм кыз җирдә аунап яткан егетләрнең берсенә чүгәләде:

– Пашка, ничек син?

Тегесе ыңгырашып кына куйды. Кыз аның башыннан сыйпап алды да карашын янә егеткә батырды:

– Нәрсә карап торасың? Шыл моннан! Туктап тор... Әгәр якын арада бу биләмәдән югалмыйсың икән, үзеңне әрвах дип уйла. Ә хәзер... Шайтаныма олак!

Илнур көлемсерәп куйды. Бу – кызык булган өчен түгел, ә дөньяның мәгънәсезлегенә аптыраудан туган көлемсерәү иде. Һәм китәргә ашыкты. Кыз да, кафе артындагы паркның агачлар куерак үскән урынында аунап яткан өч егет тә аңа кызык түгел иде инде.

Ялгышлык килеп чыкты. Ул кызны фаҗигадән араларга теләде, ә чынлыкта... Әллә нинди дөнья бу, шайтан алгыры. Нинди генә игелек эшләргә теләсәң дә, ул һәрвакыт үзеңә каршы кылынган явызлыкка әверелә. Тәүге карашка бер рәвешле булып күренгән нәрсәләр, асылда, бөтенләй башка төрле булып чыга.

Берәр бокал сыра чүмереп уйларын тәртипкә китерү ниятеннән, Илнур кафега атлады. Язгы төн үзенчә матур иде: ягымлы гына җил исеп куя, кошлар сайрый, үлән арасында чикерткәләр чекердиләр, тагын әллә нинди бөҗәкләр җыр суза. Җәй уртасы шикелле. Югыйсә, май башы гына бит әле. Әллә табигать тә бераз саташа инде. Шулайдыр. Бөтен галәм, бар дөнья, һәрбер кеше саташа торгандыр... Ә бәлки алай да түгелдер... Юк, барыбер саташадыр алар. Бу дөньяның нәрсәседер дөрес түгел. Менә ул үзенең унтугыз ел гомере эчендә генә дә... Юк, соңгы берничә елда гына да әллә нәрсәләр күреп бетерде. Һәм бер нәрсәне яхшы аңлады: ул – бу дөньяда беркемгә дә кирәкми торган кеше. Беркемгә дә. Ә бит бала чакта, мәктәп елларында өметләре зур, ышанычы ныклы иде. Ул дөньяда иң бәхетле, иң бай, иң данлыклы кеше булырга тиеш кебек иде. Моның өчен аның бөтен мөмкинлекләре дә бар – ирекле иле, халкы, үзе... Тик институттан куылып, эш эзли башлау белән, ул үзенең кем икәнен тиз төшенде. Ярый, ансы хакында иркенрәк вакытта. Ә монсы. Бүгенге, менә әлеге хәл...

Парк эчендәге кафеда иптәш егетләре белән сыра чүмергән җиреннән Илнур тәмәке тартырга дип, урамга чыккан иде. Болай, ачыган тәмәҗник түгел инде ул, авызына кергәндә генә бераз төтен суырыштыра. Кафе-ресторannарның яки рюмочныйларның да еш кунагы түгел. Әле монда утыруы иптәш егетләреннән азрак акча сорап торып булмасмы дип килүеннән генә иде. Ашыгыч рәвештә акча кирәк – кредитын бераз соңлатты, хәзер коллекторлар тынгы бирми. Менә шул... Иптәшләре кафеда кызлар белән танышып алдылар да Илнур алар янында ялгызы күңелсезләнеп утырырга теләмичә, тәмәке тартырга дип, урамга чыкты. Төнге лампочкалар нурында парк эче матур булып күренә иде. Саф һава. Кеше юк диярлек. Илнур кулындагы тәмәкесен колак артына кыстырып куйды да һава сулап, бераз әйләнеп килергә булды.

Агачлар куерак урынга җиткәч, бераз кысталганын чамалап, йомышын шул агачлар арасында йомышлап чыгарга теләде. Ешлык иде монда, ерактан да, хәтта якындагы сукмактан узып баручы да күрерлек түгел. Хаҗәтен үтәгән арада аларны күреп калды. Һәм эшнең кая таба барганын шундук төшенде. Өч егет бер кызны көчләргә азаплана иде. Икесе ике яктан кулын каерып тоткан, берсе учлары белән кызның авызын каплаган, өченчесе аның итәкләрен күтәреп, ыштанын салдырырга маташа. Кыз чәбәләнә, шыңшый, әмма аның тавышы ерак китәлми, авызы томаланган.

Фаҗига күз алдында иде. Чит-ятларның эшенә тыгылырга яратмаса да, Илнур бу юлы түзә алмады. Бәлки, сыра шаукымы да булгандыр инде бераз. Хәер, алай да түгелдер... Әлеге хәлне күрү белән үзенең Ләйләсен күз алдына китерде. Явыз егетләр кулында чәбәләнүче кыз аның сөйгән ярыдыр шикелле тоелды. Нәкъ шул сәбәпче иде. Ләйлә белән аралары өзелгән булса да... Барыбер... Кемнеңдер яратып йөргән кызы бит инде бу. Кемнеңдер сеңлесе, йә апасы. Кемнеңдер кызы. Һәм аны ниндидер өч егет көчләргә җыена. Әгәр берәү дә ярдәм итми икән, хәзер бу кыз өч егет кулыннан үтәчәк. Коточкыч хәл бит!

Һәм Илнур алар янына атлады:

– Әй, братан, тынычлан аз гына.

Егетләрнең өчесе дә чиксез гаҗәпләнү белән аңа төбәлде. Кызның ыштан төбен кармалап маташканы:

– Ты чё, мудак, совсем охирел?! – дип, сөзәргә җыенган үгездәй, Илнурга таба атлады. Тик килеп җитү белән сугышырга ашыкмады, егетнең иңеннән тартып, кафе ягына этәрде. – Монда безнең үзебезнең эшләр, братан. Бар, син үз юлыңда бул...

– Кызны җибәрегез, – диде Илнур тыныч кына.

– Син борчылма, братан. Ул үзебезнең кыз.

Илнур бераз аптырап калды. Шунда кызның сүгенгән тавышы ишетелде.

– Ычкын моннан!

Кызның авызын томалап торган егет бу якка атлый иде:

– Нәрсә сөйләшеп торасың, – диде ул иптәшенә. – Бәр дә ек. Теләсә кая борынын тыгып йөрмәс.

Һәм килгән уңайга Илнурның аяк астына төбәп, берне манчымакчы булды. Боксёр, дип уйлады Илнур читкә тайпылган арада. Гади егетләрнең берсе дә болай һөҗүм итми, йә турыдан бәрәләр, йә кырыйдан тарталар,

ә килгән уңайга астан бәрү өчен беркадәр әзерлек таләп итәлә. Бу егет әзерлекле иде. Тик ул дошманын гына дөрес сайламады. Илнур башын артка алды, һөҗүм итүченең йодрыгы борын очына тия язып узды. Илнур шундук башын ия төшеп, бер адым атлады. Бар авырлыгын алга атлаган аягына күчереп, муен тамырларын катырды. Асылда бу алга атлау түгел, ә сөзү иде. Үзе теләгәнчә үк килеп чыкмады, ул дошманының каш арасына манчырга теләгән иде, авызына туры килде. Тегенең коелган тешләре маңгай тиресен сыдыртты. Илнур аз гына артка чигенде дә терсәге белән егетнең чигәсенә бәрде. Бик дөрес булды, теге ике егет инде аңа һөҗүм итәргә тора иде. Илнур аякларын уйнатып алды. Берничә секундтан соң аларның икесе дә һушсызланып, җиргә ауды.

Илнур сугыша белә иде. Аның әтисе кечкенә чагыннан ук каратист булырга теләгән, ләкин ул чорларда бу тыелган нәрсә булган. Шуңа малаен бәләкәйдән үк кудо секциясенә биргән. Кудо – каратэ, дзюдо, тай боксы нигезендә барлыкка килгән сугыш төре. Аяусыз нәрсә. Тренировкаларда да чынлап сугышасың. Бу төр турында анекдот та бар. Русча инде.

– Нәрсә ул кудо?

– Әгәр сиңа берәрсе бәйләнә икән: «Куда-о?» – дисең дә берне манчыйсың.

Илнур баштагы мәлләрдә бик дәртләнеп шөгыльләнде. Ярышларда катнашып, урыннар да яулады. Тик соңыннан күңеле сүрелде. Бишенче класста укыганда, аңа сигезенче классның ике малае бәйләнде дә сугышып киттеләр... Илнур аяктан екты инде икесен дә, тик берсенең ияге күчкән булып чыкты һәм малайны милициядә исәпкә куйдылар. Илнур хаклы булгандыр инде, бәлки, тик үзенең хаклылыгын гына исбатлый белмәгәндер. Өстәвенә, теге малайның әтисе дә ниндидер зур чиновник булып чыкты... Сүрелде ул шуннан соң ничектер. Хәтта син иң зур җиңүләрне яулап дөньяда бердәнбер булсаң да, тормышта синнән дә көчлерәк кешеләр бар кебек тоелды. Шөгыльләнде, әлбәттә. Үзе дә ярата иде. Мәктәпне бетергәч тә, форма тоту өчен дип, үзаллы маташты әле. Меңәр тапкыр кабатланган алымнар исеңдә кала инде ул. Хәтта үзең аңлап өлгермәсәң дә, мускуллар хәтерли һәм алар нинди очракта ничек хәрәкәт итәргә кирәген беркемнән дә сорап тормый.

Әле дә шулайрак килеп чыкты. Илнур үзенең нәрсә эшләгәнен үзе аңлап өлгергәнче үк, егетләрнең өчесе дә җирдә ята иде. Ә көчләүгә эләгеп, харап була язган кыз бөтен нәфрәтен чәчеп аның өстенә килә:

– Козёл! Урод! Кем син? Нигә кысылдың монда?

Мондый хәлгә калган кыз бала аңа рәхмәт әйтергә тиеш кебек иде. Һич югы иңенә капланып еларга, һич югы... Берни дә әйтеп булмый бугай... Тик ул кыз болай кыланырга тиеш түгел иде. Илнур аның кыланышын аңлап җитәлмәде һәм үзен дә нокаутка китеп, җирдә аунап яткан теге егетләр хәлендә тойды.

Кафега кереп, берәр бокал сыра җибәрергә кирәк. Бергә килгән егетләре дә көтәдер инде... Бәлки. Ишек төбенә җитәрәк телефоны шалтырады. Таныш түгел номер булса да, ул сөйләшү төймәсенә басты һәм үкенеп куйды, тагын шул коллекторлар шалтырата иде.

– Әй, бөҗәк, синең бүгенге көнең дә үтеп китте. Бурычыңны кайчан кайтарасың?

Илнур кинәт кенә нәрсә әйтергә дә белмәде. Тавыш дәвам итте:

– Бөҗәк булсаң да, баш миеңдә сыр калмаса да, син бит яхшы беләсең – алган нәрсәне кайтарып бирергә кирәк. Син аны аңлый алырлык дәрәҗәдәме?

– Пош-шёл ты!.. – Илнур сөйләшүне туктату төймәсенә басты да ишек тоткасына үрелде.

**2**

– Сезнең дусларыгыз китте. Рәхим итеп, менә бу урынга утыра аласыз. Сезгә нинди эчемлек кирәк?

Кафеда халык күп, ә официант күрсәткән урын читтә иде. Бик әйбәт, әлегә аның беркем белән дә сөйләшәсе килми. Ресторан хезмәткәренә дә ялкау гына җавап бирде:

– Бер бокал сыра. Немецныкы.

– Ә сыра янына берәр нәрсә теләмисезме?

Теләми иде ул, тик җавапсыз да булмый:

– Кириешки.

Хезмәткәр блокнотына язды да китәргә ашыкты. Мондый хәерче клиент янында озаклап тору аның өчен дә авыр иде бугай. Ул киткәч, Илнур үзе дә җиңел сулап куйды. Аллага шөкер...

Казанда нинди генә кафелар юк инде. Грузин да, әрмән дә, чеченнар да, үзбәкләр дә, хәтта гарәпләр дә үз рестораннарын, кафеларын төзегән. Алар шәһәрнең бөтен почмагында да бар. Бары тик татарныкы гына юк. Бауман урамындагы «Татар ашлары» дигән кафе да хәзер башкача атала икән – Чәй йорты. Якында гына самогон йорты. Бик татарныкы кебек тә түгел инде ул... Хәтта Бауман урамында да татарлык юк...

Ә бу кафе урысныкы иде. Ничек кенә яманатын таратсак та, урыс ул, барыбер, үзебезнеке инде. Менә рус кешесе белән татарны янәшә бастыр – аерып алалмыйсың. Ул төрек тә, үзбәк тә, башкорт та түгел. Алар әллә кайдан аерылып: «Мин татар түгел!» – дип тора. Урыс үзебезнеке. Кафесы да шулай.

Стеналары агач бүрәнәләрдән, өстәлләр дә әллә имәннән, әллә бүтән авыр агачтан ясалган. Урындыклары да көч-хәл белән генә кузгатмалы. Өстәлләргә зәңгәр җеп белән чигүле ак җәймә җәйгәннәр. Идән уртасында чит-читләре бизәкләнгән кызыл палас. Түшәмендә вак-вак лампочкалар.

Артык әллә нәрсәсе дә юк кебек инде, тик ничектер күңелгә якын булып тоела. Гарәп яки үзбәк кафесына кереп, сыра эчеп утыралмыйсың бит инде. Бу Алланы мыскыл иткән кебек тоела. Ә монда барысы да иркен. Җайлы. Рәхәт. Монда барысы да сыя.

Иптәш егетләре китешеп беткән иде. Кызлар эләктергәч, шулай булыр инде, кайсы-кайда барып, үзләре генә калырга омтылырлар. Теләсә, бәлки, Илнур да шулай итәр иде, тик әлегә анда кызлар кайгысы түгел, Ләйләсен һаман оныта алмый, күңеле тулы мәхәббәт кыйпылчыклары. Өстәвенә, коллекторлар... Өстәвенә... Әле генә булган хәл дә тормышындагы гарип күренешләр чылбырының бер боҗрасы булып тоелды.

Илнурга гына шулай туры килде микән, әллә нindirәк дөнья булды

бу – берничек тә җай тапмалы түгел. Ул күңелен һәрвакыт тырмап торган мондый уйларга бирешмәскә тырышты. Бокалын ашыкмый гына суырды, ара-тирә кипкән икмәк капкалап куйды. Берни уйламаска кирәк, уйласаң, әллә нәрсәләргә кереп китәсең дә, яшәвеңнең бер мәгънәсе дә калмаган кебек тоела. Тик уйлары гына үзенә буйсынмады. Торым-торымга теге кызның кыяфәте калкып чыкты:

– Урод! Нигә кысылдың? Кем чакырды сине монда? Синең «ярдәм»еңә кем мохтаҗ иде...

Тормышның төрле мизгелләре була торгандыр инде аның. Тик мондый мизгелне Илнурның күңеле сыйдыра алмый иде. Булмый инде болай. Иң яхшысы, кайтып, үз бүлмәңә кереп бикләнергә дә музыка кушып куярга һәм шуның ләззәтендә йокыга чумарга. Йокы – бәхет, ул тормыштан арынып тору мөмкинлеге бирә.

Бокалының яртысына да төшмәстән, ул кафедан чыгып китте дә баягы парк аша үз өенә ашыкты. Көн бераз салкынайткан иде. Сыра сөреме шушы салкынлыктан туңып, кубып төшкәндәй булды. Уйлар да бер-берсенә ялгана башлады бугай. Ялгышты ул, хата булды барысы да... Беркемгә дә яхшылык эшләргә кирәкми иде... Бер фильм бар бит әле... Зомбилар турында... Ничек аталганын хәтерләми инде Илнур. Анда зомбилар гарип итеп күрсәтелми, барысы да нормаль кеше кыяфәтендә – кайберләре хәтта костюм-галстуктан, үзләрен итагатьле итеп тоталар. Ә иң хәлиткеч мизгелдә, аларның зомби булуы, үз теләкләрен үтәү өчен хәтта кеше ашарга да әзерлеге ачыклана. Бу тормышта да шул ук хәл диярлек. Тыштан караганда, барысы да гадәти кеше шикелле. Ә чынында... Зомби булып чыга...

Уйларына бирелеп барганда, колагына таныш тавыш килеп бәрелде:

– Әнә ул! – дип кычкырды хатын-кыз тавышы. – Тотыгыз... Әнә!..

Бу аның үз башында, үз уйларында яңгыраган ялгыш тавыш шикелле иде. Тик алай булып чыкмады... Илнур, нәрсә булды икән дип борылып караганчы, кемдер аның арт чүмеченә нindидер каты нәрсә белән тондырды. Дөнья йөзеп китте. Илнур беркадәр чайкалып торды да җиргә ауды.

– Коткаручы! – дигән тавышы ишетелде кемнеңдер. – Вәт, менә синең дә чират җитте...

Коткаручы... Әйе шул, ул ниндидер кызны көчләнүдән коткарырга теләгән иде... Тик хаталанган булып чыкты. Беркемне дә коткарырга кирәкми икән... Хәтта ярдәм сорап кычкыручыларны да... Коткарган хәлдә дә бу халыкны, бу илне дәррәү рәвештә коткарырга кирәк. Барысын берьюлы. Ә ул... Һәм менә... Аны инде берәү дә коткармаячак. Ярым һушсыз булып, җиргә егылган егетне берничә кеше аяусыз типкәли... Илнур башын капларга тырышып бөгәрләнеп ятты. Башыңа басып сикерүләре дә бар. Рәхимсез хәзер кешеләр. Тик барыбер тәненең төрле урыннарына эләккән аяк эзләреннән сызлану кала иде. Ерактан ниндидер авазлар ишетелә:

– Һә, коткаручы булырга теләдеңме?...

– Герой буласың килдеме?..

Һәм башта калкып чыккан уйларны да өзәрлек итеп тибәләр. Типсә тимер өзәрлек, дигән сүз бар бугай... Болар уйларны да өзә...

«Герой буласың килдеме?..» Әллә нинди сәер дәвер бу... Батырлык хөрмәттә

булырга тиеш бит инде, үз геройларын кешеләр югары бәяләргә, аларга тиңләшергә омтылырга тиешләр. Һәрхәлдә, элек-электән шулай килгән. Ә бүгенге тормышта ниндидер батырлык кылган кешеләргә сантыйга караган кебек карыйлар: акылы аек, психикасы дөрес булса, кеше мондый адымга барырга тиеш түгел, дип уйлыйлар. Хәтта үткән заманнарның каһарманнарын да төрлечә пычратырга, аларның бөеклеген кимчелек итеп күрсәтергә теләүчеләр бар. Намус, гаделлек, кешелеклелек кебек төшенчәләр дә шундый ук хәлдә. Әгәр кем беләндер сөйләшкәндә, бу хакта авыз ачасың икән, ул сине тыңлап та тормый, йогышлы чирең барлыгын белгәндәй, тиз арада китәргә ашыга. Монда да нәкъ теге фильмдагы шикелле: тышы бер төрле, эче – бүтән. Кешеләрнең генә түгел, хис-тойгыларның да, һәртөрле билгеләмәләрнең дә...

Ә аның чынлап та герой буласы килә иде. Үз Ватанын илбасарлардан азат иткән ата-бабаларына тиң егет булырга тели иде. Ил бит инде ул. Илне ирләр якларга тиеш. Халык өчен, илдәге кешеләр өчен ирләр җаваплы булырга тиеш. Тик аның бу теләкләрен уртаклашырга атлыгып торучы юк, шунлыктан җаны телгәләнә һәм тормышның һәр күренеше диярлек җан җәрәхәтенә тоз сипкәндәй тоела иде.

* * *

Кеше нинди авыр хәлләргә калып, кайларда гына егылса да, аның яклаучы фәрештәсе була, диләр. Аңа да үз фәрештәсе килеп сарыла. Җирдә бөгәрләнеп яткан гәүдәсен канатлары белән каплый да:

– Хәлең ничек синең? – диеп сорый.

– Ыһһы, – дип җавап бирә Илнур һәм керфекләрен күтәреп карый. Төнге парк караңгылыгын ертып, якты нур булып аның янында фәрештә басып тора. Йөзеннән ягымлылык, наз, ярату бөркелә. Илнурны ышыклар өчен җәелгән канатларыннан якты нур тама.

– Тор, – ди ул. – Монда ятма. Никадәр авыр булса да, торып басарга тырыш. Аунап ятучыларның кадере юк. Хәтта алтын булсалар да.

Илнур торырга маташа. Тик буыннары тотмый. Егыла.

– Син көчле, – дип, дәрт өсти фәрештә. – Син аягыңа басарга тиеш.

Илнур тагын торырга маташа, дүрт аяклап, сабый бала сыман мүкәләп, беркадәр бара, аннан бераз күтәрелә төшеп, аякларына баса да чайкалып тора. Тирә-ягына каранып ала. Нәрсәләр булганын, үзенең ничек шушы хәлгә төшкәнен хәтерләргә тырыша. Төн. Караңгылык. Агачлар. Кошлар тавышы. Кайдадыр якында машиналар шавы ишетелә... Бөтен тәне сызлый. Сулыш алган саен нәрсәдер чәнчеп-чәнчеп куя. Аз гына көчәндергән саен аяк буыннары өзелеп китә... Нәрсә булды соң бу?

– Кыйнадылар сине, – ди фәрештә, аның йөзе күренми, сүзләре ишетелми, ни әйткәнен Илнур сүзсез дә аңлап тора. – Синең яхшылыгыңа кабахәтлек белән җавап бирделәр.

Һәм ул барысын да исенә төшерә. Күңелен чиксез әрнү биләп ала. Ул бит яхшылык эшләргә, кемгәдер ярдәм итәргә теләгән иде. Ләкин аның яхшылыгын кабул итмәделәр... Гомер буе шулай булды бугай. Кабул иткән хәлдә дә гариплəп кабул иттеләр. Әйбәтлеккә урын юк микәнни соң бу дөньяда?

– Кешеләргә беркайчан да яхшылык кылма, – ди фәрештә. – Аларның берсе дә моңа лаек түгел. Хәтта эти-әниең дә.

Аның соңгы сүзе бик сәер булып ишетелә. Әти-әниләргә игелек эшләргә кирәк. Монысы канга сеңгән нәрсә. Шуңа Илнур:

– Кем син? – дип сорарга мәҗбүр була. – Ник алай дисең?

– Мин – синең фәрештәң. Син – минем Аллам.

– Мин Алла түгел.

Фәрештә елмайган кебек итә:

– Син – Алла. Синең кебек әйбәт кешеләрнең барысы да – Алланың бер өлеше, димәк, Алланы улбербөтен итүче.

– Ә калганнары? – дип сорый егет, үзе яклашырга теләгән теге кызны күз алдына китереп. – Калганнары кем?

– Алар – чүп.

Ә бәлки чынлап та шулайдыр ул. Үзенә карата кылынган игелекне кабул итә алмаучылар, аңа начарлык белән җавап кайтаручылар, бәлки, чынлап та чүптер... Ләкин фәрештә Илнурга уйланып торырга ирек бирми.

– Син өеңә кайт, – дип таләп итә. – Әле без тагын очрашырбыз.

Һәм юкка чыга.

* * *

Фәрештә юкка чыгу белән Илнурның күз алдында ир-егет гәүдәсе пәйда булды. Кыйналудан томаланган аңы белән егет аның кем икәнен аңлап бетерә алмады. Уртача буйлы. Ныклы гәүдәле. Ул китәргә җыенган җиреннән тукталып, Илнурның чайкалып атлаганын бераз карап торды да кире килеп култыклап алды. Куллары көчле иде.

– Ярый, болай кайтып җитәлмисең инде син. Әйдә, безнең Үзәккә кагылып чыгабыз. Өс-башыңны карарсың, үзеңне тәртипкә китерерсең...

Тавышы баягы фәрештәнеке кебек иде. Шулай да Илнур бер таныш булмаган бу кешегә ияреп, каядыр китәргә теләмәде. Бүген күргән маҗаралары да бик җиткән иде.

– Юк, мин өйгә кайтам, – дип, кырт кисте ул. – Бары тик өйгә генә.

Таныш түгел кеше карышмады:

– Яхшы, – диде ул шул ук ягымлы да, таләпчән дә тавыш белән. – Мин сине илтеп куям. Ерак яшисеңме?

Илнур ерак яшәми иде. Шушы паркны чыгып, бераз атларга гына кирәк. Теге егет артык сүзгә бирелмичә генә култыклап, подъезд төбенә кадәр озатып куйды. Һәм түш кесәсеннән алып, визитка суздыy:

– Әгәр кирәк булсам, теләсә кайсы вакытта шалтырат, йә үзең килеп чык.

Илнур визитканы алды да бер мәлгә аптырап калды. Ул томанлы аңы белән дә чамалый иде, бүгенге чорда чит-ят кешеләр бер дә юктан гына игелек итми. Димәк, бу адәмгә дә нәрсәдер кирәк.

– Кем син? – диде ул, аны исендә калдырырга тырышкандай, күзләрен кыса биреп. – Нигә миңа ярдәм итәсең?

Тик бернәрсәне дә хәтеренә сеңдерерлек хәлдә түгел иде, шулай да таныш түгел егетнең сизелер-сизелмәс елмаюын күрә алды.

– Әйбәт кешеләр бер-берсенә ярдәм итәргә тиеш, чөнки без шулкадәр аз калдык.

Әлеге сүзләр Илнурның аңына барып җиткәнче беркадәр вакыт узды.

– Шайтан алгыры! Ә син каян беләсең минем әйбәт икәнлекне.

Бу юлы егет кычкырып көлеп җибәрде:

– Бу заманда әйбәт кешеләр һәрвакыт кыйнала... – Һәм кулын сузды. – Мине Джон дип йөртәләр...

– Илнур...

Кул кысыштылар да, Джон китәргә ашыкты:

– Ярый, Илнур, очрашырбыз әле... Ә син шалтырат, йә үзең килеп чык. Ярдәм һәрвакыт булачак.

Ул киткәч, Илнур беркадәр подъезд алдындагы эскәмиядә утырып торды да авыртудан авыр сулый-сулый, чалыш-молыш адымнар белән фатирына атлады.

**3**

– Уф, Аллакаем!.. – дип каршылый әнисе. – Тагын хәмер исе килә! Әллә шуышып кайткансың инде. Киемнәрең катып беткән, йөзеңдә нур әсәре калмаган. Нишләтергә инде сине, ә?!

Илнур фатирга уза. Гади генә ике бүлмәле фатир. Обойлары күптән алыштырылмаган, стеналарының кыек икәне әллә кайдан күренеп тора. Совет чорыннан калган агач плинтусның буяулары кубып беткән. Элек алар өч бүлмәледә яшиләр иде. Анысы да артык затлы түгел, шулай да адәм рәтлерәк иде. Абыйсына бер бүлмәле яхшы фатир алыр өчен анысын саттылар да менә шушында яши башладылар. Абыйсының акчасы да бар иде. Чиновник бит! Бер файдасызга ыштан туздырып утырса да, акчаны чамасыз түлиләр. Хәзер ул фатирын курчак өе сыман бизәп бетергән инде. Бер бүлмәле дип кенә аталса да, квадраты зур аның – йөз метр, бу ике бүлмәле фатирдан ике тапкырга зуррак. Абыйсы шунда берүзе яши. Ә Илнур әти-әниләре белән шушында гомер сөрә. Ярый, берни әйтеп булмый инде монда...

Әнисе эттән алып, эткә салып сүгә.

– Ичмасам, йөзендә дә бер нур әсәре калмаган бит...

Илнур дәшми. Ни дип әйтәсең инде. Хәер... Бәлки, әйтеп караргадыр... Әйтергә кирәк...

– Әни, мин бер кызны яклашкан идем...

– Бар әле бар, юкны сөйләп торма. Юын башта, киемнәреңне алыштыр. Бу кыяфәтеңдә идәнгә дә яткырырлык түгел.

Илнур ванна бүлмәсенә уза. Яшелле-зәңгәрле-күкле төстән торган стеналар. Әтисе бер исерек чагында әнисенең чәйнәшүенә үртәлеп, иске плиталарны кубарып ыргытты да эшләп бетерерлек көч табалмады. Хәзер бу бүлмә дөньяның бер ташландык почмагын хәтерләтеп тора. Тутыга башлаган иске ванна хәерчелеккә тагы да бер деталь өсти. Илнур ваннаны чистарта торган порошок алып кайтып, бик яхшылап ышкып ялтыратып куйган иде бер заман. Әнисе сөенде башта, тик әтисе:

– Син нәрсә, эткәңнән алда йөрисең? Үзеңне күрсәтәсең киләмени? – дип шелтәләгәч, әнисе дә Илнурга кул селтәде.

– Болай гына итеп әтиең ярты сәгатьтә буяп чыга аны, менә син яңа ванна табып кара, – дип сөйләнеп алды.

Югыйсә Илнур хаклы иде бит инде. Аларның барлы-юклы акчасы белән ванна алыштыру әлегә җиңел түгел, ә болай ул күпмедер вакытка матур булып балкып торачак иде.

Стеналарын матурларга тырышып та, ПЖХ панельләре алып кайтты, тигез итеп, бер-берсенә беркетеп куйганда, ул бик әйбәт булып торачак иде. Дус егетләренең берсе шулай эшләгән. Илнурның бер атна буе йөк ташып җыйган акчасына шул дус егете белән барып алдылар. Тик әтисе моны күрү белән каршы төште:

– Кит әле, эт җыккан малай, кулыңнан килмәгәнгә нәрсә дип кысылып йөрисең. Шундый нәрсәне кеше ваннага куямыни. Плитка җәйдертәм.

Дус егетләрендә андый панель күптәннән тора һәм бернәрсә дә эшләми иде. Әтисе кире каккач, башка юл калмады. Илнур алып кайткан әйберләрен кире илтеп тапшырды.

Күңеле дә сүрелде. Әтисе яратмады, әнисе ирен хуплады, абыйсы мәсхәрәле елмаеп кына карады. Кулыңнан эш килмәгәнгә, печтәнләп йөрмә, янәсе. Абыйсын яратмый иде Илнур. Ниндидер астыртынлык, мәкер бар иде анда.

Аның ихлас күңелдән ярдәм итәргә теләве, иң кадерле кешеләренә көтелмәгән яхшылык ясарга маташуы үзенә аянычлы халәт булып кайтты. Беркемгә дә бертуктаусыз ярдәм итеп булмый. Хәтта ул үзеңнең әткәң-әнкәң булса да. Алай гына да түгел әле ул... Синең яхшылыгыңны ятлар бәяли алмаска мөмкин... Ләкин синең игелегеңне, яхшылыгыңны, ихласлыгыңны бәяли белмәгән ата-ана иң кабахәт кеше булып күренә. Чөнки син аларга ышанасың, бөтен күңелеңне әйләндереп саласың, кесә төбендәге соңгы тиеннәреңне кырып бирәсең – ә алар моны күрә һәм бәяли белми. Дөньяның бөтен чит-ят кешесе рәхмәт укыр иде, ә болар уйлап та бирми. Тиргиләр әле өстәвенә... Бала гына булгач, аны без карап үстердек, ул безнең өчен чәче белән җир себерергә тиеш дип уйлыйлар микән? Ата-аналар, сез нәрсә, балаларыгызны үзегезгә мәңгелек кол булсын дип табасызмыни?

Кеше үзаллы фикер йөртә алган көннән алып беркемгә дә буйсынырга бурычлы түгел. Хәтта ата-анасына да. Сез аның күңеленә мәхәббәт сеңдерә алгансыз икән, ул сезгә һәрдаим ярдәм итәр. Әмма ул сезгә бурычлы түгел. Ул шәхес һәм сезне дәвам итүче буларак бурычын түләгән инде. Сезнең аңа басым ясарга бер хакыгыз да юк. Балагызның өлкәнлеген һәм үзаллылыгын кичерә алмыйсыз икән, тапмаска иде.

Әллә мин теләп алган балагыз булмадыммы? Кемнеңдер бәйрәменнән эчеп кайткач котырып киткән хисегезнең нәтиҗәсе идемме? Кинәт ялкынсынып киткән тойгыларның физиологик чагылышымы? Яки арзан хакка сатып алган саклагычыгыз ертылып киттеме? Яки аборт ясатырга соңлаган булып чыктыгызмы, акчагыз җитмәдеме? Ни өчен яратмыйсыз соң? Әти-әни үз баласын яратырга тиеш бит инде... Хәтта сез мине ялгышлык нәтиҗәсе дип уйласагыз да, Ходай сезгә баланы бер дә юктан гына бирмәгән бит. Бу кешеләрнең дә җаны, каны дәвам итсен, болар да мәңге яшәү бәхетенә лаек булсын дип, баланы ул сезгә ышанып тапшырган. Бала – сезнең киләчәк тормышыгыз. Бала – ул мәхәббәтнең, гомернең дәвам итүе. Ул кешенең гомерен мәңгелек итә торган көч...

Бу үпкәләү дә, күз яшьләре дә түгел иде. Бу әрнүле тойгыларның аң белән кушылып, кан тамырлары буйлап агуы, җанның чәбәләнүе иде. Ул бар нәрсәдән котылырга теләп, күзләрен йомды. Күзләрне вакытлыча йомып кына котылып булмый шул, котылырга теләсәң – аларны мәңгелеккә

йомарга кирәк. Тик мәңгелеккә йому өчен дә көч таләп ителә, бу һәркемнең кулыннан килми – вакытлыча күзеңне йомганда да, керфекләрең калтырана башлый икән, мәңгелек турында нинди сүз булсын инде.

Илнур да бик теләп, үз-үзенә кул салыр һәм күңелен игәүләгән тойгылардан бөтенләйгә котылып калыр иде. Тик мондый адымга барыр өчен ниндидер чиктән ашкысыз зур сикәлтә кирәк. Үкенүдер бәлки... Бәлки, бөтен нәрсәдән өметең өзелеп, яшәү мәгънәсен чуалтудыр. Юк... Берничек тә әйтеп була торган хәл түгел... Тик Илнурның бүген үләсе түгел, ә үтерәсе килә иде. Ул бар. Ул хаклы. Һәм ул гел авыр хәлгә кала... Хаклылар һәрвакыт авыр хәлгә кала икән, димәк, бу җәмгыятьтә нәрсәдер дөрес түгел. Димәк, мондый җәмгыятьне юк итәргә кирәк... Һәм яңадан төзергә...

Кран төбеннән су тамчылап тора иде. Илнур суны ныграк агызгач, тамчы тавышы кечерәеп калды, ахырдан, колак өйрәнгәч, бөтенләй ишетелми башлады. Ләкин әнисенең ачы тавыш белән чәйнәкләп йөрүен су чыжылдавы да баса алмады. Ул тавыш һаман һөҗүм итте, һаман җанны талады:

– И, үз бәхетсезлекләремә генә тапканмын икән! Ни укый, ни эшкә урнаша алмады... Шул хәтле бала булса да булыр икән, югыйсә өсте бөтен, тамагы тук булсын дип, күпме тырыштык бит инде... Аңламаса да аңламас икән кеше... Кабахәт! Җир бит! Эчеп кайткан бит... Аягында да басып торырлык түгел...

Илнур суны кушты. Ишетәсе килми бу сүзләрне. Болай да бөтен тәне сызлый, болай да җаны әрни... Ләкин әнисенең сүзләре бөтенләй басылып калмый, барыбер ишетелә.

– Абыйсыннан үрнәк алсын иде, ичмасам. Абыйсы кебек булсын иде... Балакаем, үз тырышлыгы белән әйбәт эшкә урнашты, кеше булды...

Абыйсы турында искә төшерү Илнурның җанын тагы бер тапкыр айкап чыгара. Ул су агымын көчәйтә төшә. Ванна шүрлегеннән наушнигын табып, телефонындагы музыканы акырта. Менә хәзер рәхәтрәк, һич югында әнисенең тавышы ишетелми.

Һәм дөньяга булган рәнҗешләренең барсын да үз шүрлегенә куярга азаплана.

Әти-әнисен беркадәр аңлый инде ул. Күңеле белән алар ягында. Гомер буена намуслы хезмәт итеп, гаделлек яклы булып яшәгән гади кешеләр. Бөтен тапканнары – хәләл көчләре белән. Ләкин мөлкәткә табына торган дөньяда алай итеп яшәп, бернигә дә ирешеп булмый икән. Алар да берьюлы әллә ничәшәр эштә эшләсәләр дә, артык мантый алмадылар, гомер буена очын-очка ялгап гомер иттеләр.

Гаделлек юк. Ул хәзер инде беркайчан да булмаячак. Әмма аның этисе дә, әнисе дә гаделлек, намус бар дип яши торган чорда тәрбияләнгән кешеләр... Менә шул кешеләрнең дә алама ягы була икән. Алар югары урыннарда утырган абзыйлар янында үзләрен хезмәтче кебек тоялар, бер алдына, бер артына чыгып бөтереләләр... Шуларны күзәтеп торганда, аларның намуслы булуы да, гаделлеге дә ташка үлчим генә булып тоела.

Бер карасаң, чынлап та шулай бугай ул... Болар бит чын гаделлек кешеләре түгел... Болар үзләрен изүче система нәрсәне гаделлек дип әйтсә, шуңа табынып гадәтләнгән кешеләр. Шуңа күрә дә зур чин ияләре алдында бөтерелеп торалар: үзләренең тугры, намуслы, гадел икәнлекләрен исбатларга

телиләр. Наданлык, чикләнгәнлек бәласе бу. Аны берничек тә бетереп булмый бугай. Коллыкның бер чагылышы. Коллык ул, бәлки, берничә буында гына чыгып та бетмидер әле. Ата-аналарның коллыгы балаларына да күчә, хәтта башбирмәс улларын да елан сыман буып, урап алырга маташа.

Ләкин намус һәм гаделлек дәверләрдән өстен төшенчә. Хәер, бүгенге бурлар заманында намус турында сөйләү үзе үк сантыйлык билгесе булып тоела. Тоелсын! Дөнья ул бүгенге көн белән генә бетмәгән һәм бетмәячәк тә, ул киләчәктә дә дәвам итәчәк. Ә бүгенгенең патшалары иртәгә мескенлекнең аръягындагы кешеләр булып калырга да мөмкин. Мескенлек ул күңелдә була һәм адәм баласын аннан бернинди мөлкәт дә, шөһрәт тә, дан да коткара алмый: еллар узган саен кешелекнең карашы югарырак күтәрелә, югарыдан караган саен бар да ачыклана төшә – монда инде вәгъдәләр куагына, дус-ишләр чытырманына яшеренеп калалмыйсың.

Ләкин тарих – киләчәк төшенчәсе. Ул вакытта инде бүгенге кешеләрнең дә, аның белән кызыксынучыларның да булмавы мөмкин. Ә киләчәк кешеләренә үткәннәр кызык түгел. Үткәннәрне өйрәнүнең нәтиҗәсе бер генә: үзеңнең икенчел икәнеңә төшенәсең – сиңа кадәр дә кемдер яшәгән, авыр шартлардан чыгу юлын таба белгән һәм ул синнән дә аңгырарак булмаган. Киресенчә, ул бүгенгедән дә катлаулырак чорда синнән дә әйбәтрәк яшәгән. Шулай булгач, бүгенге заман геройлары тарих күзенә карарга теләми: йә ул үзе үткәннәргә күз йомып карый, йә тарихның күзен йомдырырга тырыша. Төрлечә килеп чыга. Тарихның бик үк дөрес түгеллегенә тарих үзе шаһит.

Ә тарихны бүген ясаучылар бүгенге чорда яши. Аларның чын сыйфатларын бүген күреп булмый, кулларындагы акчаны һәм властьны файдаланып, алар үзләрен гел әйбәт итеп күрсәтергә тырыша. Аларның әйбәтлегеннән кайвакыт халыкка да бер-ике тиен төшеп кала. Әй, сөенә инде халык, шушы кешеләргә рәхмәт яудыра, мәдхия укый, озын гомер тели. Чөнки аның шушы ике тиеннән дә артыграк рәхәтлек күргәне юк. Ул аңа омтылмый да бугай... Ләкин сүз үз мескенлегеннән үзе тәм табып яшәүчеләр турында түгел. Сүз шушы мескенлектән котылырга теләп тә, бернигә ирешә алмаучылар турында. Кемдер мөмкинлек бирми. Ул үзен иң асыл, иң могтәбәр зат итеп күрсәтә.

Илнурның абыйсы белән нәкъ шундый хәл инде. Ул укуын да матур гына тәмамлады, тиз генә яхшы урынга да урнашты. Бик начар да егет түгел инде үзе, тик бераз вакчылрак кына. Һәр нәрсәсен чутлый торган. Чәйнәшә торган. Илнур аны беркайчан да абыйга санамады. Егет түгел иде ул. Сугышкан җирдән ташлап качарга, соңыннан әләкләшергә мөмкин. Сөйләшү рәвеше дә артык итагатьле... Хәтта кул хәрәкәтләре дә балериналарга тартым... Соңыннан белде инде Илнур аның кемлеген... «Абыең кебек булсаң...» – дигән сүзләргә җене котыруның сәбәбе шул иде. Бу дөньяда син нindидер җылы урында утырып, тәртипле булып кына яшәргә тиеш. Шундый булсаң, хәтта эткәң-әнкәң дә ярата. Ә «зәңгәр»легең берни тормый. Хәтта эткәң-әнкәң өчен дә.

Менә бу – гомере буена намус саклап, гаделлек яклап йөргән кешеләр. Сине намуслы итеп тәрбияләгән кешеләр. Син аларга карап үскәнсең, шуларныкы дигән юл белән киткәнсең... һәм... алар да сатлык җаннар булып

чыгамы? Әгәр җиңел юл белән үзенең арт шәрифенә җайлы кәнәфи тапкан кешене алар сиңа үрнәк итеп куя икән, монда нишләргә? Өзгәләнергә генә... Әгәр синең өзгәләнүләрең иң якын кешеләреңә дә ят икән, ары нишләргә? Ватылырга, сатылырга, сытылырга: «Әти-әни, шайтаныма олагыгыз, сезнең бөтен тәрбиягез ялган булган, мин сезнең ялганыгызга ышанган өчен бәхетсезмен...» – дип еларгамы?

Ул абыйсы кебек «авыру» да түгел, төшемле урыннарда ыштан туздырып утырырга да теләми иде. Кулыңнан берни килмәгән килеш, талантлы шәхесләрнең урынын биләп, зур хезмәт хакы алып утыру үзе үк бер җинаять бит инде. Пассив җинаятьчелек. Шуңа күрә әнисе әйткәннәрнең иң җанына тигәне – абыйсын үрнәк итеп куюы иде. Кирәкми. Куймасын. «Андый» булсаң бул, тик тормышта нинди дер урының булсын дигән кебек бит инде... Нәрсәңнедер биреп, нәрсәгәдер ireш, дигән шикелле. Бу Илнурның күңеле кабул итә торган кыйбла түгел иде.

Абыйсы шундый булгач, аңа да тәкъдим ясаучы ир-атлар табылды. Тик егет моны кабул итә алмады. Аның сөйгән кызы бар иде. Дөресрәге, яратып йөргән кызы. Яратып йөргән... Укудан куылуына да шул сәбәпче булды инде...

**4**

Ләйлә белән ул кайчан танышканын да хәтерләми. Күрше подъездда яшәгән Нәфисә апа белән әнисе бергә эшләгән, ахирәтләр булып бик тату гомер иткәннәр. Шуңа күрә, балалары да әле берсендә, әле икенчесендә үскән. Илнурның әнисе эштә чагында, Нәфисә апа караган, Нәфисә апа сменасында – Илнурның әнисе. Имчәк баласы чагыннан ук шулай. Ә инде тәпи баскач, ишегалдындагы балалар мәйданчыгында бергәләп уйнаулар, бүтән балалардан аерылып китеп, якындагы паркта адашып йөрүләр... Сабый чак маҗараларының барысын да хәтерләп бетерерлек тә түгел хәтта, алар бүтән тормышта, бүтән кеше белән булгандыр кебек тә тоелып китә.

Тик бер нәрсәне ачык хәтерли Илнур. Әти-әниләре дә аны гел искә төшереп, онытырга ирек бирмәделәр бугай. Үзе дә гел хәтерләп елмаеп куя торган булды. Ләйлә дә кайчагында: «Син бит миңа ияреп барып кына хәреф танырга өйрәндең», – дип шаяртты.

Ләйлә Илнурдан өч айга өлкәнрәк иде, шуңа аны мәктәпкә бирделәр. Илнурның җиде яше ноябрьдә генә тулачак булгач, киләсе елга калдырырга уйладылар. «Мин дә барам», – дип караса да, әти-әнисе артык игътибар итмәде. «Быел чыгымнарыбыз да күп, киләсе елга калуың яхшырак», – дип, кул гына селтәделәр. Шулай да булгандыр инде, ул елларда бөтен мәктәпләр дә диярлек ата-аналар акчасына яшәде. Класс бүлмәсен төзекләндерергә дә, җиһазлар алырга да, концерт-театрга йөрергә дә, бөтенесенә дә гел акча сорыйлар иде. Ләкин Илнур әле моны аңламый, бар дип тә белми, аның бөтен теләге – Ләйлә белән бергә булу. Шуңа күрә, ул беренче сентябрь көнне матур киемнәрен киде дә Ләйләгә иярде.

Бәйрәм тантанасында да җитәкләшеп басып тордылар, соңыннан да укытучыга ияреп, сыйныф бүлмәсенә бергә уздылар. Укытучы апа, яшь кенә чибәр кыз инде, исемлек буенча тикшереп чыкты. Илнур ул исемлектә юк иде.

– Нишлибез инде хәзер синең белән? – дип көлемсерәп, малайга текәлде ул. – Документларың монда булмагач, сине мәктәпкә алып булмый бит.

– Минем укыйсым килә, – диде Илнур, еларга җитешеп. – Укыйсым... Килә...

Укытучы апа аны кызганды бугай:

– Ярый, бүген кич өегезгә барып килермен, – дип, малайның аркасыннан сөйде. – Әти-әниең белән сөйләшербез.

Ул кичке якта чынлап та килде. Кухнядагы чәй табынында озак кына сөйләштеләр. Илнур бөтен сүзләрен дә ишетә алмады. Тик укытучы Илнур ягында иде.

– Әгәр баланың укырга теләге бар икән, каршы төшәргә ярамый, – дип үгетләде. – Киләсе елга аның мәктәптән күңеле сүрелергә мөмкин. Аннан соң улыгыз «икеле капчыгына» әйләнер дә куяр. Ә быел ул...

Кыскасы, укытучы апа җиңде. Икенче көнне мәктәп формасы, уку әсбаплары сатып алдылар да малайны мәктәпкә илтеп куйдылар.

Укытучы апаның исеме Рәшидә Әнвәровна иде. Илнур аңа чиксез рәхмәтле булды. Иң төп сәбәбе, әлбәттә, әти-әнисе белән сөйләшеп, малайны укырга бирергә ризалаштыруы, Ләйләдән аермавы өчен иде. Уку дәверендә дә әйбәт кеше булды Рәшидә Әнвәровна, беркайчан да тавышын күтәрмәде, белмәгән нәрсәләрне сабыр гына аңлатып бирде, тәртип бозсаң – алай эшләргә ярамаганын сеңдерерлек итеп әйтте. Ничек шулай итә алгандыр ул, Илнур бүген дә аңлап җитә алмый, әмма укытучы апа кисәткәннән соң шул ук хатаны тагын кабатлау – аны рәнҗетү кебек тоела иде. Ә аны рәнҗетәсе килми. Аның шат чагын күрү күпкә рәхәтрәк. Гел диярлек елмаеп сөйләшә, елмайганда, бит очларында сизелер-сизелмәс кенә чокыр пәйда була, ап-ак тешләрендә якты нур кабына, күзләреннән шаян очкын сибелә. Аның елмаюын күргәч, Илнурның да елмаясы килә иде.

Беренче сыйныфта кызлар белән малайларны бер парта артына утырттылар. Сыйныфташларның күбесе моңа канәгатьсезлек белдерде, ә Илнур сөенде генә. Ул Ләйлә белән бер парта артында иде. Аның үзе янында икәнен тою да күңелгә ниндидер җылылык, дәрт, рәхәтлек бирә.

Баштарак сыйныфташлары «кияү белән кәләш» дип ирештереп маташсалар да, бу икәүнең артык исе китмәгәч туктадылар. Илнур да сыйныфта төшеп калган малайлардан түгел иде. Иң көчлесе үк булмаса да, үз-үзен якларлык чамасы бар. Һәм, әлбәттә, Ләйләне дә.

Сигезенче сыйныфларга җиткәндә, кызларның гәүдәсе тулыша, күкрәкләре чәйнек капкачы чамасы булып бүртеп чыга, ә малайларга дәрт керә – кем кызларның биленнән кочаклап карарга омтыла, кем күкрәкләренә үрелә. Яклаучысы булмаган кызларны берәр почмакта кысрыклап елатып бетерәләр. Ләйләгә бәйләнүче булмады. Ул вакытта Илнур төрле ярышларда катнашып, беренчелекне ала торган спортчы, егетләр арасында абруйлы малай иде.

Ләйлә белән мөнәсәбәтләре дә дуслыктан узып, мәхәббәт ягына авыша башлады. Элекке кебек җитәкләшеп йөрүләр бетте. Куллары кулга тиеп китсә дә, йөрәк ярсып тибә башлый, бит очлары алсуланып чыга, башлар әйләнеп китә. Бергә атлаганда, кайвакыт сүзләр дә табылмый, әмма сүзсез генә атлау да рәхәт була. Ә аерылгач, дөнья да, тормыш та бушап калгандай тоела. Күкрәктән ниндидер иң кадерле нәрсәне суырып алган шикелле...

Мондый халәт озакка сузыла алмый иде.

Һәм көннәрнең берендә барысы да үз урынына утырды. Ни сөйләшергә белмичә, сүзләр табалмыйча аптырап барганда, Ләйләнең биек үкчәсе янтаеп китте дә, кыз сөрлекте һәм Илнурның куенына барып керде. Егетнең бөтен булмышы тыелгысыз бер дулкынга әверелде. Ләйләнең тәне кайнар да, йомшак та, татлы да иде. Ул кызны үзенәрәк тартып, куенына кысты. Ләйлә читкә тайпылган хәрәкәт ясады да тынып калды, бераздан үзе егеткә сарылды. Кызларның шулкадәр назлы итеп сарылганын беркайчан да тойганы юк иде әле Илнурның, әллә нинди тылсымлы халәт иде бу, бөтен күзәнәкләреңне тибрәндерә, җаныңны да, тәнеңне дә сүтеп җыя торган рәхәт давыл иде. Шул давыл эчендә иреннәр бер-берсен эзләп тапты... Шул давыл эченнән кайнар пышылдаулар ишетелде:

– Җаным минем...

– Бердәнберем...

Ә бераздан татлы да, газаплы да тавыш:

– Мин яратам сине... – диде.

– Мин дә... Мин дә яратам!

Бу мизгелләрне хәтергә төшерү үзе генә дә Илнурның күңеленә чиксез рәхәтлек бирә. Хәтта мәңгегә онытылмаска, гомер буе җанны игәүләргә тиешле әрнү-үкенечләрне дә, күңелне тырмап яшәгән нәфрәт барлыгын да оныттырып тора. Егет шул мизгелләргә кайтырга теләгәндәй, күзләрен йомды, күзәнәкләренең назлы тибрәнүен тоймакчы булды, әмма бу хәле озакка бармады, ачы өермә булып күз алдына икенче бер мизгел килеп басты. Монысы да бөтен җаныңны-тәнеңне актара торган иде... Тик монысы җылылык та, наз да, рәхәтлек тә бүләк итми, бу бары тик сызланулар һәм әрнүләр генә бирә, бөтен булмышыңны һәм дөньяңны тоташ ялкынга урый...

Мәхәббәттә аңлашкан көннән алып, алар үзләренең кияү белән кәләш икәнлекләренә берсүзсез ышаналар һәм никахка керер яшькә җитүләрен түземсезлек белән көтәләр иде. Ник шуны унсигез яшькә кадәр итәргә кирәк булгандыр инде. Элек уналты яшьтә үк өйләнешеп, тормыш корып җибәргәннәр, итәк тутырып, балалар үстергәннәр, тавыш-гауганы белмичә, мәхәббәттә тату гомер иткәннәр. Ә хәзер...

Югары уку йортына да кочаклашып барып керделәр. Филология факультетына. Икесе дә әйбәт укый иде. Илнур күңеленнән генә язучы булырга хыяллана, бүлмәсендәге иң яшерен урында берничә әсәре дә бар, тик аларны әле хәтта Ләйләгә дә күрсәткәне юк иде. Ләйләнең теләге – укытучы булу. Институтта да гел бергә булдылар. Һәм үзләренең кияү белән кәләш икәненә тамчы да шикләнмәделәр. Берәү дә шикләнмәде. Төркемдәшләре аларның бер-берсен яратуын белә һәм шундый якты мәхәббәткә сокланып, хәтта бераз көнләшеп тә карыйлар иде.

Көнләшерлекләре дә булгандыр. Илнур бик әллә кая киткән чибәр егет тә түгел, өс-башы да гади генә, күбесенчә абыйсыннан калган киемнәр... Кесәсе дә такы-токы. Әти-әнисеннән матди ярдәм бик аз әлэкми, үзе каян эш таба, шуның исәбенә көн күрә, ә эш дигәнең гел генә табылып та тормый. Менә шундый гади генә егет янында Ләйлә кебек алиһә йөргәч, көнләшсәләр дә аптырарлык түгел инде.

Әлбәттә, Илнурның кимсенгән вакытлары да аз булмады. Ләйләне затлы ресторannарга йөртәсе, диңгез буйларыннан ял иттереп алып кайтасы иде дә бит... Һич югында уртача гына бер җиңел машина белән каршы аласы, озатып куясы, теләгән җиреннән әйләндереп алып киләсе иде. Тик әлегә аның мөмкинлеге юк шул. Әлегә...

Ләйлә моңа артык игътибар итми иде бугай. Акыллы кыз ул, барысын да аңлап тора, үзе дә Илнурныкы шикеллерәк гади гаиләдә туып үскән. Бөтен илдә акча хакимлек итсә дә, алар дөньясында мәхәббәт тәхеттә иде. Алар бар, бергә һәм шуның белән бәхетле иде.

Көннәрнең берендә аларның төркеменә яңа студент күчеп килде. Денис исемле. Әллә кая киткән егет түгел инде. Кыска гына буйлы, ябык гәүдәле. Битен тимгел-тимгел булып сипкел баскан. Сары сыек кашлары астыннан соры күзләре ялтырый. Борыны урынына камыр уып чәпәп куйган кебек. Кыскасы, Яңа ел алдыннан подъезд алдында ашык-пошык ясалган Карбабай шикеллерәк бер нәрсә, бернинди матурлыгы юк.

Тик ул бик хикмәтле егет булып чыкты. Беренчедән, өс-башы искитмәле – бөтен киеме затлы, яңа гына энәдән төшкән шикелле. Икенчедән, үзен бик иркен тота, хәтта укытучылар белән дә югарыдан карап сөйләшә. Тегеләре дә моңа юл куя, Илнур шулай кыланса, мизгел эчендә урынына утыртырлар иде, ә моңа бер сүз әйтүче юк. Соңыннан ачыкланды, бик зур бер түрәнең баласы икән. Бер үк вакытта икътисад факультетында да укый, филологиягә килүенең сәбәбе бер – монда инглиз телен яхшы укыталар. Чынлап та яхшы, мәктәптә ун ел укып берни өйрәнә алмаган Илнур да монда килгәч, ярыйсы ук алга китте. Шуңа күрә Денисны да алар төркеменә урнаштырганнар. Ләйлә баштарак Дениска көлеп кенә карый иде. Теге ни әйтсә дә, гел аркылы килә, ирештерә, хәтта мәсхәрәли дә кебек. Илнур моңа илтифат итмәде, гаҗәп тә түгел – әтисенең байлыгы белән мактанып, шуңа аркаланып йөргән егетләрне ул үзе дә бик өнәп бетерми. Тик егет кешегә Ләйлә кебек аркылы килеп булмый, килешми ул. Ә кызларга килешә. Аларга ни әйтсәләр дә, гафу ителә.

Аз-маз акчасы булмасмы дип, бер төркем егетләр белән Илнур өй түбәсе ябарга ялланган иде. Тик беренче көнне үк түбәдән егылып төште дә хастаханәгә эләкте. Ләйлә бу хакта белү белән тәмлүшкәләрен төяп килеп җитте, озак сөйләшеп утырдылар. Ләйлә дәресләр турында, нинди темалар үткәннәре хакында сөйләде. Аның янында рәхәт иде. Кыз шулай көн дә килеп йөрде, бераздан көн аралашка күчте, ә ахырда бөтенләй килмәс булды. Илнурның аягы сынган иде, төзәлүе никтер озаккарак китте. Ләйләнең килмәвенә дә аптырарлык түгел, тиздән имтиханнар башлана, гел генә хастаханә юлында йөреп булмый, әзерләнергә дә кирәк. Үзен шулай дип юатса да, Илнурның күңелендә бераз шом да бар иде. Чирләп китмәде микән, бәла-казага юлыкмадымы...

Хастаханәдән чыккач, ул туп-туры институтка китте. Дәрес барган аудиторияне эзләп тапты да кинәт кенә килеп керергә кыймыйча, ишекне кысып кына ачып күзәтә башлады. Ләйлә Денис янында утыра иде. Тегесенең бер кулы өстәл өстендә, икенчесе Ләйләнең ботын сыйпый. Кыз карышмый, канәгать елмаеп утыра.

Моны күргәч, егет бер мәлгә исәңгерәп торды. Чынлап шулаймы соң бу,

дигәндәй, күзләрен ачып-йомып алды. Чынлап шулай икән... Аның инде дәрескә керү теләге калмады. Бу хәлгә барыбер ышанасы килми иде. Егет өенә кайтырга ашыкмады, дәресләр беткәнен көтте. Денис белән Ләйлә кочаклашып, бергә чыктылар да бай егетнең затлы машинасы янында туктап үбешеп алдылар. Аннан Ләйлә бик канәгать кыяфәт белән машинага кереп утырды. Кузгалып киттеләр... Затлы машина кузгалып китте, ә Илнур култык таягы белән алар артыннан атлады.

Ул чактагы әрнүләрен сөйләп бетерерлек кенә түгел инде. Хәтта исенә дә төшерәсе килми хәзер. Бөтен өмет-хыяллары, бөтен ышанычы, бар дөньясы челпәрәмә килде. Подъезд алдына кайтып җиткәч тә, үзләренә керергә ашыкмады. Күрергә кирәк Ләйләне. Машина белән китереп куйдылар бит, ул инде күптән өендәдер.

– О, Илнур, балакаем! – дип каршылады аны Нәсимә апа. – Исән-сау терелеп чыктыңмы? Маладис! Үзеңне сакла инде моннан ары.

Ләйлә өйдә түгел иде.

– Соңгы вакытта бик күп куялар әле дәресләрне, – дип акланды Нәсимә апа. – Кайчагында караңгы төшкәнче укыталар. Көч-хәл белән кайтып егыла, балакаем. Сиңа да куып җитү авыр булыр инде. Ярар, бергәләп ерып чыгарсыз әле...

Илнур Денисның кайда яшәгәнен белә иде. Шәһәр уртасындагы ике бүлмәле затлы фатир ул. Әти-әниләре газиз балаларының унсигез яше тулу уңаеннан бүләк иткәннәр. Мәйданы зур, ә өй җиһазлары үзләре бер фатир бәясе торырлык. Әй, бирсә биреп тә тора инде бәхетне Ходай кайберәүләргә! Ә алар шуңа да канәгать булмыйча, башкаларның бердәнбер куанычын, юанычын тартып алалар...

Илнур барлы-юклы акчасына такси алды да Денисларга китте. Тимер рәшәткәләр буйлап йөри торгач, адәм сыярлык бер тишек табып, ишегалдына узды. Капкадан керергә ярамый, Дениска шалтыратачаклар, шунсыз үткәрмәячәкләр иде. Эчтән берәрсе чыкканын көтеп, ишек төбендә озак кына басып торды. Эт ияртеп чыккан ханым читкәрәк китү белән тотканы эләктереп алды.

– Сез кемгә? – диде ханымның таләпчән тавышы. – Әй, сезгә эндәшәм!

Илнур аңа игътибар биреп тормады. Ләкин хатынның:

– Йөри шунда җыен әтрәк-әләм... – дигәне колагын рәнҗетеп узып китте.

Бу йортның кемнәр өчен төзелгәне шундук күзгә ташланып тора иде. Коридор стеналары затлы кафель белән бизәлгән, тәрәзә төпләрендә гөлләр үсеп утыра. Кайдандыр хуш ис бөркелеп, борынны иркәли. Илнурларның йорты түгел бу. Канализация, мәче сидеге, тагын әллә нәрсәләр аңкытмый. Стеналарындагы фәлән ел элек буялган арзанлы буяу кубып төшмәгән. Лифт та шалтыр-шылтыр килеп ачылмый. Затлы электроника кебек шым гына хәрәкәтләнә: «Рәхим итегез, мин сезнең хөкемдә!»

Ишекне Денис үзе ачты. Ул яланаягына тапочки кигән, өстенә озын халат ябынган иде. Илнурны күрүгә күзләре маңгаена менде, каш төпләре кызарып чыккандай тоелды. Илнур аны читкә этәрде дә эчкә узды. Нindiдер хәрәкәт барлыгын тоеп, туп-туры йокы бүлмәсенә китте. Киң диваннан шуып төшкән ялангач гәүдә тиз генә алсу төстәге халат эченә кереп югалды, бер мизгелгә генә аның тулышкан күкрәкләре ялтлап калды.

– Илнур, син ялгыш уйлый күрмә... – диде Ләйлә һәм үз сүзләренең мәгънәсезлеген аңлап төртелеп калды. – Илнур...

Егет дәшмәде. Аның хәлен аңлатырлык сүзләр юк иде. Тик Ләйлә үзе һөҗүмгә күчте:

– Илнур, без синең белән бәхетле булалмый идек... – диде ул, үзенең хаклыгына үзе дә ышана барып. – Гашыйкларга шалашта да оҗмах дип яши торган дәвер түгел хәзер. Һәркем үз хәстәрен үзе күрергә тиеш. Үз киләчәген һәркем үзе төзи...

Илнур кырт борылып чыгу ягына атлады. Һәм бүлмә уртасында катып торган Денисны күреп туктап калды. Баштанаяк күз йөгертеп алды. «Нәрсәсенә кызыккан бу моның?» – дигән уй йөгереп үтте. Һәм шундук җавабы да кул күтәрде:«Байлыгына! Байлыгына!»

– Илнур, гафу ит... – дигән тавыш ишетелде йокы бүлмәсеннән. Бераздан Ләйлә үзе дә күренде. – Илнур...

Егет нәфрәтенә тончыгып, Денис каршысына килеп басты да җан ачысы белән ияк төбенә кундырды. Денис аякларын күтәреп, идәнгә барып төште.

– Илнур, нишлисең! Үтерәсең бит... – дигәне ишетелде Ләйләнең.

Илнур ишеккә атлады.

Икенче көнне институт алдында аны Денис яллаган дүрт малай көтеп тора иде. Егет аларны буш калдырмады, әлбәттә. Ярыйсы гына манчып җибәрде. Култык таягы яхшы корал ул, әмма аягың ныклы булмагач, аның белән дә әллә ни майтарып булмый, шуңа үзенә дә әйбәт кенә эләкте. Күз төбе күгәрде, борыны канады, кабыргаларының да ныклыгын тикшерделәр, ярый әле аягын кабат сындырмадылар – анысы да бер юаныч иде.

Ә эчкә узуга белдерүләр тактасында аның укудан куылуы турында декан боерыгы эленеп тора иде. «Дәресләргә йөрмәү сәбәпле... начар укуы сәбәпле...» Хәер, кумасалар да ул бу төркемдә укый алмас иде инде...

Тик бер нәрсә үзәгенә үтте...

Әгәр кешенең акчасы юк икән, сөйгән кешесе белән бәхетле булып яшәргә дә хакы юк... Нинди җәмгыять соң бу? Бөтен нәрсә белән дә акча һәм мөлкәт идарә итә...

**5**

Су краннарын басып куйгач, әнисенең тавышы тагын аермачык булып ишетелә башлады. Бу юлы ул Илнурның әтисен тирги иде:

– Ирме син, түгелме, шул бер баланы да тыялмыйсың. Малай кешене әтисе карарга тиеш аны. Әти тәрбиясе булмаганга шундый булып үсте ул. Җебегән!

Әтисе нәрсәдер мыгырданып куйды, ни әйткәне аңлашылмады. Әниеңне ничек кенә яратсаң да, күзгә бәрелеп торган нәрсәне инкарь итеп булмый. Илнурның әнисе... әллә ниндиерәк инде ул... Әйбәтлеге чамасыз, әлбәттә... Тик кайчагында юктан да гауга куптарырга гына тора, берәр нәрсәне теләнә алды исә, кешенең җен ачуын чыгармыйча туктала белми. Бу юлы да шулай иде. Илнур әллә күпме вакыт ваннада ятты, тынычланып кереп ятарлар дип көтте. Ә әнисе һаман пыр тузынып йөри. Әтисе дәшми... Ул суыткычтан алып, бер-ике рюмка тондырып куя да башын иеп, өстәл башында уйланып утыра. Бары тик үзенә турыдан-туры һөҗүм итә башласалар гына мыгырданып куя. Кайвакыт шул халәтендә йоклап та китә.

Илнур ваннадан үз бүлмәсенә күләгә сыман тавыш-тынсыз гына узып китәргә теләгән иде. Аяк очларына басып кына, тиз генә. Әмма чыгу белән әтисенең ачулы тавышы ишетелде:

– Илнур!

Егет бер мәлгә югалып калды. Кухняга керергәме, әллә ишетмәмешкә салынып, үз бүлмәсенә элдертергәме? Бөтен тәне сызлый, башы тубал кебек... Фикерләр әкрен йөри, тиз генә ниндидер карарга килерлек түгел. Әй, лә... Илнур үз бүлмәсенә атлады. Тормышның ыгы-зыгысыннан тизрәк йокы иленә кереп качарга теләп, урын җәя башлады. Хан заманыннан калган иске диванны киңәйтеп, мең тапкыр юылып, төсе уңып беткән япманы җәеп маташканда, ишек ачылып китте дә әтисе килеп керде. Аның күзләре акайган, котырган үгезнеке шикелле сөзеп карыйлар, җиңнәре сызганулы иде. Илнур нидер уйлап өлгергәнче ул аның каршына килеп басты:

– Нәрсә, хәзер әти сүзен санга сугучы юкмыни?! – диде ул нәфрәттән карлыккан тавыш белән. – Әти-әнине санламыйбызмыни?

– Юк... әти...

Илнур сүзен әйтеп бетерәлмәде, әтисе сугып җибәрде. Кулы каты иде аның. Күз алдында ут шарлары биешеп алды да кайдандыр көтмәгәндә килеп чыккан аяусыз дулкын йөздереп алып китте. Бүлмәнең асты-өскә килде... Икенче мизгелдә башына ниндидер каты әйбер килеп бәрелде. Ул нәрсәдер әйтергә тырышып карады, әмма тавышы чыкмады. Еракташ ярсыган ир-ат тавышы ишетелде. Илнур аның нәфрәт белән тулы икәнен генә аңлый алды, сүзләрен аермады. Бары тик беркадәр вакыт узганнан соң гына үзенең идәндә ятуын аңлады, ә башына килеп бәрелгән каты нәрсә диван аягы булган икән. Әтисе сүгенүеннән туктап, аны тартып торгызды да диванга утыртып куйды.

– Кайчан аңлыйсың син әйбәтләп әйткәнне, – диде ул бераз тынычланып. – Унтугыз яшеңә җитеп бер сөендергән җирең юк бит.

Илнурның күңелендә кинәт нәфрәт давылы купты... Нинди дөнья бу? Ник һәрвакыт ул гаепле булып кала? Барысы өчен дә. Һәм тормышның камчысы һәрвакыт аның җилкәсенә төшә. Ник аны беркем дә аңламый, хәтта аңларга омтылыш та ясап карамый? Бу давыл бер мизгелгә уйнап алды да үзенең файдасыз икәнен аңлап тынып калды. Илнур билгесезлеккә текәлеп, сүзсез утыруын белде. Аның уйларлык та, хисләнерлек тә, сүз әйтерлек тә көче юк иде. Һәм хәзер аның өчен барыбер иде.

Аның бу халәте әтисен ярсытты гына:

– Кайда бурычка баттың? – дип ысылдады ул. – Кемнәрдән акча алып эчеп йөрисең? Укудан куылуыңа күпме вакыт узды инде, ник эшкә урнашмыйсың? Кредит алырга кем дә булдыра ул, менә син түләп кара.

– Түләрмен, – дип пышылдады Илнур арыган, битараф тавыш белән.

– Тот капчыгыңны! – дип ярсыды әтисе. – Түләгәнгә безгә шалтыраталармыни?! Бүген көне буе һушны алдылар. Фатирыгызны яндырабыз, диләр.

Кинәт Илнурның арка үзәген салкын җил өтеп узды. Үзенә шалтыратып, мыскыл итүләре генә җитмәгән, хәзер әти-әнисен дә куркыта башлаганнар. Ул башын күтәреп, әтисенә текәлде. Чәчләре агарып сирәкләнгән, битен җыерчыклар баскан... Күзләрендә нур сүрелгән... Кайчандыр имәндәй ныклы булып, баскан җирендә ут уйнаткан ир хәзер тыны чыккан тупка

охшап калган. Әтисен кызганудан йөрәге кысылып куйды. Тормышны бөтәйтеп булмасмы дип чаба торгач, әнә нинди көнгә төшкән бит ул. Ә Илнур үзен җәлләтергә маташа.

– Күпме бирәсең бар? – диде әтисе кырыс тавыш белән.

– Биш мең, – дип пышылдады Илнур, тамагына утырган төерне йотарга тырышып. – Түлим мин аны...

– Түлә, – дип кистерде әтисе һәм кесәсеннән биш меңлек алып өстәлгә куйды. – Бурычларны түләргә кирәк. Аста гына банкомат бар, хәзер үк түләп кер.

Һәрвакыт ачуыңны китереп торсалар да, әти-әниләр барыбер үз баласының интегүен теләми инде. Теләмичә генә интектерәләр. Хәлләре, мөмкинлекләре булса, бәлки, әллә ниләр биреп сөендерерләр иде дә... Әнә бит, берьюлы ничәшәр урында эшләп, сәламәтлекләрен бетерсәләр дә, артык алга китә алмыйлар. Кайберәүләр тормышны яхшырту өчен кыл да кыймылдатмаган хәлдә дә балда-майда йөзә, ә болар чәчләре белән җир себереп тә мантый алмыйлар. Гаделлек юк инде бу дөньяда. Гарип җәмгыять бу...

Җәмгыятьнең гариплеген исбатларга теләгәндәй, подъезд алдына чыгуга телефоны шалтырады. «Коллекторлар...» – дигән уй йөгереп үтте башыннан. Ләкин шалтыратучы Ләйлә иде. Илнурның йөрәге жу итеп куйды. Төн уртасында нишләп шалтыратырга уйлаган? Нәрсә булды икән? Бәлагә юлыкканмы? Нәфрәте чиксез булса да, Илнурның хисләре үлеп бетмәгән иде әле, ул Ләйләгә ярдәм итәргә һәрвакыт әзер иде. Шуңа ашыгып сөйләшү төймәсенә басты. Әмма телефонның теге очында ир-ат тавышы иде – Денис.

– Мин синең хәерче икәнеңне беләм, – диде ул саулык та сорашып тормастан. – Тик нигә үз кредитларыңа Ләйләне кыстырасың?

Илнурның күзе маңгаена менде:

– Мин аны кыстырмадым...

– Ә ни өчен аңа бүген көне буе шалтыратып, төрлечә куркытканнар?

– Белмим...

Илнур чынлап та белми иде.

– Вәт, син бел һәм безне тынычлыкта калдыр. Ә мин синең бурычларыңны беркайчан да үз өстемә алмаячакмын. Һәр булдыксызның спонсоры булалмыйм.

– Яхшы...

– Әгәр иртәгә дә шалтыраталар икән, без синең белән башка төрле сөйләшербез. Син минем кемлегемне беләсең...

– Яхшы, яхшы...

Илнур сөйләшүне өзде. Хәзер ул акча салачак, ә Денисның мактануын тыңлау кызык түгел... Шайтан алгыры! Ул йодрыкларын төйнәп, һаваны ертып алды... Күңелендә нәфрәт уянды. Юк, Дениска түгел... Аның кайгысы юк иде әле. Коллекторларга. Ләйләнең телефон номерын каян тапканнар, диген... Нәрсә, болар чынлап та аның тормышын тәмугка әйләндермичә туктамаска итәләрме? Тагын кемнәргә шалтыраттылар икән? Шайтан алгыры... Бүген үзен дә сәгать саен баш катырып, җәфалап бетерделәр. Бүген иптәш егетләре белән сыраханәгә баруы да эш табып яки берәрсеннән

бурычка алып торып булмасмы диюдән иде. Булмады. Үзеңә генә янаулары бер хәл әле ул, ә әти-әниеңнең, якыннарыңның, таныш-белешләреңнең телефонын табып шалтыратулары икенче нәрсә, күпкә хәтәррәк.

Менә шундый хәлиткеч мизгелләрдә ярдәм кулын сузган эткәң-әнкәңнең игелеген мәңге онытырлык түгел дә бит... Онытыла шул... Күп очракта онытыла... Әрләү-тиргәүләре белән җаныңны кимерә башладылармы, иң әшәке кеше кебек тоелалар... Ә чынында иң кабахәт кешеләр бөтенләй бүтән булып чыга...

Банкомат янына килеп басуга тагын телефон шалтырады. Тагын таныш түгел номер иде. Илнур бу юлы коллекторлар булуыннан да куркып тормыйча трубканы алды:

– Алло...

Дәшмәделәр.

– Алло... Ник дәшмисез...

Теге очта кемдер тамак кырып алды. Һәм карлыккан ир-ат тавышы янаулы да, мәсхәрәле дә тавыш белән сөйли башлады:

– Һава боза-боза йоклап ятасыңмы, бөҗәк? Ә бит тыныч йоклау өчен башта бурычыңны түләү кирәк...

Юк, төн уртасында шалтыратуын да кичереп булыр иде. Илнурның кулында акча бар. Итагатьле генә итеп сөйләшсә, хәзер түлим, борчылмагыз, дип кенә әйтер иде. Ләкин мондый мәсхәрәле сөйләшү аның канын кайнатып җибәрде.

– Ә үзең ник йокламыйсың, бөҗәк? – диде Илнур тамак төбеннән чыккан нәфрәтле тавыш белән. – Бүген кылган ялгышларың тынгылык бирмиме?

– Һо-һо, бабасырга канат үскән, – дип көлгәндәй итте коллектор. – Әллә акча таптыңмы?

Илнур нәфрәтеннән тончыгыр чиккә җитте. Шиш сиңа акча күчерү! Очрашырга кирәк, менә шунда арт сабагыңны укытып, акчаңны кулыңа тоттырып җибәрермен. Ә әлегә... Тик ул салкын канлы булырга тырышты:

– Таптым. Иртәгә кичкә очрашабыз, шунда бирермен.

– Ха-ха... – Теге тагын көлгән кебек итте. – Ә син бурычыңның ике тапкырга артуын беләсеңме?

– Юк, белмим. Биш мең яки бөтенләй түләмим.

Илнур үзенең кискен һәм катгый сөйләшүенә үзе дә аптырап куйды.

– Кайчан очрашабыз.

– Кич. Уннар тирәсендә.

Теге якта мәсхәрәле көлү тавышы яңгырады:

– Ә синең якын кешеләреңнең барысын да мин беләм. Кайберләре шундый яклаучысыз. Сәгать уннар җиткәнче мин шулар белән уйный торырмын...

Бер мизгелгә бу тавыш коточкыч фильмнардагы маньякларныкын хәтерләтеп куйды. Илнур нәфрәтеннән берни әйтәлмәде. Ә теге очтан:

– Иртәнге якта. Кайда һәм ничәдә икәнен үзем әйтермен, – дип, сөйләшүне өзделәр.

Шайтан алгыры! Эшләр тирәнгәрәк китә бугай. Әллә түләп кенә куярга да котылыргамы соң? Ләкин Илнурның нәфрәте көчле иде. Бу адәм белән очрашырга һәм сабак бирергә кирәк. Акчаңны түләсәң дә, зыян салырга

мөмкин бит әле ул. Әнә бит нәрсә сөйләп тора! «Кайберләре шундый яклаучысыз...» Бу тиклем мыскыл ителгәннән соң, аны бер җәзасыз җибәрәсең икән, ир-егет түгел, бозау син...

Илнур акчасын барларга теләп, кулын кесәсенә тыкты. Акча урынында иде. Ниндидер катыргы кисәге дә бар. Теге таныш түгел кеше, Джон биргән визитка икән. Илнур аны алып карарга кереште. Аның уртасына зур хәрефләр белән: «Тормышта авыр хәлгә калган кешеләргә ЯРДӘМ» дип язылган. Аннан соң: «Тәүлек әйләнәсенә!» Һәм телефон номеры, электрон почта адресы...

Кем беләндер киңәшләшәсе иде. Әтисе белән булмый инде, ул: «Акчаңны түлә дә кредит картаңны ертып ташла һәм оныт», – дип әйтәчәк. Ә Илнурның онытасы килми иде, күңелнең нечкә җиренә кагылды теге кеше. Үзенең җәзасыз калырына тулы ышаныч белән бер тапкыр та очрашмаган, күрмәгән-белмәгән кешене мыскыл итте... Иптәш малайларына шалтыратсаң... беренчедән, вакыт соң инде, икенчедән, алар барсын да көлкегә әйләндерәчәк. Ә менә бу Джонга шалтыратып карарга мөмкин бугай. Ул киңәш бирергә мөмкин... Һәм Илнур телефон номерын җыйды...

**6**

Алар төзелеп бетмәгән тугыз катлы йорт подвалындагы бүлмәләрнең берсендә утыралар иде. Бүлмә ярыйсы гына җиһазландырылган, җылыткычы да бар, су да килә. Бер якта стенка, икенче якта бер-берсенә терәтеп куелган ике диван. Түрдә өстәл...

Джон аны үзе каршы чыгып алды да килеп керү белән өстәл янына утыртты. Чәй кайнаган, табын әзерләнгән иде. Авызы көрешкәгә тигәч кенә Илнур үзенең сусаганлыгын аңлады. Ашыйсы да килә икән. Тамак ныгыткан арада ул үз хәлен Джонга сөйләп бирде. Тегесе кофе чүмерә-чүмерә бүлдерми генә тыңлап утырды. Бары тик Илнур тынып калгач кына:

– Нишләргә уйлыйсың соң? – дип куйды.

Илнур аңа сәерсенүле караш ташлады:

– Әйтеп торам бит инде, күрешергә, арт сабагын укытырга кирәк.

Джон көлемсерәде:

– Белмим шул, килеп чыгар микән? – диде ул, җитдиләнеп. – Андый эшләргә йомшак малайлар алынмый.

Илнур беркадәр кызып киткән иде бугай:

– Мин дә йомшак түгел, – дип әтәчләнде. – Начар сугышмыйм мин.

Тик Джон аның сүзләрен игътибарсыз калдырды:

– Алар коралланган була. Һәм, гадәттә, ялгыз гына йөрмиләр.

Илнурның бу сүзләргә исе китмәде, хәтта ишетмәде дә, ул инде ниндидер аулак урында маньяк тавышы чыгарып, телефон аша куркытып утырган теге бәндәнең иманын укыта иде. Хыялында, әлбәттә. Хыялында ул шулкадәр көчле, берәүне дә чалымга китерерлек түгел иде.

– Әй, син кайда йөрисең? – Джон аның иңеннән кагып куйды. – Син бит мине ишетмисең.

– Ә-ә-ә... Яхшы... Нәрсә дидең?

Джон көлеп җибәрде.

– Алар коралланган була.

– Ничек коралланган?

– Төрлечә. Кемдә пычак, кемдә мунчак... – дип елмайды Джон. – Кайберсендә пистолет...

Илнур бер мизгелгә уйланып торды. Чынлап та бу бик гади мәсьәлә түгел икән. Бу сиңа студентлар арасындагы сугыш кына булып чыкмый, хәтта татамидагы алыш та түгел, бу күпкә җитдирәк. Һәм Джон да хаклы, мондый эшләргә җебек малайларны алмыйлар, монда сазаган сугышчылар, кызгана да, икеләнә дә белми торган башкисәрләр эшли. Аларны җиңү өчен үзең дә шул дәрәҗәдәрәк булырга тиешсең.

– Бәлки, миңа да пистолет алыргадыр? – диде ул Джонның күзенә карап, – Атып караган бар минем, ару гына килеп чыга...

Джон аңа сынаулы караш ташлады да берара текәлеп торды. Һәм баш чайкап куйды.

– Бәлки, сиңа полициягa барып, гариза язарга гына кирәктер?

– Ничек инде?

– Гади генә. Барасың, барысын да җентекләп сөйләп бирәсең. Нинди номерлардан шалтыратканнарын күрсәтәсең. Һәм алар шул номерлар буенча коллекторларны эзләп табалар...

– Шуннан?

Джон тагын көлемсерәде:

– Шуннан инде иң кызыгы башлана. Коллекторларның телефон аша янавын, мыскыл итүен син кире каккысыз итеп дәлилли алмыйсың. Хәтта исбатласаң да... Бурычыңны сорап, телефоннан шалтырату җинаятькә чутланмый... Хәтта судка биреп, тулысынча җиңеп чыксаң да аларга бары тик кечкенә штраф чәпәячәкләр һәм вәссәлам...

Илнур полициягa барып йөрүне күз алдына да китерә алмый иде.

– Ул иртән очрашабыз, үзем шалтыратырмын диде...

– Әйе, полициягa барсаң, чират көтеп кенә дә төшкә кадәр утырырга мөмкинсең әле. Карале, бәлки, ул сиңа бернинди зыян да салырга теләмидер. Эше шул инде аның, төрле юллар белән банк акчасын кире кайтарырга тырышу. Бәлки, эшне зурга җибәрергә кирәкмидер.

– Кирәк, – дип кистерде Илнур. – Бу килеш калдырасың икән, димәк, син егет түгел.

– Алайса, сиңа пистолет алырга гына кала инде, – дип көлемсерәде Джон. – Кул сугышында син җиңә алмаячаксың.

– Алам! – Илнур тәвәккәл иде.

Джон аңа сәерсенеп карап торды да көлеп җибәрде:

– Биш мең сум өчен син кеше үтерергә дә әзерме?

Илнур җитди иде:

– Эш монда акчаның суммасында түгел, – диде ул, үртәлүен яшерергә тырышып. – Ул миннән көлде, мәсхәрә итте. Ул минем әти белән әнигә көн буе шалтыратып, өйне яндыру белән янаган. Минем элек йөргән кызга көнозын шалтыраткан. Тагын әллә кемнәргәдер әле, алары дәшмәгән генәдер. Үземне көне буе мыскыл итте... Аңлыйсыңмы? Аңласаң шул: мин аны болай гына калдырырга тиеш түгел.

– Аңлыйм... – диде Джон һәм кулындагы чынаягына карап, бер мәлгә тынып калды.

Илнурның күңеле ярсу, ул хәзер үк барып, үч алырга да әзер иде, шуңа бу тынлыкны өнәп бетермәде:

– Миңа пистолет кирәк! – дип кистерде. – Син ярдәм итә аласыңмы?

Джон карашын аңа күчерде. Бераз текәлеп торды. Һәм катгый тавыш белән әйтеп куйды:

– Булыр, – дип, ул урыныннан кузгалды. – Чәй эчәсеңме тагын?

– Юк, рәхмәт.

Джон чынаякларны алып, ишек төбендәге раковинага юнәлде:

– Алайса, йокларга кирәк. – Ул стена буендагы диваннарның ишеккә якынрак торганына ымлады. – Үзеңә урын җәя тор. Җәймәләр әнә теге шкафта.

Илнур бер диванга, бер ишеккә карап торды да:

– Миңа өйгә кайтырга кирәктер, – дип, ишек ягына атлады. – Әти-әниләр борчылып тормасын.

Джон каршы килмәде.

– Яхшы, – дип телефонга үрелде. – Хәзер такси чакырам.

Өстәлне җыештыргач, аягына киде дә урамга атлады:

– Әйдә, таксига кадәр озатып куям.

Урамда ярыйсы гына суыткан иде. Соңгы вакытта һава торышы әллә ниндигә әйләнде. Көне буе кыздыра да кич җитүгә кинәт кенә салкынайтып җибәрә. Ә төн уртасында көзге салкынлык хакимлек итә башлый. Якындагы банкоматтан әйләнеп кенә киләм дип, юка киенеп чыккан Илнур җиңелчә генә дерелдәп куйды. Ярый әле такси бик тиз килеп җитте.

– Иртәнге якта шалтыратышырбыз, – диде Джон, хушлашырга кул биреп. – Нәрсә булса да хәбәрдә тор, югалма.

– Ә пистолет? – Илнур кабат исенә төшермичә түзалмады. – Ул кирәк булачак. Онытма, яме.

Джон елмайды.

– Онытмам. Борчылма. Тик синең документларың кирәк булачак. Иртәгә әзерләп куй.

– Яхшы.

– Иртән шалтырат.

* * *

Фатирга ул шыпырт кына кереп, үз бүлмәсенә узды. Әти-әнисе йоклый иде бугай, эндәшүче булмады. Илнур тиз генә урын җәйде дә диванга ауды. Арыткан иде. Әмма тиз генә йокыга китә алмады, колак төбендә карлыккан тавыш яңгырады: «Якын кешеләреңнең барысын да мин беләм... Кайберләре шундый яклаучысыз... мин шулар белән уйный торырмын...» Аның саен күңелендә нәфрәт көчәйде. Шул ук вакытта ул үзенең көчсез һәм яклаучысыз икәнен аңлый иде. Джон хаклы, мондый эштә йомшак малайлар эшләми. Болар кешене мәсхәрәләп, таптап, җиргә сеңдереп куя торган аяусыз кешеләр. Болар белән шаяру куркыныч. Бөтенләй көтелмәгән яктан һөҗүм итеп, әллә нәрсә кылып, әллә нинди явызлык китерүләре бар.

Берничә сәгать элек кенә егетлек кебек күренгән гамәле хәзер ахмаклык булып тоелды. Юкка гына бәйләнеште бугай әле ул. Арка терәрлек бер ышанычлы терәгең булмаган килеш болай әтәчләнергә ярамый иде. Әллә

хәзер үк чыгып, теге акчаны түләп керергә микән? Алай итсәң, барсыннан берьюлы котыласың инде. Үч алынмый кала калуын. Бөтен мыскыллаулары бер җәзасыз килеш кала... Калса соң? Калсын...

Сәер инде бер карасаң, бүген аны көне буе диярлек кимсеттеләр. Бер гаепсезгә рәнҗеттеләр, мыскылладылар. Ә аның үз-үзен якларлык бер чарасы да юк. Ул хәтта полициягә дә бара алмый... Ул беркемнән ярдәм көтә алмый...

Ник гел аның белән шулай килеп чыга соң? Ник? Чөнки ул моңа кадәрге кимсетүләрнең берсенә дә җавап кайтармады. Җавап бирмәгәч, дәшми калгач, дөнья мондый хәлләрне шулай тиеш дип кабул итте һәм гадәткә кертеп җибәрде. Әгәр үзен рәнҗетүчеләргә усаллык белән җавап кайтарса, болай булмас иде. Ә ул җавапсыз калды. Тик бу юлы...

Бу юлы ул...

**7**

Илнур телефон шалтыраган тавышка уянып китте. Стенадагы сәгать алтынчы яртыны күрсәтә иде. Йокылы-уяулы егет диван буйлап капшанып, телефонын эзләп тапты. Шалтыратучы таныш номердан түгел иде. Сөйләшү төймәсенә басты.

– Алло! – карлыккан тавышында канәгатьсезлек чалымнары яңгырап китте һәм ул йомшагырак булырга тырышып тагы кабатлады: – Алло!

Җавап бирүче булмады, бераздан бип-бип килгән тавыш кына ишетелде – трубканы ташладылар. Илнур торып утырды. Бөтен тәне оешып каткан һәм авырта иде. Ул учларын ачып-йомып алды, аякларын хәрәкәтләндерде. Бераздан торып басып, гимнастика ясарга кереште. Шулай биш минут чамасы маташкач, буыннары язылып каны таралып киткәндәй тоелды. Кичә кайбер урыннарына ару гына эләккән икән, ботларында, янбашында күгәргән урыннар бар, кабыргасын да санаганнар бугай – сулыш алган саен сиздереп, авыртып тора. Ярый, төзәлер әле...

Ул арада телефонында өзек кенә бипләү ишетелде. Смс килде бугай. Әйе. Монысы да таныш түгел номердан икән. Язу кыска гына иде: «Акчаңны алып кил». Адрес күрсәтелгән. Һәм очрашу вакыты. Шайтан алгыры! Шулкадәр таң тишегеннән шалтыратмаса булмый иде микәнни? Юкка гына маташтырды әле ул бу эшне. Кичә үк түләп куйса, бүген рәхәтләнеп йоклаган булыр иде. Ә хәзер... Күзеңне тырмап чыгып китәргә кирәк. Һәм аның нибары ярты сәгать вакыты бар.

Илнур чайкала-чайкала, ваннага юнәлде. Һушка килергә кирәк иде. Ул башта салкын душта коенды, аннан суны бераз кайнарлатты. Шул рәвешле чиратлаштырып коенгач, дөнья ачыла төшкәндәй тоелды. Аннан тиз генә тешләрен тазартты да кухняга чыкты. Әнисе белән әтисе торганнар икән инде, чәй эчеп утыралар иде.

– Хәерле иртә, иптәшләр! – Илнур шат күңелле булып күренергә тырышты. – Чәйләрегез тәмле булсын!

– Хәерле, хәерле... – дип кабатлады әнисе. – Әйдә, чәй ясыйм.

– Юк, әни, – дип елмайды Илнур. – Урыныңнан кузгалма, мин кофе эчәм.

– Нигә болай иртә тордың? – диде әтисе, чәен чүмереп. – Барасы җирең бармыни?

Илнур кофега сөт өстәде.

– Эш белешергә барам.

Һәм ник болай дип әйтүенә үкенеп куйды. Хәзер сораштыра башлаячаклар инде. Аның уйларын сизгәндәй, әтисе чынаягын өстәлгә куйды:

– Кайда?

– Әлегә үзем дә белмим...

– Утырып эч, адәмчә итеп, – дип шелтәләде әнисе. – Баскан килеш чәй эчәләрмени...

– Ашыгам...

Ул чынаягын тиз генә бушатты да үз бүлмәсенә китте һәм берничә минуттан урамга атлады. Барасы җире ерак түгел иде. Кичәге паркта очрашачаклар. Кичә бик әтәчләнсә дә, бүген беркем белән дә әрепләшәсе килми иде. Арт сабагын укыту теләге дә юкка чыккан. Андыйларны берничек тә үзгәртеп булмый инде. Әтисе әйтмешли, артыннан курай белән өрсәң дә көй чыгарып булмый.

Ләкин хәзер кирегә юл юк иде бугай. Джон янына да барып чыкты, үч алырга теләгәнен әйтте. Шулкадәр әтәчләнеп тә, берни эшләмичә калса, тел бете, буш куык дип уйлаячагы көн кебек. Шулай уйлана-уйлана парк капкасына атлаганда, янына бер машина килеп туктады. Ачык тәрәзәдән таныш тавыш ишетелде:

– Әй, бөҗәк!..

Илнур бер мәлгә югалып калды. Ул мондый мәсхәрәне көтмәгән иде. Кинәт килгән ярсу белән машинаның алгы ишегенә атлады. Хәзер сөйрәп чыгарасы да измәсен изәсе. Шунсыз булмый. Әмма арткы ишекләрдән шуып төшкән ике егет аны ике ягыннан эләктереп алдылар да машина эченә сөйрәделәр. Илнур ни булганын да аңлый алмый калды. Һуш җыеп өлгергәндә, ул машинаның арткы урынында әзмәвердәй ике егет уртасында утыра иде. Чәбәләнеп карады, тик беләгеннән эләктергән куллар тимер кыскыч сыман иде, селкенергә дә ирек бирмәделәр.

– Монда сөйләшеп булмый, – диде таныш тавыш алдагы утыргычтан. – Әйдә, безгә кунакка баргач, барысын да ачыкларбыз.

Машина кузгалып китте. Илнур беркадәр тыныч кына барды да светофорга туктагач, кинәт кенә хәрәкәтләр белән кулын ычкындырды һәм уң ягындагы әзмәверне ишеккә кысрыклады, ә бер кулы белән тоткага үрелеп ишекне ачты. Хәзер тагын бер омтылыш һәм ул әзмәверне төртеп төшереп, урамга чыгачак. Көч кенә димәгән шул. Көтелмәгән кискенлек барысын да хәл итәргә сәләтле. Ул бар хәленә әзмәверне төртеп җибәрде. Әмма шунда ук күз алдында ут шарлары биеште, дөнья чайкалып китте, һәм ул караңгылыкка чумды...

Һушына килгәндә, ул ниндидер ярым караңгы фатирның бер бүлмәсендә аркалы урындыкта башын салындырып утыра иде. Кулларына полиция наручнигы кидергәннәр, аякларын каеш белән тышаулап куйганнар. Ул торып басарга итте, тик артыннан урындык та күтәрелде, шунда гына үзенең скотч белән урындык аркасына да беркетелгәнен аңлады. Шайтан алгыры! Селкенерлек тә чамасын калдырмаганнар... Укыттың ди менә арт сабакларын... Хәзер син тулысынча шушы башкисәрләр иркендә, берни кылырлык та чараң юк.

Каршыда, ике адым ераклыктагы өстәл янында, куе тузан төсендәге костюмына көрән галстук таккан такыр чәчле утыз биш яшьләр тирәсендәге таза гәүдәле ир утыра иде. Коллектор. Ул Илнурның тарткалануын мәсхәрәле көлемсерәп күзәтте дә башын чайкап куйды:

– Кирәкми, кирәкми алай тыпырчынырга...

Чынлап та кирәкми иде. Илнур тынычланырга тырышты. Боларга карышып, берни кылалмыйсың хәзер, җайларына торырга, ачуландырмаска кирәк. Ә үч алу... Бу зинданнан котылсаң, анысына да мөмкинлек табылыр. Дөнья куласа...

– Ник мине монда китердегез? – диде ул, тавышын тигез чыгарырга тырышып. – Мин бит акча алып килдем. Бурычымны түлим.

Коллекторның йөзендә ягымлылыкка тартым бер яктылык пәйда булды. Моны күрүгә Илнурның эче җылынып киткәндәй тоелды. Коллектор елмайды.

– О, әйе, әйе... – Иренендә елмаю булса да тавышы куркыныч иде. – Анысы өчен рәхмәт! Тик бу биш мең синең банкка бурычың. Банкка бурычың бетте, кредит тарихың бозылмаячак.

Илнурның йөзе яктырып китте:

– Шулай булгач?

Коллектор аңа бераз текәлеп торды да бик уйчан кыяфәткә кереп дәвам итте:

– Ләкин эшнең икенче ягы да бар бит әле... – диде ул бик авыр мәсьәләне хәл иткән шикелле. – Менә мин сиңа һәм барлык якыннарыңа көне буе шалтыраттым. Беренчедән, телефонга күпме акча китте... Икенчедән... Минем бер хезмәт көнем илле мең тора. Ә мин сиңа ике көнемне багышладым.

Коллектор, аңлыймы бу, фикерем барып җиттеме, дигәндәй, бер тын Илнурга карап торды. Ә фикер тиз генә барып җитмәде. Дөресрәге, Илнурның аңы моны кабул итми, кабул итә алмый иде. Эшнең кая борылуын аңлагач, ул тагын торырга укталып куйды.

– Тыпырчынма, – дип кисәтте Коллектор. – Син беркая да китәлмисең. Урындыгыңнан ычкынсаң да, әнә, ике абыең тора. Ә алар усал. Әгәр мин тыймасам, сине кәтлиткә әйләндерерләр иде.

Илнур як-ягына борылып карады. Ишек төбендә костюм кидерелгән үгезләр кыяфәтендә баягы ике әзмәвер басып тора иде. Шайтан алгыры! Ул хаклы иде. Чынлап та бер җиргә дә китеп котылырлык түгел.

– Син мине аңладың, шулай бит?

Илнур керфекләрен генә кагып куйды.

– Димәк, минем ике эш көнемне син түләргә тиеш буласың. Йөз мең.

Юк, каршы әйтергә дә, чәбәләнергә дә ярамый. Ачуын гына китермәскә кирәк. Югыйсә ул хәзер нервымны бетердең, дару өчен түлә дип тә сорарга мөмкин. Бу халәттән котылырга гына кирәк. Богаулардан ычкынырга. Ә соңыннан... Соңыннан күз күрер... Пистолет, автомат... теләсә нәрсә... Соңыннан ул уяу булачак, мондый капкынга аңгыра сарык кебек килеп капмаячак. Ә әлегә...

– Тик минем ул кадәр акчам юк.

Коллектор аңа кызганулы карашын төбәп, бераз торды да:

– Теләгән очракта бөтен проблеманы да хәл итәргә мөмкин, – диде. аталарча кайгыртучанлык белән. – Синең бит студентлар арасында танышларың бик күп. Ә аларның кайберсе күңел ачарга ярата... Аңлыйсыңмы? Шуларга аз гына тоз ялатсаң, сыер көтүе шикелле артыңнан калмый ияреп йөриячәкләр. Ә синең бурычың кимеп барачак...

– Юк, – дип кырт кисте Илнур. – Мин беркайчан да наркотик сатмаячакмын.

Коллектор көлемсерәп, дәвам итте:

– Алайса, башка юлны сайларга мөмкин. Синең, мәсәлән, эти-әниеңнең ике бүлмәле фатиры, өй җиһазлары бар. Бай абыең бар. Баҗаең бар. Әйткәндәй, ул түләдеме соң сиңа йөргән кызыңны алып киткән өчен. Әллә бушка гына биреп җибәрдеңме? Кыс менә шуны. Үзеңнең генә кулдан килмәсә, без ярдәм итәрбез. Бушка биреп җибәргәч, азгынлык була бит инде ул. Ә болай, һич югында, бизнес...

Бер... Ике... Өч... Тыныч бул... Тыныч бул! Түз бу хайванның мыскыллавына... Түз!

Тик Илнур булдыра алмады. Түземлек җебе өзелде. Егет бар көчен җыеп ыргылды да тәтедән очкан ук тизлегендә өстәл аша ыргылып Коллекторның бугазына ябышты. Моны беркем дә көтмәгән иде. Бер мәлгә барысы да исәңгерәп калды. Бары тик Коллектор кызарынып-бүртенеп гырлый башлагач кына ике әзмәвер килеп җитте дә аны урындыгы-ние белән бүлмә уртасына атып бәрде. Берсе Коллекторга ярдәмгә ашыкты, икенчесе Илнурны типкәләргә тотынды. Бу хәлнең ахыры бик күңелсез һәм үкенечле булып бетәчәге билгеле иде. Хәзер инде акча түләп кенә дә котылып булмаячак.

Әзмәвер типкәли... Аягы көчле, туфлие каты... Башына тидермәскә тырышып, Илнур әле алай, әле болай боргалана. Аякларга эләккәне дә үзәкне өзә. Ул беренче тапкыр үзенең урындыкка бәйләп куелуына сөенә. Урындык бераз саклый. Югыйсә әллә кайчан изелеп-сытылып беткән булыр иде инде. Болай да чыдар әмәл юк. Һушны гына җуймаска кирәк. Башка гына тидермәскә...

Кинәт дөпелдәгән тавышлар ишетелде. Нәрсәдер ауды, нидер ишелеп төште, челпәрәмә килеп ватылды. Һәм бераздан барысы да тынып калды. Кемдер пычак тотып Илнур өстенә иелде. Егет күзләрен йомды. Тик аны суймадылар, аякларындагы тышауны, билендәге скотчны гына өзделәр. Кайсыдыр аның кулындагы наручникны ычкындырды. Бераздан күтәреп алып, баягы аркалы урындыкка утыртып куйдылар. Илнур хәлсез генә башын күтәрде. Өстәл артында Джон утыра иде. Ә аның белән килгән өч егет канга батып, идәндә аунап яткан Коллекторны һәм аның иярченнәрен стена буена сөйри.

– Кесәләрен, сейфларын тентегез, – диде Джон аларга һәм Илнурга борылды. – Нигә син бер хәбәр дә бирмәдең?

Илнур башта сүзнең ни хакында баруын аңлый алмый торды. Шуннан гына Джонның иртән, коллекторлар белән очрашыр алдыннан, хәбәрләшергә кушуы исенә төште. Ул иңнәрен генә җыерып куйды:

– Өлгерә алмый калдым.

Джон урыныннан торып, Илнур янына килеп басты да аның чалбарының

арт кесәсеннән төймәгә охшаганрак нәрсә тартып чыгарды. Һәм егеткә сузды:

– Менә. Шушы нәрсә булмаса, без сине эзләп табалмый идек. Аңлыйсыңмы? Шушы маяк булмаса, син бүген әрвах идең.

Бераздан егетләр идәндә аунап яткан башкисәрләрнең кесәләрен чистартып, тапкан мөлкәтләрен өстәл өстенә куйдылар. Монда ике пистолет, документлар, берничә пачка акча, тагын әллә нинди вак-төякләр бар иде. Джон өч пачка биш меңлекне алып Илнурга сузды:

– Монысы сиңа, – диде ул, акчаны аның кулына мәҗбүри тоттырып. – Яшәп торырга. Син аңа лаек.

**8**

Джонның машинасына кереп утыргач, Илнур әледән-әле түш кесәсенә караш ташлап алды. Кесәдәге акча пачкалары аның күкрәген кыздыра иде. Алар хәтта курткасын да көйдерәдер, менә-менә киеме кузланыр да аннан биш меңлекләрнең җирән башы килеп чыгар кебек тоелды.

Бу акчалар хәләл түгел иде бугай. Тозлы тиреңне түгеп, җаныңны аямыйча хезмәт итеп, бер эштән икенчесенә чабып йөреп җыелган мөлкәт түгел бит инде. Әнә әти-әнисе күпме йөгереп тә мондый акчаны төшләрендә дә күргәннәре юк. Ә Илнурга ул күктән төшкән бәхет кебек булды.

Икенче яктан карасаң... Аңа да бит бу мөлкәт кул кушырып утырганы өчен күктән төшмәде. Ул үзен мыскыллаучылардан үч алырга теләде. Гомерен куркыныч астына куйды. Бер мизгелдә ул яшәүдән бөтенләй өмет өзәр чиккә җиткән иде. Шулай булгач, бу акчалар аңа тик торганнан гына килмәде булып чыга бит. Яулап алынган мөлкәт. Димәк, хәләл.

Хәрәм булып тоелуы, бәлки, гомер буена үз хезмәтеңә тиешле бәя алалмаудан, шул халәтеңә күнегүдән генә киләдер. Ул бит инде гомере буена кимсетелгән, кулда сизелерлек хезмәт хакы алалмаган гадел һәм ярлы кешеләр гаиләсендә үскән кеше. Хәтта гәзитләрдә дә язалар бит. Төрле чиновникларның эш хакын күрсәтәләр – кайберләре аена миллион сумлап акча ала. Ә хатыннары... Бернәрсә җитештермәгән, бернинди сәләте булмаган шул ханымнарның хезмәт хакы унар миллионга җитә... Илнурның кесәсендәге акча алар өчен печтек кенә булып күренер иде.

Хәләл булып чыга бу акчалар. Юк дигәндә дә, ул үз гомерен куркыныч астына куйды, кыйналды. Тәненең кайбер урыннары әле дә авыртып тора. Күзләрендәге томан беркадәр таралса да, баш сызлавы бетми... Сызлау да түгел инде ул, нindидер оюга тартым бер халәт. Маңгай тирәсен, арт чүмечен ташка катырып куйганнар, диярсең...

Озак кына сүзсез баруга түзмәде бугай, Джон телгә килде:

– Нәрсә, берни дә дәшмисең?

Илнур аңа күз сирпеп алды да елмайгандай итте:

– Уйланып барам әле... – Бераздан өстәп куйды: – акча турында...

– Акча – кирәкле нәрсә, – дип көлде Джон. – Нәрсәсен уйлап торасың инде аның, шатланырга кирәк.

– Шатландым инде мин... – Илнур чынлап та шат икәнен исбатларга теләгәндәй, киң елмайды. – Тик менә шунысы сәеррәк... Көтмәгәндә

шулкадәр байлык... Минем гомергә андый акча күргәнем юк иде... Ә бүген... Ул миңа тиеш түгелдер кебек тоела.

Джон аңа сәер караш ташлады:

– Кемгә тиеш соң алайса? Без үзебезгә тиярен алдык...

– Белмим...

Джон көлемсерәп карап торды да якындагы уңайлырак урында борылып, кирегә җилдерә башлады.

– Кайда борылдык без? – дип аптырады Илнур. – кирегә киттек түгелме соң?

– Әйе, – диде Джон җитди итеп, – кирегә киттек. Әгәр акча сиңа тиеш түгел икән, коллекторларга бирәбез.

Илнурның йөрәге жу итеп куйды:

– Сантыйландыңмы әллә? – дип кычкырды ул. – Тотсыннар капчыкларын! Туйганчы бер бәргәләп алмаганга үкенеп кайтам әле.

Джон кычкырып көлде генә:

– Димәк, акча сиңа тиеш. Менә күрдеңме, барысы да гади бит.

Джонның кире борылуын күреп, Илнур да елмайды. Шайтан алгыры! Ничек кенә туры булырга тырышсаң да, күзгә күренгән, кулга тигән акчаны ычкындырасы килми икән. Зур гына сумма булса, бигрәк тә. Хәтта хәрәм икәнен аңлап торсаң да, үзеңне аклау өчен әллә нинди дәлилләр уйлап табасың.

– Мин синең хәлеңне аңлыйм, – дип елмайды Джон. – Үземнең дә кайчандыр синең хәлдә калганым бар. Һәм мин сиңа бу акчаның үзеңнеке икәнен исбатлап бирә алам.

– Ничек?

– Бик тә гади генә... – дип көлемсерәде Джон. – Син беркайчан да үзеңне кимсетүчеләргә җавап бирмәгәнсең. Шуңа күрә гел уңышсызлык сагалап торган. Әле менә аз гына каршылык күрсәттең һәм бик күп мәшәкатьләреңнән котылдың. Табигать, Алла, югары көч... Нәрсә дип аталадыр ул, белмим. Әмма ул синең тәвәккәллегеңне бәяләде һәм бүләкләде.

Бу сүзләр Илнурның күңеленә сары май булып ятты. Үз уйларыңны, үз аклануларыңны кеше авызыннан ишетү шулкадәр рәхәт икән. Ул ирексездән киң елмаеп, Джонга карады:

– Димәк, бу акча – Ходай бүләге?

– Әйе, синең үз мескенлегеңнән чыгарга теләвең өчен бирелгән бүләк.

Бер карасаң, чынлап та шулайрак иде бугай ул. «Ярый инде», – дип калса, бернәрсә дә эләкми иде бит. Ә ул нәрсәдер эшләргә омтылды...

– Димәк, үзеңне кимсетүче һәр көчкә каршы торырга кирәк?

– Әлбәттә! – дип элеп алды Джон. – Әгәр син бернинди дә каршылык күрсәтмисең икән, бу – ризалык билгесе. Димәк, син үзеңне рәнҗетү белән килешәсең. Килешәсең икән, димәк, канәгатьсең. Ә тормыш сине канәгатьләндерергә теләп, тагы да көчлерәк рәнҗетүләр җибәрә.

– Лев Толстой бер яңагыңа суксалар, икенчесен куярга кушкан...

– Димәк, Толстойның яңагына беркайчан да нык итеп сукмаганнар, – дип көлде Джон. – Ул чорда бәлки шулай кирәк булгандыр. Тик без бүген бөтенләй башка дәвердә, бүтән илдә яшибез. Монда кануннар икенче. Әгәр каршылык күрсәтмисең икән, бернәрсәгә дә ирешеп булмый: сине басканнан

баса, батырганнан батыра баралар. Мескенлегеңне сизеп калсалар, хәтта иң якын кешеләрең дә сине кимсетергә, файдаланырга тырыша.

Илнур әтисе белән әнисен исенә төшерде. Илнурның бар эше дә тәртиптә чакта алар берни дәшми, тыныч кына йөриләр, ә инде хәле авырлаша башласа – һөҗүмгә күчәләр. Укуыннан китәргә мәҗбүр булса – әрлиләр, эш табалмый йөрсә – кимсетәләр... Иң якын кешеләрең әле бу! Калганнарына ни сан инде? Дөрес сөйли Джон. Хәзерге чорның кануннары бүтән... Әхлак кануннары, китап битләреннән алынган белем белән беркая да китеп булмый.

– Сине ни дәрәҗәдә ныграк кимсетергә, изәргә, мыскылларга тырышалар, шул дәрәҗәдә, хәтта аннан да куәтлерәк итеп җавап кайтарырга, каршы торырга кирәк. Шунсыз булмый.

Джонның сүзләре бернинди дә шик тудырырлык түгел иде. Соңгы бер сәгать эчендә булган вакыйга үзе генә дә моны тулысынча раслады. Хәтта аны исәпкә алмаган очракта да... Әйтик, кечкенә чагында... Илнур үзен укырга бирмәүләренә кискен каршы чыкты һәм үз дигәненә иреште. Ходай аңа ярдәмче итеп Рәшидә апаны... искиткеч укытучы Рәшидә Әнвәровнаны җибәрде. Мәктәп парк аша гына булса да, Илнурның аны күптән күргәне юк. Бер узганда шоколад булса да, кертеп чыгарга кирәк әле...

Ә менә Ләйләсен үзенеке итү өчен берни дә эшләмәде. Нидер эшләсә, мотлак, ул аны яулап алган булыр иде. Тик Илнур теләмәде. Гомер буена ышанып йөргән кешесен ятлар түшәгендә күргәч, гайрәте чикте. Ләйлә хәзер үзе ялынып килсә дә, ул аны кабул итәчәк түгел иде. Бәлки...

Әти-әнисе дә... Беркайчан, беркайда, бернинди шартларда да үзләрен изүчеләргә каршы килә белмәделәр. Өйгә кайткач кына, үзара зарланышып алдылар да шуның белән бетте. Югарыдан нәрсә әйтсәләр, шуны тыңладылар. Нәрсә кушсалар, шуны үтәделәр. Нинди басымга дучар булсалар да, баш күтәреп каршы килә, һич югы, сүз әйтә белмәделәр. Менә ни өчен алар шулай гомер буе мескенлектә яшәргә мәҗбүр!

Кинәт аның башында ниндидер фикер ялтырап китте. Ә бит ул үзе дә... Әйтик, укудан куылуы турындагы фәрманны күргәч, бернинди дә каршылык күрсәтмәде. Укыды да борылып китте... Үз язмышы белән, үз мескенлеге белән килеште, димәк. Ә болай итәргә ярамый иде. Хәер, каршы килергә әле дә соң түгел, һич югы, әлеге канунның дөреслеген сынап карау өчен булса да, бер омтылыш ясарга кирәк.

Вакыт әле иртә иде...

– Джон...

Илнурның тавышында тыелгысыз дәрт, ярсу бар иде, ә үзе иңнәренә канат үскәндәй, урынында талпынып куйды. Джон гаҗәпләнүле карашын аңа төбәде:

– Нәрсә булды?

– Джон... – Илнур сүзне нәрсәдән башларга белмичәрәк торды. – Хәзер безгә кайтабыз да мин өсне алыштырып, документларны алып чыгам һәм...

Джон елмаеп аны дәвам итте:

– Без пистолет алырга китәбез... – диде ул, башын чайкап. – Юк, туган, алай җиңел генә килеп чыкмый. Син миңа документларыңны бир. Мин синең өчен лицензия эшләтәм һәм коралга заказ бирәм. Соңыннан, бәлки, икәү бергә барып алырбыз. Бәлки, үзем генә...

Илнур ярсып, аны бүлдерде:

– Юк, Джон, юк... – диде ул һәм бераз суынып дәвам итте: – әйе, анысы да кирәк... Анысын син үзең эшләрсең... Документларны калдырам... Ә мине институтка илтеп куярсың.

– Институт? Анысы нәрсәгә тагын?

– Ректорга керәм. Каршы килү кануның ничек эшләвен сынап карарга телим.

Джон көлеп җибәрде:

– Ә син текә егет...

* * *

– Сез язылган идегезме? – диде сәркатип кыз, аңа баштанаяк күз йөгертеп. – Ул сезне беләме?

– Юк, – Илнур үзен җитди тотарга тырышты, – мин шәхси мәсьәлә буенча.

Сәркатип ректор бүлмәсенә кереп, беркадәр торып чыкты да егеткә эндәште:

– Көтегез.

Ректорның бушаганын озак кына көтәргә туры килде. Аның кәефле чагы иде бугай, егетне күргәч, ни өчендер елмаеп куйды:

– Нинди йомыш?

Илнур хәлен аңлатып бирде. Аз гына үзенчәләтергә туры килде, әлбәттә.

– Хастаханәдән чыгып, институтка килүемә укудан куылу турында боерык эленеп тора... Ачуланып, кимсенеп борылып киттем. Уйланып йөрдем дә сезгә килергә булдым.

Ректор аңа беркадәр текәлеп карап торды. Яхшы киенгән, җитди егет. Тышкы кыяфәтенә берничек тә тел-теш тидерерлек түгел. Һәм ул деканны чакырып кертте.

Декан ул студентлар алдында гына декан икән, ректор янында бик әллә кем түгел, исәнләште дә башын иеп кенә, стена читендәге урындыкларның берсенә барып утырды.

– Сезнең студентмы? – диде ректор, күзләрен ялтыратып. – Таныйсызмы?

– Әйе. Галиев.

– Студентларын танымаучылар да очрый, – дип елмайды ректор. – Укытучыларының күзенә сирәк күренәләр дә... Ә бу егетне ни өчен укудан кудыгыз?

Декан бер мәлгә ык-мык итеп торды:

– Дәресләргә йөрми, койрыклары күп... – диде аннан соң. – Уку вакытында ук эленке-салкы йөргәч, аннан яхшы белгеч чыга алуы икеле.

Ректор бер мәлгә алдындагы кәгазьләрне актарып утырды, аннан башын күтәрде:

– Шулай икәнен белгәч, нигә алдарак кумадыгыз? Әйтик, бер ай элек...

– Ул вакытта йөрештерә иде әле. Бәлки, төзәлер дигән өмет тә бар иде...

Ректор тагын кәгазьләрен актарырга кереште, бераздан Илнурга борылды:

– Китер әле больничныеңны.

Илнур портфеленнән зәңгәрсу кәгазь алып, ректор алдына куйды. Ректор аны деканга сузды:

– Танышыгыз әле.

Декан эшнең нәрсәдә икәнен шундук аңлады бугай, кәгазьгә күз генә салды да:

– Без бит бу хакта белмәдек, – дип акланды һәм Илнурга карап куйды. Илнур иреннәрен кысты. «Белдегез. Бик белдегез». Тик берни дә дәшмәде.

Ректорның катгый тавышы яңгырады:

– Әгәр кешене ашыгыч ярдәм белән хастаханәгә алып китәләр икән, ул бу хакта сезгә үзе килеп әйтергә тиешме?

Декан дәшмәде.

– Укуга кире кайтарыгыз, – диде ректор, сөйләшүгә нокта куеп. Һәм Илнурга борылды. – Ә син ике атна эчендә бөтен бурычларыңны биреп бетер. Сау булыгыз.

Илнурның кабат үз төркеменә барып укуын дәвам итү теләге юк иде. Бу мәсьәлә үзеннән-үзе хәл ителде.

– Мин синең койрыкларыңны тиз арада бетерү хәстәрен күрермен, – диде декан. – Тик үзеңә дә бер үтенечем бар.

Илнур итагатьле генә сорап куйды:

– Нинди үтенеч?

Декан бер мәлгә егеткә текәлеп торды да:

– Җитди үтенеч, – дип серле елмайды. – Син әлегә күренеп йөрмә, уку елы бетәргә дә күп калмады – билгеләреңне үзем куйдыртырмын. Ә киләсе елдан читтән торып укуга күчеп торырсың. Анда да зачёткаңны үзем хәстәрләрмен.

Илнур елмаюын яшерергә тырышып, җитди кыяфәт чыгарды. Уйлана, янәсе. Ә чынында ул деканның ни өчен болай яхшатланып китүенең сәбәбен төшенә иде. Илнурны укудан куганы өчен Денистанмы, аның кешеләреннәнме, зур гына акча алган бит инде ул. Хәзер шуны кесәсендә калдыру өчен Илнурның институтка килеп йөрмәве, күзгә-башка күренмәве кирәк.

– Яхшы... – диде дә Илнур тотлыгып калды. Болай дияргә ярамый иде. Каршылык күрсәтергә кирәк! Һәм ул дәвам итте: – Яхшы булмас бит алай. Надан булып калачакмын бит.

Декан бер тын уйланып торды.

– Беркадәр үзаллы шөгыльләнергә туры килер инде. – Ул уң кулы белән ияген кашып алды, күзлеген төзәтеп куйды, колак артын сыпырды һәм түш кесәсеннән ручка алып, аны бармаклары арасында әйләндерә башлады. – Мин... Мин сиңа иң мөһим темаларның исемлеген табып бирермен. Кыскача язылган конспектлар рәвешендә...

Илнурның кычкырып көләсе килде. Тик җитдилеген җуймады.

– Ярый инде, – дип уфтанып куйды ул бу гамәлгә чарасыздан барган кеше кебек. – Сезнең хакка алай итәргә дә була.

Деканның йөзе яктырып китте:

– Рәхмәт, Илнур! – дип, аның кулын кысты. – Бик зур рәхмәт. Ниндидер мәсьәләләр булса, туп-туры үземә кил. Ә бу сөйләшү икебез арасында гына калсын.

Каршылык күрсәтү кануны берсүзсез эшли иде.

Институттан чыккач, Илнур хисләренә урын табалмыйча йодрыклары белән һаваны ярып кычкырды:

– Йоһоһау! Эшли, шайтан алгыры! Берсүзсез эшли!

Кычкырырлыгы да бар иде. Хәзер ул укуына кире кайтты. Акча проблемасы хәл ителде. Теләсә, Ләйләне дә кире кайтара ала. Бар дөньясы түгәрәк хәзер аның. Кайдан килеп чыкты соң бу Джон! Кыйналып, паркта аунап яткан чагында юкка гына күзенә фәрештә булып күренмәгән икән. Шуны очратканнан бирле бөтен эшләре җайга китте бит. Бәлки, ул чынлап та Ходай тарафыннан җибәрелгән изге заттыр? Изге зат булмаса, бер таныш түгел кешегә шул тиклем ярдәм итмәс иде.

**9**

Ә укуга йөрмәү бик урынлы булып чыкты, чөнки аны Джон шул көнне үк үзенә эшкә чакырды.

Телефоннан шалтыратуга ук килеп җитте дә юл уңаендагы бер кафега кереп утырдылар. Бу кечкенә ашханә тыныч һәм бар җиреннән яктылык бөркелеп тора иде. Ак эскәтер белән капланган түгәрәк өстәлләр дә, ак җирлектә сыек кофе төсендәге чәчәкләр белән бизәкләнгән стеналар да, аксыл-саргылт тәрәзә пәрдәләре дә ниндидер сафлык, наз, җылылык таратып торган сыман. Керү белән борынга килеп бәрелгән тәмле ризыклар исе, өстәл янына утыруга ашказанын тәкатьсез итә. Ә инде чибәр официант кызның елмаеп поднос тулы татлы ризык күтәреп килүен күрү үзеңне оҗмахка эләккәндәй хис иттерә. Хур кызлары сиңа ни теләсәң, шуны китереп торадыр сыман тоела. Талгын гына музыка агыла, ул җиңелчә искән ягымлы җил сыман иркәләп кенә уза.

Икесе дә ярыйсы ук ачыккан идеме, әллә өстәлдәге ризыклар ымсындыргыч булдымы, башта артык сөйләшмичә генә тәлинкәләрне ялтыратып куйдылар. Өстәлдә чәй генә торып калгач, Джон сүз башлады.

– Без төрле игелекле эшләр белән шөгыльләнәбез, – диде ул үтенгәндәй итеп. – Кешеләр җитеп бетми. Син дә ярдәмгә килсәң, бик яхшы булыр иде. Теләгең булса, әлбәттә.

Көтмәгәндә килеп чыгып, тормышыңны үзгәртеп, матурлап җибәргән кешегә карышып торып булмый. Джонның кул астында эшләргә үзенең дә теләге зур иде.

– Әлбәттә, теләк бар. Кайчаннан башларга?

Джон аңа сынап карап торды да елмаеп җибәрде:

– Бүгеннән.

– Килештек, – дип, учын сузды Илнур. – Бүгеннән.

Учларын шапылдатып бәрештеләр. Илнурның күңеле күтәренке, авызы ерык иде. Тик Джон җитди кыяфәткә керде:

– Тукта, син ашыкма, – ул бераз тынып торды һәм һәрбер сүзен сеңдерергә теләгәндәй, талгын гына дәвам итте. – Безнең оешмада урамнан кереп кенә эшләп булмый, кайчагында бик җитди нәрсәләр белән шөгыльләнергә туры килә.

– Мәсәлән? – диде Илнур тәвәккәл тавыш белән һәм үзенең ник болай итүенә үкенеп куйды. – Хәер...

– Син аның кайбер моментларын үзең дә күрдең, – дип дәвам итте Джон егетнең ахмаклыгына игътибар да биреп тормастан. – Җитди, җаваплы, кайчагында хәтәр-куркыныч эшләр... Без тормышның гаделсезлекләренә

каршылык күрсәтәбез, мохтаҗларга ярдәм итәбез. Ә моның өчен бик зур әзерлек кирәк.

Джон тынып, аңа текәлде, бу юлы Илнур берни дәшмичә сүзнең дәвамын көтте.

– Күнекмәләр бик кырыс шартларда уза. Сиңа йокысыз төннәрне дә күрергә, ачлыкны да татып карарга, сугышырга, хәтта кыйналырга – тормышның бөтен михнәтләренә каршы көрәшергә туры киләчәк. Син шуңа әзерме?

Илнур мондый михнәтләрнең барысын да күргән сыман иде. Шуңа ике дә уйлап тормыйча чатнатып җавап бирде:

– Мин барысына да әзер!

– Яхшы. Бу күнекмәләр синең ихтыяр көчеңне, рухыңны ныгытачак. Әгәр сынауларны уңышлы уза алсаң, син гаделсезлекләргә каршы торучы, изелгән халык бәхете өчен көрәшүче каһарманнар сафына аяк басачаксың.

Илнур бер мәлгә дертләп куйды:

– Ә уңышлы уза алмасам?

– Ул чакта безгә хушлашырга туры киләчәк.

Илнур йодрыкларын йомарлап, тешен кысып куйды. Җиңеп чыгачак ул бар сынауларны да. Андагы ихтыяр көче башка берәүдә дә юк. Нәрсә-нәрсә, ә чыдамлыкка нык өйрәтте аны тормыш.

– Хушлашмабыз.

– Мин моңа бик нык ышанам. – Джон элеккечә үк җитди иде. – Тагы бер нәрсә бар. Сиңа күнекмәләр вакытында безнең базада яшәргә туры киләчәк, шулай уңайлырак булыр. Бер-ике атна яки берәр ай тирәсе. Барысы да сабакларны ничек үзләштерүеңнән тора. Син аңлыйсыңмы?

Әти-әнисенең үзара әләгешеп торулары да, кече малайларына әледән-әле бәйләнеп, кимсетүләре дә ялкыта төшкән иде. Илнур шатланып ризалашты.

– Әти-әниеңә: «Вахта белән эшлим, берәр ай тирәсе өйдә булмам», – дип әйтерсең. Югалтып, борчылып тормасыннар.

Тиздән аларның төркемен мәктәпләргә кыска вакытлы практика үтәргә җибәрәчәкләр. Кемнәрдер шәһәрдә кала, кемнәрдер районнарга китә. Шуңа Илнур өйдәгеләргә, «Укуга кире кайттым, практика үтәргә китәм», – дип әйтергә җыенып тора иде. Болай тагы да яхшырак булып чыга. Вахталы эш – һәм вәссәлам! И бу Джонның башы эшли дә соң, бар нәрсәнең җаен таба белә. Соклангыч! Күнекмәләрне уңышлы уза алса, бәлки, Илнур да шулайрак булыр әле.

– Яхшы.

– Әти-әниеңнәрне борчылдырырга ярамас, алар бит болай да ачы тормышта яши. – Джонның тавышында әйтеп бетергесез җылылык, хәстәрлек тойгысы ишетелде. – Хөкүмәт тә изә аларны, бизнес хуҗалары да, банклар да. Адәм тәганәсе бит, шулкадәр бай илдә гади халык шулкадәр хәерче яши. Кайда гына барып төртелсәң дә, хезмәт хакың унбиш-егерме меңнән артмый. Ә ни өчен шулай? Чөнки кешеләр кредит алырга тиеш! Хезмәт хакы югары булса, кредит алучы булмый, димәк, банкларны беркем дә баетмый. Менә бит алар ничек мыскыллый халыкны!

Джон дөрес сөйли иде. Кайда гына барып карасаң да, 15-20 меңнән артык түләмиләр, әле аларында да эшкә алмый интектерәләр. Зуррак хезмәт хакы

биргән урыннарга эләгә алган кешеләр беркая да китмичә, шунда чат ябышып утыра. Зур акчалы эш урыны табу өчен башта зур күләмдә ришвәт бирергә кирәк икән, дип тә сөйлиләр. Монысын Илнур төгәл әйтә алмый, беркайчан да алай итеп караганы булмады – ришвәт бирерлек акчасы юк иде.

– Менә, Илнур, синең игътибар иткәнең бармы икән, бөтен ил буйлап халыкны хайванга әйләндерү бара бит. Совет чорында алар һич югы эш аты булган, ә болар эш аты да түгел... Болар – куллану механизмы... Сатып алу коралы... Кредит түләү өчен яратылган кавем... Илнур, син авыл тормышын белмисеңдер инде... Тик бүгенге халык авыл фермасындагы савым сыеры хөкемендә. Ул сөт бирергә яки иткә озатылырга тиеш. Һәм ул үз хәлен үзе аңларлык дәрәҗәдә түгел...

**10**

Озак кына баргач, машина каядыр килеп туктады. Илнур йокымсырап киткән җиреннән күзләрен ачты. Тома караңгылык. Джон аның башына капланган япманы салдырды:

– Гафу ит, туган, шулай кирәк, – диде ул җитди генә. – Хәвефсезлек өчен.

Катнаш урман эчендәге зур булмаган аланлык иде бу. Ара-тирә ниндидер калкулыклар серәеп тора. Чак кына ерактарак, футбол мәйданчыгы шикеллерәк яланда һәртөрле спорт корылмалары урнаштырылган: каршылыклар аша үтү җайланмалары, кулларны-аякларны ныгыту әсбаплары... Алар тирәсендә берничә кеше күнегүләр ясый. Беренче карашка күнекмәләр үзәгенең әллә ни һуш китәрлек җире юк иде.

– Ял итәсеңме, әллә хәзер үк күнекмәләргә керешәбезме? – дип, Илнурга текәлде Джон. – Барысы да синнән тора.

– Күнекмәләргә керешербез. – Илнур бу урман арасында ял итүнең нindirәк булырын чамалый кебек иде. – Монда бушка черки туйдырып ятудан файда булмас.

– Теләсәң төрле фильмнар, видеолар карарга, компьютер уеннары уйнарга мөмкин, – дип елмайды Джон, – китаплар укырга. Монда барысы да бар.

– Күнекмәләргә керешербез.

– Яхшы. – Джон якындагы калкулыкка табан атлады. – Әйдә, башта урнашыйк.

Калкулыкның бер як читенә җитүгә, Джон кесәсеннән кечкенә пульт чыгарып, аның төймәсенә басты һәм моңа кадәр яшел чирәм булып торган урын икегә аерылды да ишек сыман нәрсә хасил булды. Текә генә таш баскыч буйлап түбәнгә атлауга стеналарга беркетеп ясалган плафоннарда утлар кабынды һәм тирә-як яктырып китте. Ике кеше сыярлык коридорның ике ягында да бүлмәләр урнашкан иде. Беркадәр атлагач, Джон шул бүлмәләрнең берсен ачып керде.

Бетон стеналы гади подвал бүлмәсе иде бу. Бераз дымсу. Салкынчарак. Түрдәге стена буенда кечкенә өстәл, уң якта тактадан ясалган как караватъ, караватъ өстендә телевизормы, ниндидер мониторм шунда – яткан килеш кенә карап була торган бер нәрсә инде, каршы якта стенада – сугыш алымнарын өйрәнү өчен эшләнгән җайланмалар, идәнендә – 3-5 килолы гантельләр, ишек төбендәрәк тактадан ясап, лак белән эшкәртелгән кием шкафы. Аның артында – ачык туалет, болай ис-косы юк, унитазы каплап

куелган. Сул як ишек төбендә кечкенә раковина, аның өстендә стенага эленгән тартма, раковина янында кечкенә тумбочка.

– Бу синең бүлмәң булачак, – диде Джон. – Шкафта киемнәрең. Өстеңне алыштыр да коридорга чык.

Илнур шкафтан хәрбиләрнекенә охшатыбрак тегелгән күксел-кара униформа алып, аны караватка куйды. Чишенде. Үз киемнәрен пөхтә итеп төреп, рюкзагына тыкты. Рюкзактагы юыну-кырыну әсбапларын алып, раковина янындагы тумбочкага куйды. Киенде. Көзге эзләп, тирә-ягына каранып алды, табалмады. Монда бер нәрсә дә ул өйрәнгәнчә түгел иде, хәтта беркадәр моңсу булып китте. Ярый, күнегер әле. Шартлар бик кырыс булачак, диде бит. Шуларны җиңеп чыгарга кирәк инде хәзер.

Коридорга чыкканда, Джон көтеп тора иде. Үз артыннан ияреергә кушып ым какты да ары атладылар. Коридорның теге башына җиткәч кергән озын бүлмә тир булып чыкты. Монда мишеньнәр әзер иде инде, Джон уң яктагы шкафны ачып, калашник автоматы тартып чыгарды да Илнурга сузды:

– Ата беләсеңме?

Илнур көлемсерәп куйды.

– Беләм...

Ул автоматның магазинын ычкындырып, патроннары барлыгын тикшереп карады да предохранительне алып, мишеньгә төбәде. Илнур ата белә иде. Ярата иде бу шөгыльне, шәһәрнең кайсы төшендә генә тир күрсә дә кермичә китми, кайчагында бөтен акчасын шунда бетерә иде. Өстәвенә, әтисенең энесе авылда яши һәм җәй буена ауга йөри. Авылга кайтканда, Илнур да аңа иярә һәм җәнлек-җанвар тапмасалар да, консерва банкаларын кырып кайталар. Абыйсының ау мылтыклары берничә, ул һәрвакыт яңа модельләр алырга тырыша, аларның барысын да тәртиптә тота. Коралларны яхшы саклау серләренә Илнурны да өйрәтә иде. Мылтык мылтык инде ул. Ә менә Калашников автоматыннан Илнур берничә тапкыр гына атып карады. Соңгы тапкыр мәктәптә хәрби җыеннар вакытында бугай. Бик начар дип әйтерлек түгел инде түгелен, ун пуляның өчесе унлыкка эләкте, калганнары тугыз белән алты арасында калды.

Ул бераз дулкынлана иде. Йөрәге ашкынып тибә. Мондый чакта үзеңне кулга алу җайсызрак – сулыш ешая, куллар бераз дерелди. Шуңа күрә беркадәр тынып торды, тынычланырга теләде. Ниһаять, сулышын тыеп, бер мизгелгә катып калды һәм тәтене тартты. Бер-бер артлы шартлау тавышы яңгырады. Берәмләп ату режимына көйләнгән автомат ут сиптерде. Бераздан Илнур автоматны читкә алып, предохранительгә куйды да мишеньне карарга йөгерде. Тишекләрнең күпчелеге уртада иде бугай, урап килүгә үк Джон кәгазьне аның кулыннан тартып алды да кычкырып җибәрде:

– Һо-һо-һо! – аның тавышында соклану катыш гаҗәпләнү ишетелде. – Син бит – әзер снайпер! Әйдәле, тагын бер тапкыр.

Икенчесе дә әйбәт кенә килеп чыкты. Монысында хәтта барлык пуля да ун һәм тугыз тирәсендә диярлек иде.

– Бу этапны үттек дип уйлыйк. – Джон автоматны кабат урынына куйды да янәшәдәге шкафтан мылтык тартып чыгарды, аның тәтедән өстәге өлешенә «Escort» дип язылган иде. Хасан Эскорт. Нәкъ менә Илнурның туган абыйсы узган җәйдә сатып алган төрек винтовкасы.

– Автомат, әлбәттә, яхшы нәрсә, – дип дәвам итте Джон. – Тик аңа лицензия алып булмый һәм шәһәр буйлап йөртү бик уңайсыз. Ә менә мылтыклар күпкә җайлырак. Мондый винтовканы күргәнең бармы?

– Бар, әлбәттә, – дип елмайды Илнур. – Минем абый аучы бит.

Джон мылтыкны Илнурга тоттырды да өстәл тартмасыннан биш патрон алып, Илнурга сузды:

– Мә, күрсәт егетлегеңне.

Бу юлы Илнур дулкынланып интекмәде, патроннарны корды да бер-бер артлы атып җибәрде. Хасан Эскорт иң җайлы винтовкаларның берсе иде. Йөртергә җиңел, ике кило да өч йөз грамм чамасы гына тора. Төгәл ата, иңсәгә бәрми. Бары тик патроннарын гына дөрес сайларга кирәк, югыйсә кайвакыт осечка биргәлиләр. Джон мишень янына җитү белән тагын кычкырып җибәрде:

– Илнур, син просто маладис! Бишесе дә унлык янында.

Тагын берничә мылтыктан атып карадылар. Барысы да уңышлы гына килеп чыкты, әлбәттә, гел унлык түгел инде, әмма Джон канәгать иде.

– Әгәр бу этапны уңышлы узсаң, киләсе көнекмәләрдә сине йөргәндә, шуышканда атарга өйрәтәсе генә кала. Иртәгә хәрәкәтләнә торган мишеньнәр белән шөгыльләнербез.

– Ә нигә хәзер үк түгел? – Илнурның күңеле күтәренке иде. – Минем куян атып алган да бар ул...

Джон рәхәтләнеп көлде:

– Яхшы, яхшы, Илнур... Тик һәр нәрсәнең үз вакыты... Хәзер бераз тамак ялгап алабыз да кул сугышы алымнары буенча дәрес үткәрәбез.

Тамак ялгау турында сүз чыгуга, ашказаны кысылып-кысылып куйды. Иртәнге якта бик әйбәт кафеда сыйлансалар да, шуннан бирле бер валчык икмәк тә капканнары юк икән бит. Ачыктырган. Инде вакыт та ару гына чабып өлгергән икән, тир стенасындагы сәгать өченче яртыны күрсәтә.

Төшке аш иртәнгесеннән күпкә аерыла иде. Беренчедән, алар бернинди кафе, яки ашханә кебек җиргә дә барып тормадылар. Джон: «Мин тиздән килермен», – дип, Илнурны үз бүлмәсенә калдырып китте. Ә бераздан ишектәге тәрәзә сыман нәрсә ачылды да кемнеңдер:

– Төшке аш, – дигәне ишетелде. – Кабул итеп алыгыз!

Илнур аларны өстәлгә урнаштырды. Джонга да бирерләр дип уйлаган иде, тик тәрәзә шундук ябылды. Нәкъ төрмәдәге шикелле. Илнур шулай уйлап, ишекне ачарга итеп карады, тик ул ачылмады. Чынлап та төрмә шикелле икән. Бу күренеш күңелне төшерә башласа да, бирешергә ярамый, Илнур барлык сынауларны да җиңеп чыгарга тиеш, ә моның өчен ашарга кирәк иде.

Икенчедән...

Бәрәңге белән кәбестәдән торган шулпага... аның хәтта суганы да юк иде бугай... арзанлы балык консервасы салып бутаганнар да шуның белән вәссәлам иткәннәр... Ачыгуың җиткәч, беренче калаклары бик җиңел керә, тик соңгарак гайрәтне чигерә башлый. Бу ашка шикәр дә салынгандыр кебек тоела. Алай түгелдер инде ул, ашка шикәр салмыйлар бит инде. «Второй» дигәне дә бик әллә ни булып чыкмады. Шикәр һәм тагы нииндидер тәмләткечләр кушып, суда пешерелгән манный боткасы. Аның каравы, зур бокалга ясалган сөтсез чәй тәмле иде. Каты һәм шикәрле. Тик бу очракта

шикәр чәйнең тәмен бозмый, киресенчә, аңа ниндидер үзенчәлекле бер чалым биреп, тәмләтеп тора.

Күп тә үтмәде, ишектәге тәрәзәчек кабат ачылып китте:

– Савыт-сабаны бирегез, – дигән тавыш ишетелде.

Илнур чәен тиз генә эчеп бетерде дә шаяртырга уйлады:

– Ә бирмәсәм?

Аңа шундук коры җавап кайтардылар:

– Кичке аш булмаячак.

Шаяртуны аңлау да юк. Ачулану да юк. Бары тик фактларны теркәү. Коры битарафлык. Шомландыра торган мондый битарафлыктан югалыбрак калган Илнур шундук савыт-сабаны җыеп бирде. Тәрәзә ябылды. Илнур өстәл артына барып утырды.

– Төшке аштан соң ярты сәгать ял, – дигән битараф тавыш ишетелде. Илнур аның кайдан килүен чамаларга тырышып, күзләрен йөгертте. Стенага уеп ясалган колонка сыманрак нәрсә бар икән. Егет барып тарткалап карады. Колонка бармак юанлык тимер рәшәткәләр артында иде, аның тавышын көйләп тә, туктатып та булмый. Әллә нинди уйларга бирелмәкче иде, «ярты сәгать ял» дигәнне искә төшереп, караватка барып ятты. Моннан ары ниләр көтәчәген белеп булмый, әлеккәндә ятып торырга кирәк.

**11**

Кул сугышы буенча күнекмәләр үткәрү өчен алар җир өстендәге спорт мәйданчыгына чыктылар. Монда бер груша асып куелган иде. Аның янында берничә гантель, катыргы тартмаларның берсендә бокс перчаткалары, калганнарында тагын нәрсәләрдер. Күнекмәләр беткәч, барысын да алып китәләр – бернинди эз калмый. Читтәрәк тапталып беткән чирәмлек, күрәсең, көч сынашулар шунда уза.

– Башта разминка ясап алырбыз, – диде Джон һәм җиңелчә генә йөгереп китте, – миннән ун метрдан да арттарак калмаска.

Илнур көлемсерәде. Шундый акрын гына барган кешедән ничек артта каласың ди инде. Теләсә, ул аны үзе калдырып китә әле... Ләкин Джон акрынлап кына тизлекне арттыра барды һәм аның белән янәшә йөгерү авырлаша башлады. Өстәвенә, кояш кыздыра, маңгайларга, борын очларына тир бәреп чыкты. Күнегелмәгән ят кием тәнгә ышкылып җәфалый. Кыйналу да үзен сиздерә, әле ул төше, әле бу төше авыртып ала. Тик сер бирергә ярамый иде. Илнур биш метр тирәсеннән дә калмаска тырышты.

Аланлык буйлап йөгергәндә шулай иде. Көтмәгәндә, Джон урманга каерды да чытырман арасына кереп китте. Монда йөгерү күпкә кыенрак: аяк астындагы вак куакларның кайсын сикереп чыгарга, кайсын урап узарга кирәк, кайберләре аякны сыдыртып кала. Джонның бик исе китми, ул тизлеген бик үк киметми дә – мондый урыннарда йөгереп өйрәнгәндер инде. Ә Илнур йөдәп бетте. Ахыр чиктә, буыннары йомшарды, үпкәләре сызгыргандай тоела башлады. Берәр куакка абынып егылса, торып басарлык хәле дә юк иде бугай. Ярый әле тиздән аланлыкка кабат чыктылар да Джон җиңелчә йөгерүгә күчте.

Спорт мәйданчыгына җитүгә аларны ябык кына гәүдәле бер егет көтеп тора иде. Илнур кебек үк киемнән. Йөзен сакал-мыек баскан.

– Бәреп ек шуны! – дип боерды Джон. – Син аны сугып аударырга тиеш!

Илнур йөгереп килгән уңайга, егет күрешергә кул сузды.

– Күрешмә, бәреп ек! – дип боерды Джон.

Илнур егетнең сузылган кулына игътибар итеп тормастан, аның ияк төбенә тартты. Көчле генә бәрде. Аперкот ясарга ул ярата иде. Әмма йодрыгы һаваны гына телеп узды. Сакаллы егет бер адым да читкә атламаган килеш ничектер янтаеп калды. Илнурның күзе маңгаена менде. Ничек шулай булдырып була икән? Хәтта ул бер мизгелгә бу егет өрәк, яки голограмма-фәлән түгел микән дип шикләнеп тә куйды.

– Бәр тагын! – дип кыздырды Джон, – бәр!

Илнур бер мәлгә тынып калды. Көндәше белән араны билгеләргә тырышты, аның ничегрәк күченү мөмкинлеген чамалады. Салкын канлы булырга кирәк. Һәм үзенең ярышлар вакытында куллана торган иң яраткан алымнар берлеген күз алдыннан үткәрде. Җитезлек, төгәллек кирәк иде. Һәм бөтен мөмкинлеген бер ноктага туплап, һөҗүмгә күчте. Ярыйсы гына килеп чыкты. Сугу техникасы да, тизлеге дә, төгәллеге дә... Ләкин көндәше бер-ике хәрәкәт кенә ясады да бер зыянсыз көйгә аягында басып калды. Бу чынлап та Өрәк-егет иде.

– Яхшы, – дип көлде Джон. – Әлегә җитеп торыр.

Алар кабат Илнурның бүлмәсенә керделәр. Джон аны груша янына алып килде.

– Моңа кадәр спорт секциясендә өйрәнгәннәреңне оныт, – диде ул этиләрчә хәстәрлекле тавыш белән. – Спорт белән урам сугышы икесе ике нәрсә. Сугышта сине чикли торган кагыйдәләр юк. Монда синең аягыңны югары күтәрүең, сикерүең – матур алымнар ясавың беркемгә дә кирәкми. Син тамашачылар яки судьялар өчен эшләмисең. Синең төп максатың – исән калу. Ә көндәшеңнең төп максаты сине үтерү яки һуштан яздыру. Шуның өчен монда иң гади һәм үтемле алымнар таләп ителә. Андый алымнар да бик күп. Тик син аларның барысын да тиешенчә үзләштереп бетерә алмаячаксың. Үзеңне саклау өчен берничә алым җитә. Менә, карап тор.

Джон груша алдына басты.

– Игътибар белән кара.

Илнур ничек кенә игътибарлы булырга тырышса да, күреп җиткерә алмады. Джон сизелер-сизелмәс хәрәкәт кенә ясаган кебек булды. Ә груша уртасында тирән бер яра булып йодрык эзе калды.

– Урам сугышында күп нәрсәне кискенлек һәм көтелмәгәнлек хәл итә, – диде Джон һәм баягы хәрәкәтен әкренәйтеп кабатлады. – Һәм төгәллек. Кешенең авырту нокталары бар, син төп-төгәл шул нокталарга бәрергә тиешсең. Хәтта сугуың баһадирларча көчле булмаса да, бу дошманыңны билгеле бер вакытка сафтан чыгарачак. Ә хәзер минем арттан кабатла.

Джон акрын гына уч төбе белән сугу техникасын күрсәтте. Илнур аның артыннан кабатлады.

– Юк, алай түгел, – дип төзәтте Джон. – Менә болай. Син бары тик кулың белән генә сугасың. Дулкын синең аякларыңнан ук килеп бөтен гәүдәңә күчәргә тиеш. Гәүдәңдәге гайрәтне уятырга. Һәм син шул гайрәтнең барысын да кулыңа күчерәсең. Бу очракта сугу көче күп тапкырга арта. Менә болай. Сизәсеңме?

Илнур аның күрсәткәннәрен җиренә җиткереп үтәргә тырышты. Беренчесе килеп чыкмады. Икенчесе ничектер сизелер-сизелмәс кенә булды. Әмма акрын гына кабатлый торгач, ул аякларыннан килгән агымның үз тәненә күчеп көчәюен тойган кебек булды. Хәзер аны кулга күчерергә кирәк иде. Күп тапкырлар кабатлый торгач, анысы да килеп чыга башлады.

– Менә шулай, – дип сөенде Джон. – Бүгенгә шушы күнегүне кабатла. Уң кулың белән дә, сулы белән дә. Көч дулкынын аякларыңнан тәнеңә, тәнеңнән кулларыңа күчерергә өйрән. Моны тизләтү өчен менә мондый күнегүләр ясa.

Һәм ул берничә күнегү өйрәтте. Болар бик катлаулы хәрәкәтләр түгел иде. Әмма күнегелгән булмагач, җайсыз тоелдылар, арыттылар. Өстәвенә, көч агымын күзәтергә, сулышны дөрес алырга да кирәк иде. Боларын өйрәнгәч тә, талгын гына хәрәкәт иткән җирдән кинәт кискен итеп бәрү өлешен үзләштерә алмый интекте. Күнегүләр бераз килеп чыга башлагач, Джон кичке ашка кадәр кабатларга кушып саубуллашты:

– Иртәгә иртә белән йөгерергә чыгабыз, – диде ул. – Аннан соң ату буенча күнекмәләр. Кичке аштан соң яхшылап ял ит. Бер арада синең рюкзагыңны алырга килерләр. Шулай тиеш. Бирмәскә тырыш. Сугыш. Җиңелсәң – алып китәләр, җиңсәң – үзеңдә кала.

Ул киткәч, Илнур күнегүләрне озак кына кабатлады. Сугу алымын үзләштерергә тырышты. Яхшы гына килеп чыга башлады. Ул хәтта: «Эх, менә бу хәрәкәтләрне Джон күрсә!» – дип уфтанып та куйды. Озак кына шулай маташкач, ишек тәрәзәсе ачылып китте дә аннан:

– Кичке аш! – дип аваз салдылар.

Кичке ашның да әллә ни рәте юк иде. Төеп пешерелгән бәрәңге. Суда пешергәннәр бугай. Тозы да юк. Бер сынык икмәк, анысы да каткан арыш ипие. Сөтсез сыек чәй. Шикәре күп. Эчкәндә тәмле кебек тоелса да, тамакны киптерә. Ярый әле бүлмәдә су бар. Тынчыган тәм килеп тора торуын, әмма салкын, сусауны баса алырлык.

Кичке аштан соң бераз ял алырга дип ятса, ишек ачылып китте һәм аннан үзе кебек үк киенгән өч егет килеп керде. Берсе коры гына әйтеп куйды:

– Үзең белән алып килгән бөтен әйберләреңне дә тапшырырга кирәк булыр.

– Ни өчен? – дип көлемсерәде Илнур. – Миңа бу хакта берни дә әйтмәделәр.

– Шулай кирәк.

Тавыш коры, анда бернинди хис-тойгы заты юк иде. Әйтерсең, кеше түгел, ә ниндидер робот сөйләшә.

– Мин бирмим, – диде Илнур, шундый ук робот тавышы чыгарырга тырышып. – Бирмәскә куштылар.

– Без алабыз, – диде дә егет әле булса караваt почмагында торган рюкзакны эләктерде.

– Урынына куй! – Илнур егет өстенә килә башлады. – Яки ипи шүрлегеңә менеп төшәм.

Егет аңа бераз карап торды. Күзләрендә нур юк, алар салкын пыяла шикелле иде. Чынлап та робот бугай болар, дип уйлады Илнур һәм арка

үзәге буйлап салкын йөгергәндәй тоелды. Тере кеше шул дәрәҗәдә салкын, шул хәтле битараф була алмый бит инде...

– Монда сугышырга ярамый, – дип, кырт кисте егет. – Әйдә, коридорга чыгабыз.

Коридорга чыгу белән Илнур әле генә бик тырышып өйрәнгән сугу алымын кулланды. Янында торган егет чайкала-чайкала артка чигенде дә таш идәнгә барып төште. Ул арада уң яктагы егет һөҗүм итте, Илнур янтаеп калды һәм уч чите белән аның муен тамырына бәрергә тырышты. Килеп чыкмады, теге уң беләге белән капланды. Ул арада сул яктагы егет бераз иелә төшеп, терсәк очы белән аның тын юлына тондырды. Илнур эч мускулларын катырып өлгерде, тик авырту барыбер сизелерлек иде. Ул бөгелеп төште дә кинәт тураеп, сул ягындагы егеткә апперкот белән бәрде. Төп-төгәл ияк астына эләкте, теге аякларын күтәреп барып төште. Әмма шатлык ләззәтен кичерергә туры килмәде, кинәт Илнурның ике каш арасына нәрсәдер килеп бәрелде. Күз төбендә ут шарлары биешеп алды. Чигәсен нидер көйдереп узды. Дөнья караңгылыкка уралды. «Үлдем бугай...» – дип уйлап өлгерде ул һәм һушын җуйды.

**12**

Илнур йокламый, ә йокы белән уяулык арасындагы ниндидер караңгы почмакта тибрәлә иде. Зәңгәрсу караңгылык эчендә вак кына йолдызлар да күзенә чалынып киткәндәй була. Ишетелер-ишетелмәс булып талгын гына музыка да агыла бугай. Бик ерактан ишетелгән йокыны китергеч аваз һәрбер сүзен миеңә батырырга тырышкандай нәрсәдер сөйли. Илнур кай урында аны бик ачык ишетә, кай урында югалтып тора... Әллә йоклап ала шунда, әллә һушын җуя. Ишеткәннәре белән килешкән кебек була. Ишетелмәгәннәренә үкенми. Аңына килгәч, җентекләбрәк уйланыр, барсын да бер җепкә тезеп карар әле. Ул сүзләрнең барысы да баш миенә җыелып бара бугай. Һәрхәлдә, Илнурга шулай тоела. Бәлки, алай да түгелдер. Бәлки бу бары тик төш кенә, бары тик саташу гынадыр...

– Җирдә кеше күбәйгәннән-күбәя бара. Бу экология өчен хәвеф тудыра. Шуңа күрә алар кешене алыштыра алырлык роботлар, технологияләр уйлап таба... Алар кеше санын азайту өчен тырыша... Гади халык алар өчен бары тик эш коралы... Шуңа аларның халыктан хәбәре юк. Берәү үләме, меңнәр үләме – барыбер. Хәерчелектә яшәүләре алар өчен файда. Надан булулары да...

Илнур башта сүзнең нәрсә турында баруын да абайлый алмады. Ул дулкын өстендә йөзгән шикелле иде, берәр җөмләне ишетеп кала да йокыга чума, аннан тагын калкып чыгып, ниндидер өзекне эләктерә һәм тагын әвен базарына китә. Уянган сыман булгач, бу мәгънәсез авазлардан котылырга теләп, куллары белән колагын капларга омтылды, әмма куллары хәрәкәтсез калды, аның бөтен тәне камыр кебек иде. Беразга тавыш тынган кебек булды. Инде тынычландым дигәндә, кабат ишетелә башлады:

– Алар безне ишетми. Төрле бунтлар оештырсаң да, митингларга чыксаң да, берни кылып булмый. Бу, беренчедән, катлаулы – митингларны законлаштыру өчен алар төрле ясалма авырлыклар тудыра. Икенчедән, митингларда сөйләнгән сүзләр – сүз килеш кенә кала, бер чара да күрелми, бу аларның мыек бөртеген дә селкетми...

Нәрсә соң бу, шайтан алгыры! Кайдан ишетелә? Ни өчен? Нәрсәдер уйларга маташудан Илнур тагын упкынга оча һәм тавыш беркадәр вакытка тынып торган кебек була, тик бераздан тагын калкып чыга:

– Шуңа күрә, алар игътибар итә алырлык гамәлләр кылырга кирәк. Ул чаралар җәмгыятьне тетрәндерерлек, күңелләрне дер селкетерлек булырга тиеш, шунсыз аларның игътибарын җәлеп итеп булмый.

Соңгы сүзләрне берничә тапкыр кабатлыйлар:

– Гипноз астында йоклаган җәмгыятьне уяту өчен аны дер селкетеп алырга кирәк. Бөтен кешеләрнең дә күңеле тетрәнерлек булсын. Бары тик шунда гына җәмгыять уяначак һәм аларга, үзен изүчеләргә, каршы тору хәстәрен күрәчәк. Аларга кискен каршылык күрсәтергә кирәк. Кискен каршылык күрсәтү – ул җәмгыятьне гафләт йокысыннан уяту.

Тавыш тагын беразга тынып тора. Тагын дәвам итә.

– Йоклап яткан кешене яңагына чапкалап уяталар, ул шунда гына сикереп тора да тирә-ягына күз сала, үзенең кайда, ничек килеп эләгүен аңларга тырыша. Йокыга киткән җәмгыять тә шулай. Яңагына шаңлап җибәрмичә аны уятып булмый. Ә уятырга кирәк. Уянсын ул, үзенең ничек шушы хәлгә төшүе турында уйлансын. Һәм аны бары тик без генә уята алабыз. Бары тик син генә... син генә уята аласың... син генә... Синең тормыштагы иң зур вазифаң шушы җәмгыятьне айнытып җибәрү. Син каршылык күрсәтмәсәң, аны беркем дә булдыра алмый.

Тавыш тынып калды. Илнур инде йокыга китте. Йокы татлы иде. Зәңгәрсу караңгылыкта кечкенә йолдызчылар тибрәлә. Бу йолдызчыклар Илнурның йокыда эрегән күзәнәкләре бугай. Йоклаганда һәрвакыт рәхәт. Ул үзенең ап-ак йомшак түшәктә изрәп ятуын үзе дә күргән сыман тоела. Ләззәт инде шулкадәр. Кинәт бүлмә эчендә ниндидер шәүлә узгандай булды һәм Илнурның яңагына тондырдылар. Бөтен дөнья дер селкенеп куйды, ул яткан бүлмәнең тәрәзәләре челпәрәмә килеп ватылды, бүлмәгә давыл керде, йомшак түшәкнең чүпрәкләре ертылды да мамыклар өермәсе хасил булды. Ул татлы йокысыннан чынбарлыкка очып төште. Күзләрен ачуга бүлмә эче яктырып китте. Бернинди давыл да, өермә дә юк иде. Йомшак түшәк тә юк. Ул как тактада йоклап яткан икән. Тавыш та юк. Хәер... Стенадагы колонка шыгырдап-шыгырдап ала, бәлки, теге сәер авазлар шуннан ишетелгәндер...

Авызында тавыклар төн кунган кебек – әллә нинди сасы ис аңкый. Корылык. Теле яңакларына ябышып шыкылдап тора. Ул ишек төбендәге раковинага табан атлады да чайкалып китте, аяклары тотмый, авырта иде. Әле берсен, әле икенчесен күтәреп хәрәкәтләндереп карады. Авыртса да, йөртергә кирәк инде аларны, бераз язылып китсеннәр. Әзрәк хәл кергәндәй булгач, учларын тезләренә куеп, берничә кат авырлык белән генә чүгәләп алды. Шуннан соң иелеп бармак башларын аяк очына тидерергә маташты, берничә тапкыр омтылгач, анысы да килеп чыкты. Һәм ул бабайлар кыяфәтендә раковина янына атлады.

Рюкзагын алып киткәннәр иде. Юыну-кырыну әсбаплары да юк. Стакан да күренми. Ул тирә-ягына тагын бер күз йөгертте дә кран борыныннан су чүмерде. Һәм Аллага шөкер итеп куйды. Су бар иде әле. Су бар! Ә бит аны да ябарга мөмкиннәр. Һәм ул комсызланып, су эчәргә кереште. Көндез генә әллә нинди тынчу ис бөркелгән кебек тоелса да, төнлә су тәмле иде.

Эчеп туйгач, өстендәге киемнәрен салып, караватбашына куйды да трусикчан гына калып, башыннан башлап юынырга тотынды. Рәхәт иде. Йокысы ачылып, дөнья яктырып киткәндәй тоелды. Бу хакта уйлауга бая гына колагына ишетелгән сүз исенә төште: «Синең тормыштагы иң зур вазифаң шушы җәмгыятьне уятып җибәрү...» Уяну чынлап та рәхәт инде, бер карасаң... Әнә бит салкын суның никадәр шифасы бар! Су аның аркасы буйлап идәнгә агып төште. Төшсен, идәндәге су да тынчу бүлмәгә сафлык бөркеп тора ул. Лычма су булган трусигын салып юды да, сыгып, сөлгегә урап киптереп кабат киде. Гимнастика ясап, юынып алгач, бөтен тәне язылып, авыртулары басылган шикелле булды. Менә хәзер кайнар чәй эчәсе иде. Ярый, анысы башка вакытта. Ни әйтсәң дә, әбиеңдә кунакта түгелсең бит, күнекмәләр үзәгендә, кырыс шартларга түзәргә, чын ир-егет булырга өйрәнәсең.

Тагын кранга үрелеп, су чүмерергә тотынды. Шунда сул беләгендә күгәребрәк торган урынга күзе төште. Сугышкан чакта бәрелгәнме, тамыр тирәсендәге бер урыны күгәребрәк тора иде. Кан алдырганда, яки укол кадатканда шулайрак булып кала... Бәлки... Әйе, бәлки аңа да укол кадаганнардыр? Яки канын алганнардыр?

Ләкин бу хакта озаклап уйланып тормады. Рюкзагында аның чәй кайнаткыч һәм кофе бар иде. Менә хәзер алар ярап куясы булган. Тик Илнур рюкзагын саклый алмады. Күңелен үкенүгә тартым хис телеп узды. Тегеләр бүлмә ишегеннән берәм-берәм керделәр бит инде. Сүз әйткәннәрен көтеп тормыйча, һөҗүмгә ташланып, берәм-берәм каршыларга иде аларны. Гадел сугыш дип тә торасы юк, кул астында нәрсә бар, шуның белән тондырасы иде. Башы эшләп җитмәде шул. Әллә яңа гына күнегүләр эшләп, үзен җиңелмәс итеп тоюдан, үз мөмкинлекләрен югарырак бәяләдеме? Бәлки, анысы да бардыр. Алай итәргә ярамый икән шул. Беркайчан да. Син алдыңда торучының кем икәнен төгәл белмисең, шуңа күрә аңа каршы сугышырга уйлагансың икән, тәвәккәл булырга һәм мөмкинлекләреңнең барысын да кулланырга тиешсең. Гаделлек, намус, егетлек турында онытырга. Үлгән яки җиңелгән кешеләргә бу сыйфатларның берсе дә кирәкми. Ә бу егетләрнең берсе дә гади түгел иде, биләмә буйлап ирекле хәрәкәт итәрлек булгач, аларның тәҗрибәсе зур инде.

Тән сызлаулары басыла төште, сусыны канды. Хәзер әллә ниләр майтарып булмый инде, тынычлап кына йоклап алырга, ял итәргә кирәк. Иртәгә нинди көн туачагын беркем дә белми, бәлки, ул бүгенгедән дә авыррак булыр...

## 13

Кемдер Илнурның иңенә кагылды:

– Әй, туган!.. – тавышы ягымлы да, таләпчән дә иде. – Торырга вакыт.

Илнур күзләрен ачты. Аны уятучы кичә спорт мәйданчыгында өрәк булып тоелган егет иде. Илнур күзләрен уалап алды. Торып утырды. Аннан соң аякларына басып, чайкала-чайкала, раковина янына атлады. Тик Өрәк-егет каршы төште:

– Хәзер үк чыгарга кирәк. Киен.

Илнур иснәнеп алды да аңа сәерсенеп карады:

– Юыныйм инде, йокы да ачылмаган бит.

– Хәзер үк чыгарга кирәк, – дип кабатлады Өрәк-егет. – Кергәч юынырсың.

Таләпчән тавышка каршы килүдән файда булмаячак иде. Бу сүзләрне әлеге егет әйтми, ул бары тик бөтен кешегә дә билгеле булган кире каккысыз әмерне Илнурга җиткерәдер генә кебек тоелды. Илнур киенде дә ишеккә атлады. Шулай да сорамыйча кала алмады:

– Кая барабыз соң?

Өрәк-егетнең җавап бирүенә өмете юк иде. Бары тик аңгыра сарык кебек бер сүзсез иярмәс өчен генә сорады. Тик егет җавап бирде:

– Рух ныгыту дәресенә.

Илнур көлеп җибәрде:

– Кая, кая?

– Рух ныгыту дәресенә, – дип кабатлады Өрәк-егет. – Безнең һәр иртә шулай башлана. Озак булмый ул.

Җир өстенә чыкканда, төн таралып бетмәгән иде әле. Спорт мәйданчыгында унлап егет тезелеп баскан, барысы да бертөрле киемнән. Барысының да йөзен сакал-мыек томалап алган. Шулар арасына килеп кушылдылар да көтә башладылар. Бераздан кайдандыр сакал-мыегын пөхтә итеп кистергән кеше пәйда булды. Аның башында патшалар таҗына охшаган нәрсә, өстендә ерактан бик затлы булып күренгән чапан иде.

– Остаз! – дип пышылдады әле һаман Илнур янында торган Өрәк-егет. – Ул безнең рухи терәгебез.

Чынлап та аны күрүгә бөтен кеше дә тураеп басып тынып калды.

– Хәерле яңа көн белән, туганнар! – дип сәламләде Остаз. – Яңа кояшның якты нурлары белән! Кояш бер булса да, аның нурлары бихисап. Сез дә шул кояш нурлары кебек барыгыз да бертуган. Барыгыз да уртак максат өчен яшисез, хезмәт итәсез. Сез бертуганнар!

Моңарчы тын да алмыйча торган егетләр беравыздан җавап бирде:

– Без барыбыз да бертуганнар. Без бертуганнар. Бертуганнар.

Озак кына вакыт шулай кабатлагач, бер рәттә торучылар кулларын ян-якка күтәреп, бер-берсенең иңенә куйдылар һәм акрын гына кайдандыр сыгылып чыккан талгын музыка астында әле уңга, әле сулга чайкала башладылар.

Тавышлар тынса да, Илнурның колагында баягы сүзләр яңгырап торды. Бертуганнар. Күңелендә туганлык тойгысы булмаса да, егетләрнең шулкадәр ярашып чайкалуы, бер үк төрле киемнән булуы беркадәр ышандыра да иде. Ә уйлап карасаң, чынлап та шулай бугай ул. Менә кичә аны коллекторлар кулыннан кемнәр коткарды? Шушы егетләрнең берничәсе бит инде. Ә Джон? Ул әлегә арада юк, ләкин туганыңнан күрмәгән игелекләр кылды. Без – бертуганнар. Әлегә якыннан аралашмасалар ни... Тора-бара аралашырлар әле. Туганлашырлар да. Бер-берсен дә, ярдәмгә мохтаҗ кешеләрне дә коткарырлар... Ә музыка шундый җылы, шундый ягымлы һәм дәртләндергеч иде. Илнурның күңеле үзе дә аңлап җитәлмәгән тойгылар белән тулды, аның менә хәзер үк кемнәргәдер ярдәм итәсе, кемнәрнедер коткарасы килде.

Бераздан музыка арткарак чигенде һәм Остазның тавышы ишетелде:

– Без – бертуганнар һәм без бер йодрык булып кешелекне коткарырга бурычлыбыз. Безнең иң төп бурычыбыз – кешелекне коткару һәм җәмгыятьне уяту!

Кинәт барысының да йодрыклары бер булып, һаваны телде:

– Кешелекне коткару! Җәмгыятьне уяту! – дип, беравыздан кабатлады егетләр. – Кешелекне коткару! Җәмгыятьне уяту!

Илнур да аларга кушылды. Кабатлаган саен тавышы көррәк чыкты, һавага атылган йодрыгы гайрәтлерәк була барды. Әйтерсең, ул җәмгыятьне уятырга теләп, күкләр капкасын кага иде. Ныграк, көчлерәк, гайрәтлерәк... Шулай итеп каксаң, җәмгыять тизрәк уяначак. Ә аның уянуы кирәк. Җәмгыять уянырга, үзенең авыр хәлдә икәнен аңларга һәм тиешле чаралар күрергә тиеш.

– Йоклаган җәмгыятьне уяту өчен аны дер селкетеп алырга кирәк, – дип дәвам итте Остаз. – Бөтен кешеләрнең дә күңеле тетрәнерлек булсын. Бары тик шунда гына җәмгыять уяначак һәм үзен изүчеләргә каршы тору юлын караячак. Аларга кискен каршылык күрсәтергә кирәк.

– Кискен каршылык күрсәтү! Күңелләрне тетрәтү! – дип кабатлады төркем. – Кискен каршылык күрсәтү! Күңелләрне тетрәтү!

Остазның сүзе үз уйлары белән тәңгәл килүенә сөенеп, Илнур да кабатлады. Бертуган дип әйтүләре хак инде шулай булгач. Әлегә якыннан аралашмасалар да, алар уй-фикерләре, омтылышлары белән бертуган. Аларның дәһшәтле тавышы арасыннан атыш, шартлау тавышларын, кемнәрнеңдер кычкыруын, акырып елавын үзәккә алган музыка бәреп чыкты һәм тыелгысыз бер ярсу белән күңелләрне җилкендерде. Мондый халәттә теләсә кайсы сугышка, теләсә-нинди ут астына барып керергә һәм сөенә-сөенә гомереңне корбан итәргә мөмкин иде. Әллә нинди бәхетле ярсу иде бу, чиксез ләззәтле бер халәт иде.

Бераздан музыка акрыная барып тынып калды да аны баягы талгын көй алыштырды. Остаз Илнур аңламый торган телдә нииндидер дога укыды һәм кулларын күккә күтәреп тынып калды, төркем аның хәрәкәтләрен кабатлады. Илнур да аларга иярде. Намаз укуның үзенчәләтелгән бер төре сыманрак тоелды ул, чүгәләп баш иеп тә алдылар, бил дә бөктеләр, учларын күккә каратып, теләнгән кебек тә иттеләр һәм бераздан дүртаяклап басып, маңгайларын җиргә тидереп тынып калдылар. Остазның:

– Башларыгызны күтәрегез! – дигән тавышы ишетелде. – Сезнең вазифагыз – баш күтәрү. Хәерле көннәр сезгә, туганнарым!

Остаз шулай дисә дә, төркем күтәрелергә ашыкмады, егетләр пышылдап кына, нииндидер дога сыман нәрсәне кабатлыйлар иде. Илнур әлегә аның ни икәнен белми, шулай да өзек-өзек сүзләрен генә ишетә һәм эчтән генә пышылдый:

– Аны бары тик без генә уята алабыз. Бары тик син генә... Бары тик мин генә...

Бераздан барысы да бер булып күтәрелеп бастылар. Остаз юк иде инде, ничек кинәт пәйда булса, шулай юкка чыккан иде. Егетләр дә тиз арада кайсы кая таралышып бетте. Илнур аларның ничек шулай юкка чыгуын да аңламыйча калды.

Өрәк-егет аның янында иде. Ул үзе артыннан ияреригә кушып, ым какты

да Илнур яшәгән подвал ягына атлады. Ишек янына җитәрәк, Илнурныкы кебек рюкзак күтәргән егет килеп чыкты.

– Минем рюкзак! – дип пышылдады Илнур. – Минеке...

Шундук күз алдында чәй кайнаткыч, кофе пәйда булды. Хәтта авызында да кайнар кофе тәме чагылып киткәндәй тоелды.

– Ал! – дип боерды Өрәк-егет. – Бирмәсә, талап ал!

– Без бит – туганнар, – дип икеләнде Илнур. – Туганнар...

– Бу туганлыкны бозуга керми, – дип кистерде егет. – Кирәк булса, ул синең өчен гомерен бирәчәк. Син дә. Ә әлегә көч сынашу мөһим.

Илнурның йөрәге дертләп куйды. Мондый мөмкинлекне кулдан ычкындырырга ярамый иде. Ул тукталып калды һәм теге егет үз янына килеп җитүгә уч кырые белән аның бугазына сукты да рюкзакка ябышты. Тик теге рюкзагын ычкындырса да, бугазын каплап өлгерде һәм һөҗүмгә күчте. Илнурның кулыннан рюкзак төшеп китте, егет үз-үзен сакларга мәҗбүр булды.

Озак кына сугыштылар. Егет юка гына кебек күренсә дә, төшеп калганнардан түгел иде, көче дә, җитезлеге дә бар, тәҗрибәсе дә җитәрлек. Илнурга берничә тапкыр бик ярыйсы гына эләкте, әмма ул үзенең бөтен осталыгын җыярга тырышты һәм ахыр чиктә көндәшен һуштан яздырды. Аяк астында аунап яткан егет өстеннән атлап чыгып, рюкзагын тиз генә эләктермәкче иде, кинәт аның авырлыгын тоеп катып калды. Бу рюкзак бик авыр, өстәвенә аныкы түгел иде.

– Котлыйм! – диде Өрәк-егет кире каккысыз таләпчәнлек белән. – Хәзер рюкзагыңны ки дә минем арттан ияр. Ун метрдан арттарак калсаң, бүген үк өеңә кайтып китәсең.

Һәм кичәге маршрут буенча йөгереп китте...

Кире әйләнеп килгәндә, Илнурның аяклары мамыкка әйләнгән кебек иде. Ул көч-хәл белән килеп җитте дә рюкзагын җиргә ыргытып, чирәмгә ауды. Хәтта мәйданчык буенда аларны көтеп торучы өч егетне дә күрмәде. Беркадәр ятуга Өрәк-егет аны тартып торгызды.


– Хәзер сине кызыклы уен көтә, тор, – дип, егетләр ягына ымлады ул. – «Каршылыклар кыры» дип атала.

Илнур эшнең нидәлеген сизде. Тагын сугышырга туры киләчәк.

– Егетләрнең һәркайсы белән өч минут сугышырга һәм һәр раундта кичә өйрәнгән алымыңны ким дигәндә бер тапкыр уңышлы кулланырга тиешсең.

Өч минут ул табын артында гына тиз үтә. Ә сугышканда... Анда һәр секунд сузыла. Бер карасаң, сугышны өч минутка сузуның да, теге алымны куллануның да әллә нәрсәсе юк кебек инде. Ләкин монда эш бераз катлаулырак: әлеге егетләрнең барысы да аның нинди алым кулланырга тиешлеген белә һәм аңа каршы килү ысулларын яхшы үзләштергән иде. Адәм күтәргесез рюкзак асып, фәлән километр йөгереп килгәннән соң бу бик җиңел булмаячак. Тик нишлисең... Сайлап алу мөмкинлеге юк...

*(Ахыры киләсе санда.)*



Рәшит
Бәшәр

# УЧЛАРЫМДА ГӨЛЛӘР ҮСТЕРДЕМ МИН...

## Иртәгә дә

Бисмилла әйтеп, татар Кояшны каршы алыр.
Гомер арбасын этеп, җай гына алга барыр.
Төште инде атыннан, кайдадыр кешни аты.
Кай йолдызны нурлыйдыр тояктан очкан якты.
Юлы – чокыр-чакырдыр, барыр да татар барыр.
Кара урманда күке гомерен санап калыр.
Барыр-барыр да арыр, туктап учак кабызыр.
Кайгы-хәсрәтләрен ул дәрьяларга агызыр.
Агыздың, агызмадың, таңгы җилгә бәйләнеп,
Кояш чыгышы белән бар да кайтыр әйләнеп.
Һәрбер кысыр басуга иген чәчеп калдырыр.
Дөм караңгы җирдә дә өмет шәмен яндырыр.
Өр-яңа нигезләргә көмеш тәңкәләр салыр.
Ул үтеп киткән юлда
Йә берәр яңа кала, йә яңа сала калыр.

## Ә елга агып ята

Үткәннәремә карыйм еллар пәрдәсен ачып:
Малайчагым комлыкта тора балтырын кашып.
Терсәге сыдырылган, күлмәкчән, юеш ыштан.
Җәлпәк борын очына кызыл балчык ябышкан.
Кармагы ята комда терәлеп аягына.
Тал чыбыгы селкенә бәртәснең саңагында.
Бәртәсне чандыр малай комнан иелеп алды.
Кузгалды... Ярдан менде. Ә елга агып калды...
Кукуруз басуыннан авылга туры юлы.
Үләннәргә ышкыла ак бәртәс койрыгы.

---

Рәшит БӘШӘР (1949) – *шагыйрь һәм прозаик; А.Алиш исемендәге әдәби премия лауреаты. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. «Сандугачлы бишек», «Ачык капка», «Былбыл оясы» һ.б. китаплар авторы. Чаллыда яши.*

Шаяртты мине малай, сизмәдем качасын да.
Кул изәде – югалды зур алма бакчасында.
Еллар пәрдәсен ябам, ә елга агып ята...
Үткәннәрдән бүгенгә әйләнеп, кире кайтам.
Яшьлектә бер алманы өзмичә калган идем.
Шул алманы бер кызга сузмыйча калган идем.
Ул тыйнак кызчык иде, мин тыйнак малай идем.
Ул хәзер әби инде, үзем дә бабай инде.
Кулымдагы алмамны чөйсәм кошлар юлына,
Килеп төшәр микән ул ак әбинең кулына?
Ә елга агып ята...
Йөрәгемә дулкыны өзлексез кагып ята.

## Базар

Чегән кызы сыйпый учымны,
Алданырга әзер без аңа.
Шау-гөр килә Мәскәү базары,
Һәр сәүдәгәр – Алдар таз анда.

Күзләп йөрим кала базарын,
Кемдер тавык, кемдер каз ала.
Эзләп йөрим татар сөйләшен
Урыс телле яңа Казанда.

Ишетелеп китеп кайчакта
Колагымны назлый моңлы сүз.
Азан моңы күккә таралгач,
Шунда онытылып йомдым күз...

## Мәңгелек кошлар

Саубуллашып, чыгып китә дуслар
Төбенәчә ачык ишектән.
Төн пәрдәсен йомшак тибрәндереп
Сулыш алуларын ишетәм.

Ераклаша аяк тавышлары,
Китеп югалалар... Юллар тын.
Китеп югалалар... Бик күпләре
Кошлар булып оча югартын.

Күк гөмбәзен ярып оча алар,
Учка куна ап-ак каурыйлар.
Ак нур булып күзгә тула алар,
Җилләр булып чәчем тарыйлар.

Изрәп ятам, җил сулышын тоеп,
Кояш туып килгән бер мәлдә.
Күкрәгемдә бер кош бәргәләнә,
Канат җилпер җире тар мәллә?

* * *

Яктылыкка, бары яктылыкка
Мин омтылган идем тумыштан,
Фәкыйрьләнеп, йончып, хәлсезләнеп,
Чыгып киләм инде тормыштан.

Күлмәгемнең сүтек җөйләрен
Тегәр җебем калды бер саплам.
Мин кояшка, бәлки, орынырмын
Соңгы үргә менеп җиталсам.

## Ул

*Улә, диләр, кеше бер мәртәбә,*
*Ничә тапкыр туа –*
*Кем белгән?*
Кадыйр Сибгатуллин

Ничә тапкыр җирдә яшәгәндер,
Ничә үлеп, ничә терелде.
Челләләрдә сусап тилмерде дә,
Ай нурына иренен тидерде.

Күзләрендә төсләр алышынды,
Гашыйк булып ничә тилерде.
Кояш чыккан ал тарафка таба
Үз дәүләтен эзләп йөгерде.

Ничә туып, ничә яшәгәндер,
Шашып көлде, үксеп елады.
Үксез илнең үксез туфрагына
Чәчелешеп калды еллары.

Икейөзле җаннар көлә-көлә
Алдадылар. Мең кат алданды.
Шиңде диеп уйладылар, ә ул –
Кояш нурларына ялганды.

...Гөлле бакчадагы исәр шагыйрь,
Ихлас бәндә ул мин... Мин идем.
Өмет белән ил йөзенә баккан
Якты бер җыр, шашкын моң идем.

* * *

Җылылык эзлим мин кешеләр күзеннән...
Хәсрәткә, нужага, кайгыга
Түзелгән, теш кысып түзелгән.
Сөенеч-шатлыгы, дерелдәп,
Керфектән яшь булып өзелгән.

Яктылык эзлим мин галәмнәр катыннан...
Кемнеңдер йолдызы кабынган,
Яктырган, нурланган, балкыган.
Күгеннән өзелгән, атылган
Топ-тонык йолдызлар артыннан.

Дисбегә ак көннәр тезелгән,
Аралаш карасы тезелгән.
Тезелгән... тезелгән... тезелгән.
Аннары өзелгән... өзелгән.
...Җил генә йөгерә киткәннәр эзеннән.

* * *

Ялган режиссёр. Ялган рольләр.
Ялган бер спектакль – яшәү дә.
Гаип була ялган «даһи»лар
Тормыш сәхнәсеннән төшүгә.

Дөньялыкта бик шәп уйныйлар:
Бәндә оста мәкер, хәйләгә.
Шыгыр-шыгыр сәхнә әйләнә...
Спектакль тәмам. Һәммә ялган
Галәм тузанына әйләнә.

* * *

Менәсе үрләрем күтә... Ә гомер чиксез түгел.
И күңел! Кара төннәрдә якты көн булып түгел!
Түгелде нур. Сыйпап үтте былбыллы ояларны.
Тирә-як тын. «Әллә кошлар сайрарга оялалармы?» –
Дигән идем. Кинәт кенә моңга күмелде бу як.
Һәммә нәрсә җырлый монда һәм дирижёр – һәр куак.
Йа Ходаем! Ни тылсым бу? Яшәреп китте күңел.
И күңел! Көмеш нурларга яшел гөл булып үрел!

## Киләчәктә

Көн яктысы күзләргә мөлдерәмә тулачак.
Кошлар җылы ояда сайрашып уяначак.
Ышаныгыз, мин әйтәм: «Бар да әйбәт булачак!»
Хөр фикерле, иманлы, азат буын туачак.
Кояшлы тәрәзләргә кошлар моңы куначак.
Ышаныгыз, мин әйтәм: «Бар да әйбәт булачак!»

Сөендереп адәмне иректә гүзәл илдә
Татарстан әләме җилфердәп торыр җилдә.
Сәламләп якты көнне барчагыз куаначак.
Ышаныгыз, мин әйтәм: «Мәңге шулай булачак!»

## Мирас

Җәяүле бер адәм баласы мин,
Кара таплар җанда, ак таплар.
Алтын-көмеш калмый нәселемә,
Кала миннән уйлы китаплар.

Учларымда гөлләр үстердем мин,
Шагыйрь булып җирдә яшәдем.
Ак кош булып очты шатлыкларым,
Йөрәгемә тамды яшьләрем.

Мин калдырып китәм нәселемә
Алтыннардан кыйммәт китаплар.
Якты көннәр укыр ул китапны,
Һәрбер сүзен төннәр кабатлар.

## Йөрәк

Бу җирдәге бөтен аһ-зарлар йөрәгемә килеп бәрелә.
Бәрелә дә тетри йөрәгем, күтәрелә басым тәнемдә.
Бетә кинәт көннең яме дә, Кояш сүнә... Күкләр караңгы.
Аландагы энҗе чәчәккә кунды микән энә карагы?
Тетрәү үтә... Тыныч йөрәгем, Кояш нуры керә күземә.
«Дөнья исән!» – диеп сөенәм, яшәү көче сизәм үземдә.
Сискәндереп селкенде дә гөл: «Җир тетриме?» дигән шик килде.
Керпе икән... Үлән кыштырдый...
Һәммәсен дә йомшак тирбәтеп, Җир йөрәге тибә шикелле.

## Әйләнеш

Кырау сукты – җәйләр шиңделәр,
Тамчы тамды – кышлар үлделәр.
Гөнаһлардан җирне чистартып,
Илгә яшел язлар килделәр.
Ихатага җәйләр керделәр,
Әмма җәйләр кыска иделәр.
Гөнаһларга баткан адәмнәр,
Пычрак ерып, көздә йөрделәр.

## Кайтаваз

Тын өйләрне уятып,
Гармун уйнады таңнар.
Бизәкле кәрнизләргә
Эленеп калды моңнар.

Таралыша кичләтеп
Уенга килгәннәр дә.
Яшьлекнең аяк эзләре
Суына үләннәрдә.

Түр тәрәзәсе ачык.
Тешсез авызын ачып,
Яшьлеге кайтавазын
Тыңлый бер ялгыз карчык.

*«Мәйдан – батырлар өчен!» әдәби конкурсы*



Амур
Хан

# ПОТАП

хикәя

*Атаклы көрәшче Рафаил Ясәви улы*
*Мөхәммәтшинның якты истәлегенә*

Тавыш көчәйткечтән: «Көрәштә катнашырга теләүчеләр хөкемдарлар янына җыелыгыз!» – дип оран салуга, ир-атлар бер-бер артлы мәйдан читендәге өстәл тарафына ашыкты. Әле мәктәпне дә тәмамламаган яшь-җилкенчәк, имтиханнарын тапшырып җәйге ялга кайткан студентлар, инде ир уртасы булганнар, җиңәме-юкмы, бер генә Сабан туенда да катнашмый калмаучы, чәчләре генә түгел, сакалларына кадәр чал сарган олы яшьтәге бабайлар – барысы да шунда. Ә иң арттан баручы, гәүдә авырлыгыннандыр инде, бераз сөйрәлебрәк атлаган кебек тоелган ир затын күргәч, халык, үзе дә сизмәстән, дәррәү кул чабарга кереште.

Дөрес, монда да һәр нәрсәгә канәгатьсезлек белдерүчеләр юк түгел иде. Мәйдан тирәли утыручылар тарафыннан:

«Һаман шул Потап булыр инде. Тагын баш батыр булып калачак икән. Җитмәсә җитмәс икән кешегә...» дигән сүзләр дә ишетелеп китте.

– Матур көрәшә бит, чукынмыш! – дип куйды берсе.

– Шулаен шулай да, тик башкаларның да бүләк аласы килә бит...

Бил алышырга теләк белдерүчеләрнең барысыннан да диярлек зуррак гәүдәле, кыяфәткә шактый яшь күренүче, якты кояш нурларында ялтырап торучы кыска кара чәчле Рафаил турында әйтүләре.

Авыл кешеләре кушаматсыз яшәми инде ул. Гәүдәгә хәйран зур булгангамы, бераз сәеррәк, алпан-тилпән атлап йөргәнгәме – Рафаилгә авылдашлары, иске рус мультфильмнарында еш очрый торган Михайло Потапыч исемле аю белән чагыштырып, «Потап» дигән кушамат такты. Еш кына хәтта үзенә дә шулай гына дәшәләр.

...Элек-электән Сабан туйларында авыл халкы телендә, беренче чиратта, көрәш булды. Рафаилнең көрәшче булып китүенә дә шул йогынты ясамый калмагандыр. Кызыгырлык та шул, бөтен авыл кешеләре каршында көндәшләреңне бер-бер артлы отасың, син көчле! Бар халык сиңа карап

соклана, җан ата, алкышлый. Горурланмаслыкмы әллә?! Ә инде баш батыр дәрәҗәсен ала калсаң, бөтенләй күтәреп йөртәләр, әле генә сине сырт салырга маташкан көндәшләрең җыелышып, куккә чөя! Моңарчы татар көрәшен тамаша буларак кына күзәтеп утырырга күнеккән, аның нечкәлекләрен, тәртибен бөтенләй дә аңламаган малайда көннәрдән бер көнне милли спорт төренә кызыксыну уянуы, бәлки, шуның белән дә бәйледер.

Аның беренче тапкыр кулына сөлге тотып, көрәш мәйданына чыгуын авыл халкы әле дә хәтерли...

Рафаил хәрби хезмәттән иртәгә Сабан туе буласы дигән көнне, бәйрәмдә үткәрелә торган төрле уен-бәйгеләрдә катнашучыларга өләшү өчен авыл халкыннан бүләк җыю көнендә кайтты. Бу чара – үзенә бер төрле бәйрәм. Яшь-җилкенчәк гармун тартып, җырлый-җырлый, бии-бии, өйдән-өйгә йөреп, бүләк җыя. Күпчелек кешеләрнең сөлге-тастымал, шәл-яулык кебек чүпрәк-чапрак бирүен исәпкә алып булса кирәк, бу чараны «Яулык җыю» дип йөртәләр.

Рафаил сабакташлары белән икенче көнне Сабантуй буласы урында очрашырга сүз куешты.

...Бер сыйныфта укыган яшьтәшләренең яртысы диярлек бәйрәмгә кайта алмаган – кемдер график белән эшли, кемнеңдер имтихан тапшырасы бар, кайсыныңдыр башка мәшәкате чыккан. Шулай да уннан артык кеше җыелды. Хәл-әхвәлләр сораштылар, мәктәпне тәмамлап таралышканнан соң кемнең кая барып төпләнүе, кайда эшләве хакында гәпләшеп алдылар...

– Карале, Рафаил, әйдә көрәштә катнаш әле бүген, – дип куйды кинәт бәйрәм башланмас борын кәефләнеп өлгергән сыйныфташы Равил.

Рафаил көтелмәгән тәкъдимнән аптырап китте:

– «Сүз югында сүз булсын – ата казың күкәй саламы?» дигән шикелле килеп чыкты бу синең, ахир, – диде ул, елмаеп. – Ни сөйлисең? Нинди көрәш?

– Ә нәрсә? Гәүдәң бар, армиядә көч туплап, чыныгып кайттың. Мәктәп елларында ук Хәлим абыйдан дәресләр алып йөрдең бугай...

Дөрес анысы, мәктәпне тәмамлар алдыннан гына булса да, Рафаил физкультура укытучысы булып эшләүче Хәлим абыйдан милли көрәш нечкәлекләренә өйрәнә башлаган иде. Аның бер сүзе әле дә исендә: «Көрәшчеләр келәмдә вакытта бер-берсенең сулышын, йөрәк тибешен тоя», – дип әйтә торган иде Хәлим абый. Инде шактый алымнар, көрәш хәйләләрен үзләштергән кебек тоелса да, Рафаил ни өчендер кулына сөлге тотып, Сабан туе мәйданына, авылдашлары каршына чыгарга батырчылык итмәде. «Келәмгә чыгучы өчен иң әһәмиятлесе – үз-үзеңә ышаныч. Миндә бармы ул? Әгәр ышаныч юк икән, мәйданга чыгып та торма: күпме генә шөгыльләнсәң дә, матур көрәш алымнарын күрсәтә алмыйсың, җиңүгә теләгең дә югала», дигән караштa иде егет.

Шуңа күрә Рафаил уены-чыны белән әйтелгән бу сүзләргә күнәргә ашыкмады.

– Шул гына җитмәгән иде! Шаярасыңдыр дип кабул итәм. Әйдә, осталар көрәшен күзәтеп, иркенләп сөйләшеп кенә утырыйк әле, – дигән булды.

Ләкин Равилнең тәкъдимен башка сыйныфташлары да күтәреп алды, берсен-берсе бүлдерә-бүлдерә дигәндәй, әле кичә генә армия сафларыннан кайткан егетне үгетләргә тотындылар.

Рафаилнең тәне чемердәп китте. «Әллә соң...» Ул мәйдан читендә

көрәшкә керергә теләүчеләрне теркәп утыручы хөкемдарлар янында мәш килгән укытучысы Хәлим абый янына китте.

Кочаклашып күрештеләр, хәлләр сораштылар. Рафаил сабакташлары ясаган тәкъдим турында әйтте.

– Нишләргә икән, Хәлим абый? – диде ул остазының күзләренә туры карап. – Ничек уйлыйсың, мин әзерме?

– Нәрсә дип әйтим икән, энекәш? Үз-үзеңдә ышаныч сизәсең икән – тәвәккәлләргә була. Иң мөһиме көрәштә көндәшеңне җиңү түгел, ә үз-үзеңне җиңү! Әлбәттә, төрле сүзләр ишетергә мөмкинсең. Син моны булдыра алмаячаксың, көчең, түземлегең җитмәячәк, бу синең өчен түгел, дип әйтүчеләр дә, сине хуплаучылар, мактаучылар да табылыр. Максат куясың икән, аңа ирешергә кирәк. Һәм бетте! Беренче адымны ясыйсыңмы, әллә урыныңда басып каласыңмы – монысы үзеңнән генә тора, – диде Хәлим абый, көрәктәй киң учларын Рафаилнең җилкәсенә куеп.

Егет кабат сабакташлары янына килде.

– Ярар! Чыгам! Тик көләсе түгел! Беләсез, минем Сабан туенда гомергә көрәшкәнем юк, – диде ул һәм, кырт борылып, янә мәйданга, көрәшкә язылу өстәле тарафына юнәлде...

Сабан туе батыры исемен алырга теләүчеләр хәйран күп булып чыкты. Кемнең кем белән бил алышачагын билгеләү өчен башта әзерләп куелган аркан гына җитмәде. Шобага гадел булсын өчен гадәттә авыл халкы яратып тамаша кыла торган «Сәлим-Сәлимә» уенына дип тәгаенләнгән гаять озын баудан файдаланмыйча булмады.

«Сәлим-Сәлимә» дигәннән... Бу урында әлеге уенның тәртибе белән дә таныштырып үтү мәслихәт булыр. Мәйдан уртасына ике потлы гер куялар. Озын арканны гернең тоткасы аша чыгарып, бер башына ир-атның, икенче башка хатын-кызның биленнән бәйлиләр. Күзләрен яулык белән каплаган килеш, ир белән хатын, әледән-әле «Сәлим! Сәлимә!» дип кычкыра-кычкыра, бер-берсен куып тотарга тиеш. Мәйданның шактый киң булуын, уенчыларның берни күрмәвен һәм бер карашка тип-тигез күренгән мәйданның кайбер урыннарында чокыр-чакырлар булуын исәпкә алганда, гаять мавыктыргыч тамаша килеп чыга...

Шобага нәтиҗәләре буенча Рафаилнең Салих исемле, үзеннән ике яшькә өлкән, спорт ягыннан әллә ни алга китмәсә дә, Сабан туенда берничә тапкыр бил сынап карарга өлгергән авылдашы белән алышачагы билгеле булды.

Рафаилгә бәхет елмайды. Юк, хикмәт көндәшенең профессиональ дәрәҗәгә ирешкән чын көрәшчеләр исәбеннән булмавында гына түгел. Армиядә хезмәт иткәндә физик яктан шактый көч туплаган булса да, Рафаилнең моңарчы татар көрәшендә катнашканы юк, нечкәлекләрен белеп бетерми, Хәлим абый өйрәткәннәр дә онытылып беткән. Салих белән алышка чыкканчы, көрәшне мәктәптә үк тәртибенә китереп өйрәнүче үсмерләр, бик күп ярышларда, узган Сабан туйларында шактый уңышларга ирешкән ир-атлар көрәшен дикъкать белән күзәтеп, алардан төрле алымнар өйрәнү мөмкинлеге бар...

Мәйдан уртасына чыкканда, Рафаилнең башында әлеге дә баягы «кеше көлкесенә калмасам ярый инде» дигән уй бөтерелде. Каш астыннан гына әйләнә-тирәне күзләп алды. Ул да булмады, мәйдан көлү тавышларына күмелде. Бу мизгелдә аңа авыл халкы аннан көләдер кебек тоелып китте.

Бактың исә, мәйданның бер почмагында мәңге айнымас Хәмит гер күтәрергә азаплана икән.

Спорт белән ныклап шөгыльләнмәсә дә, Салих «төптән юан», шактый нык гәүдәле күренә. Алай дисәң, кем белә бит, ә бәлки башкаларга сиздерми генә берәр секциягә дә йөри торгандыр. Буйга да Рафаилдән калышмый...

«Ярар, анысы аның эше. Иң мөһиме – сер бирмәскә, оятка калмаска!»

Көндәшләр, сөлгеләрен бер кулга тиешенчә төенләп, кара-каршы бастылар, кул бирешеп күрештеләр дә бер-берсенең билләрен кочып алдылар. Хөкемдарның сыбызгы сызгыртуы булды – Салих Рафаилне чалып та екты. Бу күренештән канәгатьсез калган җанатар тамашачылар дәррәү кычкырырга, сызгырырга тотынды.

– Хәрәмләшмә, Салих, ник чаласың?!

– Хөкемдар, ни карап торасың, Салихка штраф бир!

– Татар көрәшен башка нәрсә белән бутама...

Һәм башкалар, һәм башкалар.

Дөрес, Рафаилнең бу хәлгә һич кенә дә ачуы чыкмады. Ул моны хәтта көткән иде. Тик Салихның җитезлеге бераз аптыраШта калдырды. Көндәшенең алыш башлануга ук чалып егуы бары тик «психологик һөҗүм» генә икәнлеген яхшы аңлады Рафаил. Хөкемдар да Салихка штраф билгеләп тормады. Беренче очракка дип, кисәтү генә ясады.

Бер-берсенең биленнән җайлап эләктерү, күтәреп салу өчен уңайлы мизгелне тотып алырга ниятләп, көндәшләр мәйдан уртасында байтак таптандылар. Ниһаять, андый мизгел килеп тә җитте. Рафаил кинәт кенә алга талпынды да Салихның биленнән нык итеп кысып тотты һәм җирдән күтәреп алды. Мәйдан кинәт сүндерелгән радио кебек бер мәлгә тынып калды.

– Ну! Әйдә, солдат, манчы! – дип кычкырды Рафаилнең бер сабакташы, Сабан туе мәйданын яңгыратып.

Тирә-як көлү тавышларына күмелде. Рафаил Салихны күтәргән килеш берничә мизгел торды да, аның авырлыгыннан үзе дә авар дәрәҗәгә җиткәч, гәүдәсен бора төшеп, көндәшен җиргә ыргытты. Салих уң җилкәсе белән яшел чирәмгә килеп төште. Халык бердәм кул чабарга кереште. Әле тегендә, әле монда хуплау авазлары ишетелеп китте. Ләкин хөкемдарның фикере башкачарак булып чыкты.

– Сыртка сала алмады. Бер балл! – дип игълан итте ул.

Чиста җиңү түгеллеген Рафаил үзе дә яхшы аңлый иде. Шуңа күрә каршы сүз әйтмәде, көрәшне дәвам итәргә әзер икәнлеген белдереп, сөлгене кабат кулына чорнады. Ләкин... Салих җилкәсен каты авырттырган иде, күрәсең. Йөзен сытып, уң җилкәсен уа-уа, мәйданнан чыгып китте. Хөкемдар Рафаилнең кулын күтәрде.

– Алыш тәмам. Техник җиңү яулаган Рафаил икенче турга үтә...

Ләкин, иптәшләре күпме генә кыстаса да, хөкемдар микрофоннан берничә тапкыр исемен әйтеп кычкырса да, Рафаил көрәшкә бүтән кермәде. Чынлыкта үз гаебе бөтенләй булмаса да, аның белән көрәш вакытында кулын имгәткән Салихны кызганды ул, үзен гаепле хис итте...

Рафаилнең көрәштә беренче тапкыр чирканчык алуы шулай тәмамланды...

Сабан туеннан соң берникадәр вакыт үткәч, бил алыш барышында Салих белән килеп чыккан хәл бәгырен шактый вакыт тырнап торса да, күңеленә

көрәш җене кереп оялаган Рафаил күнегүләрен дәвам итәргә булды. Көн саен ук булмаса да, буш вакытларында Хәлим абыйдан дәресләр алды, район үзәгендәге спорт комплексына барып шөгыльләнде, анда үткәрелә торган турнирларда катнашты. Сирәк-мирәк кенә булса да, призлы урыннар өчен алган дипломнар, истәлекле бүләкләр аның көрәшче буларак үз-үзенә ышанычын шактый көчәйтте. Һәм... өч елдан, Әлмәт физкультура техникумында белем алып кайтканнан соң, авыл Сабан туенда күптән хыялланган максатына иреште – баш батыр исеменә лаек булды. Алай гына да түгел, икенче елны үзен район үзәгендә уздырылган бәйрәмдә сынап карарга булды. Төрле авыллардан килгән көрәшчеләр арасында гәүдәгә Рафаилнең үзеннән һич калышмаган әзмәвердәй егетләр байтак иде. Тик, ни генә булмасын, Рафаил аларны, кайсын баллар аермасы буенча, кайсын чиста җиңү белән берсе артыннан берсен ота барды.

Баш батыр исеме өчен көрәш. Рафаил әле ел башында гына Казанда үткәрелгән бәйгедә Татарстан чемпионы исемен алып кайткан Вадим исемле керәшен егете белән бил алышырга тиеш. Көндәшенең спорт белән ныклап шөгыльләнгәнлеге әллә кайдан күренә – гәүдәсе тыгыз, мускуллары уйнап тора. Авырлыгы да Рафаилнекеннән әллә ни ким булырга охшамаган. Ул моны көндәшен биленнән кочып күтәреп карагач та аңлады. «Моны сыртка салуы җиңел булырга охшамаган, – дип уйлап куйды ул. – Зыян юк, бөтен кеше дә җиңәргә теләп көрәшә инде», – дип, үзен үзе тынычландырырга тырышты.

Ләкин Рафаил һич кенә дә оятка калырлык көрәшмәде. Дөрес, күпме генә тырышса да, чиста җиңүгә ирешә алмады, әмма очколар буенча барыбер Вадимнан өстен чыкты.

Бу – Рафаилнең район Сабан туенда беренче тапкыр баш батыр булып калуы иде...

Шулай гадәтләнгән инде, район Сабан туе батырларын Казанга, республика бәйрәменә дә чакыралар. Сүз дә юк, авыл яки район Сабан туе батыры исемен яулау – зур мәртәбә. Ә менә Татарстан күләмендә беренчелекне алу бөтенләй икенче нәрсә. Шуңа күрә анда катнашырга чакыру килгәч, район бәйгесендә беренчелекне алудан канатланган, үзенә ышанычы ныгыган Рафаил икеләнеп тормады, шундук риза булды. Шулай да, бу хакта Хәлим абый белән киңәшеп алырга кирәк тапты.

Ул килеп кергәндә, остазы ишегалдында, лапас ишеге янына куелган тумранда малларга башак бирү өчен балта белән салам турый иде.

– Районның баш батыры булуыңны исәпкә алганда, һичшиксез, катнашырга кирәк. Мондый мөмкинлек теләсә кемгә бирелми. Ләкин аңлыйсың булыр, анда инде син Рафаил түгел, безнең район данын яклаучы вәкил буларак көрәшәчәксең. Җаваплылык бермә-бер артачак, – диде ул, Рафаилнең тел төбен аңлап алгач.

– Шунысы бар шул, – Рафаил кыска итеп киселгән чәчләрен сыйпап куйды. – Шүрләтә бераз...

– Шүрләмә! – дип, кырт кисте Хәлим абый һәм балтасын тумранга кадап куйды да аркасын лапаска терәп чүгәләде. – Мин сиңа ышанам. Сиңа бөтен район ышана. Синең тормыш өчен бары тик син җаваплы. Бүген кем булуыңны кабул ит, кем булырга теләвең өчен җаваплылыкны үз өстеңә

ал. Кичә синең белән нәрсә булган, бүген нәрсәләр кичерәсең – берсе дә мөһим түгел. Үткәннәр сиңа нәрсә бирде – шул хакта гына уйлан һәм нәтиҗә ясап, максатыңа таба атла. «Бу юлы мине берни, беркем туктата алмаячак. Төгәл беләм – мин булдырачакмын!» – дип, үз-үзеңне ышандыр! Тормыш тәгълиматың шул булсын!

– Ә җиңелсәм?

– Җиңелсәң... Уйлама ул турыда. Республика бәйгесендә катнаша алу – үзе үк зур җиңү. Аңлыйсыңдыр, анда барысы да – синең кебек үк кешеләр, синең кебек үк батырлар. «Мин – монда көчле кеше! Үземне сындырырга, кимсетергә һичкемгә ирек бирмәячәкмен!» Үз-үзеңә шулай әйтергә кирәк!..

Рафаил берара сүзсез утырды. Аның уйларын Хәлим абый бүлдерде:

– Тик синең бер зур кимчелегең бар, энем.

Егет мондый сүзне ишетермен дип бөтенләй уена да китермәгән иде, шундук борчуга калып, остазының күзләренә сораулы караш ташлады.

– Сиңа яхшылап «мостик» ясарга өйрәнергә кирәк. Бөтен алышларыңны күзәтеп бардым. Көндәшеңне очко белән оту начар түгел. Оста итеп мостик ясый белсәң, көндәшеңнең кем булуына, нинди авырлыкта булуына карамастан, бөтен гәүдәң аркылы әйләндереп салу бермә-бер җиңел булачак. Әйдә күрсәтәм...

Шулай диде дә Хәлим абый сикереп торып басты.

– Киттек бакчага! – дигән сүзләр белән йөгереп кенә өенә кереп, ике сөлге тотып чыкты һәм бакча капкасына таба атлады.

Рафаил сүзсез генә остазы артыннан иярде. Хәлим абыйның элек бөтенләе белән диярлек бәрәңге утырту өчен файдаланылган галәмәт зур бакчасының яртысы яшел чирәмгә күмелгән.

– Карчык белән икебезгә ярты бакчага утырткан бәрәңге дә күп әле, – дип аңлатты Хәлим абый, Рафаил тарафыннан һичшиксез бирелергә тиеш дип уйлаган сорауга җавап итеп.

– Әйдә, тот әле, энем!

Хәлим абый алып чыккан сөлгеләрнең берсен Рафаилгә тоттырды.

Татар көрәшенең күп кенә серләренә өйрәткән остазының кечкенә гәүдәсенә күз төшереп, Рафаил ихлас елмаеп куйды.

– Хәлим абый, шаярасыңмы әллә, син бит мине күтәрә алмыйсың.

– Күрербез! – диде остаз, хәйләкәр елмаеп һәм Рафаилгә карап күз кысып алды.

Бер-берсенең билләрен сөлге белән урап тоттылар. Җайлы мизгелне көтеп, берникадәр мизгел таптанып торганнан соң Хәлим абый кинәт Рафаилгә таба кискен адым ясады да аның билен нык итеп кысып тоткан килеш артка таба бөгелеп төште. Шулвакыт Рафаил һич көтмәгән хәл килеп чыкты. Туксан тугыз килограмм авырлыктагы егетнең аяклары җирдән аерылды. Ул да булмады, Хәлим абыйдан бик күпкә авыррак Рафаил яшел хәтфә чирәм өстенә гөрселдәп килеп төште.

– Аңладыңмы инде?

– Ничего себе!.. Нәрсә булды бу, Хәлим абый? – Рафаил, әле генә булган вакыйгага ышаныргамы-юкмы дигәндәй, чирәмдә ятуын дәвам итте. – Мондый хәлне күз алдына да китермәгән идем...

Остазының сүзе бетмәгән иде әле.

– Казан авыл түгел, анда таләпләр катгый. Хәтта бик яхшы көрәшсәң дә, кагыйдә бозу җиңелүгә китерәчәк. Шуңа күрә онытма, билбауны дөрес итеп тот. Аны көндәшеңнең корсак турысына китереп тоту, боргалау, бөтерү, өстән аска күчереп йөртү, төртеп яки этеп җибәрү, көндәшеңнең битенә һәм кулларына баш белән терәлү, каршы як аста калганда, аның күкрәгенә төшү тыела...

Рафаил, остазы әйткәннәрне «мыегына чорнап», ике атнадан булачак республика Сабан туена әзерләнергә кереште.

Район спорт комплексына барып шөгыльләнергә тырышты. Ләкин авыл кешесенең башка эшләре дә муеннан бит әле. Эш урынында да, шәхси хуҗалыгында да һәрдаим чыгып торган мәшәкатьләр белән өзлексез «көрәшергә» туры килә. Атлаган саен йорт-җирне калдырып йөреп булмый. Шуңа күрә Рафаил дә клубтагы спорт залыннан күнекмәләр ясау өчен үзенә кирәкле кайсыдыр җиһазларны йортына алып кайтты, ике метр озынлыгындагы ашлама капчыгына ком тутырып куйды. Анысы – Хәлим абый өйрәткән алымнарны ныгыту өчен хезмәт итәчәк «көндәш» ролен башкарды...

Хәрби хезмәткә китәсе елны эретеп ябыштыручылар курсында укып кайтканнан бирле Рафаилнең Казанга аяк басканы юк иде. Нык үзгәргән башкала. Ул чакларда әле кылган, алабутадан башка берни үсмәгән ялан кыр урынында зур-зур йортлар калкып чыккан. Юкса, әллә ни күп вакыт та үтмәде бит үзе. Үсә Казан, үсә...

Хәлим абый, Рафаил һәм район бәйгесендә батыр асты калган Вадим – өчәүләп, шәһәр үзәгендәге «Казан» кунакханәсенең бер номерына урнаштылар. Кичкә кадәр шунда ял итеп, беренче каттагы ресторанда тамак ялгап алдылар. Ә кичкырын аларның номерына бер ир килеп керде.

– Мин Сабан туен оештыру комитетыннан. Милли көрәш бәйгесен үткәрү өчен җаваплы, – дип таныштырды ул үзе белән. – Хәзер сезгә Үзәк стадионга барып теркәләсе булыр. Шунда ук, теләсәгез, шөгыльләнеп, кем әйтмешли, бил яздырып алырсыз. Үзегез белән спорт киемнәрегезне, документларыгызны алырга онытмагыз, – диде дә кая, ничек барырга кирәклеген аңлатып чыгып та китте.

Кремльдән һәм әкияти «оча торган тәлинкә»гә охшаган цирк бинасыннан кул сузымы гына урнашкан Үзәк стадионга җәяүләп тә барып була. Казан урамнары буйлап, матур заманча йортларны, берсенә-берсе терәлеп торган кибет витриналарын күзәтә-күзәтә бардылар.

Республика Сабан туе батыры дәрәҗәсен дәгъвалап, төрле районнардан килгән алтмышлап көрәшче арасында Рафаил кебек мәһабәт гәүдәлеләр дә, карап торышка бик ябык, кечкенә буйлылар да бар. Шактый яшьләр дә, инде чәчләренә чал кереп өлгергән ир-атлар да күренә. Теркәп торучылар әйтүенчә, республика Сабан туенда көрәшчеләр гәүдә авырлыгы буенча төрле төркемнәргә бүленеп, көч сынашачак икән. Иң күп дәгъвачылар Рафаилләр төркемендә. Ә Сабан туе башта шәһәрнең халык яратып йөри торган биш мәйданында үтәчәк, районнардан килгән батырларны да иртәнге якта шул урыннарга таратачаклар, ди. Төштән соң исә, шул биш җирдә беренче-икенче урыннарны алучылар арасында шәһәр читендәге «Каенлык» дип аталган гаҗәеп матур аланда үткәрелә торган төп бәйрәмдә Татарстанның иң оста көрәшчесе ачыкланачак...

Рафаил Дәрвишләр бистәсенә баручылар арасына эләкте.

Ямь-яшел чирәм белән каплаган зур мәйдан тирәли тамашачылар өчен эскәмияләр көйләп куелган. Ике келәм. Алардан бераз читтәрәк, өстәл янында – баш хөкемдар, аңа ярдәмгә чакырылган көрәш тәртибен яхшы белүче казый, сәркатип, келәм арбитры, ян-як хөкемдарлар һәм табиб гәп кора. Янәшәдәге кәнәфидә, үзенең яшь, дәртле чакларында көрәшеп йөргән мизгелләрен хәтеренә төшерептер инде, үзалдына елмаеп, сакалын сыпырып, андый-мондый низаг чыккан очракта аны җайга салу өчен махсус чакырылган мәртәбәле аксакал, көрәш ветераны утыра.

Иң беренче эш итеп, көрәштә катнашырга теләгән ир-егетләр табиб тикшерүе үтәргә тиеш. Шунсыз көрәшче келәмгә чыга алмый. Барысының да кан басымын, тән температурасын тикшерделәр, нинди дә булса хроник чирләре барлыгын-юклыгын ачыкладылар. Көрәшергә теләгән кешене табиб бик җентекләп тикшерергә тиеш. Рафаил шуны да искәрде: авыл Сабан туйларыннан аермалы буларак, исерек яки авызыннан аракы исе килгәннәргә, шулай ук кан басымы югары булганнарга мондый ярышларда катнашырга рөхсәт ителми икән.

Бил алышырга теләгән һәр кеше кебек Рафаил дә бер бит кәгазьгә үзе турында мәгълүматлар тутырды – исем-фамилиясен, туган елын, эшләгән урынын язды. Бу анкеталарны җыеп алгач, баш хөкемдар көрәшчеләрне үлчәүгә бастырып, нинди авырлыкта булуларыннан чыгып, аерым төркемнәргә бүлде. Һәр үлчәү авырлыгында аерым шобага салынды. Көрәшчеләр шактый күп иде. Шуңа күрә баш хөкемдар микрофон аша очрашуларның олимпия системасы буенча, ягъни оттырган кеше шундук төшеп кала торган итеп үткәреләчәген аңлатты.

Исемнәре аталгач, арбитр, сыбызгы сызгыртып, Рафаил белән шобага буенча аның көндәшен келәмгә чакырды. Көрәшчеләр кул биреп күреште һәм билбауларын бер-берсенең билләренә салды. Арбитр ике якның да әзерлеген тикшерде дә, сыбызгысын икенче тапкыр сызгыртып, көрәшә башларга боерды.

Көндәшләр, беренче минутларда бер-берсен сынап, «кылларын тарткалап», кискен хәрәкәтләр ясаудан тыелып, келәм уртасында таптанып кына тордылар. Бу хәл озакка китте булса кирәк, аларның һәр хәрәкәтен дикъкать белән карап утыручы тамашачылар арасында шау-шу, көрәшчеләрне пассивлыкта гаепләп, канәгатьсезлек белдерү башланды. Бу хәлгә арбитр да битараф кала алмый иде, билгеле. Сыбызгы сызгыртып, көрәшне туктатты һәм егетләрнең икесенә дә кисәтү ясады, активрак хәрәкәтләнергә кирәклеген искәртте.

Шуннан соң, ниһаять, көрәш җанланып киткән кебек булды. Әле берсе кискен хәрәкәтләр ясарга тырышып карый, әле икенчесе. Берничә талпыныш ясаганнан соң, Рафаил үзе кебек үк таза гәүдәле көндәшенә якынаеп, аның билен кысып тотуга иреште. Мизгелне кулдан ычкындырырга ярамый иде, бар көчен бер йодрыкка туплап дигәндәй, көндәшен күтәреп алды да аны ыргытырга теләп, артка таба бер-ике адым атлады, ләкин аның гәүдә авырлыгын дөрес чамаламаган булып чыкты. Шуңа күрә яңадан аягына бастырырга мәҗбүр булды. Тәнәфескә озак калмаган иде инде, Рафаилнең көндәше дә «уянып» китте. Кинәт кенә алга ыргылып, аның билен каты итеп кысты да күтәреп ыргытырга ниятләде. Тик ул теләгәнчә барып чыкмады, ахыр чиктә үзе аста калды.

Тәнәфес вакытында Рафаил янына Хәлим абый килде. Кыяфәте житди.

– Йә, ничек, энекәш, үзеңә ошыймы көрәшүең? – диде ул киная белән.

Рафаил аңа берничек тә җавап кайтармады.

– Җитте, энекәш, икегез дә күп таптандыгыз. Кая активлык, кая мин өйрәткән алымнар? Мостик куллан, мостик! – Җиңелчә генә шәкертенең җилкәсенә төртеп алды да – бар да әйбәт булыр, Алла боерса! – дигән сүзләр белән, тамашачылар арасына кереп югалды.

Рафаил яхшы аңлый, саф җиңү өчен көндәшеңне җирдән күтәреп, күкрәк яки янбашы аша аркасына ташлау кирәк.

«Ләкин бу галәмәт авыр көндәшне сыртына салу мөмкинме соң? Ул бит миннән дә күпкә авыррак. Алай дисәң, Хәлим абый да миннән ике мәртәбә җиңелрәк...»

Ул тагын көндәшен күтәреп, аны ыргытырга тырышып карады, тик көндәше кулларының берсен билбавыннан ычкындырды, аяк чалырга маташты. Моны ачык күреп торган баш хөкемдар да, арбитр да көрәшне туктатмады, алымны төгәлләргә мөмкинлек бирде. Рафаил, нәтиҗәдә, көндәшен ыргыта алмады. Билбавын кулыннан ычкындырган, тезләре белән аның билен кысып, ыргытырга комачаулаган егеткә штраф баллы, ә Рафаилгә активлык өчен бер очко бирелде.

Бу хәлдән соң Рафаилнең көндәше бөтенләй төшенкелеккә бирелде кебек. Үзе һөҗүмгә күчмичә, келәмнән читкә чыгу ягын карады, көндәшен этеп чыгарырга маташты. Шулай итеп, тагын бер штраф баллы алды.

Үз-үзенә ышанычы арта барган Рафаилнең саф җиңүгә ирешәсе бик килгән иде. Ләкин, ул да булмады, казый алышны туктатты. Әгәр көрәш тиешле вакыт аралыгында бер якның да саф җиңүе белән төгәлләнмәсә, җиңүчене, көрәшнең сыйфатыннан, кемнең күпме балл җыюыннан чыгып билгелиләр.

– Булды, вакыт чыкты, – диде баш хөкемдар микрофонга. – Өстенлек көндәшен дүрткә бер исәбе белән откан Рафаил Мөхәммәтшинга бирелә...

Икенче әйләнештә Рафаил ничек тә Хәлим абый өйрәткән алымнарны кулланырга булды. Һәм бик урынлы. Көрәш башланып, бер минут та үтмәде, Рафаил көтмәгәндә көндәшенә ташланды да, аның билен нык итеп кысып, касыгы белән «чөеп» тегенең аякларын җирдән аерды һәм артка таба бөгелде. Көндәше аркасы белән яшел чирәмгә килеп төшкәнен сизми дә калды. Чиста җиңү. Мәйдан хуплау авазларына күмелде...

Сабантуйда баш батырны билгеләү өчен төрле үлчәүдә җиңеп чыккан көрәшчеләрне очраштыралар. Рафаилнең ничек оста көрәшүен җентекләп өйрәнеп утырган, гәүдәгә дә үзеннән ике мәртәбә диярлек авыр булуын яхшы аңлаган көндәше аның белән бил алышып та тормады, мәйданга чыгуга Рафаил янына килеп, аның кулын күтәрде. Шулай итеп, Рафаил Дәрвишләр бистәсендә үткән Сабан туеның баш батыры булып калды. Аңа, гадәт буенча, галәмәт зур тәкә бүләк иттеләр. Аңа өстәп, биредә башка кыйммәтле бүләк тапшыру гадәте дә бар икән. Рафаилгә заманасы өчен шактый затлы исәпләнгән видеомагнитофон бирделәр. Ә шулай да тәкә Сабан туеның иң кыйммәтле символы, бизәге булып тора. Батырның тәкә күтәреп, мәйданны әйләнеп чыгуы – үзе үк зур вакыйга!..

Казанга Рафаил белән Вадимның тренеры сыйфатында килгән Хәлим абый, «Потап» һәм бил алышудан баш тартып икенче урынга калган

Мансур исемле көрәшче «Каенлык»ка республика Сабан туеның финалына киттеләр...

Район бәйгесендә батыр асты калган Вадим да килеп җиткән. Ул Горький исемендәге Үзәк ял паркында узган Сабан туенда икенче урын яулаган булып чыкты. Вадимга бүләкне акчалата гына биргәннәр. Димәк, финалда ул да катнашачак...

Инде республика беренчелекләрендә үзен күрсәтеп өлгергән Вадимның исеме көрәш сөючеләргә азмы-күпме таныш булса, Мамадыш районыннан килгән тагын бер егет – моңарчы милли көрәш өлкәсендә исеме-фамилиясе бер генә тапкыр да колакка чалынмаган Рафаил Мөхәммәтшин бәйрәм тамашачылары өчен көтелмәгән сюрприз иде. Аның матур, чиста итеп көрәшүен, оста алымнар ясавын зур кызыксыну белән күзәтеп утырдылар.

Финал көрәше башлану белән Рафаил алга ыргылды һәм бер баллык алым ясады. Ул гына җитмәгән, аркасына ятты дип, хөкемдарлар тарафыннан көндәшенә бер кисәтү дә ясалды. Җиңү мизгеле якынлашуын җаны-тәне белән тоя башлаган Рафаил янә рәттән ике актив алым эшләде. Хөкемдар аның көндәшенә автомат рәвештә икенче кисәтү бирде. Вакыт чыкты. Нәтиҗәдә, туплаган баллар аермасы буенча республика Сабан туе баш батыры исеменә Мамадыш районыннан килгән, моңарчы спорт сөючеләргә бөтенләй таныш булмаган яңа көрәш йолдызы – Рафаил Мөхәммәтшин лаек дип табылды. Барлы-юклы ике атна эчендә өч Сабан туе батыры булуга ирешеп, үзенең гаҗәеп матур көрәше белән бар халыкны таң калдырган Түбән Ушмы авылы егете!..

***

...1999 ел. Чираттагы Сабан туена бер ай чамасы вакыт калган иде. Мөхәммәтҗан абый Рафаилне үз хозурына дәште. Егет кергәндә, аның кәефе шактый күтәренке иде. Рафаилне дә аягүрә басып каршы алды. Бер-берсенең хәл-әхвәлләрен сораштырып утырганнан соң, хуҗалык рәисенең йөзенә җитди төсмер керде. Берара Рафаилнең күзләренә туп-туры карап утырды да сүзен дәвам итте:

– Потап! – Хуҗалык рәисе, үзенең шаяруыннан канәгать кыяфәттә картларча кеткелдәп көлеп куйды. – Алга таба нишләргә исәплисең?

Рафаил мондый сорауны көтмәгән иде. Ил агасының яшьтәшләре, көрәшче дуслары кебек үзенә «Потап» дип сүз катуына аптырамады да, үпкәләмәде дә. Шулай да хуҗалык рәисенә сәерсенеп карап куйды.

– Ә нишләп «Потап» әле? Син бит миңа «Бүре» кушаматы таккан идең, – дип көлде егет.

Чынлыкта, уйлап карасаң, аңа «Бүре» кушаматы да туры килер иде. Ни өчен дигәндә...

...Рафаил, һава шартлары нинди булуына карамастан, көн саен диярлек, авылдан ерак булмаган урманга барып, төрле күнекмәләр ясарга, йөгереп кайтырга күнекте. Тугыз ай чамасы элек тә урманнан кайтып килә иде. Көн салкынча. Тау итәгендә, басу-кырларда инде октябрь башында ук яуган кар ята. Җылысы бөтенләй диярлек булмаса да, көзге кояш күзләрне иркәли. Егет юл уңаендагы буага күз салган иде, ярдан ерак түгел генә, су эчендә мәш килүче бер аксыл тапны күреп алды. «Берәрсенең эте суга

төшкән инде әллә?» – дип кычкырды ул. Әйтерсең лә, янәшәсендә кем дә булса бар. Аяклары Рафаилне үзләреннән-үзләре шул тарафка әйдәкләде.

Якынрак барып карагач, егет үзенең ялгышканын аңлап алды. Салкын судан юка шома боз өстенә чыгарга азапланучы хайван һич кенә дә эт түгел иде. Бүре!

«Ак бүре инде әллә?! Каян килеп чыккандыр бу якларга? Мондый бүреләр Себердә, суык якларда гына яши түгелме соң?»

Алай гына да түгел, яр буенда иптәшләренә ничек ярдәм итәргә белмичә аптыраган тагын ике ерткыч таптана. Алары да шул ук токымнан булырга охшаган. Ярдагылар: «Коткар әле безнең дусны!» – дигән кебек ялварулы күзләрен Рафаилгә төбәделәр. Бүреләр белән күзгә-күз очрашудан каушап, берара каккан казык кебек хәрәкәтсез басып торганнан соң, ни булса шул булыр дигәндәй, егет ярдәмгә ташланды.

Көннәр шактый салкын тоелса да, әле ныгып өлгермәгән көзге боз, билгеле, аның авырлыгына түзмәде, чатнама салкын су гәүдәсен куырып алды. Рафаил калтыранган бармаклары белән бүренең муен артыннан эләктереп алды да, юка бозны вата-вата, ярга таба атлады. Кулларына күтәреп алгач кына, ерткычның йөкле икәнен шәйләде. «Сине коткарыр өчен Аллаһы Тәгалә мине шушы мизгелдә шушында китергәндер инде, – дип елмайды Рафаил, ана бүренең күзләренә текәлеп. – Әнә бит, туачак балаларыңны да саклап калырга насыйп булды».

Ул ярга чыгып җитүгә, янына кара төстәге «Джип» килеп туктады. Иптәшләрен судан чыгарганны карап торган бүреләр, куркышып, урманга таба чаптылар. Машинадан көяз генә киенгән хуҗалык рәисе Мөхәммәтҗан абый белән урман караучы Харис чыкты.

– Рәхмәт, энекәш! – диде урман караучы, Рафаилгә булыша-булыша. – Чын батырлык эшләдең бит, безнең чибәркәйне үлемнән коткардың. Тыюлыкта шушы бүреләрне үрчетеп карамакчы булабыз. Белмим инде, барып чыгармы, юкмы. Менә, син күреп алмаган булсаң, ана бүрене дә, туачак балаларын да югалткан булыр идек. Рәхмәт...

– Бүре үрчетмәкче?! – Харисның бу сүзләре Рафаилгә сәер тоелды.

– Бүре дигәч тә... Беләсеңме алар нинди файда китерә? Безнең якларда кабан, төлке, бурсык ише тәртипсез җанварлар артык күбәеп китте, ә бүреләр бөтенләй калмады. Бүре бит ул – урман санитары, энекәш...

– Харис, күп сөйлисең. Тизрәк машинага кереп утырыгыз, – дип ашыктырды аларны Мөхәммәтҗан абый. – Рафаилне катырып үтерәбез бит инде. Бозлы суда коенып чыгу уен эш түгел. Әйдә, миңа кайтабыз, җылынып алырбыз...

Шушы вакыйгадан соң Рафаил, чынлап та, авылдашлары телендә күпмедер вакыт «Бүре» булып йөрде. Ләкин бу кушамат, ни өчендер, озын гомерле булмады. Спортчы дуслары да, район халкы да аны, элеккечә, «Потап» дип кенә йөртте. Тора-бара ана бүре белән булган әлеге вакыйга бөтенләй дә онытылды кебек...

– Нигә алай дисең, Мөхәммәтҗан абый? «Алга таба...» Тел төбеңне аңлап бетермәдем.

– Нигә дип... Шушы әзмәвердәй гәүдәң белән гомер буе мәдәният йортында эшләп йөрмәссең бит инде...

Мөхәммәтҗан абый Рафаилнең хәрби хезмәткә чакырылганчы ук эретеп

ябыштыру серләрен өйрәнгәнлеген яхшы белә. Белә дип, хуҗалыкта андый һөнәр ияләренә кытлык булгач, Рафаилне, кулына юллама тоттырып, үзе үк Казандагы махсус курсларда укыткан иде бит. Ләкин, ни хикмәт, ике айдан эретеп ябыштыручы таныклыгы белән кайткан егет барыбер бу һөнәр буенча эшләмәде, фермада мал караучы, абзар чистартучы булырга теләүчеләр табылмагач, аңа Казанга киткәнче башкарган хезмәтендә калырга туры килде. Мәктәптә «дүрт»ле, «биш»легә генә укыган егет, алга таба институтларда югары белем алу мөмкинлеге булса да, хәтта армия хезмәтеннән соң да, авыр, пычрак эш дип тормады, фермада эшләвен дәвам итәргә булды. Туган авылын калдырып, матур тормыш эзләп, каядыр китү дигән уй аның башына кереп тә карамады. Сөйләшүләр бу мәсьәләгә кагылган мәлләрдә: «Тегесе дә китсә, монысы да чыгып шылса, авылда кем генә калыр да, кем генә эшләр соң?» – дип кенә әйтә торган булды ул.

Өстәвенә, Рафаилгә кечкенәдән үк көрәш җене кагылган иде бит. Хәлим абыйдан дәресләр алуын ташламады.

– Карале, энекәш, – диде Хәлим абый көннәрнең берендә. – Күрәм, ярыйсы гына өйрәнеп киләсең. Үзең дә сизә торгансыңдыр. Синдә потенциал зур. Сабантуйда көрәшү – бик яхшы. Тик сиңа, мөмкинлегең барында, зур спорт юлын сайларга кирәк дип исәплим.

Ләкин Рафаил профессиональ спортчы булу турында уйламый иде.

– Бу хакта сөйләштек бит инде, Хәлим абый, – диде ул, кулын селтәп. – Авылдан беркая да китмим!

– Беләм. Шулай да... Әлмәттә физкультура техникумы бар. Шунда укып кайтсаң шәп булыр иде, диюем. Мин өйрәткәннәр белән генә әллә ни ерак китә алмассың. Ә анда, үзең дә чамалыйсыңдыр, профессионаллар укыта. Анда профессиональ спортчылар әзерлиләр. Ә авыл... Беркем дә сине авылдан җибәрергә ашкынып тормый. Моннан китмичә дә зур уңышларга ирешергә була. Район үзәгенә йөрисең бит әле, беркем тыймый. Нәрсә, сыерларың синнән башка сөт бирми башлар, дисеңме әллә?..

Ничек итсә итте, ләкин Хәлим абый Рафаилне Әлмәткә барырга күндерде. Күмәк хуҗалык җитәкчесе Мөхәммәтҗан абый баштарак, аның ниятен белеп алгач, бераз кәефсезләнеп киткән кебек булды. Ни дисәң дә, үз эшен авырлыклардан зарланмый гына җиренә җиткереп башкаручыларны, кем әйтмешли, көндез шәм кабызып эзләп тә табып булмаган бер мәлдә шундый сүз ишет әле! Ләкин рәис күңеле белән аңлый – Рафаил дә киләчәген уйларга, яхшырак, яктырак тормышка лаек...

Әлмәттә укып кайтканчы Рафаил урынына кеше тапканнар иде инде. Гомер буе механизатор булып эшләп, лаеклы ялга чыккан Мәлик абый, өйдә эшсез ятуны күз алдына да китерә алмаган алтмыш яшьлек ир, үзе бу эшкә алынган. Ә Рафаилне авыл клубы директоры итеп билгеләделәр. Бер карашка бу эшнең әллә ни авырлыгы да юк иде кебек. Авыл халкы арасында абруй казанган Рафаил җитәкчеләр белән дә уртак тел таба белде. Хуҗалык рәисе Мөхәммәтҗан абыйга рәхмәт, клубка яңа җиһазлар кайтартты, кечкенә генә булса да, спорт залы ачып җибәрде. Моңарчы яшьләр бу бинага әллә нигә бер кайта торган киноны карарга яки бильярд уйнарга гына килә иде. Хәзер исә көне-төне шунда диярсең – клуб ишеге иртә таңнан караңгы төнгә кадәр бикләнми башлады...

Өзлексез күнегүләр ясау үз нәтиҗәләрен бирми калмады. Физкультура техникумында укып кайткан елдан башлап, авыл, район Сабан туйларында әллә ничә ел рәттән Потап-Рафаилгә тиңнәр табылмады...

– Синең белән сөйләшәсем бар, энем, – дип дәвам итте сүзен Мөхәммәтҗан абый, Рафаилнең җилкәсенә җиңелчә генә төртеп.

Егет җитәкченең күзләренә текәлде.

– Синең көрәш ятратканыңны беләм. Шөкер, уңышларың да җитәрлек. Кайбер зур спортчылар да мондый җиңүләр белән мактана алмый. Шулай да... Әйт әле, энем, туйдырмадымы?

Рафаил тыйнак кына елмаеп куйды.

– Төрле чаклар була, Мөхәммәтҗан абый. Кайвакыт кирәкме бу, дип тә уйлап куям. Бер-бер артлы шушы күнегүләрне ясап, нәрсә исбатлыйм? Кем артыннан чабам, кемне узып китәргә омтылам? Мине нәрсә этәрә моңа, дим. Чөнки кайчандыр, көрәш белән шөгыльләнә башлаган елларда үз алдыма куйган максатларыма ирештем бит инде. Әллә кайчан ирештем. Кем әйтмешли, алмаган бүләк, яуламаган үр калмады.

– Кызык сүз әйттең, «ирештем», дисең. Ә нигә... Нигә һаман Сабан туйларында елның елында сине күрәбез соң алай булгач? Димәк, нәрсәгәдер ирешмәгәнсең булып чыга, һаман да нәрсәгәдер омтыласың?

– Мин беркайчан да дан артыннан кумадым. Башкалардан аерып торучыниндидер осталыгым да, белемем дә юк. Хикмәт җиңүләр яки оттырышларда түгел бит. Болар барысы да үзеңнең мөмкинлекләреңне ачыклау өчен. Медальләр, дәрәҗәләр җыймыйм мин. Көрәш – минем бөтен барлыгым. Мин үз-үземне җиңәргә тиеш. Дан, хуплаулар, бүләкләр үзләренә булсын. Миңа алар кирәкми. Мин көрәшсез булдыра алмыйм, Мөхәммәтҗан абый. Хәзергә шулай. Бу – минем тормыш. Минеке генә! Кем генә, нәрсә генә әйтсә дә.

– Ә шулай да... Бернәрсә дә, беркем дә мәңгелек түгел. Киләчәкне дә уйларга кирәк бит, энем. Көннәрдән бер көнне Рафаил дигән көрәшче дә пьедесталга менми башлар. Шул чаклар күз алдыңа киләме? Тарих битләрендә генә калу куркытмыймы?

– Үземнең мәсьәләдә генә әйтмим, бу бар кешегә дә кагыла. Курку хыялларны, өметне үтерә. Нәкъ менә курку кешегә үзе чын-чынлап сәләтле булган гамәлләр кылырга комачаулый. Ул сине параличлый. Берәр нәрсә телисең икән – ал! Бүген ал! Синеке булырга тиеш нәрсә синеке булырга тиеш! Курыкмаска, бернидән курыкмаска кирәк!

Мөхәммәтҗан абый Рафаилне авызын ачып тыңлап утырды.

– Син, энем, чын философ булып киткәнсең бугай. Әллә ниләр сөйлисең, – диде ул, ихлас елмаеп. – Тик... Беркөнне Салих белән сөйләшеп утырдык. Халык бәйрәмендә көрәшкә профессионаллар кермәсен иде, ди. Ул сине профессионаллар исәбенә кертә. Ул гына түгел, бик күпләр. Ничәмә-ничә ел рәттән авыл Сабан туе батыры, район, республика, хәтта бөтен Рәсәй күләмендә мәртәбәле урыннар алган кешене профессиональ спортчы дию дөрестер дә.

– Бу сүзне миңа да еш әйтәләр. Тик мин көрәшчеләрне «профессионал» яки «һәвәскәр»ләргә бүлеп карау ягында түгел. Без барыбыз да диярлек авылда туып-үскән егетләр бит. Шәһәрдә тәрбияләнгән «профессионал»лар белән бил алышудан тартынырга кирәкми. Кагыйдәләр, көрәш шартлары

бөтен кеше өчен бер үк. Сабан туе ул – бөтен халык бәйрәме. Шәһәрдән кайткан өчен генә кешене көрәштә катнаштырмау гаделлек булмас иде...

– Ярар, Рафаил энем, көрәш мәсьәләсендә синең белән бәхәс корып утыра алмыйм инде мин. Сүзем башка нәрсә турында иде. Гомер уза. Күреп торасың, мин дә олыгайдым. Беркөнне район җитәкчеләре белән шул хакта сөйләштем. Эштән китәргә теләвемне әйттем. «Үзеңә алмаш тапсаң, рәхим ит», – диделәр. Рафаил улым, мин бу урында сине күрәм.

Рафаил, чынлап әйтәме бу дигәндәй, Мөхәммәтҗан абыйга сынаулы караш ташлады. «Ни сөйли бу? Нинди рәис? Нигә мин?»

– Йә, нәрсә диярсең?

– Туктале, Мөхәммәтҗан абый, шаярма. Нинди җитәкче чыксын миннән? Белемем дә юк, шул физкультура техникумы гына.

Хуҗалык рәисе үз фикереннән кире кайтырга уйламады да.

– Белем мәсьәләсендә борчылма, кирәк булса, читтән торып, авыл хуҗалыгы институтында укырсың. Халык сине хөрмәт итә, район җитәкчеләре дә уңай караштa. Ризалаш.

– Ә көрәш?..

Хуҗалык рәисе вазифасына керешкән очракта спортны ташларга туры килергә мөмкин. Моны Рафаил яхшы аңлый. Беренчедән, вакыт мәсьәләсе, икенчедән, рәис башың белән ничек кулыңа сөлге тотып, мәйданга чыкмак кирәк?! Сүзе күп булачак...

Рафаил рәис тәкъдименә тәгаен җавап кайтарырга ашыкмады.

– Мөхәммәтҗан абый, синең сүзләрдән әллә ничек булып китте әле. Бераз уйларга вакыт бир. Сабан туйлары үтсен инде...

– Аңлыйм, аңлыйм, энем. Сабан туена бер ай вакыт бар әле. Күреп торам, чабыш аты бәйгене алдан сизә дигәндәй, синең дә йокың качкан, күңелең мәйданга ашкына.

– Син әйткәнчә эшләсәм, зур спорт ярышларында катнашырга вакыт булмаячак бит. Ә минем спорттан бөтенләйгә китәсем килми. Минем бер «чир» бит инде ул. Нишләтим, башкача булдыра алмыйм. Килер бер көн, туктармын. Ә әлегә...

– Ярар, Рафаил энем, сөйләштек. Озын сүзнең кыскасы, бәйрәмнән соң җавабыңны көтәм, – диде Мөхәммәтҗан абый, сөйләшүгә нокта куеп.

Хуҗалык рәисе башын аска иеп, әле генә ишеткәннәре турында уйлана-уйлана, бүлмәдән чыгып киткән Рафаил артыннан карап калды.

«Шәп егет! Хәзерге яшьләр арасында аның кебек рухи һәм физик яктан нык кешеләр бармак белән генә санарлык шул. Спорт, милли көрәш яшь буынны упкынга тәгәрәүдән саклауда мөһим чараларның берсе дип, юкка гына әйтмиләр бит. Беренчедән, малайлар физик яктан чыныгу алып, көчле, сәламәт булып үсәләр, икенчедән, тәрбиялелек ягыннан да алар башка яшьтәшләреннән бер башка өстен. Андыйлар тормышта да үз юлларын таба, кеше була...»

Бу сөйләшүдән соң ун көнләп вакыт үтте. Хатыны белән улы йоклаган иде инде. Рафаил дә, вак-төяк эшләрен тәмамлап, ятарга әзерләнде. Утны сүндергән иде, ишегалдындагы Бурзайның ярсый-ярсый өрүе ишетелде. Аннары эт чиелдап куйды да тынып калды. Өйдәгеләрне уятмас өчен аяк очларына гына басып, егет ишегалдына чыкты. Баскыч төбендә зур гына гәүдәле өч ир-ат басып тора. Рафаил аларның берсен дә танымады.

– Нәрсә кирәк иде, егетләр? Төн уртасында нишләп йөрисез? – дип сорады Рафаил.

Ул да булмады, тегеләрнең берсе аңа таба талпынды һәм Рафаилгә кизәнде. Ир, билгеле, моны көтмәгән иде, шуңа күрә тегенең йодрыгы Рафаилнең яңагын сыпырып үтте. Шуны гына көткәннәр иде, күрәсең, – аның иптәшләре дә Рафаилгә ташланды. Физик яктан нык кеше булса да, көчләр тигез түгел иде. Өчесе бергә өстенә ябырылып, Рафаилне җиргә егып салдылар һәм типкәләргә тотындылар. Егеткә куллары белән йөзен каплап ятудан башка чара калмады.

– Быелгы Сабан туенда эзең булмасын, ишеттеңме? Бу авылда да, башкаларында да, районда да!..

Кинәт алар янында ук соры шәүлә пәйда булды.

– А-а! Бел...! – дип кычкырып җибәрде кыйнаучыларның берсе, балтырын уа-уа. – Пшол! Егетләр, эт! Сак булыгыз, сезне дә тешләмәсен.

Шул ук мизгелдә караңгы почмактан тагын бер ерткыч килеп чыкты. Аның артыннан икенчесе, өченчесе.

– Бүре бит болар! – дип җикерде «башлык». – Сарайлары ачык, тизрәк шунда кереп качыгыз.

Ләкин алар качып өлгерә алмады. Берничә мизгелдән өчесе дә бүре тешләгән аякларын ышкый-ышкый, ыңгыраша-ыңгыраша, җирдә яталар иде инде. Ул арада уянып, тышка чыккан хуҗабикә тиз генә милициягә, Мөхәммәтҗан абыйга шалтыратты. Хокук сакчылары район үзәгеннән килеп җиткәнче, Мөхәммәтҗан абый һәм аның машинасына утырып килгән берничә ир-ат бандитларның кул-аякларын бәйләп куйган иде.

– Яз көне мин сине коткарган идем, хәзер син мине бәладән йолып калдың. Рәхмәт сиңа! – Рафаил канлы куллары белән ана бүренең йонын сыйпады. – Нәрсә, бурычыңны үтәдең, алайса?

Ул кат-кат рәхмәт сүзләре әйтә-әйтә, ана бүренең колак артын кытыклады. Ә бүре, аңа җавап итеп, бары тик авызын зур ачып иснәп кенә куйды. Аннары юеш борынын Рафаилнең битенә тигереп алды да урман тарафына юл алып, күздән юк булды. Иптәшләре дә, инде шактый үсәргә өлгергән булсалар да, әлеге тамашага катнашмыйча читтән генә күзәтеп торган көчекләре дә, аның артыннан караңгыга кереп югалды.

Рафаилнең хатыны беренче тапкыр иренең күзләреннән саркып чыккан яшь тамчыларын күрде...

– Коткаручыларыңмы? – дип куйды Мөхәммәт абый, ерткычлар киткән якка текәлеп. – Бүре дигәч тә... Акыллы җанвар шул алар, бүтән сүз юк...

Рафаил аңа тегеләрнең ни «йомыш» белән килгәнлеген сөйләп бирде. Мөхәммәтҗан абый әлеге дә баягы тәкъдимен кабатларга дип авызын ачкан гына иде, сүзнең кай якка борылачагын шундук чамалап алган Рафаил кистереп әйтеп куйды:

– Сабан туйлары үтсен дидем бит, Мөхәммәтҗан абый, аннан соң күз күрер, яме...

Рафаил, кулына микрофон тотып, мәйдан уртасына чыгып басты. Бу хәлне күзәтеп торучы халык тын калды.

– Потап нәрсә сөйләмәкче? – дип куйды берәү.

– Җырларга җыенадыр, – диде янәшәдә генә берәү һәм, үзенең тапкырлыгыннан канәгать калып, мәйданны яңгыратып көлеп җибәрде.

– Җәмәгать, авылдашлар, – дип башлады сүзен Рафаил. – Авыл Сабан туенда катнашмаска булдым быел. Кирәкми. Гел мин генә батыр калырга димәгән. Ә мин, көрәшсәм, бил бирмим. – «Потап» эчкерсез елмаеп куйды. – Яшьләргә дә үсәргә мөмкинлек бирик...

Бу хәбәрне төрлечә кабул итүчеләр булды, билгеле. Кемдер: «Менә, ичмасам, ир-егет сүзе! Афәрин!» – дип уйлап куйды. Кемдер исә: «Күптән шулай кирәк иде, юкса елның-елында бөтен затлы бүләк «Потап»ка эләгә», – дип фикер йөртте. Ә кемдер: «Әһә, теге көнге кисәтү башына барып җитте бугай», – дип тә уйлап куйгандыр. Шушы уйны ишетеп алган, диярсең, Рафаил сүзен дәвам итте:

– Кайберәүләрегез ишеткәндер инде, беркөнне миңа «кунаклар» килде. Өйгә. Көрәштә бүтән катнашмаска киңәш иттеләр. Моның кем кушуы буенча эшләнгәнен яхшы беләм. Ул кеше бүген дә биредә. Алай ярамый. Матур түгел. Ләкин шуңа күрә көрәштән баш тарта икән дип уйламагыз. Әйтүемчә, миңа дан-шөһрәт тә, затлы бүләкләр дә кирәкми. Аллага шөкер, бар нәрсәм җитеш. Яшьләргә юл бирергә кирәк дип исәплим. Ә мин... Мин район бәйгесендә катнашырга исәпләп торам. Анысы да соңгы тапкыр. Сәбәбен әйтеп тормыйм, соңыннан үзегез дә аңларсыз. Тагын бер кат бәйрәм белән сезне, авылдашларым!

Рафаил авызыннан ишеткәннәрдән авыл халкының хәтере калды. Инде ничә ел рәттән беркемгә дә бил бирмәгән алыштыргысыз батырның кинәт кенә шундый карарга килүенә, инде әйтелгәнчә, кайсыдыр көнче бәндәләрнең эчтән генә булса да куанып куйганлыгы, кемнәрнеңдер чын-чынлап кәефе кырылуы көн кебек ачык иде. Җиренә җиткереп, матур итеп көрәшүче Рафаилнең Сабантуйда катнашмаячагын белеп алгач, мәйдан тирәли утыручылар арасында хәтта кулын селтәп торып китүчеләр дә булды...

Озак уйланды Рафаил хуҗалык рәисенең тәкъдиме турында. Хатыны, туганнары белән киңәшләште. Һәм ризалашты.

Вакыт дигәннән, күмәк хуҗалык рәисенең никадәр авыр, үтә җаваплы эш башкаруын аңлатып тору кирәкмидер. Әмма Рафаилне эшнең авырлыгы, үтә җаваплылыгы һич куркытмады. Аның фикеренчә, кешенең күңелендә берәр төрле теләк-омтылыш була икән, аңа ирешү өчен шартлар тудыру да әллә ни кыен түгел. Рафаилне иң борчыганы – аның «чире». Көрәш. Егет яхшы аңлый – чынлап та хуҗалык рәисе булып эшли башлаган очракта көрәш турында бөтенләй үк онытмаса да, аңа башкачарак карарга, гомумән, яшәү рәвешен тамырдан үзгәртергә туры киләчәк. Ләкин...

Ләкин бәйрәмнән соң хуҗалык рәисе эшенә керешкәч тә, ул милли көрәшне ташламады. Күренекле көрәшче Рафаил Ясәви улы Мөхәммәтшин, тулаем алганда, Мамадыш районы Сабан туйларында унҗиде мәртәбә баш батыр дәрәҗәсен яулады, «Ватаным Татарстан» газетасы каһарман шагыйрь Муса Җәлил истәлегенә уздыра торган татар көрәше буенча Бөтенроссия кубогында беренчелекне алды, Россия һәм Татарстан чемпионы, Россиянең спорт мастеры, Татарстан Республикасының физкультура отличнигы исемнәренә лаек булды.



*Гитара кылларын чиртеп, үзе язган җырларны интернет киңлекләренә чыгарган Оксана ИЛЬЮП 1984 елның 16 августында Башкортстанның Салават районы Лаклы авылында дөньяга килгән. Хәзер Чиләбе шәһәрендә яшәп иҗат итүче бу сөйкемле ханымны татар хатын-кызлары арасында беренче бард дип атасак та, дөрес булыр. 2014 елда аның «Гитара кыллары» дип аталган тәүге альбомы яздырыла, ә 2019 елда Чиләбедә «Оча алам» дип исемләнгән шигырь җыентыгы басылып чыга. Аерым шигырьләре Татарстан китап нәшриятында басылган «Яңа гасыр тавышы: антология»сендә дә урын ала. Һөнәре буенча икътисадчы булган Оксана 2011–2018 елларда Чиләбе өлкә татар Конгрессының Башкарма комитетында сәркатип вазифасын башкара. Шул елларда шагыйрь Ирек Сабиров белән аралашып яшәү аның иҗат куәсен тагын да үстерә, камилләштерә. Быел исә авторның «Үзгәрдең» атлы яңа шигъри җыентыгы дөнья күрде һәм, әйтергә кирәк, Оксананың каләме дә, китабының исемендә язылганча үзгәрде, үсте, шомарды.*

**Фәнил ГЫЙЛӘҖЕВ**

# Оксана Ильюп

## ЯЛГАН КОЯШ КҮЗНЕ ЧАГЫЛДЫРА...

***

Ак чәчәкләр өзелә дә чәчкә куна,
Дөньяны күк бизи мине, мин – өлеше.
Мин ярашлык таптым Җирдә яшәвемдә:
Үзәгемдә – Галәм аңы, Галәм көче.

Вакыт ватык – аны ерып чыгып була,
Гүя агым елга: ега, нидер сөйли.
Ә хыялым – кул сузымы ераклыкта.
Һәм йөрәкне гомумкүләм рәхмәт били!

Хыялларга иң кыска һәм туры сукмак –
Ихлас рәхмәт. Рәхмәт шушы тормыш өчен!
Бәхет – миндә, һәр вакыйга – минем дәвам.
Мин үзем дә бу Галәмнең бер өлеше.

Анык аңлыйм: ни көтәргә, нәрсә өчен?
Нинди куәт тупланганын төгәл беләм.
Кичә чәчкән орлык-уйлар чәчкә аткан –
Өзелә дә чәчкә куна берәм-берәм...

***

Мөһим микән вакыт төшенчәсе,
Сулар өчен мизгел генә калган чакта?
Карашыңны якты төшкән якка төбәп...
Һәм бу мизгел гасыр булып тынып калса.

Һәм син үзең гаять кыйммәт бәһа биреп
Чапкан эшләр, борчылулар гүя тузан.
Гүя кояш таплары ки, күренми дә.
Бер сулышка тик беравык мизгел сыйган...

Бер дә таныш булмаган хис... Бар да анык –
Сәбәпләр дә, мәгънәләр дә ярылып ята,
Сорауларга җаваплар да... Менә хәзер,
Сулар өчен бары мизгел калган чакта...

***

Җан өтелгән, җылың җитмәгән мәл,
Туңып, ахры, калырмындыр көздә.
Күрешәлмауларның тәэсиреме?
Көзгә әверелдекме үзебез дә?

Октябрьнең салкын төннәреннән
Кайнар учларыңны эзлим һаман.
Ялган кояш күзне чагылдыра,
Ә чын хисләр – сентябрьдә калган.

Өметсезнең соңгы өметедәй –
Теләнче күк, ярсып, назың көтәм.
Бер тамчы да җитәр төсле. Ләкин
Наз диңгезе кипкән бугай күптән.

Әйтер сүзләр әйтелепләр беткән –
Синсез көннәр-төннәр, әй, озын ла...
Мин күшеккән берни түгел, үзең
туңып калма, берүк, үз бозыңда!

## Күзәтүче

**1**

Төн җисеме Таң учында ярымшәрә калган.
Мин бары тик күзәтүче – тәрәзәгә багам.

Төннең татлы исен Таңы комсызланып сулый.
Төн – чуалчык, Таң куенында ләззәтләнеп дулый.

Һәм бу – Төннең янып бетәр, көеп бетәр чагы.
Көле генә калганчыга кадәр сөя Таңы.

**2**

Көнкүрешләр тасмасына үтеп керә хәтер –
Битарафлык күргәзмәсе. Кемнәр, ниләр әйтер?

Битарафлык. Буш күкрәктә йөрәк туңган күптән.
Гарьсез караш. Үксеп елар чаклар, хәер, үткән.

Рөхсәт итмим – юк мәгънәсе, хисләр чыгар ташып.
Күзем йомам. Күзем ачам – кабат төннең башы.

**3**

Гүя үсмер чагы Төннең –Таңын көтә гашыйк.
Мизгел кадәр йотым бәхет татыр өчен шашып.

Ә аннары, бар да булгач, шигырь укый аңа.
Чыклар булып, назлы Таңның күз яшьләре тама.

Ул озата Төнен. Язмыш бик аз вакыт язган...
Мин – бары тик күзәтүче, тәрәзәгә багам...

***

Җанны телеп, кыш узганны көтәм...
Ә урамда – күз ачкысыз буран!
Бу салкыннар бер мәл бетәр әле,
Кар астында язлар сулый сыман.

Бар дөньяны сабырлыкка төреп,
Җир өстендә ята калын юрган.
Тыйнак кына үз вакытын көтеп,
Кар астында язлар сулый сыман.

Карлар белән эрер бар борчулар
(Явып тора алары да һаман).
Март елмаер: «Ач күзеңне» диеп, –
Кар астында язлар сулый сыман!

***

Ниләр генә юраса да дөнья
Табигатьнең кыш сүрүе купкан.
Бәйсез күңлең языклы яз сорап,
Беркөн мине онтуыңнан куркам.

Ә син кайнар кочагыңа төреп,
Үбәсең дә кабат маңгаемнан:
«Шикләнмә!» дип, пышылдыйсың.
Шулчак
Куркуларым юкка чыга сыман.

Үз-үземнең җүләр уйлардан да
Кочагыңда тынычлыгым табам.
Ниләр генә юраса да дөнья
Без бәхетле!
Һәм без бергә һаман!

***

Бар җиһаным синең белән. Синең якта.
Ярымчиттә булалмыймын берничек тә.
Йөрәгемә ярсу салып сине күзлим –
Һәм.
Таныш шәүләң гел күренә күк ишектә.

Тәрәзәгә төн үрмәли. Әлли-бәлли
Моңын көйли җилләр. Гүя, мин – бишектә.
Җилләр түгел, синең сулыш бугай анысы,
Юк!
Ярымъерак булалмыйсың берничек тә.

Сабыр булып таңны көтәм. Әкрен генә
Аркамнан үп, уйларымны син ишет тә.
Елмаермын, төш аралаш җылың тоеп.
Син –
Ярымъякын булалмыйсың берничек тә.



*Курудимова Людмила Пётр кызы – гагауз шагыйрәсе, язучы, тәрҗемәче. Ул 1989 елның 3 июлендә Молдавия Республикасы Гагаузия административ территориаль берәмлеге Чадыр-Лунг шәһәрендә туа. Әстерхан дәүләт университетының чит телләр факультетын тәмамлый. Шигырьләре Гагаузиядә нәшер ителә торган «Туган тел», «Байрак» газеталарында, Төркиядә чыгучы «Кардәш каләмнәр» журналында басыла. 2017 елда аның «Сабыр чишмәсе» исемле шигырь җыентыгы дөнья күрә. Шул ук елны ул Истанбулда узган Беренче төрки телле яшь язучылар форумында катнаша. Бүгенге көндә Мәскәүдә яши. Тәрҗемә эшләре белән шөгыльләнә.*

Мила
Курудимова

# АЛДА НИ КӨТӘСЕН КЕМ БЕЛГӘН...

## Сөю ничек үлә

Нинди матур бармакларың – үбәр идем аларны.
Иңнәреңә назлы сыенып, көтәр идем таңнарны.

Тезләреңә башым салып, ятар идем изрәп...
Хисләремнән исәрләнеп, йөрер идем миңгерәп.

Ак күгәрчендәй очарсың бер чакны кочагымнан
Һәм әйләнеп кайтырсың син нәфрәтем учагына.

Билгеле, сөюе булгач, бардыр хыянәте дә.
Мәхәббәт – татлы агудыр кешелек хәятендә.

Башканы назлавың уйлап, шатырдатып, берәмләп,
Төз, матур бармакларыңны сындырыр идем тәмләп!

Бүтәннәргә баккан өчен чукыр идем күзеңне,
Елан булып буар идем, чагар идем үзеңне!

Сөю үткән икән – инде оныт, саклама ачу!
Юкса, эчтән кимерәчәк көнчелек атлы ярсу!

Бир кулыңны, тик онытма йөрәгең дә бирергә!
Сөюнең гомере чикле – әзерсеңме үләргә?!

## Алга

Алга бар, юлыңны дәвам ит!
Тукталма, һаман да алга кит!
Гомер ул юка җеп – йөгер, чап!
Тормышның кадерен бел, ямен тап!

Күңелең сафлыгын җуймасын,
Җан ачың югалсын, йомшарсын!
Сүзләрең канатлы кош булып,
Кемгәдер бәхеткә юл ярсын!

Белегез, елмаю, моңлану –
Ул җанның авазы, дусларым.
Күрегез, күңелнең җыр сузып,
Ирекккә очучы кошларын.

Җанда яз, урамда кар ята.
Бәхетне эзлик һәр мизгелдән!
Күпме җәй, күпме кыш бирелгән?!
Алда ни көтәсен кем белгән?!

## Унның тугызы

Мин беләм, унауның тугызы
Сатачак, хыянәт итәчәк,
Яманлап, каныңны эчәчәк,
Җаныңны телемләп тетәчәк.

Унауның тугызы лаф орыр,
Ялкынлы сүз сөйләр каршыңда.
Үзләре – хәнҗәрләр батырыр
Борылган арада артыңнан.

Ак төстә шикәрме, тозмы ул? –
Авызга капмыйча белмәссең.
Унауның тугызы булма син,
Бул, дустым, син – меңнән берәүсе!

## Яңа юллар

Әй, яңа юллар! Бармы, юкмы сез?
Мүкле туфрагым корыды сусыз.
Бик үкенечле юллар сайладым –
Онытылыр, дидем. Киттем. Югалдым.

Ерак юлларда күз нурым калды.
Сагыну-сагыштан йөрәгем талды.
Аһ, ана телем! Саф суың синең
Җанны сугара – күренми төбең!

Исемә төшә әнкәм көйләгән
Табында капкан ипи телеме.
Балны уртлагач рәхмәт әйтергә
Онытkan чагым, йотып телемне.

Мул тормыш күреп үсмәсәк тә без,
Фәкыйрьлек күреп чикмәдек иза.
Әти-әниләр әүвәл өйрәтте
Намуслы һәм чын кеше булырга.

Керәм буш өйгә, йомам күзләрне.
Колакта аваз: «Елама, кызым!
Бу җирдә һәркем синдәй мөсафир –
Килә ялгызы, китә ялгызы».

«Елама, көрәш! Артка чигенмә!
Тор да алга бар! Юл юк кирегә!
Кеше бул!» – диеп, һәркем сөйли лә,
Тик әнкәм сыман беркем сөйми лә...

Яшьлек ташлады ерак җирләргә,
Ләкин туган җир күңел түремдә.
Кемдер «акыллы», кемдер «ахмак» ди,
Һич исем китми кеше сүзенә.

Һәр әйткән сүзне тыңлау артык эш,
Ямь табып яшим бүгенге көннән!
Нинди хозурлык, нинди гүзәллек!
Бу озын юлда күпме җан миндәй!

Ярлы булса да кадерле туфрак
Газиз ядкаре – ул бала чакның!
Мин аңа мәңге тугры каһарман
Арабыз – ерак, күңелебез якын!

## Өч кала, егерме тугыз сала

Кушучлап таш катыш туган җир туфрагы –
Башка һичбернинди байлык юк, танышым!
Булырсың микән син ихлас дус-аркадаш? –
Дип дәшә өзлеккән һәм садә тавышым.

Тамырыбыз далаи Буджактан. Бу йөрәк
Нинди кан сугара? Исеме – гагауз.
Халкыбыз башкача, үзгәрәк, сәеррәк...
Кем соң без? Төркиме, балканмы, әллә рус?

Әүвәл бу безнең җир, аннары – сезнеке...
Иртәгә кем кызы булачак кемнеке?
Туп сыман типкәләп, тарафтан тарафка
Халкымны әтмәлләп, күпме кан катнашкан.

Өч кала, егерме тугызлап саласы.
Һәр таңда максат бер – мал-мөлкәт табасы
Бар безнең. Без ата-ананың кадерсез,
Тик нужа куарга яралган баласы.

Көчәнү азагы – бөкрелек газабы,
Их, өйдә булсачы безгә дә догачы!
Туган як җилләре чакырып иссәме?
Йөгереп кайтырмын япанчы[1] булганчы!

## Сөюнең яралуы

Эч мине, син йотым-йотым эч!
Бак миңа, күрмәгән төсле һич!
Тот кулым, кушучка ал җанны!
Карашым күр – ничек май-баллы!

Җылыны урлаган угрыдай
Кояшны бу кышта кем чәлгән?
Болытка шәмәхә төс бөркеп,
Ялкынсыз җан көлгә әйләнгән.

Күзләрең йом да син, хыяллан!
Бар дөнья буялсын аклыкка.
Ак карлар вальс биеп тибрәлсен,
Былбыллар сайрашсын таллыкта!

Һәм җырла бер милли көйгә син!
Җыр бит ул – хисләрнең юл башы.
Читлеген тарсынган кош сыман
Талпына йөрәгем, тыңлачы!

## Сабырлык чишмәсе

Сабырлык чишмәсе – кан һәм су.
Кем нәрсә дәшмәсен – әрәм сүз.
«Хөрмәтлем!» – дисең син. Аһ, оныт!
Җан саклап калды тик соң өмет.

Калды тик теш кысып чыдарга –
Син сабый түгел лә, елама!
Чит җирдә юк ла ул кадер-сан,
Иң газиз туфракка тарта кан.

Тәмлерәк, татлырак шикелле
Ватанда ашалган икмәк тә –
Төшләргә кереп ул йөдәтә –
Туган җир кайда да йөрәктә!

Дога да булышмый күптәннән –
Сабырлык чишмәсе түкәнгән.
Күр әнә халкыңны, Ай-баба![2]
Ул – коллык биштәрен күтәргән...

***

Ул синең сихерче күзләрең
Якуттай җемелдәп яналар.
Ул синең иреннәр – татлы бал,
Ымсытып, күземә багалар!

Ул синең саф алтын кулларың
Канаттай җәелә сак кына.
Ул синең буй җитмәс йөрәгең
Җанымны тиң күрми, тарсына!

---

[1] Япанчы – чит дәүләт кешесе, гастарбайтер.

[2] Ай-баба – Михаил Чакир (1861-1938). Гагауз мәгърифәтчесе һәм рухание. Беренче гагауз нәшриятын булдыруда башлап йөрүче.

## Сәрхушлек

Болгатып атар, өзгәләр, ватар,
Җаныңа тулыр! Сөю ул – давыл.
Уратып алыр бар булмышыңны –
Күпме кусаң да китмәс ул, калыр!

Суык кыштагы чи утын сыман
Көтәрсең аның ялкын карашын.
Көзгегә кара, көзге алдашмас –
Тик сөю килсә дөрләп янасың.

Һич көтмәгәндә мәңгелек кышның
Ачып керер ул бозлы ишеген.

«Ник суык, ник буш бүлмәң?» –
дип сорар,
Җавап бирерсең: «Үзем шикелле!»

Сәрхуш карашың кабат елмаер,
Түргә кодалар, диеп: «Хуш килдең!
Соң күрешкәннән ничә кыш үткән,
Кайда шул гомер югалып йөрдең?»

Күзләрең йомып, моңлы көй итеп,
Тынын тыңларсың сөю хисеңнең.
Шигырь язарсың куеп күпнокта...
Менә син кабат сәрхуш – исердең!

## Алтын туй

Бабай һәм әбинең алтын туй –
Нинди зур шатлыклы көн бүген.
Ике җан табышып парлашкан,
Тиң күреп, үз күреп бер-берен.

Булганнар терәк тә, иптәш тә,
Сердәш тә, күзгә-күз карашып,
Урталай бүлгәннәр тәгамне,
Кайгыны, шатлыкны, аңлашып.

Тормышның михнәте күрелгән,
Татылган ачысы-төчесе.
Яшь чакта төрлесе булгандыр,
Аны соң кем искә төшерсен.

Тормышның башында фәкыйрьлек
Аларны күп тапкыр сынаган.
Эш сөяр һәм тырыш булганнар –
Шуңа да рухлары сынмаган.

Шатлыклы, бәхетле көн, дибез –
Алтын туй! Ул соң ни дигән сүз?

Юл биреп, бер-берең холкына
Ярашып яшәү ул, булып үз!

Бабай һәм әбинең туй көне!
Бабакай иртәрәк уянган.
Ул манҗа[3] пешерә бирелеп,
Өстәлдә кыяры тозланган.

Ак шәраб салачак бабакай,
Пар касә кырларын тутырып.
Моннан да зур сәбәп табылмас,
Тост әйтер, эчәр ул утырып!


Шәрабны онытылып кояр ул,
Эчәр ул, көйләгәч табынын.
...«Өченче ел инде буш касәң!
Ник мине ялгызым калдырдың!» –

Дияр ул. Яшь тамар күзеннән.
Сәгате суккачтын, билгеле,
Яңадан кавышыр ике җан!
Ә бүген аларның туй көне...

*Гагауз теленнән* **Фәнил ГЫЙЛӘҖЕВ** *тәрҗемәләре.*

[3] Манҗа – гагауз милли ризыгы.

# ГАЛИ АРСЛАНОВ: «КУЛЫҢНАН КИЛСӘ, КЕШЕГӘ ЯРДӘМ ИТ!»



*Татарстан Фәннәр академиясенең мөхбир-әгъзасы, сәнгать фәннәре докторы, язучы Гали Арсланов – милли сәнгатебез тарихын һәм аның теоретик нигезләрен өйрәнгән күпкырлы шәхес. Аерым сәхнә әсәрләрен һәм, гомумән, сәнгать үсеше тенденцияләрен тикшергән, аның киләчәген күзалларга омтылган галимнең фәнни хезмәтләре сәнгать, әдәбият белгечләре генә түгел, тарихчы, мәдәният хезмәткәрләре өчен дә бай һәм киң диапазонлы нигез булып тора.*

**– Актанышның мохите, табигате кешеләренә дә йогынты ясый дип әйтәләр. Түмерҗә авылы да сезнең шәхес булып формалашуыгызда зур роль уйнагандыр?**

– Актаныш җирлеге кешеләре башкорт мәдәниятен дә, татар мәдәниятен дә сеңдереп үсә. Хәзер дә хәтерлим: кечкенә чакта иртән йокыдан уянганда, радиодан озын башкорт җырларын тапшыралар иде. Сәгать җиде тулып китүгә, Татарстан концерт бирә башлый. Шулай булгач, без ике мәдәниятне дә кабул итеп үскән кешеләр. Йогынты ясаган күренешләрдән беренчесе мәдәният булса, икенчесе – табигать. Актанышның табигате уникаль. Туган җирнең, Агыйдел буйларының матурлыгы минем күңелемдә хәзер дә саклана, гомерем буена ияреп бара. Өченчедән, әлбәттә, кешеләр. Актанышның кешеләре самими, шәһәрдәге исәп-хисап дигәннәре аларда юк, булса да – азрак. Әлеге дә баягы шул табигать һәм музыканың йогынтысыдыр инде. Шушы әйберләр сәнгатькә тартылуны, матурлык яратуны тәрбияләгәндер. Мин кечкенәдән үк сәнгатькә тартылып үстем. Җырлап, баянда уйнап, концертлар алып бара идем. Һәм болар барысы да мәктәп елларында ук тәрбияләнгән. Безнең дүрт класслы башлангыч мәктәптә укытучы берәү генә, дәресләрне чиратлап бирә иде. Ул вакытта үзеңнең биремнәрне укып-эшләп бетерәсең дә башкаларны тыңлап утырасың. Үскәндә колакка кергән әйбер, гомумән алганда, онытылмый.

Без, дүрт классны тәмамлагач, Теләкәй авылының сигезьеллык мәктәбенә укырга күчтек. Теләкәй безнең авылдан ике-өч чакрым ераклыкта. Көн саен таң белән чыгып китәсең, иртән сәгать сигезгә дәрескә барып җитәргә кирәк. Ул вакытта мин инде җитди генә җырлый башлаган идем. Әле дә хәтерлим: «Дим-дим» җыры белән мин беренче мәртәбә алтынчы класста Актанышка смотр концертына бардым. Сигез сыйныфны алты кеше тәмамладык. Мин берүзем тугызынчы сыйныфка бардым, калганнар барысы да колхозда эшләргә калдылар. Өч ел берүзем биш чакрым ераклыктагы Такталачыкка йөреп укырга туры килде.

Такталачыктагы мәктәпкә төрле авыллардан килгән илле укучыдан егерме бишен сайлап алдылар. Рус теленнән изложение яздырып, математикадан мисал чишәргә

бирделәр. Мин ике сәгатьлек биремнәрне бер сәгатьтә тәмамладым да эшне тапшырып чыгып киттем. Соңыннан малайлар: «Нинди юләр икән бу?» дип карап калган идек синең арттан», – диделәр.

**– Соңрак тормышыгыз сәхнә юлы белән ничек бәйләнеп китте?**

– Мин унберенче сыйныфны укып бетергәч, кая барырга икән дип икеләнеп калдым. Әнкәйнең изгелеге, алдан күрүчәнлеге булгандыр инде: «Улым, укырга кирәк, укысаң, кеше булырсың», – дип әйтә иде ул. Математика өлкәсендә дә сәләтем бар. Валентин Краснов дигән укытучым соңыннан, мин аспирантураны бетергәч кенә: «Ник математика буенча китмәдең?» – дип әйтте, ләкин үз вакытында юнәлеш бирмәде. Шул вакытта Әлмәт шәһәрендә театр студиясе ачылды. Яшь актёрлар әзерләү өчен Казаннан режиссёр Габдулла Йосыповны җибәргәннәр иде. Шактый гына кеше арасыннан узып, студиягә укырга кердем. Анда укуның шундый үзенчәлеге бар иде: студиядә роль бирәләр һәм укыганда ук инде эшли башлыйсың. Авылдан-авылга йөреп, Татарстанда гына түгел, Свердловск, Чиләбе, Түбән Тагил, Себер якларында да булып кайтырга туры килде. Уйнап та йөрибез, декорацияләрне көйләп, бушату, ут кору эшләрен дә башкарабыз. Алары өчен аерым 70-80, кайчагында хәтта 100 сум да түлиләр иде. Авылдан чыгып киткәндә плащ һәм абыйның иске пинҗәк белән чалбарыннан башка бернәрсәм дә булмаса, ярты ел укып-эшләгәннән соң кышкы каникулда авылга кайтканда пәлтә, бүрек, костюмнар алып, тулысынча киенгән идем инде.

Соңыннан мин өч ел армиядә хезмәт иттем. Ул вакыт эчендә театрда да үзгәрешләр булган иде: Габдулла абый киткән, студия ябылган.

Армиядән мин көзен кайттым, ул вакытта кабул итүләр инде тәмамланган, укырга керергә мөмкинлек юк иде. Шул вакытта Актанышка комсомол райкомына эшкә чакырдылар. Ул чагында социалистик ярыш бара иде. Колхозга барып, яшьләр белән очрашып, лекцияләр укып, иҗтимагый эшләрдә һәм шул ук вакытта районның сәнгать тормышында да катнаштык. Шулай итеп, бер ел вакыт узып та китте, ләкин әнкәйнең «укырга кирәк» дип әйткән сүзе күңелдә йөри. Шул елны мин Казанда Ленинград мәдәният институты филиалы ачылу турында ишеттем һәм, барып, кабул итү имтиханнарын тапшырдым. Профессор Ширияздан ага Сарымсаков режиссура бүлегенә кабул итеп алды. Институтны тәмамлаган елны Актанышта халык театры ачылды. Актанышка кайтып, диплом спектаклен – Аяз Гыйләҗевнең «Көзге ачы җилләрдә»сен яңа гына ачылган халык театрында куйдым. Актёрлык осталыгы буенча укыткан Роберт Батулла кабул итеп алды – дипломны бишлегә яклadым. Шуннан соң бер ел Актанышта режиссёр булып эшләдем. Әнгам Атнабаевның «Мәхәббәт турында җыр»ы белән Казанда республика күләмендә узган халык театрлары бәйгесендә лауреат булдык.

**– Театр – үзе бер дөнья. Ә фән дөньясы ничек сезне үзенә тартып китерде?**

– Квалификацияне күтәрү өчен Казанга килгәч, аспирантураны тәмамлаган, кандидатлыкны яклаган Ильтани Илялова белән сөйләшеп, аспирантура турында сораштым. Шулай итеп, аспирантураны да белешеп кайттым. Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтына имтихан бирергә килдем һәм өч кеше арасыннан минем берүземне аспирантурага алдылар. Бу инде тормышның беренче этабы иде. Җитәкче итеп Баян абый Гыйззәтне билгеләделәр һәм «Хөсәен Уразиков иҗаты һәм 1930-1940 елларда татар театр сәнгате» темасын бирделәр. Икенче җитәкче итеп Мәскәүдән Россиядә генә түгел, бөтен дөньяда билгеле театр белгече Константин Лазаревич Рудницкий билгеләнде.

**– Фән – шактый вакыт һәм тырышлык сорый торган өлкә бит...**

– Диссертация язу өчен ел ярым вакыт кирәк булды. Бу эштә иң авыры – материал



*Гали Арсланов шәкертләре белән.*

туплау. Бөтен периодиканы, революциягә кадәрге чордан алып барлык газета-журналларны карап чыгарга кирәк иде. Сирәк китаплар бүлегендәге материалларны кулга бирмиләр, кирәкле язмаларны күчереп алырга кирәк. Көне буе утырып, күзләр бетә, борыннарга тузан тула. Минем темага кагылышлы булган бөтен мәгълүматны, гомуми театраль агымнарны карап барырга, Хөсәен абый Уразиков үзе катнашкан спектакльләр турында рецензияләрне табарга кирәк иде. Теманы тулаем күз алдына китермичә, диссертация язуга тотынып булмый. Бөтен дөнья буенча диярлек материал җыярга, архив, музейларны йөреп чыгарга, көне-төне әдәбият укырга кирәк иде. Мин бит режиссурага, иҗади фикерләүгә өйрәнгән кеше, ә театр ул башка дөнья – монда аналитик фикерләү кирәк.

**– Ләкин шушы авырлыкларга карамастан, сез тормышыгызны фән юлыннан дәвам иткәнсез...**

– Минем шундый сыйфат бар: нинди дә булса эшкә тотынам икән, ахырына кадәр җиткерәм. Авыр булды. Бик авыр булды. Яза башлаганда бигрәк тә. Русча язарга кирәк, кайвакыт бер җөмләне дүртәр тапкыр язып карый идем. Соңрак инде яза-яза кул шомарды.

Диссертацияне язып бетердем, ләкин аны яклау өчен Мәскәүгә юлларны табарга кирәк иде. Чират дигән әйбер бар. Шуңа өстәп, телисеңме-теләмисеңме, мәскәүләр читтәгеләргә бераз өстән карый. Кандидатлык диссертациясен, берничә ел узгач, 1984 елны якладым. Шунысы әйбәт булды: кандидатлыкны яклаганчы ук инде мин докторлык темасы буенча эшне башлаган идем. 1993 елда Мәскәүдә «Татар театры режиссурасының эволюциясе (1906–1941)» дигән темага докторлык диссертациясен якладым.

Соңыннан мин Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының сәнгать бүлегендә 2016 елга кадәр эшләдем. Фәнни эш белән шөгыльләнү өчен коллектив бердәм, гаиләң бөтен булырга тиеш. Мәсәлән, станок артында хезмәт куйган кеше сәгатен тутыра да өенә кайтып китә, ә көн-төн эшләүне таләп иткән фәндә башны сүндереп куеп булмый. Фәнни идеяләр кайвакыт йоклаган вакытта килә. Бүгенге көндә өч әзер хезмәтем ята, ләкин хәзер язылган эшләрне бастырып булмый башлады, мотивация югалды. Сирәк кенә мәкаләләр язгалыйм. Тик өстәл астына язудан ни мәгънә?

**– Бүгенге көндә зал тутырып халык җыючы спектакльләр бар, ләкин үз заманында баш әйләндергеч уңышка ирешкән «Әлдермештән Әлмәндәр» дәрәҗәсенә менәрлек перспективалы спектакльләр ни сәбәпле хәзер юк икән?**

– Иң беренче сәбәп – театр сәнгатенең катлаулылыгында. Театр бик күп компонентлардан тора. Спектакльдә уникe кеше катнаша икән, уникесе дә югары дәрәҗәдә уйнарга тиеш. Икенчедән, шушы актёрлар яхшы уйнасын өчен режиссёрның бар элементларны да исәпкә алуы кирәк. Өченче компонент – художникның эше. Ә композиторның эше дә халык күңелендә эз калдыра алырлык булырга тиеш. Костюмнар, декорацияләрне исәпкә алып, бөтенесенең дә югары дәрәҗәдә, югары гармониядә булуы зарур. Моннан тыш әле драматургия бар. «Әлдермештән Әлмәндәр» турында әйтәбез икән, анда үзенә күрә фәлсәфәсе дә, юморы да бар. Шуңа күрә спектакль бар кешенең дә йөрәгенә барып җитә. Театр сәнгатенә таләпләр артык зур һәм шуларның бөтенесенең дә тәңгәл килүе бик сирәк очракта була: йә актёр тартып җиткерми, йә режиссёр эшләп бетерә алмый...

**– Театр – тәнкыйтьчеләр өчен дә катлаулы сәнгать төредер?**

– Анализлау өчен дә театр сәнгате шулай ук бик катлаулы. Спектакль ул тулы бер система. Әгәр системаның бер өлеше була икән, башкалары аңа яраклашырга тиеш. Образлар системасы, аерым бер принцип буенча, конфликт нигезенә корылырга тиеш. «Яңа татар пьесасы» дип исемләнгән бәйгедә мин жюри әгъзасы. Йөзләгән эшләр килә, ләкин арадан иң әйбәт дигәннәре, сәхнәгә куярлыклары икәү-өчәү генә була. Туфанның да «Әлдермештән Әлмәндәр»е берәү генә. Көн саен шедеврлар тудыра торган кеше юктыр. Бүгенге сәхнәдә уйнала торган спектакльләрне начар дип әйтеп булмый. Иң югары кимәлдә бәяләнерлек спектакльләр сирәк туа. Шунысы сөенечле: бездә хәзер яшь режиссёрлар күренә башлады. Аларның әле барысы да алда.

**– Үзегезнең тормыш юлына әйләнеп кайтсак, «бу очракта башкача эшләгән булсам» дип уйлаган вакытларыгыз булдымы?**

– Ялгышлар дигән сүзме инде бу? *(Көлә.)*

**– Шулай дип әйтсәк тә була...**

– Алай дип уйлаган вакытлар күп. Миңа хәзер җитмеш биш яшь. Кеше тормышка нәтиҗәләр ясый торган вакыт. Кайчагында кайтып уйлап утырасың да «менә бу вакытта болай эшләгән булсам, әйбәтрәк булган булыр иде», дип уйлап куясың. Шәхси тормышта, кешеләр белән мөнәсәбәтләрдә ялгышлар бар. Төгәл мисаллар китерәсем килми, ләкин тормыш еш кына анализларга, уйларга этәрә. Минем принцибым бар: әгәр кулыңнан килсә, кешегә ярдәм ит! Гомер буе мин шушы принцип белән яшәдем. Аяк чалучылар булганда да начарлык белән җавап бирмәдем. Ул яктан вөҗданым тыныч.

*Әңгәмәдәш* – **Алинә ХӘБИБУЛЛИНА.**

# «ШӨГАРӘ» СҮРӘСЕ ӨМЕТ УЯТА

Олыгая-олыгая, башка гел дә сәер уйлар да килә башлый икән. Әйтик, яшьрәк чакта дөньяда поэзия, гомумән, кирәк микән, дигән ахмак сорау берничек тә килә алмый бит инде. Әмма хәзерге меркантиль җәмгыятьтә шигъриятсез дә бәхет чигеп, матур гына яшәп буладыр төсле тоела миңа. Бүген шигъриятнең йогынты радиусы бик нык кечерәйде. Шигырь китапларының тиражы бермә-бер кимеде. Элек поэзиягә хәерхаһ булган бериш матбугат басмалары да шигырь бастырмый башлады, ләкин аңа карап, аларның тиражы аз гына да артмады, киресенчә, кими генә төште. Без барча иҗат төрләренең дә нигезендә поэзия ятканын яхшы беләбез, юкса әдәбият та, сәнгать тә, канат очы киселгән кошлар кебек, җирдән генә теркелдәргә мәҗбүр булыр иде. Ләкин бүген укучылар тарафыннан мавыгып укыла торган байтак әдәби әсәрләрнең дә, бөтен каналлардан тәүлегенә 24 сәгать буе яңгырап торган күпчелек җырларның да поэзия белән бернинди дә алыш-биреше юктыр дип беләм. Җитди музыка өлкәсендә дә консерватория белеме алып чыккан яшьрәк буын композиторлар, нигездә, татар моңына матәм маршы язу белән шөгыльләнә. Һәм аларның кайберсе турында, күз дә йоммыйча, безнең хәзерге Сәйдәш, дип язып та чыгалар әле.

Татар театрларына йөрүчеләр дә игътибар итә булыр: хәзер күп кенә тамашалар без карап, тәрбияләнеп үскән, сүз сәнгатенә нигезләнгән спектакльләргә түгел, ә каяндыр читтән килеп кергән хореографик күренешләргә охшап тора. Шулай итеп, театр сәнгате безнең күз алдында әкренләп кенә бию сәнгатенә әйләнеп бара. Андый тамашалардан инде бер генә татар кешесе дә күңеле тулып, елап чыкмастыр.

Иҗатта поэзия микъдарының кимүе яки бөтенләй юкка чыгуы, беренче чиратта, күңелләрдә моң шәрифләренең коргаксый баруына турыдан-туры бәйледер. Поэзия белән моң, асылда, синоним сүзләр булып тора. XX гасыр татар драматургиясенең иң бөек әсәрләреннән берсе – «Әлдермештән Әлмәндәр» спектакле нәкъ менә тирән моң белән сугарылган югары поэзия әсәре буларак кабул ителде дә. Дөрес, аны бүген дә кабат сәхнәгә кайтару омтылышлары юк түгел. Дәрт бар, әмма дәрман җитәр микән?

Әйе, бүген поэзия тормышның барлык сфераларыннан да кысрыклап чыгарыла бара. Кансыз, чорсыз заман шуны таләп итә, күрәсең. Ләкин мин үзем дөньяның шигырьсез яши алуына барыбер дә шикләнеп карыйм. Юк, шагыйрь Лилия Гыйбадуллина бер әңгәмәсендә, бу дивана заманда кешегә шигырь кирәк, дигән өчен генә түгел, җиһанда бу җәһәттән тагын да кәттәрәк дәлил – аргументлар бар.

Әйтик, мәсәлән, без галимнәр ярдәмендә, ниһаять, Коръәни-Кәримнең «Нәхел» («Бал корты») сүрәсенә азмы-күпме төшенә алдык. Дөресрәге, 16 нчы сүрәнең ни өчен нәкъ менә «Бал корты» дип аталуын бераз чамаладык шикелле. Бактың исә безнең җир өстендәге тормыш-яшәешебез бал кортларына мотлак бәйле икән ләбаса. Әгәр алар юкка чыкса, гыйльми исәпләүләр буенча, дүрт елдан кешелек үзе дә яшәүдән туктый икән. Бәгъзеләр юкка тиле көче белән шапырына: дөньяны бетерер өчен, әнә, бернинди дә атом бомбасы кирәкми булып чыкты. Әгәр без табигатьне хәзерге кебек вәхшиләрчә агулап торсак, җирнең язмышын гап-гади бал кортлары хәл итеп куячак. Шуңа күрә ышанып әйтергә була: кешелекнең яшәеше өчен поэзия дә, бал кортлары кебек, бик тә кирәкле бер хикмәттер. Коръәни-Кәримнең 26 нчы сүрәсе юкка гына «Шөгарә» («Шагыйрьләр») дип аталмыйдыр. Әлеге атамага да хәзергә адәм акыллары ирешмәслек символик мәгънәләр яшерелгәндер. Мәхлукат, күрәсең, шагыйрьләрсез, шигъриятсез дә яши алмыйдыр.

2021 елда бер Татарстан китап нәшриятында гына да эреле-ваклы 24 шигырь китабы дөнья күрде. Мәҗмугаларның гомуми тиражы да шул сан тирәсендә тирбәлә – 24 мең тирәсе. Алар арасында Г.Тукай, М.Җәлил, С.Хәким китаплары да, Ф.Яруллин, Л.Шагыйрьҗан томлыклары да, Ренат Харис («Өмет йолдызы»), Нәҗибә Сафина («Өтерләр юк йөрәк тибешендә»), Факил Сафин («Сер»), Ләис Зөлкарнәй («Узганны кабатлау»), Ләбиб Лерон («Мәхәббәтнең канат җиле»), Марат Кәбиров («Яралы моң») җыентыклары да бар. Ә менә калган тугыз автор – барысы да яшьләр. Машалла! Биредә мин аларның һәркайсын исемләп атап чыгарга җөрьәт итәм. Ник дигәндә, киләчәктә татар шигъриятенең хәл-халәте нәкъ менә шушы яшьләргә дә турыдан-туры бәйле булачак. Менә алар: Ленар Шәех («Казан – Мәскәү»), Лилия Гыйбадуллина («Сөрән»), Фәнил Гыйләҗев («Кирмән нигезе»), Гөлүсә Батталова («Кесә тулы – давыл!»), Рифат Сәлах («Мин – хыялың синең!..»), Булат Ибраһим («Утырып сөйләшик әле бер...»), Алмаз Мансуров («Син әйт кенә...»), Ләйлә Фаяз («Сөйләшәсе иде...»), Гөлназ Газизова («Ышандыр»)... Бу исемлекне, кинәнә-кинәнә, тагын да дәвам итәргә мөмкин. Шөкер, хәзергә шигъриятебездә яшьләр, иң мөһиме – талантлы яшьләр аз түгел әле. Ә менә киләчәктә ничек булыр – хәзерге вазгыятьтә әйтүе кыен.

Татарстан китап нәшриятында Г. Тукайның «Мәҗмугаи асаре» китабы нәшер ителү узган әдәби елның, һичшиксез, иң зур вакыйгасы булып тора. Шагыйрь үзе искәртеп узганча, бу китапта аның «халкына калдырырга теләгән әсәрләре» генә тупланган. Тукай исән чагында әзерләп калдырган мәҗмуга Җамал Вәлиди мөхәррирлегендә 1914, 1918 елларда – Казанда, 1933 елда Токиода дөнья күргән. Ниһаять, 109 елдан соң ул кирилл имлясында да басылып чыкты. Әлеге китапта урын алган әсәрләрдән Тукайның үз иҗатына ни дәрәҗәдә кырыс һәм таләпчән булуы аермачык күренеп тора. Бу җәһәттән дә безгә Тукайҗаннан өйрәнәсе дә өйрәнәсе әле.

Узган әдәби елның тагын бер җитди вакыйгасы – ул Р. Харисның «Татар Декамероны» поэмасы басылып чыгуы. Дөрес, поэма үзе «Казан утлары» журналы сәхифәләренә үк үтеп керә алмады, шагыйрьнең нәүбәттәге «Өмет йолдызы» китабында дөнья күрде. Бактың исә аны 21 яшьтән өлкәнрәкләргә генә укырга ярый икән. Ун мәхәббәт тарихына нигезләнеп, мавыктыргыч итеп, җиңелчә юмор белән өртелеп язылган бу әсәрдә мин үзем тәртип-низам кысаларыннан чыккан бер генә сәтыр да, бер генә строфа да очратмадым. Үз гомерендә ул мәхәббәт маҗараларына кем генә юлыкмаган да, кем генә аларны күңелендә якты вә татлы бер хатирә итеп сакламый икән?! Кыскасы, узган ел 90 яшен ваклаган шагыйрьнең яшьләрчә мутлыгына сокланырга гына кала.

Узган ел Флёра Гыйззәтуллинаның «Казан утлары»нда дөнья күргән «Коллык зинданы» поэмасы әдәби җәмәгатьчелек тарафыннан аеруча хуплап кабул кылынды. Әлеге әсәр тирән фәлсәфи уйлануларга корылып, югары шигъри накал белән иҗат ителгән. Әйтерсең, аны 90 яшьлек шагыйрә язмаган, диярсең. Тормыштагы һәр хәл-вакыйгага үз карашын белдереп барырга омтылган әдәбият галиме Миләүшә Хәбетдинова да «Коллык зинданы»на соклануын белдереп, «Казан утлары»нда әтрафлы мәкалә бастырып чыгарды. «Флёра Гыйззәтуллинаның «Коллык зинданы» поэмасы – вакыт һәм үзебез турында уйлану ул. Татар дөньясын тутык кебек эчтән ашый торган коллык психологиясенең сәбәпләре турында уйланырга чакырган поэма иҗат итүе өчен шагыйрәгә баш иеп рәхмәт әйтәм... Минемчә, бу поэма безнең заманның йөзен билгели торган әсәрләрнең берсе булып танылачак», дип язды ул «Чүп базары»нда яңгыраган шагыйрь тавышында нинди аһәңнәр ишетелә?..» дигән әлеге хезмәтендә. Шагыйрә иҗатына бирелгән бик тә югары һәм лаек бәя бу! Үз чиратыбызда без дә Флёра апабызга тазалык-саулык теләп, яңа иҗат ачышлары теләп калыйк.

*Ә без барыбыз да шәпмә-шәрә,*
*Йонын кыркып алган сарык сыман.*
*Тәкать корта халык телефоннан:*
*Сарык хәлен сорап балыкчыдан, –*

дип язган шагыйрә укучыларны саллы-саллы әсәрләре белән тагын да куандырыр әле, иншалла.

Узган ел нәшер ителгән китаплар арасында иң саллысы, мөгаен, Ләис Зөлкарнәйнең «Узганны кабатлау» мәҗмугасыдыр. Һәм күләме, һәм полиграфик эшләнеше, һәм төзелеше, һәм әсәрләрнең эчтәлек-формасы җәһәтеннән ул югары кимәлдәге уникаль басма булып чыккан. Ләиснең шигъри зәвыгы университетка укырга килгәндә үк калыплашып өлгергән иде инде. Тора-бара ул тагын да камилләште, шагыйрьнең фикерләү формасы зур үсеш-үзгәреш кичереп, ул метаметафора рәвешен алды. Бу инде белгечләр телендә элитар поэзия дип атала. Ләис Зөлкарнәйнең әлеге китабында, нигездә, нәкъ менә шундый шигърият үрнәкләре тупланган. Билгеле, аларга төшенү өчен укучыдан шактый җитди әзерлек таләп ителә. Ул әсәрләрне укыганда, еш кына шагыйрь укучы белән түгел, ә үз-үзе белән сөхбәтләшә кебек тә тоела башлый. Дөресрәге, поэзия үз-үзе белән гәпләшә сыман... Нишлисең, метафораның менә шундый хикмәтле үзлеге бар шул аның. Әлеге китап, асылда, халкыбызның шанлы да, ханлы да, канлы да тарихын бәян итүгә багышланган. Хәтта мәҗмугадагы күпчелек шигырь-кыйссалар да зур күләмле «Алтын Урда» бәянының бер кыйсеме буларак кабул ителә. Кыскасы, Ләис Зөлкарнәй татар поэзиясенең хәзерге үсеш кимәлен билгели торган китап язуга ирешкән. Зур шагыйрьгә тагын да зуррак корабларда озын-озак гасырларның дәрья-диңгезләрен исән-аман кичеп чыгарга насыйп әйләсен.

Узган әдәби ел тагын бер шигъри балкышы белән күңелләргә уелып калды. Көтмәгәндә-уйламаганда диярлек шигърият күгендә Лилия Гыйбадуллина йолдызы гөлтләп кабынды. Юк, без аның җитди талант иясе, уйлы-гамьле эстет шагыйрь икәнен моңарчы да яхшы белә идек. Әмма 2021 елда ул тәмам тугарылып китте, илдә-көндә үз иҗатын бар куәтенә яңгырата алды. Аның шигырьләрендә хатын-кыз нәзбереклеге дә, ир-ат дуамаллыгы да табигый рәвештә бербөтенлек хасил итә. Узган ел Лилиянең югары дәрәҗәдә үткәрелгән әдәби конкурста берьюлы дүрт номинациядә җиңеп чыгуы үзе бер могҗиза булса, «Казан утлары» журналында милли гамь белән сугарылган, «Дәвам» дип исемләнгән шигъри гөләндәмен бастырып, ул шигърият галәмен янә бер тетрәтеп алды. Моңарчы журналыбыз бер шагыйрь иҗатына, нигездә, 5–6 биттән артык урын бирми торган иде. Бу очракта да Лилиябез басманың күптән гамәлдә йөргән канунына үз төзәтмәсен керткән булып чыкты. Югары кимәлдә язылган, бербөтен аһәң-яңгырашка ия шигырьләргә хәерхаһлык күрсәтеп, редакция хезмәткәрләре бик тә дөрес эшләгән, минемчә. Әйе, әдәбиятта үз сүзен зурдан кубып әйтергә алынган талантлы яшьләргә һәрвакыт светофорның яшел уты янып торуы хәерле.

*Кыйбла якка карап яткан мәлдә,*
*Кемдер дөбердәтте ишекне.*
*Һәм ул: «Бабай! Ач ишекне!» – дигән*
*Җанга якын тавыш ишетте, –*

дип яза Ләбиб Лерон «Соңгы патриот» дигән шигырендә. Барыбызның да диярлек җан әрнүенә әверелеп барган «бабай – онык мөнәсәбәтләре» проблемасын шагыйрь, чыннан да, «җанга якын» итеп хәл кылуга ирешкән. Ул газиз оныгы белән, кинәнеп, үз ана телендә аңлашып, аралашып яши алуына куана. Сөенерлек тә: оныклар кавеме уптым ана теленнән язып барган чакта – бигрәк тә. Ә менә әлеге шигырьнең лирик каһарманы ана телебез һәрдаим каһәрләнеп, хәкарәтләнеп торганда да, аны оныгына исән-аман килеш тапшырып кала алган. Бу үзе үк хәзер фидакярлек үрнәге саналырга лаек игелекле гамәл инде.

2021 ел Ләбиб Лерон өчен дә гаять уңдырышлы ел булды. Ул иҗат активлыгын тагын да арттыра төшеп, көлтә-көлтә шигырьләр иҗат итте, алар шигърияткә хәерхаһ булган барлык басмаларда да дөнья күрде.

Узган ел талантлы прозаик һәм шагыйрь Марат Кәбировның Казанда, Татарстан китап нәшриятында, ниһаять, тәүге шигырьләр китабы басылып чыкты. Шулай итеп,

укучылар, шигърият сөючеләр өр-яңа шигъри дөнья белән якыннанрак таныша алды. Марат, беренче чиратта, шигырьне, бериш проза әсәрләреннән аермалы буларак, гади, аңлаешлы итеп язу куәсенә ия. Аның шигъри әсәрләре академикка да, авыл агаена да бердәй аңлашыла булыр. Юкса бездә хәзер күзгә төтен җибәреп, әйтәсе сүзне томанга төреп язарга адарыну галәмәте ныклап шәкелләшеп бара. Аларны укыганда, бу шигырьләр кем өчен языла соң, дигән табигый сорау да тумыйча калмый, билгеле. Бигрәк тә китап мөхәррирләренә андый ребуслар белән һәрдаим очрашырга туры килә. Сүз дә юк, бу очракта примитивлык белән гадилекне бутарга ярамый. Примитивизм рәсем сәнгатендә генә хуплана. Һәрхәлдә, халкыбызның «галилек – гадилектә» дигән гыйбарәсе һәрвакыт актуаль булып кала. Бу җәһәттән мин сезнең дикъкатькә М.Кәбировның бер шигырен тәкъдим итәргә телим. Менә ул:

*Кыңгыраулар өзелмәде*
*Гомерем дугасыннан.*
*Бүген салмый йөрим әле –*
*Эчми дип уйласыннар.*

*Урам буйлап кызлар үтә –*
*Тилерткеч буйлар-сыннар...*
*Иярмимен – хатынына*
*Тугры дип уйласыннар.*

*Хәсрәт урамына чыгам*
*Газаплар оясыннан.*
*Елмаямын – бер кайгысыз*
*Яши дип уйласыннар.*

*Менә шулай яшәп кенә*
*Китәрмен дөньясыннан.*
*Китәрмен дә кире кайтмам –*
*Үлде дип уйласыннар.*

Мин үз гомеремдә теләп тә, теләмичә дә исәпсез-сансыз тезмә әсәрләр укый-укый шундый уйга килдем: чын шигырь хакыйкатьнең үзе кебек үк гади булырга тиештер ул. Ә бу дөньяда безнең күзгә төтен җибәрүчеләр болай да хәттин ашкан.

Әйе, бүген без үтә дә меркантильләшкән, аңлаешсыз, кан исеннән исергән алама бер дәвердә яшәп ятабыз. Мондый сәер шартларда, кеше күңелен отыры хәвефләнү, курку, өметсезлек, хайвани хис-инстинктлар били барганда, җәмгыятьтә шигърияткә урын тарайганнан-тарая баруы бик тә яхшы аңлашыла, әлбәттә. Бу уңайдан шагыйрьләр турында сакланып калган бер риваять тә искә килә. Риваятьтә әйтелгәнчә, орышка керер алдыннан бөек хан мондый фәрман бирә торган булган: «Шагыйрьләрне һәм ишәкләрне уртада калдырыгыз! Алар сугыштан соң кирәк булачак!» – дигән ул. Күрәсез, безнең орышлы заманга да тач туры килеп тора бу борынгы хан фәрманы! Нәкъ Ркаил Зәйдулла язганча инде:

*Кабатлыйбыз, ахры, тагын бабайларның хатасын, –*
*Кем соң белсен ул Үләтнең таҗлар киеп кайтасын?*
*Ахырзаман атнасы да ерак калмаган бугай,*
*Анда вирус, монда... ересь – керер тишек тапмассың...*

Шигърият өчен менә шундый үтә дә хәерсез, экстремаль шартларда да шагыйрь, шагыйрәләребез, үз тәкъдири вазифасына тугры калып, «Казан утлары», «Сөембикә», «Идел», «Мәйдан» журналларында, «Мәдәни җомга» газетасында саллы-саллы шигырь шәлкемнәрен, поэмаларын тәкъдим итте. Алар арасында Рәдиф Гаташ, Зиннур Мансуров, Данис Хәйруллин, Эльмира Шәрифуллина, Рәшит Бәшәр, Айрат Суфиянов, Рифат Җамал, Мөхәммәт Мирза, Сөләйман, Фирүзә Җамалетдинова, Илсөяр Иксанова, Сирень Якупова, Рифә Рахман, Луиза Янсуар, Әлфия Ситдыйкова, Лилия Фәттахова, Ленар Шәех, Гөлнур Корбанова, Эльмира Җәлилова, Булат Ибраһим, Дания Нәгыйм һ. б. ның әсәрләре бар. Кем әйтмешли, һәркайсы төрле тонда, төрле тәмдә, төрле тында иҗат итүче каләм әһелләре. Иң мөһиме – алар мөкатдәс ана телебездә иҗат итеп, газиз милләтебезне олылап яшәүче фидаи затлар. Иосиф Бродский юкка гына, шагыйрь – телне яшәтү чарасы, димәгәндер. Безләр әнә шуны тирәнтен аңлап иҗтиһат кылырга бурычлы да инде.

**Газинур МОРАТ**

# ХИСЧӘН ФИКЕРЛЕ ШАГЫЙРЬ

***(Рәшит Әхмәтҗанов иҗаты турында уйланулар)***

## Тукай эргәсендә

*«Китмибез»не кабат укысыннар*
*Кемнәр әлифбаны таный аз-маз.*
Р.Әхмәтҗанов. «Ант»

Тәүге әсәрләреннән алып, соңгы сулышына чаклы Рәшит Әхмәтҗанов Тукай рухы белән яшәде. Бөек шагыйрь аның өчен һәр тарафтан үрнәк, өлге һәм юлны күрсәтүче маяк кебек балкып торды.

*Тудыр, халкым, яңа Тукайларны,*
*Без батырдык сине моң-зарга,*

– ди ул символик мәгънәле «Гомер агачымның гомерләре» исемле шигырендә, халкына мөрәҗәгать итеп һәм шул ук вакытта остазыннан гафу үтенеп.

XX гасыр ахыры шагыйре Тукайдан «Тормыш һәм иҗат дәресләре» алып, шул ук вакытта гади имитация юлына төшмичә, аның милли рухын, сурәтле фикерләү байлыгын саклау, дәвам иттерү рухы белән иҗат итте, аның яңа шартлардагы дәвамчыларының берсе буларак һәрдаим «янәшәдә» атларга тырышты.

Язманың башында искәртелгәнчә, аларны якынлаштырган янә бер тарихи үзенчәлек бар: икесе дә – апрель ае балалары.

Үзен күрү насыйп булмаган оныкларына Тукай истәлеккә үзенең рәсемен калдырган. Бик күп татар шагыйрьләренең игътибар үзәгендә торган шикелле, ул сын Р.Әхмәтҗановка да тынгы бирми. «Тукайның соңгы рәсеме» исемле программ памфлетында ул остазының йөзен, күз нурларының моңын, карашының көчен һәм, иң мөһиме, ул яшәгән тирәлек, даирәнең милләт сандугачына каршы алып барган явызлыкларын фаш итә. Әсәр кыю, ифрат тәвәккәл метафора һәм халык иҗаты энҗесен искә алу белән башланып китә: «Күзләр – кара кояш! Гамь яктысы... Гөлҗамаллар төнлә җеп эрлиләр. Иреннәрдә сүзләр: «Сынды кылыч... Бар ышаныч сездә, тереләр!..» Алдагы юлларда Тукайны яшьли фани дөньядан алып киткән мохит сурәтләнә. Чөнки Тукайның гүргә иңүен тизләткән, «тере килеш кеше ашаган патша», аның явыз яраннары, бу очракта «Кара төндә» кеше суярга әзер Столыпин искә алына. Кинаяле, тирән эчтәлекле берничә сүз, җөмлә белән Тукайның фаҗигале язмышын да, татар халкының зәүкый үсешенә тәэсирен дә ачып бирә шагыйрь.

*Көн дә үтергәннәр әкрен генә,*
*Кага-суга торгач – бер үлгән.*
*Әмма җирдә күпме телсезләргә*
*Тел ачкычы биреп өлгергән...*

*Ахыры. Башы узган санда.*

Алдынгы карашлы Тукайны эзәрлекләүдә реакцион көчләр берләшеп, аның үлемен тизләтү юнәлешендә бердәм хәрәкәт иткәннәр.

*Ильминскийлар балта бирер,*
*Ишмиләре балта чабарлар.*

Кара эчле, мәкерле дин әһелләре үткен сүзле Тукайны күрә алмаганнар, аның бәгыренә тигәннәр. Р.Әхмәтҗанов «Ишми ишанның Тукайны соңгы юлга озатканда әйткән тәкбире» шигырендә аны үзеннән үк фаш иттерә:

*Тукай гына түгел, «без дә яздык»,*
*«Зина кылдык донос акчасына».*

Үзенең гөнаһларын таныган була да, Тукайны тудырган, яшәткән, кулына каләм тоттырган өчен Аллаһка үпкәсен белдерә: «Үзең саклагансың аны, Аллам. – Үз башына җитә язды балаң». Чөнки Тукай халыкны аздырды, баш бирмичә яшәргә өйрәтте, имансызлары шагыйрьне әләм урынына күтәрде дип, ишан янау, куркыту юлына баса: «Каләменә тотынсаммы әгәр? – Ул кяферләр әле дарга менәр! Бер серемне әле әйтми калам». Мәгәр үзе дә кӧтелгән нәтиҗәнең нәкъ киресе килеп чыгуын соңыннан гына төшенә. Тукайны хурлау, кимсетү аны мактау, олылау, дәрәҗәсен күтәрү булып чыга. Тыныч, салмак өслүб, 10-10 иҗеге белән язылган шигырь Р.Әхмәтҗановның уңышлы публицистик әсәрләренең берсе булып, Тукайның XX гасыр башы иҗтимагый, әдәби тормышында тоткан урынын тәгаенләргә мөмкинлек бирә.

Мәҗүси аң төпкелендә туып, халык мифологиясендә бөреләнеп, Тукай иҗатында әдәби образ – символлар дәрәҗәсенә күтәрелгән Шүрәле, Су анасы, Кисекбаш кебек «персонажлар» Р.Әхмәтҗанов шигырьләренә көтмәгәндә, уйламаганда, ком арасында җәйрәп яткан энҗе бөртекләредәй килеп кереп, үзгәрәк булмыш сыйфатлары илә ачылып китәләр. «Су анасы» әкиятендәге «Тукай малае» урлаган таракны Р.Әхмәтҗановның «Эзләдем» парчасында замана билгесе – алтын алка алыштыра. Ул – шаян да, куркак та үсмерне ирештереп, су төбендә ята.

*Син кем үзең?*
*Су кызымы, бүтәнме?*
*Алтын алкаң суга төшеп киткәнме?*
«Эзләдем»

Унөч яшьлек малай алтын алканың суда күмелеп, янәдән калкып чыгуын күзәтә һәм шундый нәтиҗәгә килә: «Батар иде – ай саклыйдыр, күрәсең».

Иртән ул уяныр-уянмас, елый-елый, судан алтын алканы эзли, табалмый. Аның каравы ул гаҗәеп хәлгә юлыга: аның күзенә ай икәү булып күренә: «Кичә күлдә бер генә ай иде бугай». Балачакның бәхетле бер мизгелен чагылдырган сюжет канвасы, «Җилләр үрә ай нурыннан ефәкне», йөз меңләгән мәрҗәннәр «чәч бөртегең саен җемелдәп» кебек киңәйтелгән метафоралары Тукай әсәрен яңачарак юнәлештә үстерәләр, заманчарак яшәеш бирәләр.

Тукайның сатирик каләме «җан өргән» Кисекбаш Р.Әхмәтҗановның «Бишташ» поэмасына шулай ук кешеләрне сөймәгән, явыз гамәлле зат булып килеп керә. Аның холкы-менәзе бер дә үзгәрмәгән, нияте һаман усаллыкта икән:

*Күзе бар күк явыз Кисекбашның*
*Кол Галине эзли.*
*Икенче кат үтерергә теләп,*
*Эзли – өмет өзми.*

Ә бөек шагыйрь Кол Гали Кисекбаш белән әңгәмәгә кереп, аның дәрәҗәсенә төшеп ваклашмый. Ә хөкемдарның «сөекле кәнизәге» үлемнең серен ачу белән чикләнә.

*Үз чираты җиткәч, Гали аңа:*
*«И падишаһым, – дигән –*
*Синең гүзәлең бит бары сине*
*Сөймәгәнгә үлгән».*
«Бишташ»

Кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр, мәхәббәт кебек нечкә хисләрнең асылы гасырлар дәвамында да үзгәрми дигән фикер уздыра кебек шагыйрь.

Тукай иҗатында урын алган мифологик образларга, шул ук Кисекбашка да яңачарак, заманчарак мөнәсәбәт тә урын алырга, башкачарак интерпретация булырга да мөмкин икән.

Шулай ук ачлык мәйданы каһарманнарының берсе, күренекле шагыйрь Г.Морат Кисекбашка «мөнәсәбәт»не үзгәртә дә куя.

*Ә көчекләр Казан урамыннан*
*Өрә-өрә куа Кисекбашны.*
*Әгәр сиңа ялгыш абынса ул,*
*Урам ташы, берүк кичер башны,*
*Кичерә күр, берүк кичер башны.*
*Кичерә күр, кичерә күр берүк, –*
*Минем баш ул ауный – татар башы.*
«Ачлык»

Тукайның Р.Әхмәтҗанов иҗатына шифалы тәэсирен «кәттә» образларын үстерүгә генә кайтарып калдыру дөрес булмас иде. Бер яктан, ул остазыннан туган халкының рухын, моңын, аһәңен олы вә фаҗигале тархын чагылдыруга өйрәнсә, икенче тарафтан, аның образ – символлар, сурәтле фикерләү үзенчәлекләренә, тел-өслүб байлыгына таяна. Шулай да сәяси вә милли юнәлеш якынлыгы үзәктә тора. Аны Тукайның туган халкына биргән олы вә мәртәбәле бәясе рухландыра. «Чәчте-урды халкым, Горур булды, Үз язмышын читкә бирмәде!» – ди ул «Бәйрәм» шигырендә.

Замана шагыйре татар сүз сәнгатенә намус белән хезмәт иткән бер иҗади шәхесне дә онытмый, аларга олы ихтирамын шигъри юлларда калдыра: М.Җәлил, Ф.Кәрим, Г.Кутуй. А.Алиш батырлыклары, иҗади казанышлары алдында баш ия, Х.Туфан, С.Хәким, С.Сөләйманова, Р.Гәрәй, Ә.Маликов һ.б. әдәби элгәрләреннән «якты нур» алуын бер дәкыйкага да онытмый. Аерым алганда, «Җәлилчеләрне уйлаганда» шигырендә ул Мусаның курку белмәс холкы, илгә, халкыбызга дан алып килгән батырлыгы белән соклана һәм шунда ук туган телебезгә олы мәхәббәтен сиздерергә дә җай таба. Үзләре турында гына уйлап яшәгән «куркак җаннар»ны кояш яктысына «тартып чыгара», «куркак җаннар язган китапларның эчтәлеге бик тиз искерде», ди ул.

*Таш капчыкта яңгыраган телем.*
*Таш балчыкта гөлләр үстерде.*
«Җәлилләрне уйлаганда»

«Пәһлеваннар спектакле»ннән алты җырның икенчесен, өченчесен Җәлил «башкара». Бу җырларда «таудан, диңгездән» килгән дошманнарга каршы, «орышка, далага, күккә» карап башкарылачак бәрелеш, гомумән, коллык богауларын өзү өчен көрәш рухы алга чыга.

Тукай, Җәлилләрдән кала аның өчен бөек шәхес, шигърият йолдызы – Хәсән Туфан. Ул аның исемен аеруча зур горурлык белән «Бишташ» поэмасында искә ала һәм аны «өч көн ташчы итеп» эшләтеп, «җанымның кардәше» дип атап, әдипнең рухи һәм шигъри батырлыгына югары бәя бирә.

*Бер сәфәрдә биш кыямәт кичеп,*
*Илем, сиңа кайтып булганын*
*Сагыш сихерләре ярдәмендә*
*Исбат итте менә Туфаның.*

Үзенчәлекле лирик, тирән мәгънәле җырлар, аерым алганда «Ак розалар» авторы, фронтовик, алган яралары белән көрәшеп яшәгән Зыя Мансурның вафатыннан соң язган мәрәсиме укучыны дулкынландырмый калдыра алмый.

*Ак розалар җилдән тибрәнмәде.*
*Алар үскән бу җир тетрәнде.*
*Яңа кабер.*
*Яңа авыр яра*
*Алган бүген җирнең күкрәге.*
«Җиңүләргә бардың».

Шигъри багышлауларында Р.Әхмәтҗанов теге яки бу шәхескә гади мәдхия яудыру юлына төшми, ә һәр иҗат иясенең халкыбызны, телебезне, гомумән, милли менталитетыбызны саклау, укучыга ирештерү юнәлешендәге уйлануларына өстенлек бирә.

*Онытканның телен төшенә кер,*
*Хәтәр чорны бергә узыйк, хәтер!*
*Шулай булса гына, яшәүләрнең*
*Киләчәккә кеше серен әйтер.*
«Ант». Фатих Кәрим истәлегенә.

Р.Әхмәтҗановның шигъри офыгы, нииндирәк йола-традицияләргә таянуы турында уйланып утырганда, күзем «Ачлык мәйданы» циклына кергән «Кызыл китап» шигыренә төште. Гадәти хәл-әхвәл кебек. Шалашта утырганда, шагыйрь Ш.Мөдәрриснең җиңелчә генә бәяләгәндә, беркатлырак, патриотик пафослы «Кызыл мәйдан» поэмасын укып утыра. Менә шунда аның күңеленә хәтер офыкларын җәеп, киңәйтеп куйган перспективалы бер уй килә. Ул Кремль каршындагы Кызыл Мәйдан белән Ачлык мәйданнары арасында мантыйкый охшашлык таба. Максатлары төрлечәрәк булса да, икесе дә – берсе халыкны, икенчесе милләтне бәйсезлек, азатлык өчен көрәшкә озаталар. Яшәү белән үлем арасындагы тартышта кешеләрне, ике мәйданны якынлаштырган уртаклык алга чыга.

*Җирдә яшәр өчен,*
*Үлгәндә дә,*
*Ташламаган кеше бер-берсен.*
«Кызыл китап».

Ике мәйдан янәшәлегендә автор интертекстуаль уртаклык табып, шул алым ярдәмендә фикер-хисен укучыга үтемлерәк итеп җиткерүгә ирешә.

Элегрәк язылган, «Ачлык мәйданы» бәйләменә кергән шигырьләрен укыйм һәм шул ук күп мәгънәлек, яшерен серлелек, аң төпкелендә «казыну» очракларына тап булам.

Мөстәкыйльлеген саклый алмаган, иреген, дәүләтчелеген югалткан халык шагыйре матурлыкка вәйран булып, татлы уйлар хозурында гына яши алмый. Аңа милләтенең язмышы, туган теленең киләчәге тынгылык бирми, онытылып китсә, чабуыннан «тартып» ала һәм фикерләвендә әйткән сүзе атылган ук булуны таләп итә.

Р.Фәйзуллин «Күңел һәм җан сәфәре» мәкаләсендә Р.Әхмәтҗанов иҗатын яңачарак бәяләүгә «ачкыч» бирә сыман. «Рәшит Әхмәтҗанов – чын мәгънәсендәге татар милли шигъриятенең төп, дөрес юлында торучы шагыйребез. Ул – Р.Харис та түгел, Г.Рәхим яки Р.Мингалим дә түгел. Ихтимал, аны күпмедер дәрәҗәдә М.Әгъләмов белән параллель куеп буладыр»[1].

Р.Әхмәтҗанов, М.Әгъләмов кебек фани дөнья мәшәкатьләренә, уңайлыкларына, хәтта һәртөрле дәрәҗәләргә артык исләре китмичә, илаһи шигъри дөньяда яшәүче сүз осталарына бай икән татар сүз сәнгате. Шул мизгелдә күңелгә килгән, бакыйлыкка күчкән Фәннур Сафин, Н.Акмал, К.Сибгатуллин, Г.Садә, Акъегет, Я.Игәнәй исемнәрен атап үтү белән генә чикләнәм. Аларның самими, эчкерсез шигырьләре күңелгә ерактан килгән моң, сагыш хисләрен уятып, табигый-илаһи тамырларыбыз турында уйланырга мәҗбүр итәләр. Р.Әхмәтҗановның соңгы чор лирикасын, бигрәк тә «Ачлык мәйданы» шәлкемен укыганда, Казанын яклау өчен шәкертләре белән кылычка тотынып, һәлак булган имам Колшәриф газәлләре аһәңен, Мәүлә Колый, Сукыр Зәкиләрнең милләтләренә таяныч, яклау сорап, Аллаһка мөрәҗәгать иткән сыктануларын ишеткәндәй булдым.

Суфый шагыйрьләр мирасы серлелеге, фикер-тойгыларны шәрехләүне, ачып бетерүне укучының үзенә калдыруы, һәр шәй гамәлдә Раббыбызга таянуы белән Р.Әхмәтҗановка аеруча якын һәм 1991 елда 14 көн ачлык мәйданында утырганда рухи таяныч була. Борынгы һәм бигрәк тә Урта гасыр шагыйрьләре фәлсәфәсенең һәм символикасының берничә юнәлеше Р.Әхмәтҗановка аеруча кадерле. Берсе – Аллаһны бердәнбер бөек, илаһи гадел көч һәм кыен мизгелләрдә аның мәрхәмәтенә өмет итеп яшәү булса, икенчесе – суфыйлар балягатенең (поэтикасының) әйтеп бетермәү, серлелек, бер халәттән икенчесенә күчү, фикерне, хисне укучының үзенә ышанып, юллар арасында калдыру, күп мәгънәлелек, табигатьне җанлы матдә, сердәш итеп кабул итү кебек үзенчәлекләре аеруча якын. Замана шагыйренең бөек көчкә рәхмәттән башка әйтер сүзе юк. «Алла барын биргән иде, Адәмнәр тартып алды», – ди Р.Әхмәтҗанов «Ятим татар» шигырендә.

Ул халкының тарихи язмышы, киләчәге турында сүз барганда, Аллага сыенып, язмыштан узмыш юк дип, аякларын бөкләп, сәҗдә кылып кына утырган дәрвишләрдән аермалы буларак, «адәмнәр» кылган явызлыкларның нәтиҗәсен өздереп әйтә; аның тавышы бу очракта кискен дә, кырыс та.

Дәүләти яшәешебезне үзгәрткән «билгесез» көчләрне ул маңгайга бәреп, «каз тәннәре чыгарып» фаш итә.

*Халкымны сарык итте,*
*Баламны балык итте,*
*Балалар йөзеп китте,*
*Суелыр вакыт җитте.*

«Төнге аваз».

Дөрес, шагыйрьнең хисләре, уйлары артыннын ияреп, усалланып алуын хуплап та өлгермисең, ул болай мескенләнеп утыру килешмәс, «их шулай булсачы», дип хуплап куярлык хыялый фикерен калкытып куя.

[1] Фәйзуллин Р. Күңел һәм җан сәфәре. Китапта Әхмәтҗанов Р. Моңлану. Шигырьләр, поэмалар.- Казан: Татр. кит. нәшр.,1991.- Б.6

*Бер татары калганда да*
*Бөек Болгар иле тере.*
«Ятим татар».

Серле фикер-тойгыларны шәрехләүне укучының үзенә калдыру, шулай ук суфый – символистлар күзаллавына якынлык «Яшерен уйлар» шигыренең исеменнән үк күренеп тора.

*Яшерен уйлар толымыңа,*
*Юк инде, бәйләнмиләр.*
*Яшен белән күккә язар*
*Сүзләргә әйләнделәр.*

Шагыйрь гадәти күренешне искә алу аша чиксезлеккә күк, яшен, ай кебек күләмле символларга килеп чыга.

«Күләгәм мине үчекли» шигырендә хисси киеренкелек, экзистенциаль сагыш зиһенне чуалтыр дәрәҗәгә җиткерсә, «Яндырсам газабым» назымында кичереш тирәнлеге табигатьне мәҗнүннең сердәше, кыен мизгелдә ярдәмгә килгән «җан дусты» дәрәҗәсенә күтәрә.

«Уй диңгезнең чиге юк», «Утлар салдым Идел бозларына», «Кайсы йолдыздан идем мин?» кебек фәлсәфи шигырьләреннән якты нур, кешелекле моң бөркелеп, яшәүнең кадерен белеп, бәяләп, бердәнберлеген аклап, кешелекле булып калырга омтылыш ята; олы җисемнәрне шагыйрь метафорик сөйләм аша иңли.

«Кайсы йолдыздан идем мин?» шигыре – планетар киңлектә фикерләү үрнәге. Лирик зат үзенең бик ерактан, йолдыздан «иңгәнлеген» хисси кабул итсә дә, кайсы күк матдәсеннән икәнлеген «белми калдым», сүнәрмен әгәр «Янмыйча торсам» дип, сагышка бата. Гадәти (алдың-салдың), катнаш (каерып алдың-белми калдым) кафияләре, галәм җисемнәре белән «аралашулар» лирик затның кичерешләренең, тартылган җәя кылы шикелле, киеренкелеген ачуга буйсыналар.

Мондый күләмле төшенчәләр турындагы шигъри назымнары сине – укучыны яшәеш ваклыкларыннан өскәрәк күтәребрәк куя! Мондый гадәти тормыштан аерылыбрак торгандай күренгән фәлсәфи рухлы шигырьләрнең эчке хыялый моңы да сине әсир итеп, сагышлы хисләр дулкынында калдыра. Икеләтелгән проекция алымы Р.Әхмәтҗановның «Төнге саташу», «Тамчы тавышы», «Табигать белән серләшү», «Яшерен уйлар» кебек күпсанлы шигырьләренең сынлы үзенчәлеген тәшкил итә.

Дөньяны, кеше холкын төрле чагылышлары белән иңләгән «Мамык мендәр», «Шаулады имәннәр», «Татар әбиләре» кебек шигырьләрендә медитатив – лирик аһәң халык хәсрәтен үз кайгысы итеп кабул итүгә алып килә. Шушы ике шигъри канат бер бөтен буларак күзаллана. Югарыдагы, бигрәк тә «Ачлык мәйданы» циклына кергән, аерым шәхесләрнең эчке сөйләме – монологы алымында бирелгән шигырьләренә татар халык иҗатының бәетләрендәге шикелле, үлем-төшемне Югары көчләр җибәргән табигый халәт кебек кабул итү хас. «Мамык мендәр», «Бу мәңгелек колачларын җәеп», «Кан алу», «Исәнем», «Хәнҗәр ялтырады» кебек шигырьләрендә лирик затның халык азатлыгы өчен үзен корбан итүгә әзер булуы җисми тәрдән икенчесенә күчү кебек кабул ителә.

«Үлем күзе – яхшы күзге» дигән кискен гыйбарәне исемгә чыгарган шигырендә, автор «киңәшен» мөрәҗәгать алымнарына ышанып тапшыра.

*Әйдә, энекәш, тын да алмый бергә*
*Могҗизалар көтик үлемнән.*

Шагыйрьләр язмышын Р.Әхмәтҗанов ике юлга сыйдыра.

*И-и-и, шагыйрьнең бар гомере –*
*Айлы төннәр, кара көннәр.*
«Мамык мендәр».

Бу юлларда гармониягә ирешә алмаудан туган чарасызлык та, шагыйрь фаҗигасен ачу да, халыкка хезмәт итүнең сөенеченә ишарә дә бар.

Татар әбиләренең милли үзенчәлеген, эчке матурлыкларын, сокландыргыч гадәтләрен шагыйрь бер гыйбарәгә сыйдыра.

*Йә елыйлар, йә укыйлар догаларын,*
*Алар никтер яратмыйлар сөйләргә.*
«Татар әбиләре».

Югарыда аталган фәлсәфи-этик шигырьләрендә Р.Әхмәтҗанов халкының язмышы, үткәне, киләчәге турында уйландыра, бәйсезлек, азатлык таләп итеп, «ачлык мәйданы» бәйләменә кергән шигырьләрендә татар поэзиясенең төрле чор-буын традициясенә таянып иҗат итүче лирик һәм трибун шагыйрь буларак күзаллана. Аны иң борчыганы – бөтен иҗатына хас мәүзугъ – ике чик, татарның милләт буларак югалу куркынычы борчый һәм шул афәткә бирешмәү өчен халыкны уяту рухы белән яши.

*Мин татарның теле,*
*Сезне эзләп,*
*Канга батып беткән хәтере.*
«Татар теле».

Шул ук вакытта ул төшенкелеккә бирелеп, киләчәккә ышанычын да югалтмый.

*Тереләчәк Иман!*
*Ул әлегә*
*Далаларда йөргән бер качак...*
*Ул адашкан барлык балаларын*
*Үзенә алып кайтачак.*
«Кояш чыккан кайтыр юлларга».

Рәшит Әхмәтҗанов Баулы төбәгенең латыйф табигате кочагында туып, төрле гамәли һөнәрләрне үзләштереп, үз көнен үзе күреп, халкының тарихи фаҗигасен ихласи йөрәге, җаны аша уздырып, туган милләтен коллык богавыннан коткару хыялына бирелеп, ачлык мәйданын оештыручыларның берсе булып, гомерен туып-үскән туфрагында алтмышка җитмичә дә тәмамлап, чордашларына һәм киләчәк буыннарга энҗе бөртегедәй гүзәл, камил, бай эчтәлекле әсәрләрен калдырган һәм киләчәктә үз лаеклы урынын алачак иҗат әһеле дияр идем.

**Тәлгат ГАЛИУЛЛИН,**
*филология фәннәре докторы.*

# ДОНКИХОТЛАР НИЧЕК ҮЛӘ?

*Равил Сабырның «Фәхрине үтереп ташладылар» романына («Казан утлары», 2022 ел, 9-10 нчы саннар) бәяләмә*

Равил Сабырны драматург буларак белгәнгә, «Фәхрине үтереп ташладылар» романын укуга, яшерен-батырын түгел, «драматург чәчмә әсәр яза башласа, шулайрак килеп чыга инде» дигән һавалырак бер фикер бөреләнеп өлгергән иде, чөнки роман композициясенең ябык пространствосы, геройларның динамикалы, хис-кичерешләргә бай, киеренке диалоглары, конфликтның табигатенә интрига төсе хас булу нәкъ шулай уйларга нигез бирә. Һәрвакыттагыча монда да ләкин...

Әсәрдә узган гасырның 90 нчы еллары сурәтләнә, һәм шул чор логикасына ярашлы, роман үзе дә жанры ягыннан криминаль роман рухында иҗат ителгән. Дөресен әйтергә кирәк, укучыны мондый жанр инде күптән сискәндерми. Туксанынчы еллардан бирле без криминаль субкультурага да, аны романтик рухта кабул итәргә дә өйрәндек. Без югары даирәдәгеләрнең, хәтта мәдәният өлкәсендә эшләүчеләрнең үз-үзләрен «төшенчәләр» («по понятиям») буенча тотуына күнектек, үзебезнең дә көндәлек сөйләмгә килеп кергән «крыша», «бабки», «блатной», «братва» кебек сүзләргә аптырамыйбыз. Алай гына да түгел, көч куллану, рәхимсезлек, җинаять өчен җәзасызлык, әхлакый тотнаксызлык культына ияләштек, бу күренешләргә иң сизгер өлкә – тел дә җавапсыз калмады: «кемнең кулында – шуның юлында», «көчленеке замана», «кул кулны юа, ике кул битне юа» кебек гыйбарәләрне еш кабатлыйбыз. Тар даирәгә генә билгеле булган кушаматлар тагу да – җинаятьчел субкультурага хас тагын бер үзенчәлек («Фәхрине...» романындагы кушаматларга игътибар итегез: Буржуй, Сансыз, Штирлиц, Профессор, Санчо, Вальтер, Кипиш һ.б.). Ә инде кинофильмнар, романнарның баш геройларының «законлы карак» булуы алдан ук ул сәнгать әсәренең популярлыгын тәэмин итә, хәтта ки бу образларны романтизацияләү аркасында, алар үрнәк яшәү рәвеше, идеология буларак кабул ителә. Әйтергә кирәк, Россиянең социомәдәни киңлегендә бу күренеш чагыштырмача яңа һәм стихияле рәвештә тарала, бу теманың чынбарлыкны рациональ танып белүнең бер төре булган әдәбият-сәнгатькә үтеп керүе исә җәмгыятькә куркыныч тудыра торган әлеге субкультура турында чаң кагарга вакыт икәнлеген искәртә. Ягъни әдәбиятта әхлаксызлык, үлем-үтереш белән мавыгу, җимереклек, кан исе килеп торган әсәрләр күбрәк туган саен җәмгыятьнең ни дәрәҗәдә авыру булуы турында фикер йөртергә мөмкин.

Жанр хасиятеннән Равил Сабыр әсәрендә бу билгеләрнең барысы да бар, романның хронотобы узган гасырның 90 нчы елларында республикадагы оешкан җинаятьчел төркемнәрнең яшәешенә пәрдә читен күтәреп күзәтү мөмкинлеген бирә. Әмма Сабыр моның белән генә чикләнсә, ул криминаль романнар эчтәлеген меңенче тапкыр кабатлаган авторларның берсе булыр иде. Романны башкаларыннан аның милли эчтәлеге аерып тора.

Әсәрнең милли катламын аның XX йөз башында иҗат иткән Галимҗан Ибраһимов, 1960–1990 нчы еллар әдәбиятының күренекле вәкиле Мөдәррис Әгъләмов белән диалогка керүе, дөнья әдәбияты, сәнгать әсәрләре белән интертекстуаль бәйләнешләре һәм образлар системасы тәшкил итә. Автор XX йөз башында формалашып, 90 нчы елларда тагын бер тапкыр югары ноктасына җиткән милли идеалларның безнең гасырда ни өчен гамәлгә ашмавы турында уйлана, аның сәбәпләрен ачыкларга тырыша.

Ибраһимовның да, Сабырның да әсәрләре кешене җиңел генә «үтереп ташлау» турындагы хәбәр белән башланып китә. Галимҗан Ибраһимовның «Тирән тамырлар» романының беренче җөмләсен әсәренә исем итеп чыгарып һәм әсәрдә «олы абый» ролен башкарган Кадыйр авызыннан рефрен итеп кабатлаттырып, Равил Сабыр ике чор арасына күпер сала: язучы бәян итәсе вакыйгалар бушлыктан барлыкка килмәгән, алар Ибраһимов романында тасвирланган Октябрь инкыйлабыннан соңгы, Бунинча «каһәрле көннәр»дән тамырланып килгән. Һәм менә ул көннәрнең «яңа кешеләр»енә бәя бирер, аларны хөкем итәр көн килеп җиткән. Равил Сабыр бер очтан аларны да чын мәгънәсендә бикләп куеп, үзләренең кагыйдәләре буенча хөкем итә.

Кемнәр алар, нинди алар теге заманның Фәхриләрен үтереп ташлаучылар? Рус әдәбияты белгече М.Н.Эпштейн 1917 елгы революция вакытында патшаның бәреп төшерелүен, җиңел генә Аллаһтан ваз кичү актын З.Фрейдның борынгы кабиләчелек чорында улларының җыелышып, юлбашчы аталарын үтерүе турындагы фикере белән бәйли: «Революцияләрнең һәм аннан соң урнашкан тоталитар режимнарның психоаналитик нигезе шундый. Ата кеше улларының инстинктларын чикли, һәм алар, үзара сөйләшеп, аны үтерәләр. Хакимият Өлкән яки Оруэллның «1984» китабы аша таныш булган Олы абый кулына күчә. Гасырлар буе «самодержавие-православие»га (төрки халык мисалында «күктә – Аллаһ, җирдә – хан» – **авт.**) тугры булган халыкка патшаның бәреп төшерелүе иреккә чыгу шатлыгын алып килә... Бер үк вакытта – бушлыктан, әтисез, Аллаһсыз, ягъни терәксез калудан курку да. Шунда ятим калган халыкка тиз арада Аның урынын алырдай Олы абый кирәк була. Агай-эне арасында олы абый урынын алу өчен канкойгыч көрәш башланып китә...» Равил Сабырның бүгенге геройлары әнә шул Олы абыйның каты кулы астында үскән ятим халыкның ятим балалары. Алар өчен әти урынына калган олы абый – авторитет, кем авторитет – шул олы абый. 90 нчы елларның криминаль мохитендәге олы абый феномены ул бер үк вакытта физик көч культы белән дә бәйле. Кем көчле, алар шуңа буйсына.

90 нчы еллар – ул әле оешкан җинаятьчел төркемнәрнең ажгырып торган чагы гына түгел. Ул әлеге дә баягы XX йөз башында буржуаз җәмгыятьтә формалашкан милли азатлык идеяләренең кабат яңарып, мәйданнарга ташып чыккан көрәш чоры да. Безнең геройлар да – Галимҗан, Хамис, Илгизәр, Кадыйр һәм Диләрә милли идеяләр белән янып йөргән, булачак милләт хадимнәре һәм милләт әнкәсе, яңа заманның «яңа кешеләре». Алар үзләренең хыял-омтылышларын, тормышларын милләткә хезмәт итүгә багышлыйбыз дип, үзара кан эчеп антлар бирешкән рыцарьлар, үз заманнарының донкихотлары. Ниятләре изге, алар нәкъ XX йөз башының милләт хадимнәре кебек үк милләтнең тәрәккый китүенә иман китерә, шул юлда үзләрен корбан итәргә әзер. Моның өчен милли җанлы яшьләр нәкъ урта гасырлар рыцарьлары кебек сайлаган юлларында бергә булырга, ул юлдан беркайчан да, нинди генә шартларда да тайпылмаска дип, кан чыгарып, ант бирешәләр. Урта гасырлар көнбатыш мәдәниятендә кабул ителгәнчә, кан белән ант бирешкән рыцарьлар, гадәттә, нинди дә булса Орденга карый. Тамплиерлар ордены, мәсәлән, һәм алар өчен намус эше гомердән дә кыйммәтлерәк. Ә безнең рыцарьлар әле кичә генә «Шаяннар һәм тапкырлар клубы»ның актив әгъзалары (бу клуб күп кенә яшьләргә карьера ясауның беренче баскычы булып китте), татар факультетының зур өметләр баглап тәрбияләгән студентлары иде. Алар яшь, саф, матур, үткәннәре тапсыз, киләчәкләре өметле күренә иде. Бүген инде укучы ул донкихотларның кызганыч хәлгә калган ямьсез гәүдәләнешен генә күрә: Хамис, Илгизәр акча колы булып, антларына хыянәт иткәннәр, Галимҗан азгын хисләрен һәм куркаклыгын таный алмыйча оясына поскан, дөньяга чын йөзен күрсәтергә кыймыйча яши, Диләрә – рыцарьларның музасы – фахишәлек юлына басып, чәчәк кебек яшьлеген әрәмгә

уздырган. Милләтнең юлбашчысы булырга тиешле Кадыйр исә гомерен криминаль дөньядагы Олы абый ролен алган.

Кадыйр – үз заманының Дон Кихоты һәм аның Санчо Пансосы – Зөлмәт дусларын үзләренең криминаль дөньясындагы кагыйдәләр буенча хөкем итәргә алыналар. Хөкем барышында Равил Сабыр янә Британия язучысы Дж. Оруэллның «Big brother is watching you» эффектын куллана. Бикле бүлмәдә Кадыйр үзе юк, аның ихтыярын Санчо-Зөлмәт гамәлгә ашыра, әмма Олы абыйның барлыгы, үзе кабердә булса да, кабер салкынлыгы белән сизелә. Әсәрне уку барышында Кадыйрның «үткен күзе» бу бүлмәдә генә түгел, ә дусларын гомер буе күзәтеп барганлыгы аңлашыла. Язучы бу бүлмәне тасвирлаганда, гомумән, буяуларын кызганмый: мистика, төсләр ярдәмендә геройларын газапланырга мәҗбүр итә, ягъни аларны шәхси тәмуг казанына ыргыта.


Әсәр икенче төрле «Татарча үтереш» дип атала. Журналда бастырганда, эчтәлеккә әсәрләрнең русча исемнәрен бирү гадәте бар. Романның русча исемен без авторның үзеннән сорап, икенче исемен куйдык та, чөнки «Фәхрине үтереп ташладылар» җөмләсенең татар укучысы өчен генә аңлашыла торган мәгънәсе бар. Татарча үтереш нинди була дигәндә, автор әсәрдәге мәгънәсез үтерешнең сәбәпләренә ишарә итә. Дөресен әйткән – туганына ярамаган дигән әйтемдәгечә, Равил Сабыр татарның дөреслекнең күзенә туры карый алмыйча, хатасын танудан куркып, тәүбә итәсе, җәзасын алырга әзер буласы урында тагын да зуррак җинаятькә барырга сәләтле икәнен күрсәтә. Ул юкка гына персонажыннан Мөдәррис Әгъләмовның «Ә чын язмыш үзең язган гына!» дигән юлын кабатлаттырмый. Һәр буын үз гамәлләре өчен үзе җаваплы. Һәр буын үзенең дә, милләтенең дә, халкының да язмышын үзгәртә ала. Әмма ни өчендер җиңел юл сайлый һәм җинаять кылганын сизми дә кала.

Мәкалә башында «драматургиягә хас ябык пространство» дигән идек. Романда әлеге ябык пространствоның үз вазифасы бар: язучы монда гүя химия лабораториясендә, ул пространствоны, вакытны мөмкин кадәр кыса (бикле бүлмә, бер-ике сәгатьлек сөйләшү), кайчандыр югары идеаллар белән янып яшәгән кешеләрнең эш-гамәлләрен пробиркага салып үлчи, тәҗрибә үткәрә. Тәҗрибә минутына кадәр көтелгән нәтиҗәне бирә, гипотеза раслана, ягъни барысы да нәкъ Кадыйр белән Зөлмәт уйлаганча килеп чыга, полиция нәкъ вакытлы килә.

Менә шунда укучы милләткә хезмәт идеалы белән җәмгыятьтә хөкем сөргән криминаль дөнья романтизмы бәрелешенең шаһиты була. Шунысы ачык аңлашыла: болар икесе беркайчан янәшә дә, бергә дә яши алмый.

**Ландыш ӘБҮДӘРОВА**

# СӨЕМБИКӘ ШӘҖӘРӘСЕНӘ ӨСТӘМӘЛӘР




Казан, Касыйм ханлыкларында өч мәртәбә абруйлы ханбикә буларак дан казанган Сөембикәгә, ниһаять, быел Рязань өлкәсенә кергән Касыйм шәһәрендә затлы бер һәйкәл куелды. Ә берничә ел элек казакъ кардәшләребез дәүләте башкаласында – Астана шәһәрендә бер урам аның исеме белән аталган иде. Тумышы белән шул яклардан бит ул. Җаек-Урал елгасының урта бер өлешендәге җәйләүләрдә уйнап үскән кыз.

Бәлки киләчәктә безнең Казаныбызда да Сөембикә ханбикә һәм аның даирәсенә кергән шәхесләр исемен даими искә төшереп торырдай бер чара күрелер әле. Бездән ерак чорда яшәгән бабаларыбыз белән бергә Идел буе Болгар дәүләтенә нигез салган бер тарихи шәхескә дә һәйкәл куелуы турында хәбәр булды бит. (Дөрес, ул һәйкәл ни сәбәпледер Идел буе ярында түгел, чуваш кардәшләребез биләмәсенең Чүпрәле районы чигенә якын бер урында урнаштырылуы гына сәерсендерә.) Сөембикә ханбикә яшәгән дәверне чагылдырган истәлек мәйданчыгында мин Җангали белән Шаһгалине дә, Сафа белән Кошчак угланны да, аларның уртак балалары сыннарын да күрергә теләр идем. Әйе-әйе, Сөембикә белән Җангали янәшәсендә аларның кызы да булырга тиеш. Безнең тарихи әдәбиятта ул кыз фәкать бер мәртәбә генә искә алына – Һади Атласиның узган гасыр башында язылган «Сөен-бикә» китабында гына. Ул әсәр кабат 2009 елда нәшер ителде. «Сөен-бикә» исеме белән ул язма авторның «Сайланма әсәрләре»нең беренче томына кергән. (Автор анда кайсы чыганакларга нигезләнеп язуын да хәбәр итә.) Ләкин шуннан соң нәшер ителеп, дөньяга таратылган бер генә тарихи һәм әдәби китапта да бу факт искә алынмый. Ә унҗиденче гасырның бер рәссамы тарафыннан иҗат ителгән төсле сурәттә исә ул кыз анасы янәшәсендә басып тора. Дөрес, безнең күпчелек авторлар аны Сөембикәнең улы рәвешендә күрергә күнеккәннәр. Ул сурәтне нәшер иткәндә дә, кызларча киенгән баланы: «Сөембикә янәшәсендә улы Үтәмешгәрәй», дип таныту еш кабатлана.

Сөембикә ханбикәгә багышланган язмалардагы кайбер башка фактларны да тулырак ачыклар вакыт җиткәндер, шәт.

### 1

Иң элек аның туган-үскән якларын, ата-бабаларын искә алып үтик. Югыйсә безнең кайбер тарихи хезмәтләрдә аның атасы Йосыфны Нугай Урдасының башлыгы, хәтта ки «ханы» рәвешендә таныту очраклары да бар. Сөембикә үз илендә яшәгән дәвердә әле ул гадәти бер олыс башлыгы, олыс морзасы гына була. Күренекле Мәскәү тарихчысы Вадим Трепавловның 2015 елда нәшер ителгән «Кочевая империя ногаев XV-XVII веков» китабына күз төшергәләп алыйк. Әлеге китапта Йосыфның берничә буынга өлкән бабасы Идегәйнең ни рәвешле Нугай Урдасы бәклеген оештыру тарихы, варисларының шул бәклек белән идарә итүләре тасвирлана. Идегәй әмир Чыңгыз хан нәселеннән чыкмаганлыктан, ул оештырган ил-дәүләтнең башлыклары да хан дәрәҗәсен кулланырга тиеш булмаганнар. Хәер, Нугай Урдасы биләмәсен элек берара

үз карамагында тоткан атаклы яугир Аксак Тимер дә бит шундый ук хәлдә була – «әмир Тимер» дәрәҗәсен куллану белән чикләнә. Йосыф морзаның бабасы Нуретдин улы Ваккас бәк була. Ваккас үлеп, берникадәр вакыт үткәч, 1480 еллар тирәсеннән, Нугай Урдасы идарәчесе булган бәк вазифасын аның улы – Муса башкара. Муса морзаның тиз арада бәккә әверелүен китап авторы аның бер кызын казакъ ханы Мөхәммәдкә ярәшүенә бәйли. «Муса бәк идарә иткән дәвердә Нугай Урдасы олыслары бердәмлеккә ирешә. Бердәм була», дип тә белдерә автор. Муса бәк 1502 елда вафат була. Ил-йорт белән идарә итүче бәк вазифасы баштарак аның энеләре – Ваккас уллары Ямгырчы (1502–1504) белән Хәсәнгә (1504–1508) йөкләнә...

Муса бәкнең берничә хатыннан туган унҗиде улы исә үз чиратларын көтәләр. (Бу саннар 1995 елда Махачкалада нәшер ителгән «Посольские книги по связям России с Ногайской Ордой» китабында китерелә. Мәскәүдә Казан ханлыгы белән аралашу вакыйгаларын чагылдырган шундый ук контора да булган. Шул илчелек архивында сакланган язмаларны без сирәгрәк кулланабыз.) Сөембикәнең атасы Йосыф морза шул унҗиде ир баланың урта буын вәкиле була. Бәклек тәхете Ваккас балаларыннан бушаганнан соң, Мусаның өлкән буын уллары арасында үзара көрәш башлана. Йосыф морзага идарәче төркем сафына басу чираты 1537 елда гына җитә. (Беренче кияве вафат булып, ике ел үткәч.) Шул елгы морзалар җыелышында Сәет Әхмәт (русча язмаларда ул еш кына Шайдак исемендә теркәлә) бәк буларак танылa. Аның ике туганы – Хаҗи Мөхәммәд белән Мамай морзалар урынбасар буларак билгеләнәләр. Мамай ул вазифаны үтәргә теләмәвен белдергәч, аның урынына Йосыф морза күрсәтелә. Ә ил башлыгы – бәк вазифасын үтәү бәхетенә инде ул 1549 ел урталарында гына ирешәчәк. Мамай морзаның үз олысының үзәктән бик читтә – Әстерхан ханлыгы янәшәсендә булуын һәм әлеге корылтай барганда инде аның Сафагәрәй ханның каенатасы икәнлеген дә әйтеп үтү кирәктер. Бу язмага бәйле вакыйгада да аның өлеше булуы бик ихтимал. Ләкин әле Мамай белән Йосыфның бер анадан булу ихтималы өйрәнелмәгән.

Муса бәкнең өлкән улларыннан берсе – Җанмөхәммәд исемлесе, агалары белән тәхет өчен тарткалашулардан соң булса кирәк, Казанга барып урнаша. «Династия бәйләнешләрен ныгыту максатыннан, ул кардәше Йосыф кызы Сөембикәне Казан ханы Җангалигә кияүгә бирүдә катнаша» дигән фикер дә әйтелә «Татар экциклопедиясе» басмасының 2 нче томында (645 б.) китерелгән белешмәдә. В.Трепавлов китабында да Җанмөхәммәднең үз кешеләре белән Казан ханлыгына күченеп киткәнлеге хәбәр ителә. Дөрес, ул китапта 1530 еллардан соң кайбер Урда вәкилләренең күрше ханлыкларга үзара бердәмлекне ныгыту өчен махсус җибәрелү очраклары булганлыгы да теркәлгән. Мондый арадашлык бигрәк тә күрше Әстерхан ханлыгы белән даими рәвеш ала диярлек. Нугай Урдасы бәк-морзалары анда тәхет биләшү вакыйгаларында да актив катнашалар. Күрше ханлыкларның хөкүмәте рәвешендәге диван әгъзасы буларак теркәлү очраклары да булган, дип хәбәр итә В.Трепавлов. Күрше ханлыкларга күчеп утырган очракта да алар үз олысы кешеләренең бер өлешен һәм үзләренең сак гаскәрен үзләре белән алып китә торган була.

**2**

Җанмөхәммәднең Казанга күчеп килгәнче үк Җангали ханның ата-анасы белән таныш булу ихтималы бар. Чөнки Касыйм ханы Шәех Әүлиярның (?–1516) җәмәгате, булачак ханның анасы Шаһисолтан да Нугай Урдасыннан чыккан килен була. Чыганакларда аның атасы Ибраһим бәк була дип күрсәтелә. Һ.Атласи китабында да ул шул исемдә теркәлгән.

Шәех Әүлияр ханның да бик дәрәҗәле токымнан чыгуын әйтеп үтү кирәктер. Аның бабасы Бәхтияр солтан Алтын Урда мәмләкәтенең соңгы кыйпылчыгы саналган Олы Урда (Бөек Урда) ханы Шәех Әхмәднең бертуганы була. 1502 елда ул ханлык таркатылгач, бу хан варисларының бер өлеше Әстерханга яки Нугай Урдасы тарафына барып сыенырга мәҗбүр була. Шәех Әүлиярның үз олыс-биләме, мөгаен, Мәскәү кенәзлегенә якынрак булгандыр. Ул даулы җирдән качу урыны итеп Мәскәүне сайлый.

Кенәз Иван III аның олыс кешеләренә яшәргә башкаладан утыз-кырык чакрымдагы бер шәһәрне бирә. 1512 елда Касыйм ханлыгы тәхете бушагач, кенәз аны шунда ханлыкка тәкъдим итә. Бу очракта, мөгаен, Шәех Әүлияр бабаларының Касыйм ханлыгын нигезләгән Олуг Мөхәммәд хан вәкилләре белән бер тамырдан чыккан Алтын Урда ханы Тимер Котлык варислары булганлыгы да истә тотылгандыр.

Шаһгали белән Җангали Алтын Урда империясенең соңгы кыйпылчыгы – Олы Урда таркалган шушы буталчык чорда туганнар дип фаразлана. Дөрес, татарча нәшер ителгән күпчелек язмаларда Җангали күпкә яшьрәк итеп күрсәтелә. Һади Атласи һәм башка кайбер тарихчылар ул фикер белән килешми. Күпчелек авторлардан аермалы буларак, үз хезмәтен язганда, Һ.Атласи XIX йөз авторы Николай Новиков хезмәтләрен дә кулланган. XVI йөздә Россиядә яшәгән чит ил дипломаты Сигизмунд Герберштейн язмалары белән дә таныш булган. Австрия дипломатының шул язмалары белән тирәнрәк танышу өчен ул бер язмасында немец телен өйрәнүен дә әйтеп китә. Ә бу дипломат исә үз вакытында Касыйм ханлыгы тәхетен биләгән яшүсмер Шаһгали белән дә, аның энесе белән дә (1525 елда) күрешеп сөйләшкән икән. Шул хакта язып та калдырган. Шаһгалинең шыксыз кыяфәтен иң тәүге тапкыр тасвирлап язучы да шушы дипломат була.

Казанның бәк-морзалары 1531 елда Кырым ханлыгы вәкиле Сафагәрәйне ханлык тәхетеннән куып җибәрә. Тәхет биләргә лаеклы дәрәҗәле шәхес рәвешендә Шәех Әхмәд хан нәселе вәкиле Җангали чакырыла. Тарихчы Сәләм Алишев аңа бу вакытта егерме яшь тулган булырга тиеш дип фаразлый. Мәскәүнең бөек кенәзе Василий да Казанлылар фикерен хуплый. Дистә ел чамасы Касыйм ханлыгы тәхетен биләп торган Җангалине Казанга җибәрергә рөхсәт бирә. Әлбәттә инде, үз киңәшче-ярдәмчеләре белән бергә җибәрә ул аны.

Казан ханлыгы тәхетен 1532 елның июнендә биләгәч тә, Җангали өйләнергә ниятли. Йосыф морза кызы Сөембикәгә өйләнергә теләвен белдереп, рөхсәт алу өчен Мәскәү кенәзенә илчеләр җибәрә. Аннан рөхсәт хаты алынгач та, яучыларын Нугай Урдасына – Җаек тарафына юллый. Һәм шул җәйдә алар өйләнешәләр дә. Бу вакыйгада арадашчыдимче вазифасын үтәүче Урда вәкиле Җанмөхәммәд морза булгандыр, дигән фикер алда әйтелгән иде. Бу чорда Нугай Урдасы белән Казан ханлыгы чикләре хәзерге Оренбург өлкәсе тирәләрендә булган дигән мәгълүмат бар. Шул шәһәрдән көньяк тарафкарак аккан Сакмар-су белән Оренбургны хәзерге Самара белән тоташтыра торган Сәмәр (Самара) елгалары чик буе булган дип фаразлана. Җанмөхәммәд яки башка бер морза җитәкчелегендәге Казан вәкилләре булачак ханбикә Сөембикәне кайсы тарафта каршы алганлыгы турындагы язмалар сакланмаган булса кирәк. Бу киленнең үз хезмәткәрләре һәм сакчылары белән ничә олауга төялеп килү вакыйгасы да хәзергә билгесез. Мәсәлән, бер тарихи язмада Алтын Урданың бер ханы кәләшенең үз бирнәсе һәм якыннары белән утыз арбага төялеп, аларны атка атланган йөзләп сакчының озатып килүе теркәлгән. Ул чорда һәр киленнең туганнары һәм хезмәткәрләре белән бергә «яңа йортка» килеп төпләнү тарихы байтак язмаларда бар. Анда бер үк ханның берничә хатынының үз авылҗәйләүләре булганлыгы да искә алына. Нугай Урдасы төбәгеннән чыккан бәк-морзаларның һәм киленнәрнең җәйләү-авыллары Казанга якын-тирәләрдә урнашкан булгандыр, дип фаразлана. Хәтеремдә әле, 1960 елларда кайбер язучы һәм галимнәр арасында «Дөбьяз төбәге халкы сөйләмендә нугай татарлары йогынтысы чамалана» дигән фикер йөри иде...

Сөембикәне, аның бирнәләрен һәм хезмәткәрләрен Казанга алып килгән дала юлларын да күзалларга тырышыйк. Бу җәһәттән Мәскәү конторасында Нугай Урдасына кагылышлы сакланган бер язмага тукталып китәсе килә. Йосыф морзаның якын туганы («энесе» дип тә язалар) Исмәгыйльнең олыс биләмәсе Урданың көнбатыш чиге буенда Идел тирәләрендә була. Ул Казан ханлыгыннан тыш, Мәскәү кенәзлеге белән дә яхшы мөнәсәбәттә яши. Йосыф морза бервакыт аңа Мәскәү белән араны өзәргә киңәш итеп, хат та яза. Исмәгыйль исә агасына мондыйрак эчтәлекле хат җибәрә. «Син Бохара ханлыгы йогынтысында яшисең, синең сәүдәң шул якка корылган. Ә миңа Мәскәү

якын, минем малларымны шунда бик теләп алалар», дип яза ул. Сөембикәне Казанга озата баручы туй кәрваны да, бәлки, Җаек (хәзерге Урал) елгасы тирәләреннән элекке сәүдәгәрләрнең ямчы юлына төшеп, Исмәгыйль морза биләмәсе аша үткәндер. 1551 елда Сөембикә ханбикә Мәскәүгә озатылгач та, шушы ук Исмәгыйльнең ханбикә һәм аның балаларын азат итү өчен Иван патшага берничә хат юллаганлыгы да мәгълүм...

**3**

Җангалине Казан тәхетен биләргә тәкъдим итүчеләр ханлыкның диван идарәсе башлыгы Булат Ширин белән аның фикердәшләре була, диелә. Шул фикердәшләр төркеменә Ибраһим хан кызы Гәүһәршад та керә. Бу ханбикә башлангыч чорда Җангали ханның якын киңәшчесе рәвешендә дә сурәтләнә. Чөнки аның анасы Фатыйма-Солтан да Нугай Урдасы бәк-морзалары нәселеннән була. (Бу ханбикәне еш кына Ибраһим ханның икенче хатыны Нурсолтан кызы дип тә язалар. Дөрес, Нурсолтан да аңа ана. Ләкин икенче, Җаек төбәге халкы кулланышындагы «биана» гына булырга тиеш.)

Кызганычка, тәхет биләү чорында Җангалинең төп киңәшчесе Мәскәү кенәзлеге вәкиле генә була. Үзен Казанга чакырып китерүчеләр белән бердәм булып эшләп китә алмый ул. Һәм 1535 елның җәй ахырында аны тәхеттән төшерергә карар итәләр. Ул Казаннан алтмыш-җитмеш чакрымнардагы Иске Казан шәһәрчегенә «сөргенгә» җибәрелә. Мөгаен, аның төп утар-җәйләве дә шул тирәдә урнашкан булгандыр. Сентябрь ахырында аның шунда үтерелүе хакында хәбәр алына. Ләкин ул яшь ханны кем үтергәнлеге ачыкланмаган.

Җангали вафат булганнан соң, Сөембикә Чыңгыз хан варисларында кабул ителгән тәртип буенча аның бер туганына кияүгә бирелергә тиеш була. Казан ханнарына нисбәттә дә бу йола-тәртип даими рәвештә үтәлеп килгән. Аны мөселман дөньясында мәҗбүри рәвештә үтәлергә тиешле «левират йоласы» дип тә атыйлар. Җангалинең бердәнбер ир туганы Шаһгалинең (кайбер язмаларда Шәех Гали) кыяфәте күңелгә ятышлы булмау сәбәпле, Сөембикә аңа барудан баш тарткандыр, мөгаен. Аның туганнары, шул исәптән Җанмөхәммәд морза да бу хәлне башкаларга аңлата алганнардыр, күрәсең. Бу вакытта инде Шаһгалинең Фатыйма исемле хатыны булганлыгы да билгеле. Шаһгали кәкре кыска аяклы, шыксыз гәүдәле һәм иләмсез йөзле булса да, сугыш мәйданнарында зур батырлыклар кылган шәхес санала. Мәскәү кенәзлегенең Литвага һәм башка төбәкләргә, шул исәптән Казан ханлыгына каршы оештырылган яуларында ул зур-зур хәрби берәмлекләр белән оста идарә итүче буларак таныла. Ә шәхси тормышта зур уңышларга ирешә алмый. Баласы да булмый...

Сафагәрәй ханның вафат булуы турында хәбәрне алгач та, Йосыф морза аны кызы белән килештерү фикеренә килә. 1549 елның җәй башында ул Мәсәү кенәзе Иван IVкә Шаһгалине Казан тәхетенә билгеләргә, Сөенбикәне ханбикә итәргә кирәк дип, хат юллый: «Минем дустым олуг кенәз Иван... Җангали ханга кызыбызны биреп, кода булышкан идек. Синең дустың, безнең киявебез Җангалине үтерделәр... Хәзерендә Шәех Гали илә дуслыкта һәм якынлыкта буласыбыз, аңа үзебезнең кызыбызны бирәсебез килә. Элек иленнән качкан казанлылар илә Шәех Галине Казан өстенә җибәр. Чапкыныбыз Байсунгар шунда Казан халкына: «Менә сезнең падишагыз, менә сезнең качкан бәк-морзаларыгыз», – дип белдерер, дип яза ул. Әгәр килешмәсәләр, яу оештырылыр, минем гаскәриләр дә синең гаскәреңә булышка килер, дип тә өсти Йосыф морза.

Бу вакыйганың ничек тәмамланганын укучы белә инде. Ул Казан ханлыгының юкка чыгуы белән тәмамлана. Чынлап та, Шаһгали берничә ай дәвамында Казан ханы вазифасын үтәп ала. Мәскәү вәкилен идарәче рәвешендә Казанга кертүгә каршы килүче дә ул була. Ләкин тотрыклылыкка ирешә алмый. Чөнки Мәскәү түрәләре инде бу вакыйганы үзләренчәрәк хәл итәргә уйлаган булалар. Һәм озакламыйча ул уйларын тормышка да ашырачаклар.

1551 елның җәендә Сөембикә берничә якыны һәм балалары белән бергә Мәскәүгә озатылачак. Бу вакыйганы Нугай Урдасы зыялылары бик авыр кабул итә. Йосыф морза,

аның бертуганы Исмәгыйль һәм башка морзалар Сөембикәне һәм аның балаларын үзләренә кайтаруны үтенеп, Иван патша исеменә берничә хат юллыйлар. Араларында бик кызыклы эчтәлекле хатлар да бар. Нугай Урдасы белән Мәскәү арасында илчеләр даими йөреп тора. Ул хатлардагы төп үтенеч, төп янаулар Белек Булат исемле морзаның хатындагычарак яңгырый. «Әгәр дә син сеңлебезне безгә бирмәсәң, ул чагында безгә биргән антыңны бозган буласың!» Исмәгыйльнең дә беренче хаты шундыйрак эчтәлекле була. Менә Иван патшаның Исмәгыйльгә язган җавабының бер өлеше. «Сез миңа Йосыфның кызы Сөен-бикәне сорап, аны үзегезгә җибәрүне үтенгән идегез. Без аны җибәрмәкче булган идек. Шәех Гали хан безгә багынып, Сөен-бикәне үзенә сорады. Ул аның туганы Җангали ханның хатыны булып, сезнең динегез буенча аңа булырга тиешле... Без бикәгә зур сый күрсәтеп, аны Шәех Галигә бирдек». (Хат эчтәлекләре Һади Атласи китабында язылганча китерелә.)

«Бераздан Исмәгыйль морза Җангалинең Шәех Гали асрамасында булган кызын Мөхәммәд исемле углына бирдерүне үтенеп, Иванга икенче хат юллый. Җавап шулай ук: «Без Шәех Гали белән ханбикәне зурлыйбыз… Олыгайгач, бикә улын йортлы итәрбез», рәвешендәрәк тәмамлана. Һ.Атласи китабының 226 битендәге астөшермәдә исә бу кызның Җангали хан баласы икәнлеге, аның Әстерхан ханы Ак Күбәк улы Хәбибуллага бирелгәнлеге белдерелә, диелә.

Инде Әстерхан ханнары тарихын барлаган башка китапны кулга алыйк. Зайцев Игорь Владимировичның шул ханлык тарихына багышланган китабы 2004 һәм 2006 елларда Мәскәүдә басылып чыкты. Анда Ак Күбәк ханның ике мәртәбә Әстерхан ханлыгы тәхетен биләве (1532-1533, 1545–1550), тумыштан Себер ханы Мортаза улы булганлыгы әйтелә. (Ак Күбәк хан турында кыскача мәкалә «Татар энциклопедиясе»нең 1 нче томында да китерелә.) Әстерхан ханлыгы тәхетен биләгән чорында аның Нугай Урдасы бәк-морзалары ярдәменә таянган булуы да чамалана. Бу вакыйгаларда безгә таныш Мамай морзаның катнашу ихтималы да зур. Аның биләмә-олысы Әстерхан янәшәсендә үк булганлыктан, кайвакыт аны шул ханлык вәкиле итеп күрсәтү очраклары да күзгә чалына. Мәсәлән, кайбер хезмәтләрдә аны «Сафагәрәй ханның каенатасы, Әстерхан ханлыгы вәкиле» рәвешендә дә теркиләр. Ак Күбәк исеме 1550 елдан соңгы тарихи язмаларда теркәлмәгән. Аның улы Хәйбулла (русча язмаларда Кайбула) 1552 елның маенда Мәскәү кенәзлегенә барып урнаша. Мәскәүгә килгәч тә, ул Иван патшага Сөембикә ханбикә кызына өйләнергә теләге барлыгын белдерә, рөхсәт итүен үтенә. Иван патша аның гаиләсен Юрьев шәһәренә урнаштыра. Шул ук җәйдә Иван IV «дусты Ак Күбәк ханның улын» үзенә кабул итүе турында Исмәгыйль морзага да хәбәр итә. Хәйбулла Мәскәү тарафыннан оештырылган күпчелек сугышларда катнаша һәм 1570 елда вафат була. «Мергивана белән аларның ике улы – Мортаза белән Арслангали туа. Мортаза чукынгач, Михаил Кайбулловичка әверелә», диелә әлеге китапта. Рус елъязмаларында «Мергивана» рәвешендә төркәлгән исемне хәзер татарчалаштырасы гына кала. Дөрес, XIX йөздә нәшер ителгән башка тарихи хезмәтләрдә бу кыз исеменең башкачарак язылган булуы да ихтимал.

**Лирон ХӘМИДУЛЛИН,**
*ТРның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты*

**Редакциядән:**

*Шушы айда язучы Лирон ага Хәмидуллинга туксан яшь, җәмәгате, язучылар оешмасында чирек гасыр хезмәт иткән Дания ханым белән бергә яшәүләренә илле биш ел тулды. Киләчәктә дә аларга тигез тормыш һәм Лирон агага иҗади уңышлар теләп калабыз!*



*Бергә – гомергә! Лирон Хәмидуллин белән Дания ханым. 1982 ел.*



*«Яшь ленинчы» газетасы (хәзер «Сабантуй» журналы) редакциясендә (сулдан уңга): Госман Садә, Барлас Камалов, Лирон Хәмидуллин, Зөлфәт. 1982 ел.*



*Татар энциклопедиясе институтында эшләгән еллар (сулдан уңга): Фәрит Шәрифуллин, Гомәр Сабирҗанов, Вакыйф Зыятдинов, Алсу Яруллина, Лирон Хәмидуллин, Дания Хәмидуллина, Вакыйф Нуриев, Миргалим Харисов. 2007 ел.*



*Хәмидуллиннар гаиләсе бергә җыелгач. Утыралар (сулдан уңга): оныклары Мансур, Дания ханым, Лирон ага, оныклары Таһир. Арткы рәттә: уллары Булат һәм кызлары Зөһрә. 2000 ел.*



*Лирон Хәмидуллинның 75 яшьлек юбилее мәҗлесендә. Беренче рәттә (сулдан уңга): Дания ханым, оныгы Мансур, Лирон Хәмидуллин, Равил Фәйзуллин; икенче рәттә: Булат Хәмидуллин, Туфан Миңнуллин, Роберт Шәмгунов, Разил Вәлиев, Миркасыйм Госманов. 2007 ел.*



*Лирон Хәмидуллинга Габдулла Тукай премиясен тапшыру тантанасында. Лауреатны ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов, ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, каләмдәшләре котлады. 2020 ел.*



*Казакъстан Президентының тәбрикләү хатын тапшыру вакытында Казандагы вәкиллектә. 2021 ел.*

*Фотолар* **Лирон Хәмидуллинның** *шәхси архивыннан алынды.*

# ШӘРЫК ШАГЫЙРЬЛӘРЕ*

## Кереш сүз урынына

Быелгы 2022 ел – татар әдәбияты һәм әдәбият белеме, гомумән, татар мәдәнияте тарихында гаять зур урын биләп торган ике зур шәхес өчен юбилей еллары. Газиз Гобәйдуллинның тууына 135 ел булса, Гали Рәхимнең тууына 130 ел тула. Аларның тормыш юлы – гомерне фәнгә һәм милләткә багышлау тарихы ул. Туганнар, хезмәттәшләр, фикердәшләр буларак, милләткә хезмәттә иңгә-иң торып атлаган бу шәхесләр фән тарихында да күбрәк янәшә телгә алыналар.

Газиз Салих улы Гобәйдуллин – 1887 елның 26 июнендә, Мөхәммәтгали Мөхәммәтшакир улы Габдерәхимов – 1892 елның 4 ноябрендә сәүдәгәр гаиләсендә туганнар. Аларның әтиләре шәһәрдә билгеле бай Исхак Айтугановның кызларына өйләнгән була: Өммегөлсем – Газизнең, Бибигайшә – Галинең әниләре. Гаилә хәлләре дә охшаш – җитеш, мул тормышта, чын татар тәртипләре хөкем сөргән йортларда аралашып үсәләр. Вакыты җитүгә, Газизне – кайчандыр әтисе укыган кадим «Халидия» (1895–1904), Галине «Мөхәммәдия» (1898–1905) мәдрәсәсенә укырга бирәләр. Зиһенле, акыллы яшүсмерләр укуда алдынгы була. Әмма мәдрәсә белеме генә аларны канәгатьләндерми: өйгә укытучылар чакырып, рус һәм Европа телләрен, әдәбиятларын, тарих, фәлсәфә кебек фәннәрне, гарәп, фарсы, төрек телләрен өйрәнәләр.

Шуннан соң күпмедер вакытка аларның юллары аерыла. Газиз, өйдә әзерләнеп, 3 нче Казан гимназиясен тәмамлау турында аттестат ала һәм Казан император университетына укырга керә (1909-1916). 1907 елдан татар милли матбугатында хикәяләре, фәнни һәм тәнкыйди мәкаләләре басыла башлый. Университетны тәмамлагач, Троицк шәһәренең мәдрәсәләрендә укытып ала һәм 1919 елны Казан университеты аспирантурасына укырга керә.

Галинең әтисе Мөхәммәтшакир, улын да үз эзеннән җибәрергә теләп, 1905 елны аны Казандагы Сәүдә (Коммерция) училищесына керергә күндерә. 1913 елны училищены тәмамлагач исә, Мәскәүдәге Коммерческий институтның икътисад бүлегенә җибәрә. Гали әдәбият һәм фән белән кызыксына, 1909 елны, рус телендәге «Вокруг света» дигән китапка нигезләнеп, мәдрәсәләр өчен «Җир йөзе» дип аталган география дәреслеге бастырып чыгара. Актив рәвештә татар вакытлы матбугатында язышa, беренче шигырьләрен, хикәяләрен, мәкаләләрен яза. Әтисе үлгәннән соң (1917), институтны ташлап, Казанга кайта һәм гомерен гуманитар фәннәргә багышларга карар кыла.

Шундый ук адымны Газиз дә ясаган була: юридик факультетның беренче курсын тәмамлагач, ул үз теләге белән университетның тарих-филология факультетына күчә һәм Н.Н.Фирсов, М.М.Хвостов, Н.Ф.Катановлар җитәкчелегендә төркиләр һәм монголлар тарихын өйрәнә башлый.

Инкыйлабка кадәр Гали белән Газиз, аларның эне-сеңелләре Казан татар яшьләре арасында үзләренең таланты, хөр фикере белән аерылып тора (Газизнең белемле, күп телләр белгән энесе Кадыйр һәм сеңлесе Мәрьям дә университет тәмамлыйлар, беренче татар этнографларыннан булалар). Татарлар оештырган күп кенә милли-мәдәни чараларны башлап йөриләр, аларда катнашалар; Ф.Әмирхан, Г.Тукай, Ә.Хәсәни, Г.Колахмәтов һ.б. татар зыялылары белән аралашып яшиләр. 1907 елда Г.Гобәйдуллинның беренче хикәяләре басыла, 1911 елны Г.Исхакыйның «Ике йөз

* Гали Рәхим. Шәрык шагыйрьләре. Казан: Электро-типография «Милләт», 1919.

елдан соң инкыйраз» әсәре хакындагы күләмле аналитик язмасы татар әдәбияты мәйданына үзенчәлекле фикерле тәнкыйтьче килүне хәбәр итә. Шушы вакыттан ул һәм галим, һәм язучы буларак вакытлы матбугатта даими рәвештә күренә. Әдәби әсәрләре арасында «Бер хыял» (1913), «Җомга көн» (2013), «Әкиятләрдән берсе» (1914), «Вәсвәсә» (1915), «Хәкимә әби» (1915), «Юлдаш эзләгәндә» (1914), һ.б.; тәнкыйди-аналитик язмалардан, «Сәгыйть Рәмиев шигырьләре тугрысында» (1913), «Яшь әдәбиятыбызда – «Яшь йөрәкләр» (1913), күпсанлы рецензияләр; фәнни хезмәтләр буларак, «Сәет Баттал газый» хикәясе тугрысында» (1911), «Иске тел вә миллият» (1913), «Милләтне ничек аңлыйсыз?» (1913), «Мәрҗани хатирәсе» (1914), «Марко Поло хакында бер тәҗрибә» (1915), «Мәрҗанинең голум, фөнүн вә сәнаигъка карашы» (1915), «Мәрҗанинең тарихи хезмәтләре» (1915), «Алтын Урданың эчке корылышы» (1917), «Милләтчелекнең бәгъзе әсаслары» (1917) һ.б. язмалар  – бу мирасның зур булмаган бер өлеше генә. 1918 елда аның мөстәкыйль хикәяләр җыентыгы басылып чыга, 1919 елда тагын бер хикәяләр тупланмасы дөнья күрә.

Гали Рәхим әдәби барышка 1913 елны, күпсанлы хикәяләре белән килеп керә: «Эч пошканда», «Яз әкиятләре», «Хан мәчетендә», «Серле-серле әкият» кебек хикәяләр яңа нәшер ителә башлаган, ләкин татар дөньясында зур шау-шулар уяткан «Аң» журналында тәкъдим ителә. Шул ук елны Г.Рәхим тәнкыйтьтә дә үз сүзен әйтерлек әзерлекле булуын дәлилли. «Аң»да дөнья күргән «Тукаев – халык шагыйре» язмасы аны әдәбият теориясе һәм поэтикада иркен «йөзүче», Европа, рус, шәрык әдәбиятлары тарихын яхшы белүче аналитик итеп күрсәтә. 1914 елны Г. Рәхим «Аң»да «Халык әдәбиятыбызга бер караш» дигән мәкаләләр циклы белән чыга. «Галия» (1914), «Яз әкиятләре» (1913), «Шагыйрь» (1914), «Җиткән кыз» (1915), «Әбү Сәгыйд» (1915), «Хыял дәрьясында» (1915), «Миләүшәләр арасында» (1915), «Ярыш (булган эш)» (1916), «Догаи Сәйфи» (1916) һ.б. хикәяләре кеше психологиясен яхшы белүче прозаик буларак таныта. Ул шигырьләр яза, драматургия өлкәсендә дә үз көчен сынап карый: «Дача кайгысы» (1914) комедиясе, «Җанвар» (1919) драмасы үз вакытында билгеле әсәрләрдән булып, «Сәйяр» труппасы тарафыннан сәхнәгә куела. Татар театр сәнгате хакындагы мәкаләләре аның сәнгать мәсьәләләрендә үзен иркен хис итүе хакында сөйли.

Октябрь инкыйлабыннан соң, Газиз дә, Гали дә Казандагы төрле вузларда, курсларда укыталар, фән белән җитди шөгыльләнәләр, фәнни хезмәтләрен бастыралар. Аларның тирән белеме, күп телләр белүе, энциклопедик мәгълүматлылыгы һәм туктаусыз хезмәттә булып, гомерләренең һәр минутын фәнни эзләнүләргә яки иҗат эшенә багышлавы хакында замандашларының истәлекләрендә сакланып калган.

Г.Гобәйдуллин фәндә, аеруча, тарих һәм әдәбият мәсьәләләре белән ныклап шөгыльләнә. 1918 елда инде ул тарих (төрки-татар тарихы, дин тарихы, Русия тарихы) дәреслекләре нәшер итә. «Идел буенда керәш тарихыннан» (1923), «Пугачёв явында татар-башкортлар» (1923), «Борынгы болгарлар» (1924), «Пугачёв явы» (1924), «Татарларның килеп чыгышы һәм Алтын Урда» (1924), «Татар тарихы» (1925), «История народов СССР в эпоху феодализма» (1931) кебек хезмәтләр аның кызыксыну объектларының гаять колачлы булуын күрсәтеп тора. 1925 елдан башлап Г.Гобәйдуллин азәрбайҗан, үзбәк тарихына, төрки халыкларның борынгы тарихына һәм мәдәниятенә караган эзләнүләр алып бара, хезмәтләр яза.

1917 елдан соң Г.Рәхимнең татар әдәбиятындагы зур әсәрләр хакындагы мәкаләләре пәйда була. Г.Ибраһимовның «Казакъ кызы» романы, К.Насыйри, Г.Гобәйдуллин, Һ.Такташ иҗаты турындагы язмалар әдәби җәмәгатьчелектә зур кызыксыну уята. Бигрәк тә 1925–1932 елларда күпсанлы мәкаләләр, чыгышлар, докладлар авторы буларак, исеме һәрдаим матбугатта яңгырап тора. Галим берничә юнәлештә актив эзләнү алып бара: халык авыз иҗаты әсәрләрен җыю һәм анализлау методикасы; сәнгать, поэтика һәм халык авыз иҗаты бәйләнешләре; сәнгатьнең килеп чыгуы

хакындагы концепцияләр; әдәби иҗат теориясе һәм психология; тарих һәм этнография. Татарстанны өйрәнү җәмгыяте кысаларында милли тарихка караган чыганаклар һәм мәгълүматларны бастырып чыгаруы, әдәбият тарихына караган мәкаләләре, Гыйльми Үзәк кушуы буенча төзегән «Фольклор һәм халык әдәбиятын җыю өчен кулланма» (1926), «Авылны өйрәнү өчен җентекле кулланма-программа» (1930) кебек хезмәтләре дә – шушы кызыксыну-эзләнүләр нәтиҗәсе. Болардан тыш, ул иҗат эшен дә ташламый. Балалар өчен хикәяләр, романслар, «Көзге хикәя» (1918), «Бер шагыйрьнең өйләнүе» кебек хикәяләр, «Идел» (1921) повесте – әдәби мирасының иң затлыларыннан.

Кызганычка каршы, 1917 елда илгә килгән үзгәрешләрне кабул иткән, татар милләтен үстерү-үзгәртү өчен инкыйлабны файдалы дип ышанган мондый шәхесләр язмышы аяныч төгәлләнә. Илдә яңа тәртипләр урнашып бара, ышанычсызлар исемлегенә эләккән Г.Гобәйдуллин гаиләсе белән 1925 елны Бакуга күченергә мәҗбүр була. Ул биредә көнне төнгә ялгап эшли, төрки халыклар өчен заманча гуманитар фән юнәлешләре булдыруга өлеш кертә. 1928 елдан профессор дәрәҗәсенә лаек була, Казан белән дә араны өзми – мондагы зур гыйльми проектларда катнаша.

Г.Гобәйдуллин 1937 елның 18 мартында кулга алына һәм октябрь аенда атып үтерелә. 1957 елның 12 октябрендә реабилитацияләнә.

Гали Рәхимне 1930 елның маенда кулга алалар, ул Ак диңгез – Балтыйк каналында эшли, 1934 елның 22 августында азат ителә. Әмма 1937 елның язында кабат кулга алына. 1940 елның 27 февралендә суд Г.Рәхимне 8 ел концлагерьга җибәрергә хөкем итә. Аннан каты авыру хәлендә кайтып, 1943 елның 3 мартында гүр иясе була. 1958 елның 2 февралендә реабилитацияләнә.

Гали Рәхим һәм Газиз Гобәйдуллин калдырган мирас арасында алар бергәләп әзерләгән фундаменталь «Татар әдәбияты тарихы» хезмәте бар. Төрки халыклар тарихын, фольклорын, күпсанлы чыганакларны өйрәнеп, борынгы кулъязмаларны барлап язылган хезмәт милли сәнгать тарихын чишмә башыннан алып күзәтеп, бәяләп чыгуны күз алдында тотып уйланыла. 1922-1923 елларда «Татар әдәбияты тарихы»ның икенче һәм өченче кисәкләре басылып чыга. 1924 елны беренче кисәге, 1925 елны «Феодализм дәвере» исеме белән кыскартылган икенче басма дөнья күрә.

«Татар әдәбияты тарихы өчен материаллар җыю юлында бер тәҗрибә. Мәдхәл» исеме белән аталган беренче кисәктә рун, уйгыр һәм гарәп язулы гомумтөрки истәлекләр, суфыйчылык һәм аның шәрык әдәбиятына тәэсире, уйгыр, чыгтай, сәлҗүк һәм госманлы әдәбиятлары турында мәгълүматлар бирелә.

«Татар теле һәм әдәбиятының тарихи язмышы», «Идел буенда иң борынгы тел ядкарьләре», «Идел буенда чыгтай әсәрләре», «Идел буенда госманлы әсәрләре» дигән өлешләрне берләштергән икенче кисәктә татар әдәби теленең барлыкка килүе һәм үсүе, борынгы тел ядкарьләре буларак «Коман мәҗмугасе», каберташ язулары, ярлыклар игътибар үзәгенә куела. Рабгузиның «Кыйссас әл-әнбия»се, Сөләйман Бакыргани әсәрләре, «Сөбат әл-гаҗизин», «Кисекбаш китабы», «Сәйфелмөлек» кебек әдәби әсәрләр аерым-аерым тикшерелә.

Өченче кисәк XVII, XVIII, XIX йөзнең беренче яртысында иҗат иткән әдипләр мирасына, аларның әсәрләренә, халык авыз иҗатына, сәяхәтнамәләргә, васыятьнамәләргә күзәтү ясый, татар әдәбиятының зур этапларын бәяләп һәм тикшереп уза.

Хезмәтнең әһәмиятен аңлау өчен, иң беренче чиратта, ул заманда татар әдәбияты тарихының – фән буларак эшләнмәгәнлеген, аның нинди концептуаль нигезгә салыначагы ачыкланмаганлыкны, кайсы дәверләрдән башланырга тиешлеге расланмаганлыкны әйтергә кирәк. Бу юнәлештә Г.Рәхим һәм Г.Газиз – беренче, һәм аларның татар әдәбияты тарихын гомумтөрки мәдәният кысаларында өзлексез барыш итеп тезә алуы гаять зур ачыш, казаныш була. Мондый концептуаль нигезне, әлбәттә, чын мәгънәсендә гыйлем ияләре, һәм Европа, һәм шәрык фәненнән мәгълүматлы шәхесләр генә булдыра алуы шиксез.

Татар тарихы, теле һәм әдәбияты тарихының бүгенге үсеш баскычында без нәкъ менә Г.Рәхим һәм Г.Гобәйдуллиннар концепциясенең дөрес икәнлеген таныйбыз, төрки-татар әдәбияты барышын алар билгеләгән вакыт кысаларында, Орхон-Енисей ташъязмаларыннан башлап өйрәнәбез дә. Шул ук вакытта аларның күп кенә ачышлары XX гасыр дәвамында фәнни әйләнештә булса, күп кенә сукмакларда татарны өйрәнү фәненә үсеп китәр өчен нигез булыр иде дигән үкенеч тә бар.

Үзгәртеп корулар ачкан мөмкинлекләрдән файдаланып, 1990 еллардан башлап Гали Рәхимнең һәм Газиз Гобәйдуллинның исемнәре халыкка кайтты, аерым хезмәтләре, әдәби әсәрләре дөнья күрде.

Гали Рәхимнең кабат басылып чыкмаган хезмәтләре арасында «Шәрык шагыйрьләре» (Казан: Электро-типография «Милләт», 1919) китабы да бар. Укучыларыбызга шушы китапны кирилл хәрефләренә күчереп тәкъдим итәбез.

**Дания ЗАҺИДУЛЛИНА,**
*академик, филология фәннәре докторы*

# ИРАН ШАГЫЙРЬЛӘРЕ

Иранның бөек шагыйрьләреннән Сәгъди, Җәләлетдин Руми, Гомәр Хәйям вә башкаларның исемнәре күп кешегә мәгълүм. Ләкин күбесенчә без аларны – исемнәре, күп булса, тәрҗемәи хәлләре аркылы гына таныйбыз. Безнең арада фарсы теле өйрәнү мәкъбүл булмаганга, үз телебезгә тәрҗемәләр дә юклыкка күрә, иске замандагы шанлы Иранның кыйммәтле әдәбият хәзинәсе безгә ябык була килгән. Бик аз гына, беркадәр күбрәк муллалар, бу хәзинәдән файдаланганнар; Иран шагыйрьләрен укып, ләззәт алганнар. Бу әдәбият исә – чынлап та бөек һәм парлак, ул бик күптәннән бирле Европалыларны үзенә гашыйк иткән; бөек Гёте да иран әдәбиятын сөючеләрдән булып, берничә мәртәбә Европалыларны шәех Хафиз белән таныштырган. Хәзер Гареб галәмендә бу әдәбиятның мәхбүбләре[1] бик күп. Хәтта аны җыю өчен ачылган махсус сагаидләр[2] дә юк түгел.

Иран әдәбиятының иң парлак заманы унынчы гасыр милади, унбишенче гасыр арасында (хәзерге 3–9 гасыр) булган. Иң шөһрәтле иран шагыйрьләре шушы биш йөз ел эчендә җитешкәннәр.

Бөтен иран әдәбияты, бигрәк тә лирикасы, суфилык яде белән сугарылган. Ислам шәркында тамыр җәеп, ахырда ислам мәдәнияте кырыйга йөз тоту уена, сүнү уена иң зур сәбәпләрдән берсе булган суфилык мөселман дөньясына башлап иранлылар аркылы кергән. Дини хискә буялган бу фәлсәфә мәзһәб инсаннарны дөньяны куярга, дөньяви рәхәтләрдән, ләззәтләрдән бизәргә өнди; дөньяви тормыштан ваз кичеп, турыдан-туры Алла белән галәкане идеал итеп куя. Суфи Аллага коры гыйбадәт белән генә канәгатьләнми, ул аңар гашыйк; аның юлында, аңар ирешү, күңел белән аңар тартышу өчен ул бөтен нәрсәне корбан итә; чөнки Алласына булган гыйшкы суфи күз алдында бөтен дөнья ләззәтләреннән кадерле; мәхбүбәнең гыйшкы, шәрабнең биргән исереклеге аның каршында һич юк булып калалар. Ләкин без Иранның суфи шагыйрьләрен укыганда аларның шигырьләре дөньяви, хәтта шәһвәти хисләр, тән рәхәтенә, тән ләззәтенә сәна[3] уку белән тулы булуын күрербез. Бу соң ни өчен шулай? Суфилар моны үзләренчә аңлыйлар: суфи шагыйрь гөлне, шәрабне, исереклекне, мәхбүбәнең гыйшкын, аның аһу күзләрен, үбешләрен, кочышларын мәдехләп шигырьләр яза икән, ул бу нәрсәләрне чын үз мәгънәләрендә алмый, бу

[1] Мәхбүб – яратучы.
[2] Сагаид – үзәк.
[3] Сәна – мактау.

аның каршында тик бер әдәби форма, киная – аллегория генә. Ул дөньяви ләззәтләр хакында сөйләсә дә, аңлаган кеше моннан суфиның Аллага булган гыйшкы аркасында килгән илһамыннан алган рәхәтен аңларга тиеш. Шунлыктан тәсауф[4] мәзһәбендә булган иран шагыйрьләре үзенең шигырьләрендә бер дә курыкмыйча мәгъшукасын мактый, исереклеген һәм аның биргән рәхәтен иң матур буяуларда тасвир итә. Ләкин шул шигырьләр иң тәкъва суфиларның да дини хисләрен рәнҗетми, бәлки аңар рухани тойгылар, тәсауф фикерләре бирә; чөнки ул бу шигырьләрдән башка мәгънә аңлый, аларны үзенчә, суфиларча тәэвил итә[5]. Гади кешеләр исә шул ук шигырьләрне гади мәгънәсендә аңлап укыйлар, шул ук шигырьләр аларга бөтенләй башка – дөньяви – хисләр бирәләр. Менә иран шагыйрьләренең бөтен сере шунда. Аларның һәрбер сыйныф арасында мәкъбул булуын шушы ноктаи назардан[6] карап кына аңларга мөмкин. Ләкин, чынлап та, һәммә иран шагыйрьләре үзләренең шигырьләрен шул ноктаи назардан карап кына язганнармы, әллә юкса шул «ике мәгънәлелек» калканы артына яшеренеп, чып-чын дөньяви шигырьләр дә язгалаганнармы – бу бик чуалчык һәм шөбһәле мәсьәлә. Чынлап та, аларның бик күп шигырьләрендә шул кадәр ап-ачык «дөньявилык» сизелә дә, аларның тәсауф ноктасыннан гына карап язылулары хакында уйлаганда, тәмам аптырап, шашып калырга туры килә...

1914 нче елда рус матбугат базарына мөстәшрәф[7] Крымскийның тәхет тәхрирендә[8] «Персидские лирики» наменда кечкенә генә бер китап чыкты. Бу мәҗмугада матуфи академик Корш һәм аның шәкерте Умов каләмнәре белән Иранның мәшһүр шагыйрьләреннән тәрҗемә ителгән нәмунәләр җыелган. Бу мәҗмуганы укып чыгу мине, үземнең фарсы телен белмәвем өчен, чын күңелдән тәэссеф итәргә[9] мәҗбүр итте. Һәм анда басылган шигырьләрдән бәгъзеләрен тәрҗемә итеп, татар укучысы күз алдына ташларга җөрьәт иттерде. Минем кылган тәрҗемәләрем бик иттифакый[10] сайланган (мин үз күңелемә иң ошаган шигырьләрне генә сайлап алып тәрҗемә иттем). Түбәндә китерелгән шигырьләр шагыйрьләрнең характерын укучы алдында, әлбәттә, тәмамә ачып күрсәтә алмыйлар. Чөнки моның өчен Корш мәҗмугасындагы нәмунәләр генә дә кафи[11] түгел. Һәрбер даһи шагыйрьләрнеке күк, бу шагыйрьләренең дә дәверләре бик киң. Мәүзугълары[12] да, шигырьләрендәге фикерләре дә бик төрле. Аларның куәи иҗадиясенең[13] характеры бер-ике иттифакый алынган шигырьләр аркылы гына аңлашылу ихтималы юк. Минем аларны матбугатка чыгарудан максудым тик Иран әдәбиятындагы шул безгә күптән белергә тиешле булган шәрык әдәбияты бакчасындагы нәфис чәчәкләрнең исләрен әдәбият мөхибләренең[14] борыннарына сиздерү, анда булган бәһасез алмасларның нурлары белән күзләрен кытыклау гына. Тәрҗемә икенче тел аркылы булганлыктан, үзем дә тәрҗемә кылганда, русчасына хәрфия муаффәкыять итмичә, бары тик шигырьнең асыл фикерен һәм төп рухын гына югалтмаска тырышканлыгымнан, шигырьләрнең фарсы оригиналларына караганда озынлык-кыскалык һәм ифадә[15] җәһәтеннән шактый гына аермалы булулары ихтималдыр дип уйлыйм. Шулай ук шигырьләремнең бәгъзеләрендә вәзен[16] вә кафия[17] ягыннан кайбер җитешсезлекләр булуын игътираф итәм[18]. Шулай булса да, тәрҗемә ителгән әйберләремне аерып калдырмый, бергә ябештереп чыгарырга теләгәнлегемнән, мин андыйларын да төшереп калдырмадым.

Хафиз шигырьләренең кайберләрен мин рус шагыйре Феттан алдым. Фет исә үзе немесчәдән тәрҗемә кылган. Минем аның аркылы иткән тәрҗемәләрем бер телдән ике тел аша дүртенче телгә авыштыру булганга, аларның фарсыча асылларыннан байтак ук ераклашулары табигый. Ләкин хәләлендә шагыйрьнең аңлатырга теләгән мәгънәләре югалмагандыр дип зан итәм. Фет аркылы кылынган тәрҗемәләр сызык астына төшереп күрсәтелделәр. Корш тәрҗемәсендә булмаган шигырьләр генә Фетныкыннан алынды.

**Гали РӘХИМ**

## Хафиз[19]

Иран шагыйрьләренең иң бөекләреннән саналган шәех Хафиз Ширази милади ундүртенче – һиҗри сигезенче гасырда җәнүби[20] Иранның мәшһүр Шираз шәһәрендә туып, шунда гомерен үткәргән, гомумән, ике ислам шәркында, гали әл хосусый шәрык әдәбиятларында бу шәһәр һавасының хушлыгы, гөлләре, былбыллары һәм шәрабы белән шөһрәт тоткан иде. Хафиз заманына кадәр Шираз төрек-татар сиәләсеннән[21] булган хөкемдарлар кул астында булган. Хафизның ахыр гомеренә таба бу силәлә тәхеттән куылып, Шираз чын иранлы Закириләр силәләсеннән, Дәшаэ тәхет тозагына төшкән иде. Шагыйрьне һәр ике силәләдән булган хөкемдарлар үзләренә якын кылдылар. Хафиз аларның һәр икесенең сараенда зур илтифатка заһир булды. Аларны мәдехләп, шигырьләр язды. Ләкин аның казанган шөһрәте ул шигырьләре аркылы түгел, бәлки гомумән, мәүзугъдәге «газәлләре» беләндер. Аның шигырьләре «диване Хафиз» наме белән мәшһүр мәҗмугадә җыелган. Хафиз – чын халык шагыйре; аның шигырьләре хәзердә дә иранлылар арасында гади халык җырлары шикелле җырланып йөриләр.

Бу китаптагы тәртип буенча Хафизның 1, 3, 5, 7 һәм 11 нче шигырьләре – Корш аркылы, 4, 6, 7, 9 нчы һәм 10 нчылары Фет аркылы тәрҗемә ителделәр.

### Газәл

Сөеклемнең хуш исләрен гөлләремә аңкытып син
Кай өлкәдән, кай илләрдән, саба җилкәй, исәсең?
Сиңа рәхмәт укыйм... Ләкин аның бөдрә чәчилән
Шаярырга, әдәпсез син, ничек җөрьәт итәсең?
Гүзәлемне бикләр гөлгә охшатмакчы булабыз:
Чәнечкелеме гөлгә соң аның төсле булырга!
Лалә[22] димсең... Лаләгәме булырга тиң аңарга?
Чәчәкләрен атар-атмас тота ул йөз корырга.
Сиңамы соң, әйа нәркис[23], охшарга күзләренә;
Бу нурлы, дәртле күзләр бит сиңа килми якын да.
Һаваланмак килешми һич, буең берлә, әй сәрви,
Синең янда аның зифа буе булган чагында.

### Кыйтга

Әгәр дә мин түгәрәк күл булып,
Шунда йөзгән аккош син булсаң?
Челтерәп аккан чишмә мин булып,
Кырыйда үскән камыш син булсаң!
Гөл чәчәкнең куагы мин булып,
Шунда үскән ал гөл син булсаң!
Җирдә яткан өрек мин булып,
Чүпләүчесе – былбыл, син булсаң.

### Фазыл (кафиясез)

Дөньядагы барча матурларның
Шаһы булырлыкка лаек син;
Алар йолдыз булса күк йөзендә,

[19] Шәмседдин Мөхәммәд Хафиз Ширази (1321-1389/1390) – фарсы шигъриятенең классик үрнәкләрен тудырган мәшһүр суфи шагыйрь, суфичыл поэзия кануннарын тудыручылардан.
[20] Җәнүби – көньяк.
[21] Силәлә – нәсел мәгънәсендә.
[22] Лалә – тюльпан (Г.Р.искәрмәсе).
[23] Нәркис – нарцисс (Г.Р.искәрмәсе).

Айга тиңләнмәгә лаек син.
Җимешләрдән татлы иреннәрең,
Авызларың зәмзәм чишмәсе,
Чәчләрең нәкъ көзге караңгы төн,
Күзләрең дә кара сөрмәле.
Йөзең синең күзне чагылдыра,
Якты көндә нурлы кояш күк,
Синең гүзәл йөзең каршысында
Башкаларның сула йөзләре.
Дөньядагы барча гүзәлләргә
Солтан булганлыкка лаек син;
Күк йөзендә кызлар йолдыз булса,
Айга тиңләнмәгә лаек син.

## Кыйтга

Кап-караңгы төн буенча мин янамын шәм кебек,
Көн кебек син ялтырыйсың бу җиһанга ямь түгеп.
Син генә ян, син генә яктыр, гүзәлем, нурланып;
Мин чыдамам, күз нурыңнан мин сүнәрмен хурланып...

## Газәл (кафиясез)

Гөл өзмәгә теләп бер заманны
Кергән идем гөл бакчага мин;
Ишеттем мин аның шул чагында
Сандугачның мәхзун авазын:
Ул да, мескен, гашыйк булган икән
Минем төсле, гүзәл бер гөлгә.
Тирән уйга талып йөрдем шунда
Башым түбән салып кайгыдан,
Кызганычлы хәлен бу былбылның
Күп уйладым шунда йөргәндә.
Нигә соң гөл болай чәнечкеле?
Нигә былбыл аңа гашыйк соң?
Явыз тәкъдир нигә соң аларга
Кавышырга ирек бирмәгән?...
Сүнәргәме мәҗбүр булыр инде
Сандугачның янган йөрәге?
Әллә ташлар микән бер заманны
Бу гүзәл гөл вафасызлыгын?
Йөрәгемне минем яралады
Былбыл бичараның аһлары;
Мин гашыйкның күңлен шул вакытны
Тынычсызлык килеп каплады.
Хисапсыз күп гөлләр бу бакчада
Чәнечкеле алар һәммәсе;
Вафасызлык ялгыз хөкем сөрә,
Юк шул бәхет явыз дөньяда.

## Газәл

Хозур кыл, шатлан инде, сайра, былбыл:
Вазаларда чәчәк атты кызыл гөл;

Ачылды инде күңелеңнең йозагы;
Хәтәр түгел сиңа аучы тозагы,
Халяс булдың лачынның тырнагыннан,
Котылдың син еланның да угыннан.
Чәнечкесе кадалыр тик гөлеңнең,
Каның агызыр синең ул күкрәгеңнең.
Каның саркып агып беткәч үләрсең,
Ләкин шунда да сайрарсың, көләрсең.
Әҗәл биргән өчен инде син, былбыл,
Ходаңа тик шөкер сәҗдәсе кылгыл.

## Кыйтга[24]

Тәкъдирләр алдан язылган булгач,
Инде нишлим мин?
Шәраб эчмәгә тәкъдир кушкачтын,
Инде нишлим мин?
Арсланга – чүл,
Урман – кошларга
Билгеләнгән бит,
Тәкъдир Хафизга мәйханә биргәч,
Инде нишлим мин?

## Газәл

Әйа, сакый[25], теркелдәң, шәрабтан тизрәк китер син,
Берәр-икешәр кадәч тутырып шәрабыңны китер син!
Яшен-картын аермыйча куәт-гайрәт бирүче,
Гыйшык утын басучы шул суыңны тиз китер син?
Шәраб безгә кояш күк ул, кадәч тә нурлы ай күк,
Кояш нурын кочаклаган гүзәл айны китер син!
Кеше гакылы үҗәт бит ул; – аны баглап куярга
Бау урынына «шәраб» атлы ефәк җепләр китер син!
Эчемдә янган утны мин шуның белән басыймчы,
Ки дәрья дулкыны төсле сыек ялкын китер син!
Чәчәкле гөлләрең шиңсә, аларга «әлвидагъ» дип!
Эчендә гөл күренгән саф эчемлекне китер син!
Әгәр дә сайравыннан туктаса былбыл, ни булган?
Шешә авызында сайраган шәрабны фәна китер син!
Үтеп киткән гомер хакында уйлауны куеп тор!
Да сорнай белән сазның моң авазын китер син!
Төшемдә генә насыйп миңа күрү сөйгән ярымны? –
Тынычлап йоклата торган дәваны тиз китер син!
Мин исерек әйттем: ләкин дә югалтыр чын гакылны
Тагын өч-дүрт кадәч тутырып шәрабыңны китер син!

## Газәл (кафиясез)

Әгәр дә һич сәбәпсез мин боексам,
Әгәр басса җанымны кайгы-хәсрәт.
Башым һәм авыруга сапса сәбәпсез,
Әгәр дә сызлый башласа сөякләр,

[24] Бу китапта «кыйтга» шәрык әдәбияты истилахындагы мәгънәсендә түгел, бәлки бөтеннән җөз (отрывок) мәгънәсендә алынды (Г.Р. искәрмәсе).
[25] Сакый – мәйханәләрдә шәраб ташучы (Г.Р.искәрмәсе).

Бирә күрмә миңа тәмсез дару һич:
Яратмыйм мин табибларның дәвасын.
Сәламәтлек теләсәң син миңа, дус,
Кадәч тутырып, шәрабны китер тиз.
Китер тизрәк сазыңны, сорнаеңны,
Китер монда годеңне, танбурыңны;
Әгәр инде кяр[26] итмәсә алар да,
Якут төсле ал иренне китер син;
Тимәс булса аларның да шифасы
Хафизга һич дәва юктыр, диең син.

## Газәл

Кабак алдында аунаган бу башка
Төшә калса горурлы күз карашы,
Аягың берлә типмә син аңарга:
Булыр ул тик минем языклы башым.
Күңелдән гәрчә хур күрсәң дә, дустым,
Хәкарәт итмә син, зинһар, сүзең илә;
Хәлемне аңла да читтән узып кит:
Хафизның ихтыяры юк үзендә.
Кабак бусагасындагы тузаннан
Аның бит фани гәүдәсе яралган.
Шуңарга ул разаләткә дә төшкән,
Йөзе дә һәм шуңарга гына каралган.

## Газәл

Әсирлеккә сатылса да, Йосыф кайтыр Кәнгангә –
Кайгырма син!
Күз яше күп түгелсә дә, җирдә гөлләр үсәр әле –
Кайгырма син!
Мескен күңел! Киләчәктә хозур көннәр булыр әле –
Кайгырма син!
Гакылсызлык мәңгелеккә башны каплап тормас әле –
Кайгырма син!
Тагын килер шатлыклы яз, утыртыр ул җир йөзенә
Яшел тәхтен;
Саргайса да, табар былбыл кызыл гөлдә кызыл каннар –
Кайгырма син!
Өмидсезлеккә батма һич, аңлый алмыйм дөньяның мин
Серләрен, дип:
Бу дөньяда син белмәгән гаҗәибләр хисапсыз бит –
Кайгырма син!
Кәгъбәне син зуаф өчен юлга чыккач адашсаң да,
Чүлгә кереп,
Чәнечкеле агачларга буталса да аякларың –
Кайгырма син!
Фәнаң гәрчә безнең теләгәнгә хилаф әйләсә дә,
Моңар кадәр
Һаман михнәт кенә чигеп тормый кеше бу дөньяда –
Кайгырма син!

[26] Кяр – тәэсир.

Бәхетсезлек силе ташып, сине төпкә батырмага
Уйласа да,
Дәрьяларда йөзгән вакыт көймәчең «Нух» булган чактыр,
Кайгырма син!
Юллар нинди куркынычлы, нинди озак булсалар да,
Ахрысында
Кайчан да бер вакыт туктап ял итәрсең бәдиһи[27] дип –
Кайгырма син!
Сөйгәнеңнән аерылсаң да, дошманнардан җәфа күрсәң дә,
Син һаман,
Барчасы бит мәгълүм диең тәкъдирләрнең патшасына –
Кайгырма син!
Әя, Хафиз, гамь чикмә һич кара төннәрдә суффәндә
Ялгызлыкта:
Алда тәсбих, кулда Коръән булган чакта, һич вакыт
Кайгырма син!

## Газәл[28]

Без, шәех Хафиз һәм аның яраннары – дәрвишләр, кызык кешеләр без: риазәт[29] чигеп, дөньяның авырлыкларын аркабызда ташыйбыз. Зарланабыз, сыкранабыз; шуның белән бергә үк безнең күңелләр шат; күзебездән яшьләр тамса да. Йөрәкләребез янып торган шәм күк якты; янган шәм күк эрибез, ләкин әтрафка шатлыклы нур чәчәбез, бәхетлеләрчә елмаябыз. Мәгъшуканың кара керфекләре кальбебезне канга сусаган хәнҗәрләр күк яралыйлар; ләкин без шул җәрәхәтләрнең газабы белән генә дә дөньяда яшибез, шулар аркасында гөнаһ диңгезенә дә чумабыз шул.

Тәүбә дигән нәрсә безгә мәгълүм түгел; без аны белмибез. Шулай булса да, күңелебездә явызлыкның әсәре дә юк. Һаман да яктылык балалары булып калабыз, золмәт таныш түгел безгә. Шуңар күрә дә халык безне аңлый алмый. Чөнки халык ул өч кенә төрле кешене таный: беренчесе – тыштан мөтәгассыйб[30], эчтән кара күңелле монафикъ[31], икенчесе – үз рәхәте өчен генә тора торган фәсыйк[32], өченчесе – иң гади, урта юл белән баручы инсан. Шуның өчен дә безнең шикеллеләргә ул исем дә таба алмый, аңламый да.

## Газәл

Ачуланма безгә, мөҗтәһид[33], каш җыерма әхлактан дәрес бирүче хуаҗә! Без дөньяда бары рәхәт кенә эзлибез, бу соң гөнаһмы инде?

Тия сахрасында адашкан бәни Исраил төсле, риазәттән ачыктык та, Ходадан татлы нигъмәтләр сорыйбыз, бу соң гөнаһмыни инде?

Дөрес, мәйханәче карт – безнең дустыбыз; без моны һич кемнән яшермичә, бөтен халык алдында икърар итәбез, чөнки без монафикълар түгел. Монафикъ булмау гөнаһмыни инде?

Без, башкалар күк, сугышларда гөнаһсыз адәм канын коймыйбыз – без тик йөзем җимешенең генә канын агызабыз. Бу соң гөнаһмыни инде?

Без күңел хәзинәләребезне ачабыз да, андагы энҗеләрне гыйш–гыйшрәт юлына юмарт кул белән чәчәбез, юмартлык гөнаһмыни инде?

---

[27] Бәдиһи – билгеле.
[28] Гаҗәземне икърар итеп бу газәлләрне нәсер белән тәрҗемә иттем. Аларның 3,4,5 нчесе һәм 6 нчысы мөстәшрикъ Корш аркылы, калганнары рус шагыйре Фет аркылы тәрҗемә ителделәр (*Г.Р. искәрмәсе*).
[29] Риазәт – теләкләрне тыеп тору, ашау һәм эчүдә чикләнгәнлек (аскетлык).
[30] Мөтәгассыйб – фанатик.
[31] Монафикъ – икейөзле.
[32] Фәсыйк – имансыз.
[33] Мөҗтәһид – тырышучы, юл яручы.

Без мәхбүбәне мактап шигырьләр язабыз; бәлки моның өчен безне киләчәктә шөһрәт көтә торгандыр.... Уйлап карагыз: бу соң гөнаһмыни инде?

Син, теләсәң, ишәк төсле гомерең буенча авыр йөкләр астында арканны бөк, без исә бөтен авырлыкларны өстебездән ташларга гына тырышабыз, бу соң гөнаһмыни инде?

## Газәл

Күкрәгемдә гөл, кулымда кадәч, янымда гүзәл яр булганда, шаһларның шаһы да иң түбән бер кол белән бәрабәр минем өчен!

Безнең төнге мәҗлесебезгә чыраглар китереп маташмагыз: арабызда «яр» булганда, безгә башка якты кирәкми, чөнки мәҗлесне нурландыру өчен аның йөзендәге яктылык кафи.

Йөзем чукларының исереклек бирә торган суына безнең игътикадыбыз[34] хилаф түгел, таки аны эчүчегә асла куркыныч юк. Ләкин синсез эчелгән шәраб та харам ул. Хәтта хуш исле гөлне иснәү дә синсез гөнаһ безгә.

Гуд агачлары яндырмагыз бу мәҗлестә, хушбуйлар аңкытып та азапланмагыз; һич кирәге юк! Синең чәчләреңнең аңкыткан хуш исләре каршында дөнья хушбуйларының катрә кадәр кыйммәте юк бит соң!

Колакларым минем гуд, сорнай нәгъмәләрен, сазның моңлы авазын гына тыңлыйлар; синең якут иреннәреңнән башка, кадәчләрнең кулдан кулга йөрүенә башка һичбер нәрсә күренми минем күземә бу чакта.

Шулай ук, бу мәҗлестә затлы нигъмәтләрнең ләззәтеннән бәхәс итү дә бикяр эш, кирәк шунда алар әллә нинди ерак җирләрдән китерелгән булмасыннар; чөнки минем каршымда синең татлы иреннәрең – мин алардан кәүсәр сулары суырам. Оҗмахның бөтен нигъмәтләләрен тәнавел итәм[35].

Бушаган күңелемнең төбендә бары ялгыз синең кайгың гына хәзинә шикелле сакланып калганга кадәр, мин бөтен гомеремне исерекләр белән бергә мәйханәләрдә утырып уздырачакмын.

Нигә инде син, юкка, ризалә[36] хакында сүз ачасың? Минем ризаләтем минем шөһрәтемнең терәге ул! Нигә син миңа шөһрәтемне сакларга кушасың? Минем өчен шөһрәт ризаләтнең чишмәсе генә бит ул?

Дөрес, сезнеңчә, җүләрләр, тибкечләр, михнәт тастымаллары инде; инсанлык шаэненә[37] дә лаек булмаган адәмнәр инде без... Ләкин уйлап карасагызчы: замана балалары арасында безнең шикеллеләрне күпме таба алырсыз икән соң?

Зинһар, урам сакчысын миңа яхшылыкның мисалы итеп күрсәтмәгез. Безнең ишеләргә гыйфрит төсле күз уйнатуына карап кына бит, элек аның изгелеге хакында хөкем итеп булмый: белсәгез, үзе дә эченнән кая яшеренеп эчү турысында гына уйлый торгандыр ул.

Әй, Хафиз, вакытыңның кадерен бел дә мәхәббәттән һәм шәрабтан һичбер вакыт качма: риазәт заманы кичте инде, гөл һәм ясмин чәчәкләренә чолганып яз килеп җитте...

*(Ахыры киләсе санда.)*

[34] Игътикад – ышану.
[35] Тәнавел итү – татып карау.
[36] Ризалә – түбәнлек, хурлык, яманлык.
[37] Шаэн – дәрәҗә.

# МӘХКӘМӘИ ШӘРГЫЯ ОЕШУ

## «Мәгърифәтле монархия»нең мөселманнарга карата сәясәте

XVIII гасыр уртасында Идел буе мөселманнарына карата хакимият һәм Рус православие чиркәве тарафыннан алып барылган чукындыру сәясәтенә каршы торуда татарлар җиңеп чыга. Бу җиңү хакимиятнең мөселманнарның төрле социаль катламнары белән хезмәттәшлек итә башлавында чагылыш таба. Яңа сәясәтнең нигезләре һәм төп принциплары XVIII йөзнең соңгы өч дистә елында формалаша һәм, нигездә, зур үзгәрешләрсез 1917 елга кадәр дәвам итә. Бу вакыйгалар император Екатерина II (1762–1796) шәхесенә һәм ул алып барган сәясәткә бәйле.

Екатерина II идарә иткән елларда Европа йогынтысы, либераль идеология тагын да көчәя. Сәясәттә дөньяви элементлар арта. 1764 елда Екатерина II Рус православие чиркәвенең һәм монастырьларының җирләрен һәм крестьяннарын дәүләт файдасына тартып ала, аларны башта икътисад коллегиясенә, ә 1786 елдан казна карамагына күчерә.

Екатерина IIнең 1784 ел 22 февраль Указы Идел буенда яшәгән мөселман динендәге «чабаталы морзаларга», тиешле документлар белән затлы нәселдән чыгышларын расласалар, дворян булып язылырга хокук бирә. Шул рәвешле хөкүмәт татар халкының элита вәкилләре белән яңа мөнәсәбәтләрен рәсмиләштерә.

Әле Екатерина IIгә кадәр үк хөкүмәт, рус эшмәкәрләре Урта Азия ханлыклары белән халыкара кәрван сәүдәсен оештыра алмагач, бу хезмәткә татар крестьяннарын һәм сәүдәгәрләрен җәлеп иткән була. Урта Азия белән сәүдә өчен корылган Оренбург, Троицк, Верхнеуральск, Җидепулат (Семипалатинск) кебек кирмәннәр янындагы Меновой дворлар янында татар бистәләре барлыкка килә. Иң зур татар сәүдәгәрләре колониясе 1745 елда Оренбургтан 18 чакрымдагы Каргалы елгасы буенда нигезләнгән Сәет бистәсендә формалаша. Урта Азиядән кайтарылган арзанлы мамык татар эшмәкәрләренә Казан тирәсендәге мануфактураларында – комач, казакъ даласы терлекләре ит тозлау, май эретү, сабын җитештерү, тире эшкәртү мануфактуралары ачарга мөмкинлек бирә. Иң мөһиме: эшмәкәрләр татарның дини һәм мәдәни үсешен финанслый башлыйлар – мәктәп-мәдрәсәләргә, голәмәләргә матди ярдәм итәләр, мәчетләр төзиләр һ.б. Урта Азия һәм Казакъ даласында сәүдә итү юлы белән баеган татар эшмәкәрләре, 1775 елда сәүдәгәрләр катламы оешкач, гильдияләргә язылып, Россия җәмгыятендә ярымөстенлекле катлам вәкилләре булып китәләр.

Яңалыклар социаль өлкәләрдә генә түгел, ә дәүләт белән ислам дине арасында мөнәсәбәттә дә ачык чагылыш таба: актив христианлаштыру сәясәте толерантлык ягына үзгәрә.

«Мәгърифәтле монархия»нең идеологы илдә – тәртипне, җәмгыятьтә һәм шәхси әхлак нормаларын саклау чарасын диндә күрә.

Империя хакимияте белән Идел буе мөселманнары арасында мөнәсәбәтләрне җайга салуда Екатерина IIнең беренче адымы булып, 1764 елны «Яңа чукындырылганнар эшләре конторасы»н таркату тора. Шулай итеп, православие чиркәвенең мөселман җәмгыятъләренең көндәлек дини тормышына кысылуы нык кими (*Ислаев Ф.Г. Ислам и православие в Поволжье в XVIII в.: от конфронтации к терпимости. Казань, 2001.* С. 176-*177, 214)*. Ләкин чукындыру кампаниясе халык күңелендә рус хакимиятенә ышанмау, аның һәр яңалыгын, реформасын мөселманнарга каршы юнәлтелгән, алдау юлы белән аларны чукындырырга омтылыш дигән берьяклы кабул итүгә сәбәп була.

Екатерина IIнең Идел буйлап сәяхәте вакытында Казанда ике таш мәчет төзергә телдән рөхсәт әйтелә. Әлеге хәл бистәдә яшәүче татарлар белән епархия җитәкчелеге арасында каршылык китереп чыгара. Бу каршылыкны хәл итү өчен Екатерина II 1773 елның 17 июнендә «Барлык диннәргә карата түземлелек һәм православие дине архиерейларына башка диннәр эшләренә, шул исәптән аларның гыйбадәтханәләрен төзүгә дә кысылмау, бу эшләрне дөньяви хакимият кулына тапшыру» турында Указ – беренче тапкыр империядә исламга карата толерантлык сәясәтен игълан итә; дәүләт һәм ислам дине, православие чиркәве һәм мөселманнар мөнәсәбәтләрендә яңа тәртип урнаштыра; җирле хакимияткә төрле дин тотучылар арасында «мәхәббәт, тынычлык һәм үзара аңлашып яшәү» хөкем сөрүен тәэмин итү бурычы куя.

1783 елны хөкүмәт мәхәлләләрдә ислам дин әһелләренең фәкать Россиядә яшәүче мөселманнардан булуын таләп итә башлый. *(Загидуллин И.К. Исламские институты в Российской империи: Мечети в европейской части России и Сибири. Казань, 2007. С. 62–73).*

XVIII йөзнең соңгы утыз елында Кырымны яулап алу, Польшаны бүлү, Россиянең Кара диңгездә ныгуы, аның Казакъ җөзләрендә сәяси йогынтысы көчәю һ.б. факторлар империядә дини мәсьәләгә халыкара төсмер бирә. Яңа шартларда төрле конфессия вәкилләренә карата дини сәясәтнең уртак принципларын эшләү, православие динендә булмаган халыкның дин эшләре белән идарә итү тәртибен һәм алар өстеннән дәүләт күзәтүен булдыру сорала.

Беренче модель Идел (Казан, Түбән Новгород, Әстерхан губерналары) һәм Себердә формалаша. 1764 елда «Яңа чукындырылганнар эшләре конторасы»н тараткач, христианлаштыру сәясәте һәм 3 елга салымнардан азат итү льготасы саклана, тик хәзер христианлаштыру сәясәте Рус православ чиркәве көче белән генә үткәрелә башлый, нык йомшый.

Авылда ревизия мәгълүматлары буенча 200–300 ир-ат яшәсә, яңа мәчет төзергә рөхсәт бирелә. Кечерәк авыл җәмгыятьләре күршеләрендәге тагын да кечерәк торак пунктларында яшәгән дин кардәшләрен исемлеккә кертү юлы белән мәхәлләдәге мөселманнар санын канун таләп иткән күләмгә җиткереп, яңа мәчетләр төзи. Мөселманнар белән христианнар бергә яшәгән авылларда ислам гыйбадәтханәләре төзү тыела. Хакимият мөселман руханиларын санга сукмый, аларның хезмәтенә яңа тәхеткә утырган императорга тугры булу турында ил халкын ант иттергәндә генә мөрәҗәгать итә.

Икенче модель Көньяк Уралда, Оренбург губернасында өстенлек итә. Биредә Рус чиркәве миссионерлык эше алып бармый диярлек. Урта Идел буеннан аермалы буларак, биредә дин әһелләре хакимият тарафыннан таныла. 1736 елдан хакимият Уфа өязенең 4 даругасына 4 ахун билгеләү һәм аларның эшчәнлеген күзәтеп тору белән шөгыльләнә. Шул ук указ буенча мәчет-мәктәпләрне фәкать хакимият рөхсәте белән төзү тәртибе кертелә.

Руханилар башкорт волостьларында ярымөстенлекле катлам тәшкил итәләр: алар, авыл старосталары кебек үк, гади халык түли торган салымнардан азат ителә.

1734 елның 31 май указы нигезендә мәхкамә эшләре буенча һәр юлы Уфага, воевода янына барып йөрүнең кыенлыгы һәм араның ераклыгы турында халык биргән күпсанлы шикаятьләрне исәпкә алып, хөкүмәт, кеше талау һәм үтерүгә бәйле җинаятьләрне тикшерүне һәм карар кабул итүне рус хакимияте карамагында калдырып, Уфа өязендәге барлык рус булмаган халыкларга да үз мәхкамәләрендә (третийские суды) карар чыгарырга рөхсәт бирә. Шәригать мәхкамәсе фәкать зур авылларда гына эшләргә тиеш була. Авыл җыены аның составына бер өлкән яшьтәге кешене һәм мулланы билгеләп куйган.

Шәригать мәхкәмәсе чыгарган карарларга башкорт старшиналары үзгәреш керттерә яки үзләренә кирәкле карар чыгару өчен басым ясый торган булганнар. Көньяк Урал төбәге башкортлары 1767 елны Уложенная комиссиягә биргән наказларында мондый очракларга чик куюны сораганнар. Алай гына түгел, авылда сугышкан кешеләрне һәм бәхәсләрне хәл иткәндә, старшинадан тыш, мулланы катнаштыруны үтенеп сораганнар, чөнки бу өлкә шәригать мәхкәмәләре карамагында булмаган. Шәригать мәхкәмәләре мирас һәм милек бүлү, ир белән хатынны аеру, вак-төяк ызгышлар һәм кул күтәрү, бурыч кайтару, чит кеше мөлкәтен үзләштерү яки тартып алу, җир буенча бәхәсләр кебек һәм бер гаиләгә кагылырга мөмкин булган мәсьәләләрне карап тикшергәннәр. Инде әйткәнебезчә, старшиналар да вак-төяк иҗтимагый тәртипне бозу очракларын тикшергәннәр. Шәригать мәхкәмәсе чыгарган җәза – мәсәлән, таяк белән суктыру – мәчет янында тормышка ашырылган. Күрәсең, карарлар да мәчеттә кабул ителгән.

XVIII гасыр уртасында татарларның Идел-Чулман якларыннан Көньяк Уралга күченүләре дәвам иткән, төбәктә эчке миграция дә көчле барган: яңа авыллар нигезләнгән яисә аларга яңа кешеләр килеп төпләнгән. Шул сәбәпле, төбәктә руханилар саны да арткан. Мондый шартларда гаять зур территорияләрне биләгән даругаларда канцелярияләре булмаган 4 ахун гына авыл муллаларын күзәтеп тора алмаган. Торак пунктларда дини тормышның барышын төбәкләрдә руханилар арасындагы үзара мөнәсәбәтләр билгеләгән. Моның шулай икәнен төбәкләрдә яңа ахуннар пәйда булуы да күрсәтеп тора. Бу исә төбәкләрдә яңа дини үзидарәләр оешу билгесе була.

80 нче еллар башында Оренбург губернасы Уфа наместничествосы итеп үзгәртелә. Ул Уфа һәм Оренбург өлкәләренә аерыла. Даругалар өязләр белән алыштырылгач, ахуннарның хакимияте һәм күзәтчелеге юкка чыга. Хакимият бу үрчүне рухани булырга тиешле кешеләрнең матди байлыкка омтылуында күрә: рухани мәхәллә халкы хисабына яши, дәүләт салымнарыннан һәм йөкләмәләреннән азат була дип аңлатырга омтыла. Чынлыкта исламны тарату, халыкны белемле һәм хак мөселман итү өчен тырышучылар да күп булган дип уйларга кирәк. Дини активистлар үзләрен рухани дип атап, авылдан-авылга йөреп, мәчетләрдә һәм йортларда халыкны вәгазьләү белән даими шөгыльләнгәннәр. Аларның ни сөйләп йөргәнен хакимият белмәгән һәм мондый хәлне өнәмәгән. Бигрәк тә сугыш шартларында полиция күзәтүе көчәйгәндә, аларның эшчәнлегенә игътибар арткан, ләкин барыбер хакимият үзенә кирәкле мәгълүматны туплый алмаган *(Азаматов Д.Д. Оренбургское магометанское духовное собрание в конце XVIII–XIX вв. Уфа, 1996. С. 21)*.

Мөселманнар яшәгән җирләрне кушу империядәге дәүләт белән ислам дине арасында мөнәсәбәтләрне тагын да төрләндереп җибәргән.

1783 елда Кырым ханлыгын кушкач, дәүләттә исламга карата яңа төрле сәясәт – өченче модель – формалаша. Екатерина IIнең 1783 ел 8 апрель манифестында кырым татарларына аларның дини хокуклары үзгәрешсез калачак, дин әһелләре,

мәчетләре һәм ислам дине дәүләт яклавында булачак дип ышандырыла. Ә Кырым ханлыгында ислам – дәүләт дине булган. XVIII гасыр ахырында Польша җирләрен Россиягә кушу турындагы указлар дин тоту иреген биредә яшәүче барлык халыкларга – христианнарга, католикларга, мөселман динендәге Литва татарларына да тарата. Литва татарлары-дворяннары хәтта христиан динендәге крепостнойларын да саклап калалар.

Дүртенче модель Казакъ даласында формалаша. 1785 елны Сембер һәм Уфа генерал-губернаторы итеп барон О.А.Игельстром билгеләнгәч, ул Казакъ даласын тыныч юл белән Россиягә кушу, колонизацияләү планын тормышка ашырырга керешә. Бу вакытта Кече җөздә Байбакты ыруы старшинасы Срым Датов Нуралы ханга каршы сугыш алып бара. Игельстром, аның өстенлеген күреп, Срым батырны яклаган кара сөяк бәкләр, нойоннар ягында солтаннарга, гомумән, аксөякләргә каршы чыгып, Даланы империягә тыныч юл белән ныклап беркетү сәясәтен үткәрә башлый. Нуралы хан, үтерелүдән куркып, 1786 елны Оренбургка килеп сыена, аны, 5 елга мең сум жалованье билгеләп, гаиләсе һәм хезмәтчеләре белән бергә Уфа каласына җибәрәләр. Кече җөз хансыз кала. Игельстромның максаты – хакимиятне, шул ук елны Оренбургта ачылган Чик буе мәхкәмәсенә, аңа буйсындырылган Кече җөздәге өч ыру өчен аерым-аерым төзеләчәк мәхкәмә советларына тапшыру була.

Бу проектта Коръән сүзе империя мәнфәгатьләрендә бик киң файдаланыла. Россия файдасына вәгазьләүдә Мөхәммәтҗан Хөсәенов төп фигурага әйләнә. Ул Оренбург чик буе комиссиясе штатына офицер итеп эшкә алына, мөселманнар аны Оренбург чик буе комиссиясе ахуны дип беләләр. Россиянең Кече һәм Урта казакъ җөзләренә карата сәясәте шушы институт аша тормышка ашырыла. Мөхәммәтҗан шул ук елны Екатерина II рескрипты белән Оренбург төбәгенең «беренче ахун»ы итеп тә раслана.

М.Хөсәенов арадашчы сыйфатында 1785 елның көзендә 208 старшина катнашындагы җыенда хан хакимиятен юкка чыгару турындагы төп сүзне Срым батырдан әйттереп, барысын да Екатерина IIгә тугры булырга шәригатьчә ант иттерә. Әби патша исә 1787 елда казакъларга тарату өчен Коръәнне типографиядә махсус бастырып җибәрә. Мөхәммәтҗанның бер айдан артыкка сузылган миссиясе моның белән генә тәмамланмый, ул җәйләүләрдә О.Игельстромның Далада тынычлык урнаштырырга өндәгән хатларын тарата. Кайткач, рапорт язып, генерал-губернаторга сәясәтен камилләштерүгә юнәлдерелгән тәкъдимнәрен җиткерә.

1786 елның май аенда баруында М.Хөсәенов җиде солтанны һәм 108 старшинаны ант бирергә күндерә. 1787 елның апрелендә тагын 214 старшина патшабикәгә тугрылыкка ант итә. Шулай итеп, Кече җөзнең идарә катламын Россиягә буйсындыру уңышлы тәмамлана, ә Мөхәммәтҗан җәйләүләрдә рус хакимиятенең ислам динен яхшы белүче вәкаләтле вәкиле буларак таныла.

Чыннан да, Далада тынычлык урнаша, расправа-мәхкәмәләр ачылгач, хакимият солтаннар кулыннан китә. Империя хакимияте, җәйләүләрдә үз йогынтысын арттыру өчен татар муллаларын, сәүдәгәрләрен киң файдалана. Оренбург һәм Троицк меновой дворлары янында таш мәчетләр төзелә, татарлар җәйләүләргә барып, вак сәүдә белән шөгыльләнәләр. Шулай итеп, Казан губернасында иген игеп, зур салымнар түләп, хәерчелектән башлары чыкмаган, укый-яза белгән, дин гыйлеменнән хәбәрдар булган татар крестьяннары биредә рус хакимияте һәм казакълар тарафыннан хөрмәт ителгән мөселман руханиларына, солтаннарның, старшиналарның хат язучыларына, аларның балаларына дин сабагы бирүче мөгаллимнәргә яки вак эшмәкәрләргә әвереләләр.

Империянең бердәм идарә һәм хокукый кырында аерым төбәкләрдә дәүләт белән

ислам дине арасында мөнәсәбәтләрнең төрле модельләре барлыкка килү, күпсанлы яһүдиләрне, католикларны, мөселманнарны һ.б. кушу православие дәүләт дине булган илдә бу халыкларга карата бердәм дини сәясәт принциплары эшләү мәсьәләсен көн тәртибенә куя. Екатерина II идарә иткән чорда мондый бердәм хокукый документ төзелмәсә дә, чынлыкта дәүләт барлык төбәкләрдә дә православие динендә булмаган җирле халыкларга (традицион диннәр тарафларыннан кала) үз диннәрен тотарга хокук бирелә (*Загидуллин И.К. Превращение ислама в «терпимую» религию в период правления Екатерины II // Вторые кремлёвские чтения «Екатерина II и имперское многообразие России: опыт политического и культурного взаимодействия» (Казань, 25-26 сентября 2009 г.) / отв. ред. И.Р.Миннуллин. Казань, 2009. С.103–109).*

## Мөселман руханиларын күзәтүче дәүләт институты оешу тарихы

1787 елны Госманлы дәүләте, 1768–1774 елларда сугыш нәтиҗәләре буенча югалткан җирләрен һәм Кырым ханлыгын яңадан тергезергә теләп, Россиягә каршы сугыш башлый. Тарихка 1787–1791 еллардагы рус-төрек сугышы дип кергән бу хәрби кампания вакытында Госманлы дәүләтенең, дини идеологияне файдаланып, Урта Азия һәм казакъ ханнарын Россиягә каршы файдаланырга омтылганы ачыклана. 1787 елның 11 сентябрендә Игельстромга хат юллап, Екатерина II төбәктә полиция күзәтүен көчәйтергә, мөселманнарны дәүләткә каршы баш күтәрүләргә китерергә мөмкин булган чит йогынтыдан сакларга боера. Шундый ук эчтәлектәге әмерне Казан губернаторы князь Мещерский да ала. Мөселманнар тупланып яшәгән губерналарга мондый хатлар җибәрүдән, Җир шарындагы барлык мөселманнарның хәлифе булган Госманлы солтаны идеологиясенең Екатерина II тарафыннан дәүләткүләм куркыныч буларак кабул ителгәнлеге аңлашыла.

Барон Игельстром шунда ук Казакъ даласындагы расправаларга чапкыннар белән фәрман җибәрә: күзәтүне көчәйтергә, әгәр дә Бохара ягыннан дәрвиш-голәмәләр күренсә, аларга коткы таратырга мөмкинлек бирмәскә!

Далага хәл-әхвәл белергә, мәгълүмат җыярга, шулай ук, Уфа наместнигы идарәсенең киңәшчесе Д.Б.Мертваго (1787–1797) да китә. Ул, әйләнеп кайткач, далада йөргәндә туган уй-фикерләрен барон О.А.Игельстромга җиткерә: төбәктә мөселман руханиларны күзәтү өчен махсус оешма төзергә кирәк. Аныңча, мондый оешма булса, хакимияткә лояль булган муллалар ислам илләренең Россия хөкүмәтенә каршы вәгазьләрен ил мөселманнары арасына кертмичә, аларга каршы торачаклар. Шулай итеп, мөселман руханиларын күзәтүче төбәк хөкүмәт оешмасы күрше ислам илләре эмиссарларының идеологик йогынтысына каршы торырлык үзәк буларак фикерләнә.

1788 елның 1 маенда Сембер һәм Уфа наместничествосы губернаторы барон О.А.Игельстром Екатерина IIгә губерна шәһәрендә мөселман руханиларыннан билгеләнгәнче имтихан алу өчен төбәкнең беренче ахуны Мөхәммәтҗан Хөсәенов рәислегендә махсус комиссия төзергә рөхсәт сорап, хат юллый. Бу комиссиягә тагын ике ахун һәм ике мулла кирәчәк дип әйтелә. Наместник махсус комиссиянең имтихан бәяләмәсе буенча кандидатларны ахун яки мулла, яки мөәзин итеп билгеләргә тиеш була. Имтиханнарда, шулай ук, төбәктәге югары мәхкәмәнең (верхняя расправа) ике әгъзасы һәм губерна прокуроры катнашырга тиеш була *(Азаматов Д.Д. Курс. хезмәт. С. 21).* Игельстром махсус комиссияне тоту өчен елга 680 сум акча сорый.

Екатерина II, сәяси мәсьәләгә киң карап, мөселман руханиларын рәсми таныргa һәм хезмәттәшлек итүгә күчәргә, шул рәвешле аларның оппозициядә булуын туктатып,

сәясәттән читләштерергә план кора һәм Оренбург губернасы кысаларында гына түгел, ә ил күләмендә махсус дәүләт оешмасы төзергә боера.

Оренбург генерал-губернаторы барон Игельстром яңа институтның вәкаләтләре турында нигезләмә әзерли. Аның тарафыннан 1789 елның 4 декабрендә төзелгән Мәхкәмәи шәргыядә имтихан алу тәртибе турындагы нигезләмә шул ук көнне Екатерина II тарафыннан расланып, рәсми рәвештә яңа оешманың эшен оештыру кагыйдәләре буларак кабул ителә. Рәис сыйфатында мөфти һәм әгъзалар сыйфатында Казан төбәге татарларыннан өч казыйдан торган һәм Уфа наместнигына буйсынган яңа институтның хокукый статусы урта дәрәҗәдәге мәхкәмә оешмаларыныкы кебек дип билгеләнә, аның административ күзәтүенә мөселманнар яшәгән барлык төбәкләр (Таврия өлкәсенән кала) керә дип тәгаенләнә. Имтиханга килүче кулында төбәк җитәкчесенең бу кеше яшәгән торак пункты һәм аның үзтәртибе язылган, шулай ук мөселманнар тарафыннан руханилыкка сайланганлыгын раслаучы рәсми кәгазьләре булу шарты куела. Имтихан татарча уздырылып, анда катнашкан губернаның ике югары расправасы (суды) рус чиновниклары өчен дәүләт теленә  дә тәрҗемә итеп барылырга тиеш диелә.

Шул ук көнне кул куелган икенче указ белән яңа оешманың рәисе һәм мөфти итеп Мөхәммәтҗан Хөсәенов билгеләнә *(В память столетия Оренбургского магометанского духовного собрания, учреждённого в городе Уфе. Уфа, 1891. С. 8-9)*. Шулай итеп, Казакъ даласының беренче ахуны Идел-Урал, Себер, Эчке Россиядә яшәгән мөселманнарның мөфтие булып китә.

Мөхәммәтҗан бине әл-Хөсәен бине Габдеррахман (1756–1824) гыйлемле нәселдән чыккан. Аның бабасы Мансур әл-Борындыкый Дагыстанда укып кайта,  Мамадыш өязе Симет авылы мәдрәсәсендә белем ала һәм Бохарага китә – Ш.Мәрҗани аны татарлар арасында Урта Азиягә барып, гыйлем алучыларның беренчесе дип саный (*Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). Казан, 1989. 236 б.)*). Кайткач, туган авылында мәдрәсә ачып белем бирә.  Мөдәрриснең гыйлеме һәм абруе империя хакимиятен дә җәлеп иткән. Ул 1734–1744 елларда Оренбург экспедициясендә ахун булып хезмәт итә. 1738 елны Орск шәһәрендә агачтан беренче җәмигъ мәчете төзетә һәм аның беренче имамы була *(Зиннәтуллина А.Ә. Кайбыч төбәгенең күренекле шәхесе // Фәнни Татарстан. 2020. №3.  96–100 б.*).

Шәхси сыйфатлары белән бабасына шактый охшаган оныгы Мөхәммәтҗан Оренбург төбәгендә күпмедер вакыт Мансур ахун язмышын кабатлап, тагын да югарырак дәрәҗәгә ирешә.

Мөхәммәтҗан Борындык авылында туган. Р.Фәхретдин Мәхкәмәи шәргыя архивында тапкан 1815 елда тутырылган хезмәт формулярында аның атасының гильдия сәүдәгәре икәне ачыклана, үзе 5 ревизия буенча (1795) Уфа ягындагы Солтанай авылына теркәлгән була. Булачак мөфти башлангыч белемне туган ягы мәктәпләрендә алган. Заманында алдынгы мәдрәсәләр белән дан тоткан, Оренбургтан ерак түгел урнашкан Каргалыга барып, Кавказдан килгән Мөхәммәд бине Гали әд-Дагыстани исемле галимнән һәм башка голәмәләрдән сабак ала *(Мәрҗани Ш. Күрс. хезмәт.  211-212 б.)*.

Ул заманда тирән дини белемгә һәм шөһрәткә омтылган татар яшьләре Бохарага барып гыйлем җыйган. Урта Азиягә белем эстәргә киткән Мөхәммәтҗанның, хәзергечә әйтсәк, Россиядә хәләл икмәк стандарты кертергә тырышлыгы игътибарга лаек. Ш.Мәрҗани язганча, егет сыра яки шәраб эшләүдән калган калдыкларны кушып пешергән икмәкнең хәләл булмавы хакында өч Бохара голәмәсеннән фәтва ала. Бу хакта Каргалы галимнәренә хәбәр итә. Фәтва шәһәрләргә таралгач, татарлар

арасында җәнҗал чыга. Күрәсең, шуннан соң икмәк пешереп сатучылар рецептларын үзгәрткәннәр яки татарлар үзләре хәләл икмәк пешерә башлаганнар.

Мәрҗанинең мәгълүматларына караганда, Мөхәммәтҗан Бохарадан туган иленә 1777 елны әйләнеп кайта *(Мәрҗани Ш. Күрс. хезмәт. 212 б.)* һәм мөдәррис булып эшли, аннары Кабулга барып белем эсти, кайткач шәехлек кыла. М.Хөсәенов Бохарага да, Әфганстанга да, белем туплаудан тыш, Чит ил эшләре коллегиясе кушуы буенча разведчик буларак мәгълүмат җыярга җибәрелгән *(Азаматов Д.Д. Күрс. хезмәт. 23 б.)*. Ягъни ул Бохара ханлыгында һәм Әфганстандагы дәүләтнең руханилар һәм башка ислам институтлары белән эшләү системасын яхшы белән.

Биредә шунысын да ассылыклап үтү мөһим: проектның авторы Д.Б.Мертваго һәм барон О.А.Игельстром, 1783 елны Кырым ханлыгын Россиягә кушкач, беркадәр вакыт дәүләт эшләре белән Госманлы дәүләтендә булалар һәм андагы ислам институтларын күзәтүче оешманың вәкаләтләре, хокуклары һәм бурычлары белән дә танышалар *(Губернаторы Оренбургского края / Авторы-составители В.Г.Семёнов., В.П.Семёнова. Оренбург, 1992. С. 116)*. Аларны 1784 елны Россиягә чакыртып алалар һәм озак та үтми, О.А.Игельстром Сембер һәм Оренбург губернаторы итеп билгеләнә.

Барон Игельстром, Госманлы дәүләтендә руханиларны күзәтү һәм алар белән хезмәттәшлек итү системасының барлык ислам институтлары белән эшләгәнен күз алдында тотып, илдәге яңа оешманың вәкаләтләре дә киң булырга тиешлеген алга куйган. Ул 1789 елның 5 декабрендә империя хакимиятенә яңа институт вәкаләтләре турындагы Нигезләмә проектын тапшыра.

Мәхкәмәи шәргыя мөселманнарның барлык дин өлкәсенә кагылышлы мәсьәләләре буенча беренчел инстанция дип игълан ителә. Ул, руханилардан имтихан алудан тыш, мөселманнар арасындагы өйләнешү, аерылышу, мәчеттә гыйбадәт кылу, дини ритуалларны дөрес башкару һ.б.ларны тикшереп, карарлар чыгару хокукына ия була (п. 1). Әлеге заманда ир белән хатынның аерылышуын мәхәллә мулласы түгел, ә аерылырга теләүчеләр сайлаган ахун яисә имам тикшереп хәл иткән. Киләчәктә һәр шундый очрак буенча карар чыгарган рухани Дини идарәгә бу хакта хат язып, аерылышуның сәбәпләрен, аерылышуга рөхсәт бирү яклы дәлилләрне хәбәр итәргә тиеш була. Әгәр Дини идарә бу дәлилләрне җитәрлек дип тапмаса, аерылышу турындагы акт аның тарафыннан юкка чыгарылган. Шулай ук ул, апелляция органы буларак, мәхәллә руханиларының ир белән хатынны аеру турында карарыннан канәгатьсезлек белдергән шикаятьләрне тикшереп, хөкем чыгарырга хокуклы булган (п. 2).

Ул елларда гаилә мөнәсәбәтләре рухани хакимият тарафыннан махсус игътибар таләп иткән. Еш кына ирнең хатынын яисә эти кешенең кызын урлап китеп, читтә никах укыту очраклары күзәтелгән. Бу ямьсез күренешне туктату өчен Дини идарә дөньяви хакимият органнары ярдәме белән Европа илләрендә кулланышта булган һәм шәригатькә каршы килмәгән яңа тәртип кертергә тиеш тапкан. Килен яшәгән торак пункт мәчетендә никахлашуга 3 атна кала һәр җомга намазы вакытында хатыйб бу хакта игълан ясарга тиеш була. Кагыйдә үтәлмәсә, Мәхкәмәи шәргыягә никахка кергән ир белән хатынны аеру, гаепле руханины эшеннән алып, мәхкәмәгә тапшыру хокукы бирелә (п.3).

Тагын бер яңалык – мәчет ачу эшенә рәсми рәвештә Мәхкәмәи шәргыяне катыштырудан гыйбарәт була, ягъни аның бу хактагы карары ахыргы сүзне әйтү өчен наместник идарәсенә бирелә (п. 5). Яңа мәчетләрне коруда христиан чиркәүләрен төзү нормативы кертелә – һәр 100 хуҗалыкка бер мәчет ачарга, ә халык азрак булганда, күрше авыл халкы белән берләшергә рөхсәт ителә. Әгәр тирә-як авылларда мәчет

булмаса, биш вакыт намаз укырга кирәклеген истә тотып, халкы кимрәк булган торак пунктларда да мәчет төзергә рөхсәт бирелә алган (п. 4).

Мәхкәмәи шәргыягә мәчетләрдә тиешле санда гына руханилар булуын, теләсә кемнең үзенә-үзе ахун, имам дәрәҗәсен бирмәвен һәм, гомумән, рәсми рәвештә билгеләнмәгән голәмәләрнең (гыйлемле мөселманнарның) бу вазифаны башкармауларын күзәтү йөкләнә (п. 6).

Өязләрдә мәчетләрне, руханиларны һәм мәктәпләрне күзәтеп тору ахуннар карамагына тапшырыла, аларның саны икедән артмаска тиеш дип төгәлләштерелә (п.7).

Россиядә тән җәзасын хакимият кенә билгели алу сәбәпле, шәригать кануннарын бозган мөселман кешесе (намазны калдыра, исерек һ.б.) тән җәзасына тартыла алмый, ул үз авыл җәмгыяте алдында гафу сорарга һәм тәүбә итәргә тиеш дип ассызыклана. Шул ук вакытта авыл җәмгыятенең җинаять эшләгән кешегә чара күрү өчен хакимияткә мөрәҗәгать итү хокукы барлыгы әйтелә (п.8).

Мәхкәмәи шәргыянең иң җаваплы өлкәсе дип мәгариф институтлары билгеләнә. Мәчет каршында гына эшләүче, ягъни указлы мулла гына белем бирүче һәр яңа уку йорты Мәхкәмәи шәргыя рөхсәте белән генә ачылырга тиеш була. Ул, үз чиратында, һәрбер рөхсәтне төбәк җитәкчелегеннән ала. Мәктәп-мәдрәсәләрдә кем укытканы, нәрсә укытканы һәм күпме шәкерт булуы хакында мәгълүмат туплау өчен, Мәхкәмәи шәргыя ай саен мәктәп мөдирләреннән укучыларның исемлеген, кемнең нинди фәннәр укыганлыгы турында хисап җыеп, генераль ведомостьларны генерал-губернаторга һәм Җәмәгать эшләре буенча Приказга юлларга тиеш була (п.9) *(Материалы по истории Башкирии.* Том *V. / Сост. Ф.Демидова. Под ред. С.М.Васильева. М., 1960. С. 565-566*).

Инде яңа оешмага кагылышлы нигезләмәләрне әзерләүдә әле оештырылмаган «Духовное собрание магометанского закона»ның рәисе итеп билгеләнгән мөфти Мөхәммәтҗан Хөсәеновның роленә тукталыйк.

М.Хөсәенов Россия кануннарын яхшы белгән, бик шәп русча рапортлар язган. Империя структураларындагы бюрократик тәртипләрне күздә тотып, бу документлар аның белән, һичшиксез, килештерелгән дип әйтергә мөмкин. М.Хөсәеновның бик актив һәм харизматик шәхес икәнлеген искәртеп, һәм мөфтинең үзе җитәкләячәк оешманың вәкаләтләрен билгеләүче искиткеч әһәмиятле нигезләмәләрне төзүдә катнашкан дип, зур ышаныч белән әйтергә мөмкин. Инде әйтелгәнчә, М.Хөсәенов Госманлы империясендә булмаган, ләкин ул Бохара ханлыгында укыган.

Бу документны эшләүдә кайсылары мөфти фикерләре булганлыкны, ягъни Урта Азиядәге мөселман дәүләтләрендәге дини институтлар белән идарә итү системасы исәпкә алынганмы-юкмы икәнен ачыклау – галимнәр алдында торган бурыч булып кала.

Екатерина II барон Игельстромның 1789 елның 5 декабрендә керткән Нигезләмә проектын расламый.

Р.Фәхреддин юкка гына: «Мәхкәмә исеме бар, җисеме юк кабиленнән – коры бер сурәттән гыйбарәт булган хәлдә ачылган» *(Фәхреддин Ризаэддин. Исламнар хакында хөкүмәт тәдбирләре //Фәхреддин Ризаэддин. Дини һәм иҗтимагый мәсьәләләр: сайланма хезмәтләр. Казан, 2011. 178 б.)*, бу фәрманда «безнең эшебезгә ярарлык вә киләчәгебезне тәэмин итәрлек бер мәддә түгел, хәтта бер кәлимә булсын күрмимен», дип язмаган *(Фәхреддин Ризаэддин. Русия мөселманнарының ихтыяҗлары вә алар хакында интикад //Фәхреддин Ризаэддин. Дини һәм иҗтимагый мәсьәләләр: сайланма хезмәтләр. Казан, 2011. 248 б.)*.

1789 елның 4 декабрендә расланган Нигезләмәдә сүз, яңа оешкан мәхәлләләрдән

килгән шәхесләрдән имтихан алудан битәр, барлык дин әһелләренең дини белемнәрен тикшерү турында бара. Бу тикшерү үзгә бер имтихан булып, ул, нигездә, сөйләшеп, аралашып утырудан гыйбарәт булган. Имтиханга килгән һәр кеше турында мәгълүмат теркәп барылган, шул рәвешле мөфти руханилар белән танышкан, аларның гыйльми фикер куәтләрен дә ачыклаган, чөнки бу кадәр зур территория белән идарә итү өчен аңа булдыклы, күндәм, җирле хакимият белән дә, күрше-күлән муллалар белән дә яхшы мөнәсәбәтләр корырга сәләтле шәхесләрне ачыкларга, аларны мөфти вәкиле итеп кую өчен исемлек төзергә кирәк булган. Дөресрәге, бу вакытка инде төбәкләрдә руханилар арасында белемнәре буенча иерархия барлыкка килгән, мәшһүр дин әһелләре горизонталь элемтәләрдә үзләренең гыйлем өлкәсендәге өстенлекләрен файдаланып, башкалар белән идарә итү системасын булдырганнар. Мөфти аралашу вакытында төбәкләрдәге авторитетлы шәхесләр исемлеген барлаган. Шулай сөйләшү-аралашу барышында ул руханиларны исламга карата илдәге яңа вазгыятьне аңлатып, тәкъдимнәрен дә җиткергәндер дип фаразларга мөмкин.

Шулай итеп, Мәхкәмәи шәргыя оештырылуның максаты – мәхәлләләргә билгеләнә торган дин әһелләреннән имтихан алу аша хөкүмәткә лояль булган руханилар төркемен формалаштырудан гыйбарәт булган. 1787 елда яңа Рус-төрек сугышы башлану, хәлифнең Россия мөселманнарына йогынты ясап, Идел-Урал төбәгендә иҗтимагый тотрыксызлык булдырырга тырышуы, империя структураларында беренче планга чит илдән янаган ислам йогынтысына каршы тору мәсьәләсен чыгарган. Бу катлаулы эшне фәкать мөселман руханилары башкарып чыга алган. Шушы вазгыятьтә, ягъни ил сугыш хәлендә яшәгән вакытта Дини идарә оештырылган. Аның максаты итеп, халыкның Урта Азия һәм Госманлы дәүләтләренең идеологиясенә иярмәвен, татар, башкорт муллаларының сәяси өлкәгә кысылмауларын, мөселманнар хакимияткә каршы баш күтәргән очракта, аларда катнашмый һәм социаль протестны әйдәми, киресенчә, җәмәгать тынычлыгын саклый торган дин әһелләре әзерләү билгеләнгән.

## Татар галимнәре яңа оешманы төзү сәбәпләре турында

Күренекле татар галимнәре Мәхкәмәи шәргыя оештыру сәбәпләре турында уйланганнар. Моңа Ш.Мәрҗани аерым игътибар иткән. Әмма аның Мәхкәмәи шәргыя ачылу турында язган бер җөмләсендә ике хата киткән. Ул: «1192 (1778) ел сентябренең егерме икесендә, чәршәмбе көнне Оренбург кальгасында бер мөфти һәм өч казыйдан торган «Мөхәммәд дине җәмгыяте идарәсе» ачыла», дип яза. Хакыйкатьтә Дини идарә Уфада оеша; бу турыдагы указга 1788 елның 22 сентябрендә кул куела, ә оешманың эшли башлавы 1789 елның декабренә туры килә.

Ш.Мәрҗани Мәхкәмәи шәргыя ачылу сәбәпләре итеп, Әби патшаның Коръән бастырырга рөхсәт бирүен һәм мөселманнарны башкаларның җәберләвеннән тыю – Кечек-Кайнарҗа исемле Россия белән Госманлы дәүләте килешүен атый. Биредә дә ялгыш киткәнен әйтергә мәҗбүрбез. Екатерина II Коръән бастырырга рөхсәтне соңрак бирә һәм ул Санкт-Петербургта 1787 елда басылып чыга *(Мәрҗани Ш. Күрс. хезмәт. 209 б.).*

Галим күрсәткән икенче сәбәп гаять әһәмиятле. 1774 елда Госманлы дәүләте белән Россия арасында төзелгән Кечек-Кайнарҗа килешүендә һәм аның эчтәлеген шәрехләп 1779 елда кабул ителгән Конференциядә Госманлы солтанының, хәлиф буларак, барлык мөселманнар өстеннән рухани суверенитеты таныла. Дөрес, бу ике документтагы Россия мөселманнарының хәлифе – Госманлы солтаны дигән маддәләр

1783 елда империя Кырым ханлыгын аннекциялəгəч юкка чыгарыла *(Бартольд В.В. Халиф и султан / В.В.Бартольд // Бартольд В.В. Сочинения. Т. VI. М., 1966. С.78).*

Ш.Мəрҗани: «Госманлы дəүлəтендə румиле гаскəр казые, анатолияле гаскəр казые, иранлы гаскəр казые дəрəҗəсендə галимнəрдəн өч зат булып, алар өстеннəн шəйхелислам (дини кануннарны аңлатучы иң өстен кеше) һəм мөфти тора. Шуңа охшатып безнең мəмлəкəттə оештырылган «Ислам дине җəмгыяте» əгъзалары да казый дəрəҗəсендə өч зат булып, алар өстеннəн торучы рəис – мөфти билгелəнə», дип төгəллəштерə *(Мəрҗани Ш. Күрс. хезмəт. 209 б.)*.

Ш.Мəрҗани Игельстромның 1789 елның 5 декабрендə төзелгəн Нигезлəмə проекты хакында хəбəрдар булмый. Лəкин Мəхкəмəи шəргыя ачылганнан соңгы 100 ел дəвамында империя хакимияте акрын-акрын барон төзегəн Нигезлəмə проектында язылган вəкалəтлəрнең шактый өлеше Дини идарəгə тапшырылган була.

1788-1789 еллардагы вакыйгаларны шəрехлəп, Р.Фəхреддин хаклы рəвештə аны хакимиятнең, Идел һəм Урал төбəге мөселманнарына мəрхəмəтле булудан бигрəк, аларны коралсыз буйсындыру телəгенə нигезлəнгəн сəяси эше дип исəпли. «Нигездə, бу вакыт коралның куəте бетеп, хəтта Оренбург вə Урал ягында булган исламнарның Россиядəн аерылулары, күз белəн каш арасы кебек аз калган иде», дип ассызыклый (*Фəхреддин Ризаэддин. Исламнар хакында хөкүмəт тəдбирлəре. 178 б.*).

Р.Фəхреддин совет чорында бу мəсьəлəгə киңрəк туктала һəм болай дип белдерə: «Зур бер сугыш һəм кырылыш сəбəбеннəн тəмам арыган һəм йөдəгəн Россиянең төшлек тарафындагы күршелəреннəн бер хөкүмəт белəн арасы бозылды, бу эш зурга китеп, фетнə көчəйде. Мəскəүнең хəлдəн тайганлыгын һəм җаны бугазга җиткəнлеген, башка кавемнəр кебек үк, бу мəмлəкəттəге мөселманнар да белделəр. Хəлне форсат санап, хөкүмəт дошманнары мөселманнар арасында йөрергə керештелəр. Бөтен Урал – Идел буйларының хакиме булган наместник тарафыннан мəркəзгə (үзəк) яман хəбəрлəр бара  башлады. Əбинең йокысы ачылып, ямьсез һəм куркыныч төшлəре хафага салды. Орлов һəм Потёмкин, фəлəн һəм фəлəннəр белəн сөхбəт кылуга (киңəшлəшүгə)  ихтыяҗ туа башлады. Ахырда бу фаҗиганең чарасы һəм бу бəланең дəвасы мөселманнарны көйлəү икəнен аңлап, аларга берəр төрле яхшылык  күрсəтү кирəк икəненə карар бирелде. Шуңа нигезлəнеп, Россия эчендə «ислам» исемле бер динне дин итеп тəсдыйк кылу (тану), мөселманнарны да мəшруг (шəригать кушкан һəм шəригать каршында дөрес булган) бер дингə иярүче халык итеп тану һəм үзлəренə күрə дини бер мəхкамə (хөкем итə торган идарə) ачарга һəм гыйбадəтханəлəр тотарга мөсəгыйдə итү (ярдəм итү) тиешлек аңлашылды.

Ошбу сəбəптəн Оренбург, Омск, Верх. Урал шəһəрлəрендə мəчетлəр салынды, Казан шəһəрендə мəчетлəр рəсми мəчетлəр итеп тəсдыйк ителде. Уфа шəһəрендə дини бер мəхкамə ачылды (...).

Россия хөкүмəте ошбу эшлəрне көймəсе комга утырганнан, картузы култыгыннан төшеп киткəннəн, йомгагы чуалганнан соң, телəр-телəмəс генə эшлəгəн иде. Хəле аз гына төзəлү белəн, бу мəхкамəне кысарга, муллаларны җəфаларга һəм алардан эт җиктерергə кереште». *(Фəхреддинев Р. Уфа шəһəрендə губернский исполнительный комитетка сайланган котлуг татар егетлəренə һəм, гомумəн, бүген эш башында торучы иптəшлəргə ачык мəктүб // Болгар вə Казан төреклəре. Казан, 1993. 246-247 б.).*

Габдерəшит Ибраһим Екатерина II мөселман мəхкəмəсен оештыруы белəн эчке тынычлык урнаштыру, татарларга илтифат күрсəтеп, аларны ризалату максатына иреште, дип саный. Аның фикеренчə, Əби патша мөселманнарга күрсəткəн иркенлеклəре җитəрлек дəрəҗəдə булмаган, күбрəк күз буяу өчен бирелгəн; татарлар форсаттан үзлəре өчен əллə ни файда күрмəсəлəр дə, Далага, казакълар

арасына үтеп керә алганнар (*Ибраһим Габдерәшит*. Чулпан йолдызы // Габдерәшит Ибраһим: фәнни-биографик җыентык / төз. М. Госманов, Ф. Галимуллин. Казан, 2011. 59 б.).

Р.Фәхреддин, киресенчә, бу гамәлнең киләчәктә ислам институтларына тәэсире яхшы булып, дин тоту өлкәсендә «күп иркенлек мәйдан алып, мәктәп вә мәдрәсәләр күбәйгән», дип белдерә *(Фәхреддин Ризаэддин. Исламнар хакында хөкүмәт тәдбирләре. 177-178 б.*). Мәхкәмәи шәргыя эшчәнлегенең нәтиҗәләре дип ул түбәндәгеләрне атый: 1) «Шәрык исламнары Россиягә мәхәббәт куйган», ягъни империя хакимиятенә сәяси лояльлек күрсәтеп, Россияне Ватаны дип саный башлаган. 2) «Россия эчендә авторитеты аз санлы адәмнәргә киртәләр булдырып, рәсми сыйфаты булмаган галимнәр, никадәр бөек булсалар да, куәтсез калганнар», ягъни мөселман дөньясында руханилар, мөдәррисләр – барчасы да хакимият тарафыннан билгеләнгән затлар булып, гыйбадәт кылу, уку-укыту кебек вазифалар алар тарафыннан гына башкарылган. 3) «Урал, Волга буйларында булган исламнарның дин вә мәзһәбләре рәсми дин итеп танылып, күңелләренә куәт кергән вә һәр җирдә мәктәп вә шәкертләрне күбәйтеп, укырга вә укытырга керешкәннәр. Императорлар исеме белән бирелгән указларына таянып, мөдәррисләр дә, үзләренең бөек должностьларда булуларын исәпләп, тәмам тотрыклылык вә сәясәт эчендә гомер кичергәннәр» *(Шунда ук, 178 б.)*. Икенче төрле әйткәндә, хөкүмәтнең рәсми рәвештә руханиларны, мәктәп-мәдрәсәләрне, мәчетләрне тануы мөселманнарга дини белем системасын корырга һәм башка рухи, мәдәни мәнфәгатьләрен канәгатьләндерергә шартлар тудырган, руханиларны мөселман җәмгыятендә югары дәрәҗәгә куярга мөмкинлек биргән.

Күргәнебезчә, татар галимнәре Мәхкәмәи шәргыяне оештыруның төп сәбәбенә концептуаль якын килеп, мөселманнар һәм хөкүмәт арасындагы упкын һәм беренчеләренең көчләп чукындыру кампаниясеннән соң хөкүмәткә ышанмаулары, читләшүләре, ә хакимияткә, конфронтацияне туктатып, килешүгә бару мәслихәт булган дигән фикерне ассызыклыйлар. Ягъни, Екатерина IIнең бу карары, мөселманнар турында кайгыртудан битәр, чынлыкта мәҗбүрияттән килеп чыккан, дәүләт файдасына ясалган адым булган.

Берничә хезмәткәрдән торган штатлары белән Мәхкәмәи шәргыянең Уфада рәсми ачылышы 1789 елның 4 декабрендә губерна түрәләре, мөфти Мөхәммәтҗан Хөсәенов һәм, билгеләнеп, Казан губернасыннан килгән казыйлар катнашында тантаналы шартларда башкарылган *(В память столетия Оренбургского магометанского духовного собрания... – С. 12-13.)*.

Әлбәттә, 1773 елда мөселманнарга дин ирекe биргәннән соң, Мәхкәмәи шәргыяне ачуның төп сәбәбе – Идел-Урал төбәгендәге барча мөселман кавемен империя хакимиятенә карата лояль рухта тәрбияләү була. Шул ук вакытта хөкүмәт, яңа институт оештырып, беренче тапкыр мөселман дин әһелләре белән хезмәттәшлеккә барган.

**Илдус ЗАҺИДУЛЛИН,**
*тарих фәннәре докторы*

*Зөләйха Хисмәтуллинаның тууына – 100 ел*

# ҖЫРЧЫЛАРНЫҢ МОҢ ӘНКӘСЕ



Күренекле җырчы һәм музыка педагогы, Татарстанның атказанган артисты, Россиянең һәм Татарстанның халык артисты, Зөләйха Гатаулла кызы Хисмәтуллинаның (1922–1994) тууына – 100 ел.

Булачак җырчы 1922 елның 22 ноябрендә Казан шәһәрендә туа.

Башлангыч музыкаль белемне 1 нче балалар музыка мәктәбендә ала. Уналты яшендә Татарстан радиосының вокал ансамблендә җырлый башлый. Ул вакытта радиода музыкаль редактор булган Җәүдәт Фәйзи киңәше белән 1940 елда Ленинград дәүләт консерваториясе каршындагы музыка училищесына укырга керә. Бөек Ватан сугышы башлангач, Казанга кайта һәм 1942–1945 елларда Казан музыка училищесында җырларга өйрәнә.

1945–1974 елларда Муса Җәлил исемендәге Татар академия дәүләт опера һәм балет театрында солист булып җырлый, кырыкка якын классик һәм милли репертуар партияләрен башкара. Күп кенә композиторлар үз әсәрләрен Зөләйха Хисмәтуллина тавышын күздә тотып иҗат итәләр. Нәҗип Җиһановның «Намус» һәм «Teләче» операларының төп партияләре, Хөснулла Вәлиуллинның «Самат» һәм «Дим буенда» операларының баш партияләре, Җәүдәт Фәйзинең «Тапшырылмаган хатлар»ы җырчының башкару мөмкинлекләрен истә тотып языла. Зөләйха Хисмәтуллина – Мансур Мозаффаров, Александр Ключарёв, Алмаз Монасыйпов, Заһит Хәбибуллин, Рөстәм Яхин һәм башкаларның бик күп танылган җырларын һәм романсларын беренче башкаручы.

1950 елда ул Казан консерваториясен тәмамлый. 1961 елдан Казан консерваториясендә укыта башлый, 1983 елдан – профессор, 1974–1983 елларда – кафедра мөдире. Аның шәкертләре арасында Әлфия Заһидуллина, Зөһрә Сәхабиева, Айдар Фәйзрахманов кебек танылган шәхесләр бар.

2016 елда җырчыны искә алу кичәсендә танылган шәкертләренең тагын берсе Зөфәр Билалов аның турында: «Әни кебек якын кеше иде», – дип сөйләгән иде. Чыннан да, Зөләйха Хисмәтуллина бик күп талантлы җырчыларыбызның моң әнкәсе булды, татар җыры үсешенә үзеннән биниһая зур өлеш кертеп калдырды.

*Бу QR-код аша сайтыбызга кереп, тапшыруны тыңлый аласыз.*

# ЮКСЫНДЫРЫП ИСКӘ ТӨШӘ...



Язучы Хәйдәр Гайнетдиновның (1952–2000) тууына 70 ел тулды. Бу исемне ишетүгә, олпат гәүдәле, көләч йөзле сурәте килеп баса, ул әйткән төртмәле сүзләр искә төшә, җырлап торган чаклары хәтердә яңара. Әйе, гаҗәеп матур җырлый иде ул, әмма беркайчан да табигатьтән бирелгән моңлы тавышы белән дә, бөек җырчы Илһам Шакировның якын кардәше булуы белән дә масаймады, гомумән, аның концертларда, халык алдында чыгыш ясаганы булмады кебек. Дуслары даирәсендә генә, анда да әле, күңелнең моң көткән халәтендә генә җырлый торган иде ул.

...Тагын әле Хәйдәр Гайнетдиновның затлы каләм белән язылган хикәяләре искә төшә. Язганының үтә камиллегенә омтылганга күрә, үз-үзенә чамадан тыш таләпчән булуына күрә аның күңелендә йөргән күп кенә әсәрләре кәгазьгә төшеп өлгермәгәндер сыман тоела. Шулай да Хәйдәр үзеннән соң гаҗәеп бай һәм килер буыннарга бик тә кирәкле иҗади мирас калдырды.

Татарстан Язучылар берлеге сайтында аның иҗат һәм тормыш юлы турында мондый мәгълүмат бирелә.

Хәйдәр Гайфетдин улы Гайнетдинов (Хәйдәр) 1952 елның 27 ноябрендә Татарстанның Зәй районы Дүрт Мунча авылында хезмәткәр гаиләсендә туа. 1970 елда урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, бер ел колхозда эшли, аннары Казан университетының татар филологиясе бүлегендә югары белем ала. 1976–1987 елларда «Ялкын» журналында өлкән редактор, бүлек редакторы, җаваплы секретарь вазифаларын башкара. 1989 елда Мәскәүдә Әдәбият институты каршындагы Югары әдәби курсларны тәмамлый. 1989–1991 елларда «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») газетасының бүлек мөдире, 1991 елдан «Татарстан» Дәүләт телерадиотапшырулар компаниясендә (ДТРК) өлкән редактор, алып баручы булып эшли. Шигъри әсәрләре белән ул республика көндәлек матбугатында 1974 елдан бирле катнаша, 1982 елда Татарстан китап нәшриятында лирик шигырьләре һәм бер поэмасы («Иске кара урман») тупланган «Ут теле» исемле тәүге җыентыгы дөнья күрә. Авторның поэтик иҗаты үзенең күтәренке, оптимистик рухы, тормышта кешелеклелек, матурлык, шатлык тантанасын сурәтләве, ил-халыкның һәртөрле бәла-казаларны җиңеп якты киләчәккә таба горур атлап баруын раславы белән игътибарны җәлеп итә.

2000 елның 23 июлендә вафат була, туган авылы зиратына җирләнә.

Татарстан телевидениесендә эшләгән елларда Хәйдәр Гайнетдинов «Җомга көн кич белән» исемле гаять популяр әдәби тапшыру белән беррәттән, Казан мәчетләренең тарихы белән таныштырган тапшырулар циклы да оештырды. Халыкның иманга кайткан, дини гыйлемгә, тарихи мәгълүматка сусаган вакытында, 1990 еллар башында Ходай үзе кушкан эш булгандыр, һәм Хәйдәр абый Аның шушы әмерен үзенә бер вазифа дип кабул иткәндер кебек тоела. Бу дөньяда кылган игелекле гамәлләре әҗер-савап булып язылса иде.

Игътибарыгызга тәкъдим ителә торган язмада Хәйдәр Гайнетдиновның «Ай күңелдә кала» дигән хикәясе урын алган. Сез аны Айдар Хафизов укуында ишетерсез. 1989 елгы язма.

*Сәхифәне «Татарстан» радиосының шеф-мөхәррире* **Нәсим АКМАЛ** *алып бара.*

### 2023 – МИЛЛИ МӘДӘНИЯТЛӘР ҺӘМ ТРАДИЦИЯЛӘР ЕЛЫ

Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов ТР Дәүләт Советына еллык юллама белән мөрәҗәгать итте. Чара ТР Дәүләт Советының 35 нче утырышы кысаларында С.Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залында узды. Утырышта РФ Дәүләт Думасы депутатлары, сенаторлар, ТР Хөкүмәте әгъзалары, муниципаль берәмлекләр, министрлыклар, ведомстволар, предприятиеләр, хуҗалык җитәкчеләре, иҗтимагый берләшмәләр, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре, әдәбият, сәнгать әһелләре һ.б. чакырылган иде. Президент юлламасын Татарстанның халык шагыйре Мөдәррис Әгъләмовның шигырь юлларыннан башлап җибәрде.

*Бер канатың була туган телең,*
*Бер канатың була туган җир;*
*Кошка гына түгел, кешегә дә*
*Канат кирәк була торгандыр.*

*Син, чыннан да, илем, әкияттәге*
*Чабып барган атка охшаган.*
*Шушы ике канат бар чагында*
*Киләчәккә, илем, ышанам.*

«Туган тел, туган җир, рухи, әхлакый кыйммәтләребез, бай тарихи мирасыбыз, милләтара һәм конфессияара тынычлык, татулык – бу кыйммәтләр һәрвакыт безнең төп горурлыгыбыз, сакчыл мөнәсәбәт предметы булачак», – дип ассызыклады Рөстәм Миңнеханов. Ул «2023 ел – милли мәдәниятләр һәм традицияләр елы» дип игълан итте. Р.Миңнеханов икътисадта зур бурычлар кую белән бергә рухи кыйммәтләрне саклау, яшь буынга патриотик тәрбия бирү мәсьәләләренә басым ясады. Быел Президентның чыгышы шунысы белән аерылып торды: Р.Миңнеханов эштә зур уңышларга ирешкән фидакарьләрнең исемнәрен әледән-әле атап торды, аларны, үрнәк итеп, халыкка күрсәтте. Бүгенге катлаулы вазгыятьтә бергә, бердәм булырга кирәклеген искәртте.

### КИТАПХАНӘГӘ – 4000 КИТАП

Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев шәхси китапханәсеннән 4000 китапны Милли китапханәгә тапшырды.

### МЕДИАФОРУМ

Сочи шәһәрендә «Вся Россия – 2022» XXVI заманча журналистика форумы (анда бөтен Россиядән һәм чит илләрдән 1000гә якын кеше җыелды) булып узды. Форумда Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Айдар Сәлимгәрәев, Татарстан Журналистлар берлеге рәисе Илшат Әминов, «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте генераль директоры Шамил Садыйков, республика газета-журналларының баш мөхәррирләре, журналистлар катнашты. Ш.Садыйков «ТАТМЕДИА» АҖнең яңа медиалар чорына нинди проектлар белән килүе турында сөйләде, мастер-класс уздырды. Форум кысаларында Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллинның Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан «Гомер калейдоскобы» китабын (татар һәм рус телләрендә) тәкъдим итү булды. Анда басмага югары бәя бирелде. Язучы-журналист (Фәйзуллинны шулай дип тәкъдим иттеләр) үзе дә чыгыш ясады.

### «МОСТАЙ»

Казандагы М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры бер кичкә кинотеатрга әверелде. Монда 2019 елда Башкортстанның халык шагыйре Мостай Кәримнең тууына 100 ел тулу уңаеннан төшерелгән «Мостай» документаль фильмы күрсәтелде. Театрның Колонналы залында М.Кәрим фонды Кәримовлар гаиләсенең шәхси архивындагы фотолардан торган күргәзмә тәкъдим итте. Фильмны зал тулы халык белән бергә ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов, ТР Президенты Аппараты Җитәкчесе Әсгать Сәфәров, Казан мэры Илсур Метшин, министрлыклар, ведомстволар җитәкчеләре дә карадылар. Тамашачылар арасында Мостай Кәримнең оныгы «Русская медиакомпания» ябык акционерлык җәмгыятенең директорлар советы әгъзасы Тимербулат Кәримов һәм аның хатыны Инга Сечина да бар иде.

### ЮБИЛЕЙЛАР

Татарстанның халык шагыйре, җәмәгать эшлеклесе Разил Вәлиевнең 75 яшьлек юбилеен туган ягында – Түбән Кама районында да зурлап билгеләп үттеләр. Халык иҗаты

йортында «Еллар аша сөйләшү» дип аталган әдәби-музыкаль кичә булып узды. Юбилярны район башлыгы Рамил Муллин, якташлары, каләмдәшләре котлады. Кичәгә кадәр Разил Вәлиев, аның белән бергә кайткан кунаклар шагыйрьнең туган авылы – Ташлыкта булдылар. Әдәби-музыкаль кичә монда да үткәрелде. Аннары «Адымнар» полилингваль белем бирү комплексында Разил Вәлиев премиясенә яшь иҗатчылар бәйгесенең йомгаклау тантанасы, шәһәр Үзәк китапханәсендә Р.Муллин катнашында мәдәният мәсьәләләренә багышланган сөйләшү булды. Түбән Камада узган чараларда Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, берлекнең Чаллы бүлеге җитәкчесе Факил Сафин, бәйрәмдарның каләмдәшләре Марсель Галиев, Газинур Морат, Алмаз Хәмзин, Хәбир Ибраһим, Лилия Гыйбадуллина, Фәтхулла Абдуллин, Марс Хафизов, Фәрит Имамов, Нурзия Мирханова һ.б. катнашты.

***

Татарстан Язучылар берлегенең Г.Тукай клубында Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, җырчы, композитор, нәфис сүз остасы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Алмаз Хәмзинга 75 яшь тулу уңаеннан әдәби-музыкаль кичә булды. Кич буена юбиляр тамашачыларга җырларын, шигырьләрен бүләк итте. Тамаша башланыр алдыннан юбилярны Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла котлады, аңа берлекнең Рәхмәт хатын тапшырды.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

ТР Президенты Указы белән татар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык иҗади эшчәнлеге өчен шагыйрә **Сания Юныс кызы Әхмәтҗанова** Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләнде.

## КИТАП ТӘКЪДИМ ИТҮ

Татарстан Язучылар берлегендә Төркиядә басылып чыккан «Татар хикәяләре антологиясе» тәкъдим ителде. Анда Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, җыентыкка кергән хикәяләрне төрек теленә тәрҗемә иткән Фатиһ Кутлу чыгыш ясады. «Татар хикәяләре антологиясе» китапка әсәрләре кергән язучыларга таратылды.

## ОРЕНБУРГ ҺӘМ БАШКОРТСТАНГА СӘФӘР

«Мәдәни җомга» газетасы, «Безнең мирас», «Казан утлары» журналлары баш мөхәррирләре Вахит Имамов, Ләбиб Лерон һәм Рөстәм Галиуллин Оренбург өлкәсендә һәм Башкортстан Республикасында булып, милләттәшләребез белән очрашулар уздырды. Оренбург өлкәсенең Татар Каргалысы, Мостафа авылларында, Оренбург шәһәренең Х.Ямашев исемендәге китапханәсендә, Башкортстанның Ярмәкәй районы Исламбахты авылында әдәбият сөючеләр, авыл халкы белән күреште, татар шәхесләре белән бәйле истәлекле урыннарда булды.

## «КАЗАН УТЛАРЫ» ТУРЫНДА

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең утырышлар залында «Казан утлары» журналы турында сөйләшү булды. Анда язучы, җәмәгать эшлеклесе Ринат Мөхәммәдиев чыгыш ясады. Сөйләшүне «ТАТМЕДИА» АҖнең генераль директоры Шамил Садыйков алып барды.

2022 елның 19 октябрендә 86 нчы яшендә Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, әдәбият галиме, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе **Нурмөхәммәт Шаһвәли улы Хисамов** вафат булды.

Мәрхүмнең җәсәде Казанның Самосырово бистәсе янындагы мөселман зиратында җирләнде.

2022 елның 19 октябрендә 93 нче яшендә Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе **Резеда Тәфкәлүн кызы Вәлиева** вафат булды.

Мәрхүмәнең җәсәде Яңа Бистәдәге татар зиратында җирләнде.

*Сәхифәне* **Вакыйф НУРИЕВ** *әзерләде.*

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*«Проза и поэзия»: роман Р.САГДИ «Альмира», повесть М.КАБИРОВА «Только ты»; поэма Л.ГИБАДУЛЛИНОЙ; стихи Л.ЯНСУАР, Р.БАШАРА.*
*Литературный конкурс «Майдан – для батыров»: рассказ А.ХАНА «Потап».*
*«Новые имена»: стихи О.ИЛЬЮП.*
*«Литература родственных народов»: стихи М.КУРУДИМОВОЙ в переводе с гагаузского языка Ф. ГИЛЯЗОВА.*
*«Искусство»: беседа А.ХАБИБУЛЛИНОЙ с Г.АРСЛАНОВЫМ.*
*«Литературная критика»: статьи Г.МУРАТА, Т.ГАЛИУЛЛИНА, Л.АБУДАРОВОЙ.*
*«История»: статья Л.ХАМИДУЛЛИНА.*
*Фотоархив к 90-летию Л.Хамидуллина.*
*«Бесценные голоса»: статьи к 100-летию З.ХИСМАТУЛЛИНОЙ и к 70-летию Х.ГАЙНУТДИНОВА. Рубрику ведет Н.АКМАЛ.*
*«Бриллианты эпохи»: статьи Д.ЗАГИДУЛЛИНОЙ, Г.РАХИМА.*
*«1100 лет со дня принятия Ислама в Поволжье»: статья И. ЗАГИДУЛЛИНА.*
*Дневник общественно-культурной жизни.*
*На наших обложках: памятник певцу, народному артисту ТАССР Рашиду Вагапову. Автор памятника – народный художник РФ Андрей Ковальчук. Фото И. Абрамовой. Поэтесса Оксана Ильюп.*

## IN THIS ISSUE:

*«Prose and poetry»: novel by R.SAGDI «Almira», story by M.KABIROV «Only you»; poem by L.GIBADULLINA; poems by L.YANSUAR, R.BASHAR.*
*Literary competition «Maidan is for batyrs»: story by A.KHAN «Potap».*
*«New Names»: poems by O.ILYUP.*
*«Literature of kindred peoples»: poems by M.KURUDIMOVA in translation from the Gagauz language by F.GILYAZOVA.*
*«Art»: discussion of A.KHABIBUllINA with G.Arslanov.*
*«Literary criticism»: articles by G.MURAT, T.GALIULLIN, L.ABUDAROVA.*
*«History»: article by L.KHAMIDULLIN.*
*Photo archive for the 90th anniversary of L.Khamidullin.*
*«Priceless voices»: article on the 70th anniversary of H.GAINUTDINOV, article on the 100th anniversary of Z.KHISMATULLINA. The rubric is led by N.AKMAL.*
*«Diamonds of the Epoch»: articles by D.ZAGIDULLINA, G.RAKHIM.*
*«1100 years since the adoption of Islam in the Volga region»: article by I.ZAGIDULLIN.*
*Diary of social and cultural life.*
*On our covers: Monument to the singer, People's Artist of the TASSR Rashid Vagapov. The author of the monument is Andrey Kovalchuk, People's Artist of the Russian Federation. Photo by I.Abramova.*
*Poetess Oksana Ilyup.*

---

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* җырчы, ТАССРның халык артисты Рәшит Ваһапов һәйкәле. Һәйкәлнең авторы – РФнең халык рәссамы Андрей Ковальчук. *И.Абрамова фотосы.*

*Тышлыкның дүртенче битендә: шагыйрә Оксана Ильюп.*